ISSN 0206–4189
Индекс 73210

12+

# Казан утлары

8.2014



# БУ САНДА:



## Искәндәр ГЫЙЛӘҖЕВ:
## «Алар онытылмас. Оныттырмасак...»

«Без һаман бары тик Җәлилнең үзен генә күтәрергә тырыштык. Ләкин ул бит берүзе генә түгел, аның белән үлем җәзасына көрәштәшләре дә хөкем ителгән. Безне бу нык уйландырырга тиеш. Сугыш вакытында андый очраклар булган микән? Нацистларга каршы көрәш оештырган бер төркем тулаем үлемгә хөкем ителгән! Әгәр дә нацистлар каршында башкаларның «гаебе» кимрәк булган булса? Димәк, алар да тарихта шундый тирән эз калдырган! Бу бер мисал гына да тарихны төрле яктан, тирәнрәк, сәяси заказларга гына таянмыйча аңларга һәм аңлатырга өйрәтә. Минемчә, ул шәхесләрнең язмышын тулы рәвештә ачыклау аларның туганнары яки аерым тарихчылар эше генә түгел, бу – дәүләт эше дә».

173

## Төлен ӘБДИКОЛЫ
## «Акылның канлы яу кыры»



«Бүген тагын хат алдым. Коридордагы өстәл тартмасын ачып карамаска ант иткән идем югыйсә, кулымны тыгып караудан тыелып кала алмадым. Ихтимал, мин үз-үзенә һәлакәт эзләп йөрүчеләрдәндер. Иртәдән бирле ниндидер кыргый бер көч, үҗәтләнеп, мине гел шул якка тартты. Кулымда — хат.
Дөресен әйткәндә, бу хатлардан куркам мин. Азагы — үлем белән тәкәнәсе бәйгегә чакыру хәбәре кебек алар. Бернинди бәйге дә кирәкми миңа. Күзгә күренмәгән караңгы көч белән даими алышка чыгу, аңа [illegible] авыр бирелә, әгәр бу хат булмаса, мин әле [illegible] булса да [illegible] идем. Ләкин күзгә күренмәгән дошманым тагын мәкерле һөҗүмен башлады. Менә ул — икенче хат...»

23

Казан утлары

www.kazanutlary.ru

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

Бу санда

ГАМЬЛЕ ӘҢГӘМӘ

Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары, мәгариф һәм фән министры Энгель ФӘТТАХОВ белән Илфак ИБРАҺИМОВ әңгәмәсе. ....9

ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Равил ФӘЙЗУЛЛИН. Яңа шигырьләр. ....3
Әмиржан МОТАЛЛАПОВ. Гамь. *Роман*. ....63
Зиннур ХӨСНИЯР. Гарасат. *Роман*. ....90

100 НЧЕ БИТ: ЧОР, МИЛЛӘТ, ВАЗГЫЯТЬ

Марсель ГАЛИЕВ. Казанга мәдхия. *Шигырь*. ....100

КАРДӘШ ХАЛЫКЛАР ӘДӘБИЯТЛАРЫННАН

Манас, Нүргун Батыр, Урал Батыр. Дастаннар. *(Мөдәррис Вәлиевнең кереш сүзе белән)*. ....16
Төлен ӘБДИКОЛЫ. Акылның канлы яу кыры. *Бәян*. ....23
Али ЖУШКУН, Сабир РӨСТӘМХАНЛЫ, Әхмәт СОЗАЕВ, Тамара ГАНИЕВА, Диләвәр ОСМАНОВ, Нурлан ОРАЗАЛИН, Жолдас СӘЕТНАЗАРОВ, Шеймит АЛИШЕВА, Турар КОЖОМБЕРДИЕВ, Мурат КАЛМЫКАЕВ *шигырьләре*. ....60, 87

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА. Аяз Гыйләҗев һәм Чыңгыз Айтматов. ....155

СӘНГАТЬ

Гүзәл СӘГЫЙТОВА. «Кәтәм сине». ....161

ЮБИЛЕЙЛАР

Рәйсә МУСАБӘКОВА. Иҗатында чор авазы *(Сәгыйть Сүнчәләйнең тууына 125 ел)*. ....166
Мансур ВӘЛИ-БАРҖЫЛЫ. Намус һәм гаделлек. *(Фәрваз Миңнуллинның тууына 80 ел) Хатирә*. ....169

ТАРИХ

Тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев белән әңгәмә. ....173

«ИДЕЛ» ЖУРНАЛЫНА 25 ЯШЬ

Рәфикъ ЮНЫС. Хәр булып туган журнал. ....176

Шаян сәхифә. Уены-чыны бергә. *Сәхифәне Марсель ГАЛИЕВ әзерләде*. ....184

АК ЖИЛКӘН

Илүзә КАШАПОВА. Фатихалы гомер. *Хикәя*. ....187

«Казан утлары» архивыннан. ....153, 164
Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. ....190

Гамәлгә куючы —
«Татмедиа»
ачык акционерлык
җәмгыяте

*БАШ МӨХӘРРИР —*

**Илфак Мирза улы**
**ИБРАҺИМОВ**

*ИДАРӘ:*

**Рабит Батулла**
**Нурия Беломоина**
**Мөдәррис Вәлиев**
**Разил Вәлиев**
**Рәдиф Гаташ**
**Дания Заһидуллина**
**Дамир Исхаков**
**Рафис Корбан**
**Хатыйп Миңнегулов**
**Айрат Сибагатуллин**
**Энгель Фәттахов**
**Равил Фәйзуллин**
**Рамил Ханнанов**
*(җаваплы сәркатип)*
**Рәфикъ Юныс**
*(баш мөхәррир урынбасары)*

---

*Мөхәррирләр:* **Айгөл Әхмәтгалиева, Гөлзадә Бәйрәмова, Әлфәт Закирҗанов, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Ләйсән Солтанова.**

*Гамәли хезмәткәрләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Наил Кадыйров, Флёра Сабирова.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Гөлнара Галиева** (баш бухгалтер).

---

✉✉: Редакция һәм нәшер адресы: *420066, Казан, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Баш мөхәррир — 222-05-50.*
*Җаваплы сәркатип, компьютер үзәге — 222-09-83 (өст.1612).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге — 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге — 222-09-80 (өст.5).*
: **Факс** — (843) *222-09-83 (өст.1612).*

: **E-mail:** kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән житешсезлекләр өчен редакция жавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 30.07.2014, график буенча 30.07.2014.
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70X108 $^1/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-2005. Тираж 3900.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләрне күзәтү буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы идарәсендә 2011 елның 23 мартында теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-44362.
Индекс: 73210 (физик затлар өчен), 16262 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

«ТАТМЕДИА» ААҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Казан, Декабристлар урамы, 2

© «Казан утлары», 2014 ел



Равил
Фәйзуллин

# ЯҢА ШИГЫРЬЛӘР

## Казан сөлгесе

Казан!
Нигә синең исемең кирәк
төрле чиркәү-соборларга?
Тәре-сурәт — иконаларга?
Ялган әкияти-мифларга?
Чукындыру үзәкләренә?..
(Менәрләгән алар!)
Бүтән атамалар юк мени?

Ничә гасыр
казыналар казанында!
Шәрекъ-гареп төенеме син?
Шатлык-кайгы өемеме син?
Империянең яман шешеме?
Рим, Константинопольләр ишеме?

Каныктылар исемеңә!
«Казанский богоматер,
Казанский икона!..
Төртенепләр дә алалар,
берне түгел, икене!..»

Казан!
Ничә тапкыр яндың — көл булдың!..
Ничә тапкыр тордың — гөл булдың!

...Заманында
дары мичкәләре тәгәрәгән җир астында
хәзер метро вагоннары!
Тирә-якта —
дөньякүләм спорт-алыш урыннары!..

---

Равил ФӘЙЗУЛЛИН (1943) – *Татарстанның халык шагыйре, Татарстан Республикасының Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты; алты томлык «Сайланма әсәрләр» һәм төрле телләрдә басылган күпсанлы китаплар авторы. Казанда яши.*

...Яшәп ятам әле Үзендә.
Яшьнәп эшлим әле Үзендә!
«Казан ятиме»ме мин?
Берәр хан нәселе торынымы?

Казан! Казан!
Кемгәдер син котёл-казан.
Безнең өчен — Алтын Казан!

...Үсә Казан!
Кыза Казан!
Кыза Заман!
Кыза һаман,
булмаса да
Ахырзаман.

Таксалар да Сиңа
меңәрләгән тәре билгесе,
безнең өчен Син
Яшәү өлгесе!

Тормыш дигән
Сабантуйда,
Дөнья күгендә
жилферди бирә
Казан сөлгесе!
Казан сөлгесе!

## Китә казлар...

*Китә казлар Донбасска.*
*Мин үзем дә уйлап торам*
*шул казлардан калмаска.*

***

*Гомерем булып, таш басмаса,*
*ташламам, җанкисәгем!*
«Шахта» җырларыннан

*Телеграмм баганасы*
*Чәчәк атса кайтырбыз.*

I

Донбасска да Донбасстан...

Гасыр буе безнең яклар
Донбасс белән тоташкан.
Күпме яшьләр бәхет эзләп,
киткән-кайткан, хатлашкан.
Күпме гомер — шахта белән,
күмер белән катнашкан!
Күпләр калган... Ярлар тапкан,
йорт корган, никахлашкан...
Яшәешкә жайлашкан.

Тора-бара оныклары
руслашкан, хохоллашкан...
...Иң хәтәре — бүген анда
ил күген тәтен баскан!
Кемнәрдер ут җибәргән бит
әллә өстән, әллә астан...
Гади халыкның башында
хәсрәтләр хәттин ашкан...
Бер корган тормышны ничек
башларга янабаштан?!

II

*Китә казлар Иделгә!..*

«Әллә мин дә китим микән,
әллә мин дә кайтыйм микән
бабайларым иленә?

Аермалар, һай, бик зур шул
Кайту белән Китүнең!
Тамыр булу — мәгънә икән
Җирдә гомер итүнең!

Бардыр, бәлки, исәннәрдер
ерак авылдашларым?
Калгандыр бит зиратларда
нәселебез ташлары?

Төрле тарафларга Язмыш
куа адәм башларын!
Китәрсең дә, кайтырсың да,
язган булса ашларың...»

III

*Киткән казлар бер кайта ул,
адашмаса юлларда...*

...Безләрдә дә төрлечә шул
кешеләр язмышлары!
Хәзер сирәк ишетелә
яшь бала тавышлары...
...Беткән авыллар өстендә
тик рәшә балкышлары.
Инеш буйларында калган
тирәк ябалдашлары...

***

Сомали дигән илләрдә
җикмиләрдер пар атлар?..
Аның каравы бар диләр,
корабларны талый торган
ушкуйниклар-пиратлар!

...Ә безләрдә юктыр димсез,
«Мал!» — дип янган ир-атлар?

Ник булмасын? — кайберләре
дөньякүләм караклар!

Пират нәрсә? Ул — башкисәр.
Диңгездәге субасар...
Субасарлар әле бер хәл,
чын юлбасар — илбасар!

Белми дисезме халык?
Исемнәре — олигарх!
(Нишләсен гади халык? —
тагарагы шул ярык...)

Алдап-йолдап, талап-урлап
туплагач илнең малын,
Кемнәрдә булсын соң инде
Дөньяның штурвалы?!

Диңгезләрне инләп йөзә
шәхси яхта-кораблар...
шундый затлы фрегатлар!

Нәрсә карый пиратлар?
Беткәнме әллә Шәкүр яки
Робингудтай ир-атлар?

———

Сомали дигән жирләрдә
бәлки, юктыр пар атлар?..
...Аларның үз хәле хәл...
Безнең хакны кем хаклар?
«Колмак бата, таш йөзә!..»
Шундый хәлләр, братлар!

***

Без яшәгән кыска гына бер гомердә
алмагачлар ничә кабат үсеп корды...
Күпме дуслар, ярлар җан тәслим кылды...
Ничә патша алышынды!..

Үзгәрешсез —
имгәтелгән Иман белән
нәжесләнгән Жир-Ана калды...

***

Елгалар ярыннан чыга,
патшалар алышына.
Ил өстенә хәсрәт килсә,
бар да халык башына.

Игенчегә нигә мылтык?
Сабыйларга наз булсын!..
Сугышсыз да бу дөньяның
ятимнәре азмы соң?

Күпме сәясәтче бии! —
бомба өстендә стриптиз!..
Болай барса дөньялар,
Ахырзаманга — бик тиз!

Кояштан күләгә эзләп,
күпме тиле азына!
Кызганыч, Тарих дигәнең
кылыч белән языла.

## Онытылыр өчен...

*Мәхбүс авызыннан*

Тагын иртә. Менә таң атты...
Үткәндәге гөнаһ-газапларны
бу Яктылык тагын яңартты!..

Ә көн озын!
Бик тә, бик тә озын!..
Онытылыр өчен кирәк миңа
Караңгылык — үлем йокысы...

## Күчмә утраулар

Очрадылар гомеремдә
ул күчмә утраулар!
Кайберләре күнелемнән
әле дә китми торалар...

Ул чагында алар мина
утрак жир булган инде!
Кин биләмә хужасыдай,
уй-гамәл зурдан иде!
Һәрберсендә ыру-нәсел дип,
йорт-кура корган идем.

Казан асулы учакта
төтен дә тәмле иде!
Наз тулы ятак янында
чәчәк бәйләме иде!

Куларбалар әмәлләдем,
сабыйлар тирбәтергә.
Китап сүзләре чыгардым,
гыйлемгә өйрәтергә.

...Жилдән микән, илдән микән,
миннәнме — нидән икән? —
тора-тора утрауларым
ярдан аерылып китә.

Пристаньдагы матрос кебек,
ыргак баулар беркетәм,
кушмакчы булып, ә үзем
китсен бу! — диеп этәм!..

Аерылып китә утрау!
Шәп күренеш! Трагикомик,
илаһи бер тамаша!
Офыклар — төсле музыка,
көлү катыш яшь аша.

Бар ул андый утраулар
Аккошта, Кабанда[1] да...
Әйтмибез генә, бар алар
һәрберебезнен жанда.

## Баскыч төбендә утырам...

*М.гә*

Күземдә яшь. Сина дәшәм.
Ишетмисен. Син ерак...
Күнелемә иш шикелле
көне — янгырлы, елак...

Таянырга Кеше кирәк,
жилгә каршы торганда.
...Алтын багана булганбыз
икәү бер жан булганда!

***

Кемнәр ниләр сөйләмәсләр!
Үз хәлемне үзем беләм!
Төшләремә нигә-нигә
керәсен син минем белән?

Хыялдагы күкләремдә,
күп йолдызлар күренде лә...
...Әле беркем ишетмәгән
бер жыр йөри күнелемдә.

[1] Аккош һәм Ерак Кабан күлләрендәге күчмә утраулар күздә тотыла. Хәзер алар яр буйларына беркетеләләр инде.

## Мәңгелек орыш

Диннәр канга-кан киләләр
Кеше иманы өчен.
Жир өстендә сугышалар
Жир асты малы өчен.

## Ирешү

Зур нәрсә ул,
бәлки, бәхет тәдер! —

Кешеләрнең
Сине
        аңлавы да,
                    ярдәме дә
кирәк булмавы.

## Кайчан? Кайда? Ничек?

Сабый туган. Яшәү Иленә
исән-имин кичелгән чик!
Бишек — тәхет. Сораулар юк:
Кайчан? Кайда? Ничек?

Ир-ат булган. Жегәр ташый!
Һәр тарафка ачык ишек!
Дөнья тулган сорау белән:
Кайчан? Кайда? Ничек?

Картлык килгән. Дәрман беткән.
Уйларда гел пошаман шик...
Саубуллашу көне килә.
Кайда? Кайчан? Ничек?

***

*Җандашларга*

Шигыремнән хисләр эзләмәгез.
Сез үзегез мина сер инде...
Булдыралган кадәр заманында
кемнәргәдер нидер сеңдердем...

Шигырь тарихларын актарганда,
Безнең исемнәр дә яңара...
...Көзем килде. Мин — ялангач агач.
Яфракларым — сезнең алларда...

# КИЛӘЧӘК ӨЧЕН — БҮГЕННӘН!

***Татарстан Республикасы Премьер-министр урынбасары, мәгариф һәм фән министры Энгель Нәвап улы Фәттахов белән «Казан утлары» журналының баш мөхәррире Илфак Ибраһимов әңгәмәсе.***



**– Август ае – Мәгариф һәм фән министрлыгының эш календарендә иң җаваплы чор. Балалар бакчаларыннан алып, барлык укыту-тәрбия учреждениеләрендә яңа уку елына әзерләнәләр. Бу эшләрдә мәгариф хезмәткәрләре белән бергә барлык авылларның үзидарә җитәкчеләреннән башлап министрлык, хөкүмәт җитәкчелеге, Президент үзе турыдан-туры катнаша. Республика күләмендәге август киңәшмәсе – әлеге гамәлләрнең иң югары ноктасы... Ул быел Саба районында узачак. Яңа уку елының планнары белән танышканчы, узган уку елының йомгакларын беләсебез килә.**

– Чыннан да, август ае – мәгариф хезмәткәрләренең иң җаваплы чоры. Нәкъ шушы вакытта узган уку елына йомгак ясала, яңа уку елына перспективалы эш юнәлешләре билгеләнә. Быел август киңәшмәсе Саба муниципаль районы җирлегендә уздырыла, бу әлеге районның мәгариф юнәлешендә алдынгы позицияләрдә торуы белән бәйле.

2013-2014 уку елы мәгариф системасы өчен шактый уңышлы ел булды. Балаларны мәктәпкәчә белем оешмаларында урын белән тәэмин итү мәсьәләсе акрынлап хәл ителә башлады. 2013-2015 елларда гамәлгә ашырыла торган дәүләт программасы кысаларында, 2013 елда балалар бакчаларында 5245 өстәмә урын, бюджеттан тыш финанслар хисабына 1612 өстәмә урын булдырылды.

Урта гомуми белем оешмаларының материаль-техник базасын ныгыту юнәлешендә шактый эш башкарылды. Соңгы өч ел эчендә мәктәпләрне капиталь төзекләндерү өчен 7,5 млрд. сум акча бүленеп бирелде.

Республикада 487 база мәктәбен үз эченә алган гомуми урта белем оешмалары челтәре булдырылды. Түбән Кама шәһәрендә Идел буе федераль округының Советлар Союзы Герое Гани Сафиуллин исемендәге Татарстан кадетлар корпусы, Казан авиация институты каршында химия юнәлешендә тирән белем бирү лицее ачылды.

Бүгенге көндә сәләтле балалар өчен интернат тибындагы 16 гомуми белем бирү оешмасы уңышлы эшләп килә. Моннан тыш Казан шәһәрендә интернат тибындагы татар гимназиясе, А.Н.Туполев исемендәге Казан дәүләт техник университеты каршында инженерия лицее ачу күздә тотыла.

Сәләтле балалар белән нәтиҗәле эш алып барыла: икенче ел рәттән Татарстан укучылары командасы Россия дәрәҗәсендә өченче урынны яулады. Быел укучыларның

бөтенроссия предмет олимпиадаларында 23 укучы җиңүче булып танылды, 50 укучы призлы урынга лаек булды. Иң яхшы нәтиҗәләр экология (14 җиңүче һәм призёр), химия (12 җиңүче һәм призёр) һәм хокук фәннәреннән (7 җиңүче һәм призёр). Аеруча куандырганы: Казанның 122 нче гимназиясе укучылары Никита Чернега һәм Алексей Волостнов Халыкара математик олимпиадада җиңү яуладылар!

Шулай ук бердәм дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре дә Россия буенча уртача күрсәткечләрдән югары.

Урта һөнәри белем бирү һәм югары уку йортлары системасында да сизелерлек унай үзгәрешләр бара. Әлеге уку йортларының материаль-техник базасы ныгытыла, белгечләр әзерләү системасы камилләштерелә. Быел Татарстан Республикасының Россия Федерациясендә WorldSkills хәрәкәте үсеше юнәлешендә лидер буларак танылуы – шуны раслый торган факт.

Бу әле ирешкән уңышларның кайберләре генә. 2013-2014 уку елына йомгаклау нәтиҗә август конференциясе кысаларында ясалачак, яңа уку елына өстенлекле эш юнәлешләре билгеләнәчәк.

**– Яңа уку елына әзерлек барган бу көннәрдә дистәләрчә мең бала төрле лагерьларда ял итә... Меңнәрчә чыгарылыш укучыларыбыз яңа уку йортларына «имтихан» тота... Болар барысы да Мәгариф һәм фән министрлыгының күз уңында бит инде...**

– Укучыларның җәйге ялын оештыру – Министрлыкның мөһим эш юнәлешләренең берсе.

2014 елда 5550 укучыга җәйге лагерьларда ял итү һәм сәламәтлекләрен ныгыту өчен шартлар тудырылды. Мәгариф һәм фән министрлыгы карамагындагы 9 лагерьда – балалар йортларында тәрбияләнүче балалар, коррекция интернат мәктәбе укучылары өчен махсус сменалар, Кара диңгез буенда – сәләтле балалар өчен төрле юнәлештәге профильле 6 смена, республикабыз лагерьларында яшь математиклар һәм физиклар, яшь информатиклар, яшь геологлар өчен махсус сменалар оештырылды.

Моннан тыш быел беренче мәртәбә республикабыздан читтә яшәүче татар балалары өчен Болгар дәүләт тарих-архитектура музей-тыюлыгы территориясендә туган телебезне өйрәнү лагере эшләде. Анда Татарстаннан һәм Россия Федерациясенең 10 субъектыннан 614 укучы ял итте. Биектау районындагы «Костёр» лагеренда – «Дуслык» сменасы, Актаныш муниципаль районы җирлегендә «Бүләк» сменасы оештырылды. Әлеге лагерьларда барлыгы Россиянең 24 регионыннан 1400гә якын укучы катнашты. Моннан тыш Актаныш районы җирлегендә «Агыйдел» интеллектуаль форумы уздырылды, биредә Россиянең 5 төбәгеннән сәләтле 100 укучы чакырылды.

Шулай ук муниципаль берәмлекләрдә 1047 мәктәп яны лагеренда – 64520 укучы, 144 хезмәт һәм ял лагеренда – 3479 укучы, коррекция мәктәпләре каршындагы 32 лагерьда 3029 укучы ял итте.

**– Соңгы елларда мәгарифкә бәйле иң күп кулланыла торган сүз – БДИ (ЕГЭ). Аның мәгариф системасына кертелә башлавына дистә ел үтсә дә, һаман хуплаучылар да, ризасызлык белдерүчеләр дә бар. Сез быелгы БДИ нәтиҗәләреннән канәгатьме?.. Киләчәктә альтернатив имтихан формасын кертү турында да хәбәрләр йөри... Әйтик, алдагы уку елыннан мәктәпләрдә рус теленнән сочинениеләр язу кире кайта. Әлеге яңалык татар әдәбиятына да карыймы?**

– 2014 елда XI сыйныфны 19585 укучы тәмамлады, шуларның 19214е – имтиханны бердәм дәүләт имтиханы формасында, 371е дәүләт чыгарылыш имтиханы формасында тапшырды.

Агымдагы елда бердәм дәүләт имтиханы оештыруга таләпләр шактый үзгәртелде: беренче мәртәбә имтихан материаллары Республика дәүләт имтихан комиссиясе әгъзаларына махсус элемтә аша имтихан буласы көнне 00.00 сәгатьтән иртәнге 7.00 сәгатькә кадәр бирелде. Һәр имтихан буласы урын металл эзли торган рамкалар һәм күзәтү камералары белән җиһазландырылды. Шулай ук һәр имтихан тапшыру пунктында полиция һәм медицина хезмәткәрләре сакта торды.

Бердәм дәүләт имтиханы 13 предмет буенча уздырылды. Башка еллардагы кебек,

укучылар тарафыннан сайланган имтиханнарда җәмгыять белеме (10 мең укучы), физика (6 мең укучы), биология (3 мең укучы) фәннәре өстенлек алды.

Россиянең башка субъектлары белән чагыштырганда, рус әдәбиятыннан кала башка фәннәрдән нәтиҗәләр югары. Аеруча географиядән уртача баллның югары булуы куандыра. Минималь күрсәткечне уза алмаган укучылар саны да, башка өлкәләр белән чагыштырганда, шулай ук азрак.

Чыннан да, бүгенге көндә рус теленнән бердәм дәүләт имтиханына таләпләр үзгәреш кичерәчәк, аерым алганда, сочинение язу практикасына кире әйләнеп кайтачакбыз. Бу исә татар теленнән бердәм республика имтиханына да аналогик үзгәреш кертүне таләп итә.

**— Күптән түгел Президент В.В.Путин Илдә югары дәрәҗәдәге инженер белгечләрне әзерләү буенча киңәшмә үткәрде. Казан, Татарстан — дәүләтнең тимерчелеге генә түгел, ә фәнни үзәге дә. Баксаң, һәр һөнәргә башлангыч юнәлешне мәктәпләр бирә... Һөнәри ориентация мәсьәләсендә тулаем элекке алымнарга кайту кирәкмиме икән?.. Урта һөнәри белем бирү мәктәпләренең киләчәген ничек күрәсез?**

— Бүгенге көндә Татарстанда эшче кадрларга ихтыяҗ 70% ка — башлангыч һөнәри белем оешмалары һәм урта һөнәри белем оешмалары әзерләгән белгечләр хисабына канәгатьләндерелә. Әлеге уку йортларының гомуми саны — 98, аларның 94е — урта һөнәри белем оешмасы, 4се — башлангыч һөнәри белем оешмасы. Аларда 67 меңнән артык студент белем ала.

Соңгы елларда урта һөнәри белем бирү системасында шактый үзгәрешләр булды. Әлеге уку йортлары челтәре реструктуризация кичерде, ягъни башлангыч һөнәри белем оешмалары һәм урта һөнәри белем оешмалары саны аларны кушу хисабына киметелде. Бу юнәлештәге дәүләт сәясәте күп дәрәҗәле урта һөнәри белем бирү оешмаларын булдыруга юнәлтелгән. Нәтиҗәдә белем бирү оешмаларының материаль-техник базасы сизелерлек ныгытылды, заман таләпләренә туры килгән белгечлекләр барлыкка килде, махсус укыту җайланмалары, бердәм корылган интернет челтәре булдырылды. Моннан тыш, белгечләр әзерләү эше белән беррәттән, төрле яшьтәге кешеләрнең белемен күтәрү яки өстәмә белгечлекләр бирү өчен шартлар тудырылды.

Һичшиксез, урта һөнәри белем бирү системасы Татарстан Республикасының бүгенге социаль-икътисади торышы һәм үсеш перспективаларына туры килерлек дәрәҗәдә квалификацияле белгечләр әзерли алырга тиеш. Бу җәһәттән Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миннеханов күрсәтмәсе нигезендә, 2014 елда республикабызда, икътисади юнәлеш өчен кадрлар әзерләү максатыннан, ресурс үзәкләр челтәре булдыру эше башланып китте. 5 өстенлекле проект билгеләнде, әлеге ресурс үзәкләренә капиталь ремонт ясау өчен, барлыгы 676 706,31 мең сум акча каралган.

Моннан тыш 2010-2014 елларга «Киләчәк» мәгарифне үстерү Стратегиясе кысаларында ресурс үзәкләргә белем бирү процессын камилләштерү өчен, 204,4 млн. сумлык заманча җиһазлар сатып алу планлаштырыла.

2013 елда Татарстан, «Россия Федерациясе субъектларында һөнәри белем бирү системасын модернизацияләү программаларын эшләү һәм гамәлгә ашыру» юнәлеше буенча конкурста катнашып, федераль субсидиягә лаек булды. Шул рәвешле, 2014-2015 елларда урта һөнәри белем бирү оешмаларының материаль-техник базасын ныгыту өчен, федераль бюджеттан 30 млн. сум акча бүленеп биреләчәк.

Шулай ук профильле ресурс үзәкләрне булдыруда «КамАЗ» ачык акционерлык җәмгыяте, «СЗМН» ачык акционерлык җәмгыяте, «АЛНАС» ачык акционерлык җәмгыяте, «Агросила-Групп» ябык акционерлык җәмгыяте, «Нижнекамскшина» ачык акционерлык җәмгыяте һ.б. финанс ярдәме күрсәтергә әзерлеген белдерде.

Бүгенге көндә уку йортларының материаль-техник базасын ныгыту максатыннан, бизнес-проектлар конкурсы игълан ителде. Бирелә төп шарт — бюджеттан соралган сумманың 50% ы бюджеттан тыш керем хисабына финансланырга тиеш. Конкурс нәтиҗәләре буенча, 2,5 млн. сум күләмендә 4 грант тапшырылачак.

Һәммәбезгә мәгълүм: хәзерге вакытта икътисад, хокук фәннәре буенча белем алырга теләгән укучылар саны башка юнәлештәгеләргә караганда күбрәк. Билгеле булганча, соңгы елларда дәүләтебез тарафыннан һөнәри хезмәткә өндәү алып барыла.

Быел, урта һөнәри белем бирү мәктәпләренең киләчәген кайгыртып, гаять зур чара уздырылды, ул – WorldSkills Russia – 2014. 16-20 майда узган чарада 35 һөнәр буенча 432 укучы һәм яшь эшчеләр катнашты. Безнең республикабыз бу чарада лаеклы беренче урынны яулады. Шулай ук ел саен «Образование. Карьера» исемле махсус күргәзмә үткәрелә, бу исә – башлангыч, урта һәм югары уку йортларының мөмкинлекләрен күрсәтү өчен уникаль мәйдан. Мондый төр чаралар яшь буынны урта һөнәри белем бирү мәктәпләренә этәрер дип ышанабыз.

**– Безне барыбер дә милли мәгарифнең киләчәге ныграк кызыксындыра... Шунысы борчый: укыту-тәрбия эшләрендә дөньякүләм кабул ителгән казанышларны киңрәк кулланган бер чорда, авылларыбызда мәктәпләр ябыла... Авылда мәктәп ябылу – 10-15 кешене берләштерүче авыл интеллигенциясе юкка чыгу дигән сүз. Бу бик тә зур югалту. Әлбәттә, объектив сәбәп – балалар саны житешмидер. Алдагы ун елда уңай үзгәрешләр көтеләме, милләтнең демографик фаразлары нинди?**

– Милли мәгариф системасын камилләштерү – министрлыкның өстенлекле эш юнәлешләренең берсе.

2013-2014 уку елы дәвамында моңа кадәр җәмәгатьчелекнең игътибар үзәгендә булган һәм еш кына тәнкыйть утына тотылган шактый проблемалы мәсьәләләр уңай чишелеш тапты:

– Татарстанда һәм республикадан читтә татар телен өйрәнергә теләк белдерүчеләр өчен «АНА ТЕЛЕ» дистанцион тел өйрәнү проекты гамәлгә кертелде. Хәзерге вакытта безнең алда әлеге ресурсны мөмкин кадәр нәтиҗәле итеп куллану бурычы тора;

– милли мәгариф белән идарә итү һәм педагогларга әлеге юнәлештә методик ярдәм күрсәтү системасы сизелерлек ныгытылды: министрлыкта милли мәгариф идарәсе төзелде, Мәгарифне үстерү институтында милли мәгариф кафедрасы һәм лабораториясе булдырылды, барлык муниципаль берәмлекләрнең мәгариф өлкәсендәге идарә органнары штатына милли мәгариф һәм регионара хезмәттәшлек буенча методист ставкасы кертелде;

– татар теле һәм әдәбиятыннан башлангыч сыйныфлар өчен, федераль дәүләт белем стандартларына нигезләнеп, яңа дәреслекләр эшләнде;

– 2014 елда IX сыйныф укучыларының барысы өчен дә татар теленнән бәйсез бердәм республика тесты үткәрелде;

– Арча педагогика көллияте базасында милли мәгариф үзәге төзелде, әлеге уку йорты базасында булачак педагогларны мәктәп яшеннән әзерли башлау эше җайга салынды.

Моннан тыш татар телен республикабызда һәм Татарстаннан читтә яшәүче милләттәшләребез арасында популярлаштыру юнәлешендә дә шактый эшләр башкарыла:

– татар теле һәм әдәбиятыннан II Халыкара олимпиада үткәрелде. Әлеге олимпиаданың дистанцион этабында биш меңгә якын студент һәм укучы катнашса, 2014 елның апрель аенда узган төп этапта 12 чит илдән һәм Россия Федерациясенең 19 субъектыннан килгән катнашучылар татар теле, әдәбияты, мәдәнияте буенча белемнәрен сынап карады;

– сәләтле яшьләрне барлау һәм үстерү максатыннан, «Илһам» дип исемләнгән республикакүләм яшь иҗатчылар конкурсы үткәрелә башлады;

– Биектау районында урнашкан «Костёр» лагере базасында, Актаныш муниципаль районы җирлегендә, Болгар музей-тыюлыгы территориясендә татар телен өйрәтү сменалары оештырылды. Әлеге сменаларда Россия Федерациясенең 24 субъектыннан 1400 гә якын укучы ял итте.

Эшләнгән эшләр шактый, әмма милли мәгариф системасында әле хәл итәсе житди проблемалар да күп. Хәзер шуларга аерым тукталып китәргә телим.

Агымдагы уку елында татар телендә белем бирү оешмаларының эшчәнлеге өйрәнелде. Республикадагы 39 татар гимназиясенең эшчәнлеге аерым контрольгә алынды. Аларның исеме җисеменә туры килергә тиеш! Шунлыктан аларда туган телдә белем һәм тәрбия бирү эшен җайга салу мөһим.

Шулай ук рус телле укучыларга татар телен өйрәтү юнәлешендә дә эшлисе эшләр күп. Ин беренче чиратта, укучы һәм әти-әниләрнең тел өйрәнүгә булган ихтыяжын

канәгатьләндерерлек заманча сыйфатлы дәреслекләр кирәк. Алдан әйтеп узганымча, әлеге юнәлештә инде эш алып барыла.

Мәктәпләрдә туган телдә белем бирүнең сыйфатын яхшыртуга инновацион эшчәнлекне кинрәк җәелдерү, укытучыларның квалификацион дәрәҗәсен үстерү нәтиҗәсендә генә ирешергә мөмкин. Шунлыктан дәреслек авторлары белән берлектә заманча технологияләрнең үзенчәлекләрен тирәнтен өйрәнүгә юнәлдерелгән методик эш яңа уку елында да дәвам итәчәк.

Чыннан да, бүгенге көндә авыл җирлекләрендә мәктәпләрнең саны кимү тенденциясе күзәтелә. Бу исә, беренче чиратта, авылларда балалар саны кимүгә бәйле фактор. Шунлыктан, белем бирү сыйфатын арттыру максатыннан, укучыларны заманча җиһазландырылган, яхшы белгечләр белән тәэмин ителгән база мәктәпләренә йөртеп укыту эше җайга салынды.

Бүген республикабызда 853 татар мәктәбе, 96 чуваш мәктәбе, 34 удмурт мәктәбе, 18 мари мәктәбе, 4 мордва мәктәбе бар, 1 мәктәптә – башкорт теле, 1 мәктәптә иврит өйрәнелә. Моннан тыш 30 якшәмбе мәктәбендә 28 тел өйрәнелә.

Шунысы куандыра: соңгы елларда республикабызда балалар саны арту тенденциясе күзәтелә. Бу исә, үз чиратында, мәктәпләрнең санын тотрыклы саклап калырга мөмкинлек тудырачак.

**– Үзгәртеп кору еллары башында Ил буенча югары белем бирү учреждениеләре, бигрәк тә аларның филиаллары күп үрчеде... Татарстанның район, шәһәрләрендә дә алар байтак иде. Шуларга карапмы, фәнни хезмәткәрләр саны да күбәйде: фән кандидатлары, докторлары... Ул югары уку йортлары һәм филиалларда сыйфат күрсәткечләренең бик түбән булуы турында инде үзәк матбугатта күп чагылды... Бу мәсьәләгә министрлык нинди фикердә тора?**

– Чыннан да, соңгы елларда кайбер югары уку йортларында, аеруча, аларның филиалларында белем бирү сыйфаты сизелерлек түбәнәя башлаган иде. Базар икътисады таләпләренә җавап бирүче белгечләрне югары дәрәҗәдә әзерләүнең федераль дәрәҗәдә үк тикшерелүе әлеге мәсьәләнең үтә дә җитди булуын күрсәтә. Мисалга, 2013 елда үткәрелгән мониторинг нәтиҗәсендә Россия буенча 373 югары уку йорты һәм филиалларның эффектив булмаганлыгы ачыкланды һәм шуның нәтиҗәсендә 45 югары уку йортының яки аларның филиалларының эшчәнлеген оптимальләштерү хакында карар кабул ителде.

Бәхәссез, ил буенча югары уку йортларының, бигрәк тә аларның филиаллары күп булу сыйфатлы кадрлар әзерләүгә шактый тискәре йогынты ясый. Шунлыктан Татарстан Республикасының Мәгариф һәм фән министрлыгы хәзерге вакытта югары уку йортларының санын киметү яклы. Чөнки югары уку йортларының санын киметү, беренче чиратта, белем бирүнең сыйфат күрсәткечен яхшыртуның төп шарты булып тора.

Бүгенге көндә барлык югары уку йортларының эшчәнлекләре төп күрсәткечләрдән чыгып бәяләнә. Әлеге күрсәткечләр исемлегенә югары уку йортларының белем бирү эшчәнлекләре, фәнни-тикшеренү, халыкара хезмәттәшлек юнәлешендәге эшчәнлек, финанс-икътисади күрсәткечләр, инфраструктура (уку һәм торак мәйданнарының җитәрлек булуы), уку йортын тәмамлаган белгечләрнең эшкә урнашулары һ.б. керә.

Быел Татарстанның ике югары уку йорты «кара тамга» алды, алар – Әлмәт дәүләт муниципаль хезмәт институты һәм Яр Чаллы дәүләт сәүдә-технология институты. Әлеге исемлеккә республикадагы 13 филиал да эләкте. Бу фактларны булдырмас өчен, беренче чиратта, үз вакытында тикшерүләр, мониторинглар үткәрергә һәм аккредитацияләрнең гамәлдә булу-булмау мәсьәләсен тагын бер кат күз алдыннан үткәрү мөһим.

Шуның белән беррәттән, соңгы дүрт ел эчендә республикабыздагы югары уку йортларында белем бирүне камилләштерү максатында башкарылган эшләрне әйтеп узу кирәк.

2010 елда республикабызда 14 фән-мәгариф кластеры оештырылды һәм югары уку йортларының һәр кластер кысаларындагы үзара хезмәттәшлек юнәлешләре билгеләнде. Шул ук елда В.И.Ульянов-Ленин исемендәге Казан дәүләт университеты базасында Казан дәүләт финанс-икътисад институты һәм Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетын үз эченә алган Казан (Идел буе) федераль университеты

оештырылды. Сонрак КФУ составына Алабуга дәүләт педагогика университеты һәм Кама дәүләт инженерлык-икътисад академиясе кертелде.

2013 елда Татарстан Республикасы Президенты Р.Н.Миннеханов тарафыннан 2014 елда икътисад өлкәсенә тиешле кадрлар әзерләүче ресурс үзәкләренең булдырылуы хакындагы документ имзаланды.

Бүгенге көндә Президентыбыз ярдәме нигезендә алдынгы эшмәкәрләр белән ресурс үзәкләр булдыру эшен башлап җибәрдек. Ресурс үзәкләр челтәре эшләп килүче һөнәри белем оешмалары нигезендә корылачак.

**– Республикабызда дәүләт телләрен үстерү буенча кабул ителгән Программада «төп башкаручы, үтәүче булып» Мәгариф һәм фән министрлыгы билгеләнгән... Алдагы елларда Сезнең министрлык тарафыннан гамәлгә ашырылачак иң мөһим юнәлешләргә тукталып үтсәгез иде... Яңа дәреслекләр төзү, милли кадрлар әзерләү һәм урнаштыру һ.б., һ.б.**

**Кырым Республикасы һәм Ак шәһәрнең Россиягә кушылуы Татарстан Республикасының халыкара һәм төбәкара бәйләнешләрен тагын да киңәйтә... Кырым татарлары белән бәйләнешләребез турында әйтеп үтсәгез иде...**

— 2013 елның 25 октябрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 794 нче санлы карары белән «Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы» кабул ителде. Әлеге программаны координацияләү безнең министрлыкка йөкләнде.

2014-2020 елларга дәүләт программасын тормышка ашыру өчен 1 млрд. 84 млн. сум акча каралган, бу исә алдагы программа бюджетыннан 9 тапкырга күбрәк. Шунлыктан программаның төп башкаручылары алдында торган җаваплылык та зур.

Дәүләт программасы республикабызда дәүләт телләрен саклау һәм үстерү, Татарстанда яшәүче халыкларның телләрен саклау, читтөбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм итү, милли кадрлар әзерләү юнәлешендәге һ.б. күп төрле чараларны үз эченә ала.

Киңәшеп эшләү, дәүләт программасы кысаларында башкарылган эшләрне киң җәмәгатьчелеккә үз вакытында җиткереп бару максатыннан, министрлык каршында дәүләт программасын тормышка ашыру мәсьәләләре буенча Иҗтимагый совет төзелде. Әлеге Совет составына иҗтимагый оешма вәкилләре, мәртәбәле тел белгечләре, журналистлар, мәктәп директорлары, практик укытучылар кертелде. Программаны нәтиҗәле итеп тормышка ашыру бары тик бергәләшеп уртак максатка юнәлгән системалы эш алып барганда гына мөмкин дип саныйм.

Сорауның икенче өлешенә килгәндә исә, чыннан да, узган уку елында белем бирү оешмалары өчен Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан дәреслекләр һәм методик ярдәмлекләр әзерләү юнәлешендә гаять күпкырлы эш башкарылды. Дәреслекләр турында сүзне иң элек татар теле һәм әдәби уку дәреслекләрен яңа баскычка күтәргән әһәмиятле үсеш-үзгәрештән башлау урынлы булыр. Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп төзелгән, башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен тәкъдим ителгән 51 дәреслек (барысы 15 укыту-методик комплекты) Россия Федерациясенең Мәгариф һәм фән министрлыгы, Россия Фәннәр академиясе, Россия Мәгариф академиясе эксперт оешмаларында тикшерелеп, шулай ук республика эксперт оешмаларында тикшерү узып, унай бәя алды. Бу дәреслекләр федераль исемлекне формалаштыруның яңа тәртибе буенча Россия Китап берлеге каршындагы иҗтимагый оешма экспертларында һәм шулай ук республика эксперт оешмаларында тикшерүне уңышлы тестә уздылар.

Алдагы уку елында да дәреслекләр әзерләү эше дәвам итәчәк. Бүгенге көндә өч юнәлештә дә 8-9, 10-11 нче сыйныфлар өчен татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре төзү буенча киеренке эш бара. Безнең алда тагын бер мөһим бурыч тора: федераль исемлекне формалаштыруның яңа тәртибе таләпләре буенча дәреслекләрнең электрон варианты да булу шарт. Бу юнәлештә дә бик җитди эш алып барыла. Шулай ук татар теле һәм әдәбияты дәреслекләрен федераль исемлеккә кертү буенча да эш тукталып калырга тиеш түгел. Төп һәм урта гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслекләрне дә комплект итеп тулыландырып, эшне максатчан дәвам итү бурычы тора.

2015-2016 уку елында барлык белем бирү оешмаларының 5 нче сыйныфлары яңа стандартлар нигезендә укый башлаячак. Әйтеп үткәнебезчә, безнең татар теле һәм әдәбияты дәреслекләре инде әзер. Татар телендә төп һәм урта гомуми белем бирү оешмалары өчен федераль исемлеккә кергән дәреслекләрне татар теленә тәрҗемә итү буенча эшебезне киләчәктә дә дәвам итәчәкбез.

Бүгенге көндә министрлык белән Кырым Республикасы арасында тыгыз элемтә урнашып килә. Безнең тарафтан Кырым Республикасының мәктәпкәчә белем бирү оешмаларына һәм урта гомуми белем бирү оешмаларына методик киңәшмә төзүдә ярдәм ителә, БДИ формасында имтиханнарны үткәрүдә әсбапларны хәзерләшү һәм, гомумән, ике республикада эшләп килгән мәгариф оешмаларының үзара тыгыз хезмәттәшлеге алдынгы бурычыбыз булып тора. Шул нисбәттән, безнең республикабыздан, тәҗрибә уртаклашу өчен, мәгариф оешмалары җитәкчеләрен һәм мөгаллимнәрен Кырым Республикасына җибәрү планлаштырыла.

**— Уку-укыту процессын әдәбият-сәнгатьтән башка күз алдына китереп булмый. Сез бу яңа вазифаларыгызга күчкән беренче көннәрдә үк язучылар белән очраштыгыз... Быел яз башыннан милли басмаларның мөхәррирләре белән киңәшмә үткәрдегез. Милли матбугат һәм мәгариф учреждениеләре белән максатчан хезмәттәшлек итүнең күп төрләре бар... Укучыларның әдәби иҗатын оештыруда «Илһам» фестивалендә Сез төп оештыручы буларак та, хәтта жюри рәисе буларак та катнаштыгыз. Бу — әлегәчә күрелмәгән үрнәк... Бу инде өр-яңа «милли компонент үрнәге». Киләчәктә дә мондый уртак эшләребез дәвам итсен иде.**

— Һәммәбезгә мәгълүм: бүген дөнья глобальләшүгә таба бара. Әмма рухи кыйбла җәмгыять өчен һәрвакыт төп ориентир булды, XXI гасырда да ул шулай булып калырга тиеш. Ә бу мәсьәләдә әдәбият, сәнгать аеруча мөһим роль уйный. Аларның төп бурычы, беренче чиратта, туган телне, рухи-әхлакый кыйммәтләрне саклау, белем-мәгърифәт тарату. Милли идеологияне алга этәрүчеләр, беренче чиратта, әдипләр, чөнки алар — иң алдынгы интеллигенция вәкилләре. Мәгълүмати җәмгыять шартларында да язучы сүзенең абруе элеккечә калырга тиеш. Шунлыктан Татарстан Республикасы Язучылар берлегенең Мәгариф һәм фән министрлыгының яшь буынны тәрбияләүдәге төп киңәшчесе булуын телибез. Чөнки укучыларда мәдәниятебезгә, тарихыбызга мөнәсәбәт, кешенең җәмгыятьтәге урыны турындагы фикерләре, иң әүвәл, әдәби әсәрләр тәэсирендә дә формалаша. Шунлыктан безнең министрлык белән Язучылар берлеге арасында тыгыз элемтә урнаштырылды.

Моннан тыш мәгариф системасындагы үзгәрешләрне үз вакытында җәмәгатьчелеккә җиткереп бару мөһимлеген исәпкә алып, министрлык тарафыннан укытучылар өчен төп кулланма булырга тиешле «Мәгариф», «Гаилә һәм мәктәп» журналларының эчтәлеген камилләштерү юнәлешендә шактый эш башкарылды, мәгарифне үстерү тенденцияләрен яктыртып бару өчен, «Белем дөньясы» исемле телевизион тапшыру булдырылды.

Әйтеп узганымча, быел масштаблы итеп «Илһам» исеме астында республикакүләм яшь иҗатчылар конкурсы уздырылды. Ул татар телен, әдәбиятын, мәдәниятен саклау һәм үстерү, укучыларда әдәбиятка, сәнгатькә кызыксыну уяту, әдәби иҗатка сәләтле булган яшьләрне ачыклау, осталыкларын үстерергә ярдәм итү максатыннан, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Язучылар берлеге, Казан (Идел буе) федераль университеты белән берлектә үткәрелде. Конкурска барлыгы 772 эш кабул ителде, 715 егет һәм кыз үз көчләрен сынап карады. Бәйгедә Чаллы, Азнакай, Актаныш районнары һәм Казан шәһәре укучылары аеруча актив катнашты. Без иҗат дөньясына тәүге ныклы адымнарын атлаган яшьләргә киләчәктә зур өметләр баглыйбыз, татар матбугатының һәм әдәбиятының йөзек кашлары — кыю каләмле журналистлар, язучылар һәм шагыйрьләр булып китәрләр дип өметләнәбез.

Һичшиксез, әлеге юнәлештәге эшчәнлегебез киләчәктә дә дәвам итәчәк.

**— Тулы җавапларыгыз өчен рәхмәт. Милләттәшләребезгә бик күп яңалыклар җиткердегез. Киләчәктә дә журналыбыз белән тыгыз элемтәдә булырсыз дип ышанып калабыз.**

# БЕЗ БЕР ТАМЫРДАН

Халыкның тарихи хәтере, омтылыш-идеаллары, фәлсәфәсе һәм сурәтле фикерләү галәме гасырлар дәвамында, гасырлар басымы астында алмазга әверелгән ташкүмердәй, авыз иҗатында – фольклорда калыплашкан һәм безнең көннәргәчә саклануга ирешкән. Бу «саф вә раушан көзге»дә төрки халыкларның да уртак тамырлары, катлаулы язмышы, зур сынаулар аша узган дәүләтчелек юлы чагыла. Үзебезнең «Идегәй» дастаны – шуны раслаучы шаһ әсәрләрнең берсе.

Без якут-сахаларның бик борынгы эпик әсәре «Нүргун Батыр» олонхосыннан өзекне – рус теле аша, атаклы башкорт кобайыры «Урал Батыр»дан һәм кыргыз кардәшләребезнең горурлыгы булган «Манас» дастаныннан үрнәкләрне оригинал теленнән турыдан-туры тәрҗемә-күчермәдә тәкъдим итәбез.

Болар арасыннан «Манас» дөньядагы иң зур күләмле эпос булып санала (мәсәлән, аның бер варианты 11 өлештән, барлыгы 500553 шигъри юлдан тора). Дастандагы вакыйгалар агышы, коры тасвирлап барудан бигрәк, каһарманнарның эш-хәрәкәтләрендә, сөйләмендә – үзенчәлекле «халык театры-тамашасы» рәвешендә ачыла. Шуңа күрә анда гомумтөрки йолалар белән бергә, искиткеч телбизәкләр – үткен сүзләр, канатлы гыйбарәләр, мәкаль һәм әйтемнәр – энҗе бөртекләре кебек җем-җем итеп ята.

Якут (саха) халык сәнгате осталары – олонхосутлар 36 мең юлдан торган «Нүргун Боотур» әсәрен музыка коралы кулланмыйча җидешәр тәүлек дәвамында җырлаганнар. Олонхода вакыйгалар бөтен галәм киңлегендә – Югары *(Үөһээ дойду)*, Урта *(Орто дойду)* һәм Түбән *(Аллараа дойду)* дөньяларда бара. Бәянның төп темасы – кешелекнең башлангычы дип уйланылган *Айыы аймага* кабиләсенең көнитеше, Урта дөньяда (ягъни җир йөзендә) гадел, бәхетле һәм бай тормыш төзүгә омтылышы. Бер якта – *Абасы* кабиләләренең кара көчләре булса, икенче якта – айыы аймага халкын алардан яклаучы баһадир ир-егет Нүргун. Бу ике башлангычның көрәше катлаулы һәм мавыктыргыч вакыйгалар тезмәсен хасил итә.

«Урал батыр» һәм «Манас» дастаннарының да нигезендә үз каһарманнары аша халыкның дәһшәтле көчләр белән көрәше, якты хыял-идеалларын чагылдыру ята. Тумыштан ук гадәттән тыш сыйфатларга (акыл, көч, шулай ук тышкы матурлыкка) ия бу батырлар да кардәшләрен берләштерү, аларга хезмәт итү максаты белән мәйданга чыга. Әсәрләрнең тарихи җирлеге борынгыдан ук килгән миф-риваятьләргә, ышануларга, бай рухи-мәдәни җирлегебезгә барып тоташа.

Бу әсәрләрнең тугандаш әдәбиятларыбыз үсешенә әлегәчә гаять көчле тәэсиренең дә сере шунда.

**Мөдәррис ВӘЛИЕВ,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*Татарстан Фәннәр академиясе*
*Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать*
*институтының текстология бүлеге мөдире*

## Манас

...Казакъ, кыргыз, катаган —
Барыбыз бер атадан.
Атабыздан калган сүз:
Үзбәкләр дә безгә үз.
Картайганда бер бүләк —
Бай Жакып бала күрептер,
Ат куяр вакыт житептер.
Кыпчаклардан Байжигит,
Кыргызлардан Элеман,
Анжыяннын Куртка карт,
Аргыннан Каракожо бар,
Нойгутлардан Акбалта,
Нугайлардан Эштек бар.
Түрк улыннан Абдулла,
Үзбәкләрдән Дамулла —
Үзләре үк утырды...
«Ат куегыз!» — дип әйтеп,
Аксакал Жакып сүз әйтеп,
Килде халык каршына.
«Ат күкләрдән инәдер,
Яхшы ат куяр микән?» — дип...
...«Аптырап торган чагым», — дип,
Бердике сөйләп салганы.
«Биргән булсаң рөхсәтен,
Мин куярмын атын», — дип...
«Баш ягына «мим» килсен, —
Пәйгамбәрнең сурәте,
Уртасына нун» килсен,—
Әүлияның сурәте,
Ахырына «син» килсә, —
Арысланны күрермен.
Инде ничек чыкты икән
Өч хәрефнен үреме?»
Укып белде «Манас» дип...
Дога кылды барысы —
Яше белән олысы.
«Аты яхшы булды, — дип, —
Әйткәндә күңел тулды» — дип,
Ата-әнисе куанды...
Аптырашып калганы,
«Рас әйткән сүзең, — дип, —
Халыкнын хан кылуына
Лаексың син үзен», — дип,
Күпчелеккә ярады,
Калганнарның барысы
Бер-берсенә карады,
Ходай рәхмәт әйләде.
«Батыр унар юлында,
Ни кылса да бай Жакып,
Дөнья малы кулында.
Яшьрәк дисә баласы,
Теләмәсә Манасы,
Карт булса да Жакыпны
Хан күтәреп алыек,
Каплан Манас баланы —
Гайрәт кылыр дошманга —
Батыр куеп салыек!»
Күңелгә шундый сүз килде,
Күпчелеккә үз килде.
Көкчө морза бәк килде:
«Ханлыкны Жакып алдымы?
Батырлыкның вазифасы
Манасына калдымы?
Кулай булса күбенә,
Агалар, сезнең белән
Шуна кинәш корамын:
Түгәрәк йортка хуп булса,
Түрәлекне сораймын!»
Айдаркан белән Камбарның
Ачуына чыдамай,
Нәселдәше казакъның
Көнчесенә чыдамай,
Жиз солтандай ир Көкчө
Житеп килеп илгә әйтте.
«Көкчө сорады түрәлек,
Күбегезгә хуп булса,
«Түрә бул», дип күрәек».
Күпчелектән сүз кайтты:
«Казакъ, калмык алсын, — дип, —
Кайчан тәхеткә менгәне
Түрә аталып калсын», — дип.
Халыкның барысы ду килеп:
«Казакъ түрә булсын», — дип,
Шул сүз үтте шау итеп.
«Күтәрәек ханны, — дип, —
Хан күтәргән жанны», — дип,
Алты колач ак киез
Астына алып салышып,
Агарган сакал Жакыпны
Акбалта белән Бердике
Житәкләшеп алышып,
Күпчелек аны сөйрәде,
«Күтәрмәгез мине», — дип,
Зирәк Жакып сөйләде:
«Күп байлыгым булса да,
Күңелем тулган хәсрәт-мон,
Күргәнсезләр, халаек,
Күп еладым бала өчен,
Акылны алган хал өчен.
Дөнья тулы байлыгым
Асылы күзгә күренмәй,
Ялварып йөрдем бала өчен.
«Картайганда хан бул», — дип,
Кайгыларга салмагыз,

Таянычым торса каршымда,
Картаеп калган яшемдә
Гөнаһлы итеп калмагыз!
Ханнын эше күп була,
«Баланны узып, син бул», — дип,
Хандай күргән күк була.
Растан мина ышансагыз,
Баламны куегыз, хуп күреп!»
Моны әйтеп бай Жакып
Ынгырашты, елады,
Борчактай яшен тыймады.
Күпме кыен күргән карт
Куанганнан елады.
Казакъ, кыргыз камап алып,
Калмык, мангул ябырылып,
Ак киезнен өстенә
Бай Жакыпны салганы.
Баласы Манас батырны
Ак киезнен өстенә
Аны да шул бергәләп
Утыртып ла алганы.
Күтәреп күп йорт алганы,
Жиде адым басканда:
«Булды, балалар, булды», — дип,
Ил агасы Жакып карт
Жиргә төшеп калганы.

Ялгыз Манас баланы
Күтәреп алып күпчелек
Әлеге торган жыенны
Жиде әйләнеп барганы.
Нәсел-нәсәп халаек,
«Життек морадыбызга», — дип,
Бердәм шаулап калганы.
Хан хөкемен тигезеп,
«Хан тажы шул инде», — дип,
Ир Манасның башына
Солтанлы бүрекне кигезде.
Шунда Жакып уй кылды,
Туксан бия суйдырып,
Тугыз көнлек туй кылды.
Нәсел-нәсәп кыргызны
Хезмәтенә торгызды.
Нугайдан калган кызыл ту (байрак) —
Жакыпта калган менә бу —
Биекләргә ашканда,
Туйны Жакып башлады.
Күп яшәгән бай Жакып
Картлык тунын ташлады.
Тугыз көндә туй таралып,
Өй-өенә киткәне.
Теләгәннәр барысы
Теләгенә иреште...

## Нүргун Батыр

...Малай белән кыз икесе генә торып кала,
бала — бала шул инде,
әлләни игътибар итми мона;
икәүдән-икәү генә калсалар да,
ун-егерме кешегә торырлык булып
уйный-көлешәләр.
Шулай көн артыннан — көн, ел артыннан ел уза.
Үсмер егет, һәркөн иртән торгач,
терлек-туарларын карый
һәм сунарга йөри.
Бай кара урманда сайлап алып кына
мөгезле жанварларны аяктан ега,
симез боланнарны ризыкка дип алып кайта,
ярсыган аюларны баш астына куеп ята.
Зур-зур ата боланнарны — мөгезеннән,
эре түшле пошиларны танавыннан тарта,
аюларны колак янындагы йонынннан тотып сөйри,
менә шулай тик шукланып йөри бу егет.
Кызыкай исә үз алдына яшәп ята,
күренми кояшка,
болытлы көндә дә күз салмый тышка,
йөзен якты күккә күрсәтми ул.
Каршылагач танны, егет йөгереп кайта,
сикерүдә сыный төрле алымнарны —
*ыстанга, кылыйа һәм куобахты*ларны.

Егетебез үсә, бик тиз үсә;
инде анын буе биек агачларнын
аскы ботагына житә
яки тәбәнәгрәк карагачларнын
ябалдашын узып китә.
Киң жилкәсе — колачы алты сажин,
сыгылып килгән биле — әйләнәсе биш сажин,
бүртеп торган ботлары — һәркайсы өч сажин;
көчле мускуллары —
алар зур, калын карагачнын
төп кәүсәсеннән үсеп чыккан гүя;
озын борыны — житез атнын алгы аягынын
балтыр сөягедәй;
киерелгән ике кашы
хәтерләтә буйга сузылып яткан ике соры асны;
түгәрәк күзләре —
әйтерсең лә ат йөгәненен үрелгән божралары;
алга чыгып торган текә маңгай,
сөзәк чигәләре,
күзгә ташланырлык янак сөякләре,
зур, калын иреннәр;
гәүдәсенен өске ягы киерелгән,
бик нык анын аскы сөякләре;
шактый төксе төс-килбәте, йөзе,
шактый кырыс холыклы ул үзе;
уйнаклаган кайнар канлы;
кабара торган кан куерыгы белән
тартышып алучан тамырлары;
тыгыз тәнле, баһадир бәдәнле,
эләктереп йомарлый ала торган зур учлы, —
чыннан да ул ифрат көчле,
житез аяклы булып житеште.
Егетләрнен асылына,
якутларнын ин-иненә әйләнде ул.
Менә шундыйрак кеше булды инде.

Кыз уналты яшькә житте, егет — унжидегә,
бу вакыт эчендә булмаган иде берни дә.
Шулчак Нүргун Боотур үзалдына уйлана
һәм шундый-шундый сүзләр әйтә башлады:
«Менә анда — өстә, безнен баш очында
кисәк-кисәкле болытлары белән
асылынып торган
сары күк-офык артында,
анын йомырка сарысы төсендәге
биекләргә ашып югалган көньяк читендә
иле булган,
йокысыннан сискәнеп уяна торган,
үзен-үзе зурга куйган *Улуу* (Олы) *тойон*,
әче авазлы *Хара* (Кара) *Суорун тойон* яши, диләр.
Аларнын утыз тугыз кабиләсендәге халык
кар бөртекләре һәм яңгыр тамчылары күк
исәпсез-хисапсыз күп, дип сөйлиләр.
Тик алар чынлап та шушы көнгә кадәр
минем кебек кешенен шанлы исеме,

данлы эшләре турында
ишетмиләр микәнни?
Ах нишләп, егетләр,
алар минем белән
күкрәккә күкрәк орышып,
көрәшеп-сугышып карарга монда килмиләр!
Мин аларны кулларымда ничек бөтереп алыр идем!
Ә уртадагы жир-анада
утыз өч кабилә яши, дип сөйлиләр.
Нишләп алар,
минем баһадир гәүдәмне изеп алырга,
минем биек исемемне таптарга дип,
ак йөземне пычрак белән капларга дип,
мина килмиләр?
Шулчак минем тәкәбберлегем тыелыр иде.
Шулай түгелмени, егеткәйләр!» —
Менә ниләр уйлаган ул, диләр.
«Түбәндә
егерме жиде аскы кабиләнең башы
*Ардәң Дуолай Буор Маңалай* карт яшәп ята, дип сөйлиләр...
Тик ник алар —
сыңар күзле абааһы (кабиләсе) атаманнары,
бер күзле егетләр, кара әзмәверләр,
тонык кына дыңгырдап ачыла торган
жәһәннәм авызыннан, *Нукэң Үөдэн* иленнән,
шыгырдап ябыла торган зиндан ишегеннән,
ләмендә су коңгызы да батып кала торган
сазламык-баткак күленнән,
өч төшендә суырып ала торган чоңгыл булган,
ялкыннары ургып торган
*Уот* (Ут) дингезеннән башларын алып
һәм минем кебек кешегә ташланып,
чигәгә чигә сугышып,
баш түбәсенә төешеп, тукмашып
һәм бер-береннән тәннәрен изгәләшеп карамыйлар?
Әгәр алар килсә, ничек итеп мин
умыртка сөякләрен үзәмә таба бөгеп сындырып,
муен чокырларына кадар идем, әй!
Язмыш әмере белән *Орто дойдуга* (Урта дөньяга)
минем кебек кеше төшүе турында
аларга чыннан да берни ишетелмәгән микән?
Шулай да, уйлыйм ки,
минем исемем
Урта дөньядагы барлык юл-чатларда
усал яшь үгез кебек
тора каты тавыш белән мөгрәп-үкереп,
минем исемем —
адарынган яшь айгыр ише —
барлык тау үткелләрендә
күкләр күкрәтеп кешни...
Ни гарьлек, әй,
япа-ялгыз мин һәр көнне
әйләнгәләп йөрим йортым тирәләй!» —
ул, шулай дип, ачуланып ята
һәм еш кына уйга бата иде;

төнлә аны йокы алмый,
көндез тамагына ризык бармый,
сенелесе белән сөйләшүдән дә ул туктады,
көлүдән һәм уеннан һич тәм тапмады.
Сенелесе үз алдына уйга калды:
«*Убаем* (абыем) ник мина үпкәләде?
Нишләп анын болай боекты күнеле?
Бәлки ул
мин пешергән ризыктан канәгать түгелдер,
бәлки мин ана тегеп биргән киемне ошатмыйдыр?»
ул шулай бик куркып кала, кыенсына,
йөзенә кызыллык килгән сыман
йөри дәшми-тынмый гына...

## Урал Батыр

Борын-борын борыннан,
Кеше-мазар булмаган,
Килеп аяк басмаган
(Ул тирәдә коры жир
Барлыгын һичкем белмәгән).
Дүрт ягын дингез ураткан
Булган, ди, бер урын.
Анда булган, ди, борын(гы заманда)
Йәнбирде дигән карт белән
Йәнбикә дигән бер карчык,
Кайда барса, аларга
Ул урында юл ачык.
Бу карт белән бу карчык
Кайдан монда килүен,
Ата-ана, жир-суы
Кайда торып калуын
Үзләре дә оныткан, ди.
Икәүдән-икәү шул жирдә
Башлап гомер иткән, ди,
Тора-бара ул икәү
Ике уллы булганнар:
Шүлгән булган олысы,
Урал булган кечесе;
Бүтән кеше күрмәенчә,
Тик яшәгән дүртәве.
Дөнья-мазар жыймаган,
Кашык-аяк тотмаган,
Казан асып, ут ягып,
Алар дөнья көтмәгән.
Авыру-сызлау күрмәгән,
Үлем барын белмәгән,
Барлык нәрсәгә үлем —
Үзебез, дип санаган.
Сунарга ат менмәгән,
Кулга садак тотмаган;
Менәренә — арысланны,
Балыгына — чуртанны,
Кошка чөйгән шонкарны,
Кан суырырга сөлекне
Үзенә иш ясаган.
Бик борыннан булганмы,
Йәнбирде үзе кылганмы,
Бара-тора шул жирдә
Йола булып киткәнме, —
Ерткыч жәнлек тотты исә,
Жәнлек иркәк булды исә,
Ирле-бичәле икәве
Башын чәйнәп ашаган,
Шүлгән белән Уралга,
Эте белән арысланга,
Шонкар белән чуртанга
Бүтән санын ташлаган;
Ерткыч жәнлекне тотса,
Ул жәнлек теше булса,
Ирле-бичә икәве
Йөрәгене сайлаган.
Үлән чемченгән жан тотса,
Кара сөлек кадаган,
Сөлегеннән суырттырып,
Канны сусын ясаган.
Бала үсеп житкәнче,
Үзе жәнлек тоткáнчы,
Баш-йөрәкне ашаудан,
Сусынга кан эчүдән
Оланнарын тыйганнар,
Һич ярамый, дигәннәр.
Ай үсәсен көн үсеп,
Балалары исәеп,
Шүлгәненә уникe,
Уралына ун тулып,
Берсе, арыслан менәм, дип,
Берсе, шонкар чөям, дип
Мазасына тигән(нән) сон,
Ике улына Йәнбирде
Төшендереп биргән, ди.

— Икегез дә — баламсыз,
Күзебезнең карасы,
Теш чыгар чагыгыз үтмәгән,
Буыныгыз катмаган;
Кулга чукмар тотарга,
Кошка шонкар чөяргә,
Әле арыслан менәргә
Мизгелегез житмәгән.
Мин ни бирсәм, ашагыз,
Мин кушканны эшләгез;
Күнегергә сыбайга —
Әнә, болан менегез,
Сыерчыкның тубына
Ягылбайны (лачынны) чөегез;
Сусасагыз уенда,
Әнә, ак су эчегез, —
Кабырчыкка тутырган
Каннан авыз тартыгыз, —
Дип боларга тагы да
Йола өйрәтеп куйган, ди.
Кан эчүдән балаларын
Тагы бер кат тыйган, ди...
Бердәнбер көн бар жирдә
Күк-күмгәк су ургылган,
Күк йөзендә кып-кызыл
Ялкынлы ут бөркелгән.
Күктә кош-корт очалмый,
Жирдә бер җан торалмый,
Аптыраган, алҗыган;
Кошы-корты, җәнлеге
Елан патша жирендә
Бары бергә җыелган,
Уралга килеп ялварган.
Урал каушап калмаган,
Жирне баскан судан да,
Күк каплаган уттан да
Бер дә куркып тормаган, —
Менеп алган Бузатын,
Кулына тоткан булатын,
Диюләргә каршы ул
Канлы сугыш, яу ачкан.
Ай сугышкан, ди, Урал,
Ел сугышкан, ди, Урал,
Утка өтәргә бирмәгән, —
Каек ясап бар кеше,
Суга батып үлмәгән.
Урал аяусыз сугышып,
Диюләрне кырган, ди;
Шул чаклы алар үлгән, ди, —
Киң дингезнең өстендә
Тау барлыкка килгән, ди.
Акбуз суны ерган, ди,
Юлы калкып калган, ди;
Урал ярган юллардан
Халык ияреп барган, ди.
Көн сугышкан, ди, Урал,
Төн сугышкан, ди, Урал.
Каты явы барганда,
Диюләрне кырганда,
Әзрәкәгә (Аждаһага) тап булып,
Икәве каршы торып,
Кылычка-кылыч килеп,
Сугышканнар, ди, болар,
Алышканнар, ди, болар.
Әзрәкә чабып караган,
Ут та бөркеп караган;
Уралны ул чапканда,
Күк күкрәп торган, ди;
Уралга ут бөркегәндә,
Сулар кайнап торган, ди,
Жирләр тетрәп торган, ди.
Урал каушап калмаган,
Һушыннан да таймаган,—
Булатыны алган да,
Әзрәкәне өзә чапкан да,
Тураклаган, ваклаган,
Кылычы дингезгә чумган,
Жир селкенгәндәй булган...

*Дастаннарны басмага*
**Мөдәррис ВӘЛИЕВ** *әзерләде.*

Төлен
Әбдиколы



# АКЫЛНЫҢ КАНЛЫ ЯУ КЫРЫ

БӘЯН

*«Яшәү яки үлем» дигән кисәтүле сорауның*
*Асылы ни:*
*Лаек язмышыңа кундәм буйсынумы,*
*Әллә кутәрелеп каршы чыгумы?*
*Үрә басып, бу орышта җиңәргәме,*
*Әллә гомерлеккә күзне йомаргамы?*
*Шулай итеп,*
*Йөрәкне чорнаган зынҗырларны өзеп,*
*Җан һәм тәнне баскан мең бәладән котылыргамы?*
*Һәркемгә хас максатмы бу –*
*Үлү, сүнү, сүнү?*

*Һәм төш күрү?..*

Уильям Шекспир (Гамлет монологы)

*«Яхшылыкны син яманлыктан йолып алып эшлә,*
*бүтәнчә аны эшләп булмый».*

Роберт Пенн Уортенн

*Бу көндәлекне миңа таныш табибым бирде. Иң гаҗәбе шул: көндәлек иясе дә минем күптәнге танышым булып чыкты. Ходай рәхмәте белән яратылган бу чиксез дөньяда язмыш юллары бер кисешә икән шул.*

*Яшьлек үзе шаулы базар кебек. Дус та күп, юлдаш та күп. Дустыңның дусты сиңа да иптәш була, аннан соң каядыр китеп югала — шулай итеп, яшь кан типкән гомереңдә онытылганнар урынына яңалары пәйда була.*

*Мин ул кеше белән ваемсыз-күңелле көннәр кичергән чорда бераз аралашып алган идем. Күз алдыма килә: чыгынкы яңаклы аксыл чырай, озын буй, арык гәүдә... Килеш-килбәтендә нәзберек зыялылык бар иде аның. Холык-фигыле дә шундыйрак: йомшак кына әйтелгән тәртмә сүздән яисә шаяртудан да кызарып чыга. Шаулы табыннарда ул бер читтә, сүзгә катышмыйча йомылып утыра, аңа бүтәннәрнең мөнәсәбәте дә сак мөгамәләле иде.*

---

Төлен ӘБДИКОЛЫ – *казакъ язучысы, драматург, Казакъстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, 2003 елда Франц Кафка исемендәге Аурупа алтын медале белән бүләкләнгән. «Төрки дөньясының ел кешесе» (2013). Әлеге әсәре («Акылның канлы яу кыры») 2004 елда Казакъстан Республикасының Дәүләт премиясенә лаек була.*

*Шәхес буларак ул мине бөтенләй кызыксындырмады, тәрбияле, белемле икәне сизелеп торган бу басынкы адәм белән очраклы гына сүз алышудан кала, бүтән берни дә истә калмаган. Гүя икебез бер корабта сәяхәткә чыкканбыз да, үзара якынаерга омтылыш ясамыйча, исәнләшкәләп, саран гына сүзләр белән хәл белешеп, вакытны уздырганбыз. Сәяхәт тәмам булгач, безгә кабат очрашырга туры килмәгән.*

*Менә хәзер, берничә дәфтәрдән торган көндәлекне укырга алынгач, моны язган авторны ул үзе дип, һич кенә дә күз алдыма китерә алмыйм.*

*Аның шәхси тормышы хакында язмалары аша берни дә күзаллап булмый, көндәлекләрдә — фәкать уй-фикер сөреше, күңел тирәнлегендәге тойгылар гына бирелә. Тик соңгы дәфтәрдә генә аның язмышыннан кайбер сәхифәләр ачылып китә. Монда инде тормышындагы мөһим вакыйгалар хат алышу рәвешендә, җентекләп бәян ителеп, көндәлеккә күчерелгән.*

*Күрәсең, ул көндәлегенең кемнең дә булса кулына керәсен алдан уйлагандыр шикелле. Бу — бик табигый. Җирдәге адәми зат нигә дип бөек ялгызлыгының шаһиты итеп, кәгазьгә ышана — чөнки ул язмаларын кемнең дә булса табасына, күңел кичерешләренә теләктәш булып, аваз саласына өмет итә.*

*Менә мин хәзер укучыма бу көндәлек-дәфтәрләрнең иң соңгы төп бүлеген тәкъдим итәм. Яшәүнең асыл мәгънәсен аңларга тырышкан, өмет белән икеләнү, чынлык белән ялган арасында бәргәләнгән җаннар өчен бәлкем файдасы тияр.*

*Көндәлек иясенең исем-атын ачып салу итагатьсезлек булыр, килешеп бетмәс, дип уйлыйм. Күп замандашларыбыз арасыннан берсе дип кабул итегез.*

## 1

*13 март*

Минем гомеремдә олы бер үзгәреш булды шикелле. Нинди үзгәреш икәнен үзем дә анык кына белмим. Бәлки ул күптәннән булып та, мин аны тик хәзер генә тоеп, искәреп алганмын. Бик мөмкин. Нервылар какшаган ахрысы, әле генә ни уйлаганымны да онытамын. Көндәлегемне дә бит әнә 3 марттан башлаганмын да аннары рәттән өч көн бушлык, 7 марттан соң гына тагын ялганып китә. Ә теге язылмый калган көннәрдә ни эшләгәнмен — үлсәм дә хәтерләмим. Хәтернең вакыт-вакыт югалып алуы, «упкынга төшүе» хакында ишеткәнем бар иде, ни белән бәйле бу — ул ягын белә алмыйм.

Гомер узган саен онытыла барган затларның саны күбәя генә. Әһәмиятле дип санаган вакыйганың онытылып, юк кына мизгелнең хәтерне бимазалап торуы да мөмкин. Хәтта бергә укыган, үсмер чакта бергә йөргәннәрнең исем-атын искә төшерә алмыйсың, очратсаң, танымый үтеп китәсең. Шулай итеп, гомерең комга сеңгән су кебек ага бирә.

Әмма хәтер тирәнлегеннән үз вакытында берниндиәһәмият бирмәгән шундый мизгелләр калкып чыга ки, аптырап каласың. Әллә соң адәми затның хәтере үз кануннары белән яшиме, дип уйлап та куясың.

Табибтан сорасаң, хәтернең вакыт-вакыт бетеп алуы — арыганлыктан, ди. Табиб бәлки хаклыдыр да... Болгавыр тормыштан аруын да бик мөмкин. Бу якты дөньяда ни генә күрмисең дә, нинди генә сынаулар кичермисең. Кирәкме ул сиңа, кирәк түгелме, куаныч бирәме ул сиңа, чиркануммы, бик гадиме ул, әллә бөтенләй аңлашылмыймы... Уйдан уй бүленеп чыга, юллар чатында торган мосафир хәлендә аптырап каласың. Яшәү мәгънәсе нәрсәдә? Бу дөньяның гаделсезлегеннән кемгә зарланырга? Кемгә рәнҗергә? Аллаһкамы? Адәм затынамы?

Бер карасаң, Ходайныкы дөрес бит: безне адәми зат итеп яралткан, рәхимле

булыгыз, изгелек кылыгыз, дигән. Шуннан артык ни кирәк? Раббының әмерен гамәлгә ашырып яши дә кеше, бар кылганы өчен җавапны үзе генә тота.

Яхшылыкның һәм яманлыкның аклану дәлилләре күп. Һәр якның үз карашы. Кемдер үзен дөньяның күрке итеп саный, шул күрке ихтыярында гомер сөреп, үз теләгән үзе канәгатьләндерү ләззәтеннән башканы белми. Ике як та үз-үзен аклау әмәлен таба; Күк астында һәммә зат үз шалашын корып, аны оҗмахка санап, җайлап урнаша.

Әмма кысан шалашка чак сыеп кергән кешегә ничек тураеп басарга? Гел генә иелеп, рух төшенкелегеннән изелгән хәлдә яшәвемнен сәбәбен дә, аны ничек атарга икәнен дә белмим мин. Кысан, кимсетелгән шалаш түбәнлеге!

Яхшылык һәм Яманлык тудырган акыллы бәхәсчеләр минем ингә баса. Ходай бар иткән дөньяга күземне каплый: кояш нурларының биешүен, табигатьнен искиткеч матурлыгын, язгы үләннәрнен хушлыгын тоймый башлыйм. Баш авыртуы йөрәкнен дулкынлануын баса. Болар нигә сон миңа?

«Уй-фикер йөртүчегә тормыш — төрмә...»

## 2

*15 март*

Өч көннән адәм баласы тәмугка да иләшә, диләр. Бәлки шулайдыр да. Тормыш авырлыкларына ярашу котылгысыз, шунсыз ничек инде бу якты дөньяда җан асрамак кирәк?! Әмма ялганга, гөнаһка, вөҗдансызлыкка, әдәпсезлеккә күнегү — иң хәтәре.

Миңа калса, кешелек сыйфатын җуйган бәндәләрнең коточкыч җинаять кылулары хакында көнаралаш матбугатта басылган язмаларга күнегеп, без ис китмичә генә карыйбыз, игътибар итмибез шикелле.

Тере килеш кемнәрнең жаны киселә?

Янәшәдә генә бу хәлләргә бернинди чирканусыз карап, битараф яшәүчеләр мине куркыта. Галәтләнүдәнме бу?

Газета укудан калдым. Кайсын алма, акка кара белән уелган: үз әнкәсен көчләп, үтергән... Икенче берәү үз кызын көчләп, жанын кыйган... Яшь килеш яңа туган сабыен чүплеккә ташлаган... Миллионер хатын үз улына кияүгә чыккан... Үтереп, адәм итен ашаган маньяклар... Ир-атка өйләнгән ир-ат... Мәет белән якынлык кылучы... Тагын шундый чиркангыч хәбәрләр төрле тарафтан агыла гына. Болар мине укшыта, гүя ислəнгән ит ашаганмын. Бу болгавыр дөньядан котылыр әмәл юк. Әйтерсен лә шакшы тәрәтханә базына төшкәнмен. Җирәнгеч нәҗестән чистарыныр чарам да юк.

Ни хикмәт, янәшәмдә күпме кешеләр берни искәрмичә битараф кына яшәп ята. Гүя, фәлсәфә ташын учына кысып, ниндидер олы белем асылын ачканнар да, шуны көндәлек ризыкка әйләндереп, көн итәләр. Серле акыл казанын ачып, дөньяны баскан хәшәплекне канунлаштырырга ирешергә телиләр сыман. Борынгы әкиятләрдә кешеләрдән корбан таләп иткән аждаһа бар бит әле. Менә шул аждаһага карусыз буйсынучылар, аяусыз ерткычның тамагы канәгатьләнсен дип, аңа иң гүзәл кызны сайлап бирә торалар. Шулай итеп, күпмедер вакыт хәвеф-хәтәрсез яшәп алалар.

Хәзерге чорда да гүя халыклар иненә галәми гыйфрит баскан да, канлы сугышлар, гарасатлы тайфуннар, җир тетрәүләр, монарчы күрелмәгән авырулар, ачлык-ялангачлык таратып, кешелек кавеменнән корбаннарны аяусыз суырып ала тора.

Бальзак: «Җир йөзендә тулысынча тормышка ашырылган кеше бәхетсезлегеннән гайре гамәл юк», дигән.

Әйе, матбугатта, эфирда атом-төш, экологик һәм галәми катаклизмнар, дөньяны су басачагы турында шау куптарулар бара. Бу инде көтелмәгән яңалык әйтеп

шаккатыру, акылны иләсләндерү генә түгел, бу — әлеге афәтләрнең чынга ашачагына шик калдырмаслык фәнни гоманлау. Коточкыч дәһшәт кубасы вакыт, гадәттә, төгәл әйтелми. Борчуга сала торган мондый фаразларның безгә нигә кирәге бар?

Әлбәттә, кайчан да булса кояш сүнәр, җирдә тормыш бетәр; әмма кешелек ирешкән бөек акыл, яшәешне мәгънәле иткән куанычлар, җәфа чигүләр, өмет һәм өметсезлек — Галәм әйләнешенә мәгънә биргән, зиһенле әхлаклылык — болар бар да җиһан упкынына төшеп югалырмы?

Ничек килешергә мөмкин: мең еллар буена тамчылап-тамчылап тупланган шәфкатьлелек, кеше хәленә керә белү, ярату, изгелек һәм үз-үзеңне аямау кебек әхлакый казанышлар бер мизгелдә җиһан карангылыгына чумып юк булсын әле. Боларның барысын да галәмнең салкын бушлыгы йотачакмы?

Ләкин башыңны күпме генә ташка орсаң да, берни дә үзгәртә алмыйсың. Радио-телевидение-газеталар һаман бер нәрсә — дөнья бетәчәге хакында юкка шау кузгаталар...

Кешелеккә әҗәл кайчан, ни сәбәптән киләсен бер Ходай белә. Бөтен дөньяны су басып, Нух көймәсе тарихы яңадан кабатланмасмы? Ә бәлки кабатлану булмас. Афәт көтелмәгәндә убылып төшәр дә... яшәеш күзгә күренмәгән бактерияләрдән яңабаштан башланыр. Югары зиһенгә ирешкән адәми зат туар өчен кабат миллиард еллар кирәк булачак.

Әгәр дә бу дөньябыз бетәргә хөкем ителгән икән һәм бу фаҗигагә күп калмаган икән, шундый итеп китәсе иде бит: гарасатлы галәми ут эчендә яисә тау кебек актарылган су дулкыны өстендә, җаныңда югары зат — кеше дигән исемгә лаеклыгыңны саклаган биеклектә, үз-үзеңне хөрмәт иткән хәлдә... Үз гөнаһларыңнан исләнгән, беркемгә кирәгең калмаган, җебек, буш җан булып Җир йөзеннән галәм чүплегенә ыргытылмаска иде бит...

### 3

*25 март*

Тәннең хасталыгы, авыруы — ризыктан. Җанның хасталыгы — күңелсез уйлардан, диләр. Бәлки шуның нәтиҗәседер, мин менә жиденче көн инде биек бетон дивар белән каймалап алынган хастаханәдә ятам. Бер кешелек кысан гына палата, өстемдә кемнәрдәндер калган иске кием. Тәрәзә каршында дөньяны каплап торган күпкатлы йортлар. Шул йорт почмагы турыннан икенче бина диварына кадәрге арада бер кыерчык күк йөзе күренә. Еракта тау түбәсе шәйләнә.

Кайтмаска дип киткән көннәр-елларны уятып, күңелне кузгатмас өчен, көндәлекне онытып торырга, кулга каләм алмаска дип үз-үземә сүз биргән идем. Әмма бүген түзмәдем, моның үз сәбәбе бар. Берничек тә аңлатып булмый торган сәер халәттә калдым да кабат кулыма каләм алырга мәҗбүр булдым....

Иртән таблеткалар кабып, тумбочка өстендә торган сулы стаканга үрелгәндә, кулым дүрткә бөкләнгән кәгазьгә тиеп китте.

Бу мизгелне мин беркайчан да онытмам... Арзанлы, саргайган кәгазь. Шактый авыр танылa торган язу. Язу рәвеше таныш, гүя мин ул кешене электән беләм шикелле. Кем икәнен анык кына исемә төшерә алмыйм... Шартлагыч матдәгә тотынгандай, кәгазьне сак кына алып укый башладым:

*«Таныш түгел дустым! Көндәлегегезгә рөхсәтсез кагылган өчен гафу үтенәм. Күңелегез чагылышын укыдым да уйга калдым. Сез мине тирән фикерләргә этәреп, эчке бәхәс кузгатырга мәҗбүр иттегез.*

*Сез, гайрәтләнеп, бернигә дә ышанмаучылар телендә «яшәү мәгънәсен эзләү» дип аталган шактый четерекле эшкә тотынгансыз икән. Әйе, мин сезнең кәефегезне төшерергә теләмим, киресенчә, күп сынаулар кичәсе чиксез рух дөньясына сәяхәтегез хәвеф-хәтәрсез булсын дим. Уңышлар сезгә, тәвәккәл дустым!*

*Минем уемча, кеше гомеренең асылы — Яхшылык һәм Яманлыкның мәңге үзара көрәшеннән тора, дигән калыплашкан фикер бәхәссез. Чөнки яшәешнең әүвәленнән үк килгән бу ике мәгънәне бер-берсеннән аерып, ике якка куеп булмый. Урамнан агылган кешеләр арасыннан берәвен тотып алып, анарда күпме «яхшылык» һәм «яманлык» ятканын ачыклап карый аласыңмы? Кеше хакында болай беркатлы фикер йөртү табигый булмас иде. Чөнки ул дошманнары өчен — кабахәт, ә яраткан хатынына — иң кадерле, бәһасез, ә дуслары тарафыннан ул юмарт күңелле, бик күркәм холыклы, дип бәяләнергә мөмкин. Бәс, шулай булгач, ул чынбарлыкта нинди кеше булып чыга? Хәтта мәхәббәт һәм нәфрәт тә кешегә карата, аның яхшылыкка яисә яманлыкка якын тору сыйфатыннан чыгып, сайланмый. Димәк, аләми затның без гел яхшы ягын гына кабул итмибез, начарлыгын да инкарь итмибез. Тормышта күпме мисаллар бар: «әйбәт» кеше «начар» кеше белән, миһербанлы кеше явыз белән дус була, һәм киресенчә — бик тә тәрбияле, итагатьле ике кеше бер-берен коточкыч дәрәҗәдә күралмас булалар. Димәк, яшәү асылы — Яхшылык һәм Яманлык каршылыгы гына түгел, ә яхшылык белән яхшылык, яманлык белән яманлык бәрелеше дә. Шулай итеп, без Яхшылык һәм Яманлыкның шартлы төшенчә икәнен танырга мәҗбүрбез. Ләкин бу мин күтәргән фикернең «баласы» гына.*

*Иң мөһиме, иң хикмәтлесе шунда: инде күпме чәйнәлгән Яхшылык һәм Яманлык, сиам игезәкләре кебек, бер-берсенең тәненә береккән, болар аерым-аерым яши алмыйлар.*

*Белгәнегезчә, кытай философиясендә Ян һәм Инь төшенчәсе бар. Яктылык һәм Карангылык, Күк һәм Җир, өс һәм ас.*

*Ян — кодрәт иясе буларак, үзеннән «юашрак» «Инь белән көч алмашып, үзара тыгыз бәйләнештә тора. Анырак итеп әйтсәк, билгеле бер вакытта Инь бер талпынышта «Ян»га әверелсә, мизгел эчендә «Ян», шартлау чигенә җитеп, «Инь» куәтенә кушыла.*

*Җир йөзендәге тереклек хәяте менә шушы ике кодрәтнең тиңдәш тугрылыгына бәйләнгән. Бу фикергә көнкүрешебездә гомер-гомергә кабатланып торган мисаллар аша карыйк.*

*Белгәнебезчә, Су — тереклек чыганагы. Бакчаларны, кырларны сугару, көтүлекләр өчен кешеләр плотиналар төзеп, сусаклагычлар ясап, суны үз файдаларына тоталар. Әлеге очракта бу — Янның игелекле бәрәкәте.*

*Әмма шул ук су язгы ташулар вакытында, котырып, плотиналарны җимерә, йортларны агызып китә, үз юлындагы бөтен нәрсәне ботарлап, юкка чыгара; шул ук бакча, кырларны, киек-җәнлекләрне, йорт хайваннарын, кешеләрне харап итә. Шулай итеп, игелекле башланган су стихиясе Инь мисалында җимергеч кодрәткә әверелә.*

*Аннары ташу тынычлана башлый, елга үз ярларына кайтып төшә, терек су кабаттан кешеләр өчен яшәү чыганагына әйләнә. Ләкин икенче язны көтеп аласың да... Ян тагын шулай, афәтле көч — Иньга әверелеп, чыгырыннан чыга. Вакытның мәңгелек әйләнешендә елдан-елга шулай. Гел үзгәреп торучы, йә игелек, йә бәла китерүче табигать стихиясе — шул ук су. Нигезендә бер үк нәрсә — су!*

*Моннан нинди нәтиҗә чыгарабыз? Тәүге карашка капма-каршы сыйфатка бүленгән Яхшылык һәм Яманлык бер үк матдәдән яралтылган түгелме? Боларны төрле тустаганга аерып салу мөмкинме? Һәм бу кирәкме? Бу хакта уйланып карагыз әле.*

*Таныш түгел дустым! Без әле сезнең белән күп нәрсә турында сөхбәтләшә алырбыз шикелле. Минем бу язмам — әңгәмәбезнең башы гына. Уртага салып сөйләшер фикерләребез аз булмас шикелле. Каршы килмәсәгез, якыннанрак танышыйк. Бу тынгысыз дөньяда икебез генә белгән нәни сер йомгагы үрелсен.*

*Сердәш булыйк. Хат язсагыз, коридордагы өстәлнең аскы киштәсенә куеп калдырыгыз.*

*Битаныш кордашыгыз».*

Аң-таң калып, хатны башыннан алып азаккача кабат укып чыктым. Нигәдер йөрәгем кысылды. Каян килгән хат бу? Палатада ялгызмын. Кем керүе мөмкин? Ни өчен мин юкта кергән? Минем арттан күзәтәләрме? Нигә минем көндәлегемне рөхсәтсез укыйлар? Ә бу хат ничек соң әле минем палатама эләккән? Шәфкать туташыннан кала кем дә кермәде бит югыйсә. Димәк, мин югында кемдер берәү сугылып чыга. Кемнедер кызыксындырам икән, нигә соң әле яшерен күзәтү? Ачыктан-ачык килергә, танышырга иде. Бу бит яшерен, серле хат...

Хәвефләнеп палата буйлап йөренәм, аяк табаннары берни тоймый. Гүя мин төшемдә, бушлыкта йөзәм. Тынычлан. Сабыр бул. Ныклап уйла, бизмәнгә куй. Шулай да булсын. Азмыни сәер бәндәләр. Син үзеннең психик авырулар яткан хастаханәдә икәненне онытма. Мондый җирдә әкәмәт кешеләр җитеп ашкан...

Үземне шулай юатып, бу хәлгә әллә ни зур әһәмият бирмәскә дигән карарга килдем. Дулкынланмаска кирәк. Сәгать унберда аутотренинг сеансына бардым. Күнегүләрне мона кадәр күзгә чалынмаган ак йөзле кыз алып барды. Күнелгә хуш килә торган. Сөйләгәндә өске ирене ягымлы бөгелеп килә. Үзе җитди, үзе елмая да кебек. Тешләре — энҗе. Күзләре — шундый нурлы, төбәлеп караса, син шул якты нурларда кинәнеп коенасың шикелле.

— Үзегезне иркен тотыгыз... Менә бөтен тән-күзәнәкләрегезгә ләззәтле дулкын тарала... Сез гүя рәхәт йокыга таласыз... Йокыга таласыз... йокыга таласыз... — дип кабатлый җитди дә, елмаюлы да иреннәр. Тын гына музыка саркый башлый, ерактан, гүя күк катларыннан иңә-иңә көчәя, тирбәтеп, моң агышы сине бүтән дөньяларга алып китә, анда инде кеше дигән затның хәвефле хисләренә урын юк. Фәкать шунда — тормыш ыгы-зыгыларыннан арынган биеклектә син чиксезлекне, иректе җан ләззәтен тоясың.

Менә син зәңгәр күл ярында утырасың, баш очында, аллы-гөлле төсләр белән балкып, салават күпере дугаланган. Артта яшь үлән хозурлыгы белән хушланган яшел үзән, чәчәкле җәйләү, җылы үлән исе борынны кытыклый.

Ерактан кемдер сиңа таба килә. Сәлам биргән кебек кулын болгый. Сиңа көтелмәгән бәхет алып килүче зат отыры якыная, менә ул янәшәдә генә, кулыңны сузып кагылырга була...

Кинәт!

— Хәзер инде уяныгыз... — дип эндәшкәнне ачык ишетәм. — Күңелегез күтәренке, тәнегез җиңеләйде, буегызга көч, җаныгызга җегәр инде. Сез хәзер очарга әзер. Уяныгыз!

Теләр-теләмәс кенә күзне ачам, киерелеп куям. Каршымда психотерапевт кыз тора, сабыйга төбәлгән кебек күзләре самими елмая. Гүя ул башымнан сыйпарга әзер.

— Бик яхшы, — дип ул әллә сеанс вакытында йокыга киткән безләрнеме, әллә үткәргән дәресеннән канәгать калып, үзен мактап алдымы — мин аңышмый калдым.

Күңелнең үземә генә билгеле яшерен почмаклары чит-ятларга ачылып киткән кебек, мин башта унайсызлану кичердем. Сагаеп кына як-ягыма күз төшереп алгач, тынычландым. Транстан чыкканда, бөтенесе дә минем кебек киерелеп, авыз ачып иснәп, унайсыз халәттә калган кыяфәткә керделәр бит. Димәк, мин генә түгел. Күнелем урынына төшеп утырды, кәнәфидән тордым да палатама киттем.

**4**

*26 март*

Төнлә болгавыр төш күрдем. Карангы коридордан киләм имеш. Юлымда аркылы-торкылы яткан тимер-томырларга, эреле-ваклы әрҗәләргә бәрелмәс өчен капшанып киләм. Каядыр ашыгам, тиз-тиз атларга тырышам. Көтмәгәндә муенымны кинәт үткен нәрсә сызып үтте. Күз кырые белән искәреп калдым: сабына кадәр стенага батып кергән хәнҗәр имеш. Бернинди авырту да сизмим үзем, баш кына як-якка чайкала башлады. Ике куллап башыма тотындым. Муеным тулысынча диярлек киселеп чыккан да, башым исә тирегә генә эләгеп тора икән. Чиркангыч халәт. Ал табан мин сынар кулым белән баш түбәсендәге чәч умасыннан тотып, икенче кулымны сузып, сукыр кеше сыман капшанып бара башладым. Бик сак атларга кирәк, берәр нәрсәгә абынып егылсам, башым муенымнан ычкынып, карангылыкка тәгәрәп китәчәк. Аннан соң эзләп табып кара. Ә коридорның азагы булмас кебек. Шушы хәлемдә мәңге барырга хөкем ителгәнменме әллә? Бәла бу. Ниһаять, стеналар аерылып китә, зур бүлмәгә килеп керәм. Кунакханә холлына охшаган. Якты, түшәме биек. Бик күп кешеләр җыелган. Якындагы кәнәфигә шыпырт кына килеп утырам да, тәвәккәлләп, башымны өзеп алып ташлыйм. Янымнан үтүчеләр минем тарафка сәерсенеп карап китәләр. Мине кыргый бер тартыну биләп ала, иелеп, ниндидер газета кисәге табып алам да, баш турысын каплыйм. Оятын кая куясың, ничек котылырга моннан? Кая яшерергә башсыз башымны?

Мин каядыр ашыга идем бит. Хәзер инде нишләргә? Башсыз килеш... Чак кына күтәреп, газета читеннән күз салсам, күрәм, күрәм! — баш шул ук урында ята. Тизрәк котыласы иде бит аннан... Үз-үземне бимазалап утырам да утырам, уянганчы шулай...

Күпмедер вакыт күзне ачарга куркып ятам. Йөрәк котырып кага. Бераздан зиһенем ачыла төшә, аптырыйм: муенымнан өзелеп, бер читтә яткан башымны ничек күрдем икән соң мин? Шул мәлдә ниләрдер уйладым да бит әле. Ничек күрдем, нинди баш белән уйладым? Менә әкәмәт. Барысы да шулкадәр ачык, өндәгечә күренде ки, һәр тойгы истә калган.

Аннары мин йокыга китә алмыйча озак яттым. Ярым караңгы палатага урам яктан төшкән сүрән яктылык кушылуы, үзле бер эретмә хасил итеп, кисәтүле саташу төсе булып тоелды. Шушы үле төс аша, нык бикләнгән хастаханәзинданымның күзгә күренмәгән ярыгын табып, өшеткеч чәнчеп, чын үтәли искән җил тәнне өтеп алды...

Саташу, әрсез чебен кебек, ябышкак булып чыкты. Күзне йомарга өлгермисең, муенның өзелгән урынында кызыл ит кисәкләре, тырпайган баш пәйда була.

**5**

*27 март*

Иң яманы — адәм затының үз-үзеннән куркуы. Кара урманда адашкан кебек, эчке дөнья аңлаешсыз, кыргый халәттә кала. Бер адашкач инде чыгар юлны таба алмассың шикелле. Куркуың көчәйгән саен үзең-үзеңә ят тоела башлыйсың.

Ә бервакыт, тычкан кебек, күнел өнеңнән йөгереп чыгасың да тышкы дөньяга кызыксыну аша гаҗәпләнеп күз саласың. Беренче карашка коточкыч тоелган хәятебездә бар бит, бар юаныч алырлык нәрсәләр! Карагыз әнә — кояш! Әнә — кешеләр урманы. Кабаланабыз, каядыр ашыгабыз. Кабатланмас бердәнбер дөньялыкта безнең теләк-дәртебез, өмет-хыялларыбыз сыйган күпавазлы яшәеш

моны безне озата бара. Әкренләп сиңа тормышны табигый тою халәте кайта, максатың барлыгы, һәр вакыйганың акылга буйсынган сәбәбе ачыклана.

Хәзер исә минем кичектергесез бурычым — сәер хат язган шәхесне эзләп табу. Уйдырма серлелеккә корылган бу уенга нокта куярга кирәк. Мондый күз буунын кемгә хаҗәте бар? Дошман тылындагы разведчик кебек, мин хастаханә ишегалдында очраган һәр кешедән шикләнеп, шушы түгелме дип икеләнеп, күз унынннан үткәрәм. Күзенә туры карау белән мин ул бәндәне танып алачакмын, дигән ышаныч та бар үземдә.

Серле кордашымны эзләгән арада мин үзем өчен бер ачыш ясадым. Тормыштагы күп нәрсәгә без өстән-өстән генә карарга күнеккәнбез, кешеләрнең асылын чамалыйбыз гына. Хастаханә ишегалдында йөргәндә мин шуңа игътибар иттем: җүләрләр арасында да әллә нинди типлар бар икән бит! Элек алар барысы да бертөсле тоела иде миңа.

Менә бу сирәк чәчле җирән адәм элек миңа йомыкый бер төмсә булып тоела иде, чынлыкта ул үзенең нәсел-нәсәбе хакында рәхәтләнеп, җәелеп китеп сөйләргә ярата икән. Танышканда үзенең кемлеген, исемен әйтмәс борын, җинемнән тотып алды да әллә нинди батырлыклар кылган бабаларын, туган-тумачаларын санарга кереште. Бакый заманнарда кайсысы хәтта рус патшасының үзенә барып кергән, кайсысы атаклы галим булганлыгы хакында җәелеп сөйли дә сөйли бу. Туктатам димә. Чыгырымнан чыгара язды.

Әнә теге пеләш башлы юанай, һәрчак чигә турында сыек чәч учмасын ялтыр баш түбәсенә таба учы белән сыпырып йөрер, сукмагыбыз кисешсә, куркытырга теләгән кебек, маңгай астыннан сөзеп карар: «Әй, туган, син беләсеңме соң минем кем икәнне? Белмисен? Бу илдә мине белмәгән казакъ юк. Каян килеп чыктың син мондый бәндә, ә?»

Тагын бер әкәмәт кеше бар. Анысының язмышы катлаулырак. Заманында ул үзен Иисус Христос дип, күк катларыннан җиргә тәртип урнаштырырга төштем, дип аңлатып йөргән.

Бу хәлдән куркып, яман кешеләр аны хастаханәгә илтеп тыгалар. Әлеге җинаятьнең башында дөньяга көчле йогынтысын җуюдан курыккан ООН тора.

Шулай да безнең хәсрәтле йортыбыз өстендә күк йөзе, язга авышып, яктыра бара. Салкын һава әле чигенергә теләми. Кайчакта, авыру сулышы кебек, дымлы җил кискен генә исеп куя, салкыны сөякләргә кадәр үтеп керә.

Беркөнне, төшке аш алдыннан, ишегалдында тәпәләшеп алдылар. Бинаһая таза гәүдәле, сакал-мыеклы адәм озын чәчле егеткә кинәт ташланды да бер потлы гер чаклы йодрыклары белән дөмбәсли дә башлады. Көч-хәл белән аердылар үзләрен. Бу кыйнашуның сәбәбен төрлечә аңлаттылар. Шәфкать туташының әйтүенә караганда, болайрак: ишегалдыннан үтеп барганда, баш табиб, туктап, озын чәчле егет белән кул биреп күрешкән, имеш. Моны күреп, сакал ачуыннан шартлый язган. Баш табибның киткәнен генә көткән дә, яман кычкырып, озын чәчле егеткә ташланган: «Нишләп синең белән күреште, ә миңа кул бирмәде?!»

Мондый хәлләрне көнаралаш күреп гарык булганнан соң, уйлап куясың: бетон дивар артындагы дөнья безнең психушкадан ни белән аерылып тора соң әле? Ихтимал, берни белән дә. Ике якта да шул ук — шөһрәт ярату, тәкәбберлек, көнчелек, юл куймау сыйфатлары.

Төштән соң дәвалаучы табибка каралырга кердем. Кечкенә буйлы, күзлекле адәм урындыкка кагылган кадак кебек шундый төз утыра. Башын артка ташлаган, күзлек пыяласы аша кысыбрак төбәлгән күзләрендә сызланган кешенеке шикелле газап чаткылары. Сорауларын төгәл бирә, үз эшен яхшы белүе сизелеп тора. Кан басымын үлчәде, йөрәкне, үпкәне тыңлап карады.

Аннан соң «тормыш хәлләренә» күчтек. Хастаханәгә кадәр ничек яшәвемне белеште. Бертөрлелек аны туйдырган, гүя ул үзен җәлеп итәрлек кызыклы әңгәмәдәш эзли иде. Мондагы яшәү шартларына күчеп, кичә төнлә кайнар су бирүне туктатулары, һава хәлләренең гел үзгәреп торуы кебек көнкүреш ваклыкларына тукталып сөйләштек.

Аннары сүзен медицина темасына борды. «Психопатология» буенча тулы бер нотык укыды. Шәхеснең ике «Мин»гә аерылуы хакында аерым тукталып, мисал китерде. Әйтик, яши шундый ир, гаиләсендә менә дигән, эшендә яраталар үзен. Бу көндезен шулай. Ә кояш баткач, төн уртасы авышкач, ул коточкыч маньякка әверелә. Хатын-кызларны көчләү, җан кыю аңа берни тормый. Менә тагын бер мисал: шундый хөрмәт казанган бер очучы бар иде, ә ул ничә ел буена кечкенә кызчыкларны хәйләләп алып китеп, көчләгән дә буып үтерә барган. Ниһаять, чираттагы җинаятен кылганда эләктергәннәр үзен. Кем уйлаган, затлы эш кешесе, экипаж командиры шундый мәкерле, кабахәт тормыш алып барыр, коточкыч җинаятьләр кылыр дип. Мондый мисалларны күпләп китерергә була. Димәк, шәхеснең икенче «мин»е барлыкка килүе, аның беренчесеннән тормыш итү рәвеше буенча кискен аерымлыгы — акыл галәмендә тирән патологик үзгәрешләр башланганлыгы турында искәртә.

Әмма мин болайрак уйлыйм: нормаль кагыйдәләр бозылып, аерып булмас дәрәҗәдә буталган бер заманда сәламәт акылның бозылуга күчү чиген ачыклау да һич мөмкин түгел. Әйтик, алты бармаклы бала туды, ди. Бу — патология. Ә инде мәхәббәтенә, кан кардәшенә, дустына хыянәт итүне патология дип санамыйлар. Димәк, без мондый мәгънәсезлеккә күнеккәнбез. Югыйсә бит әхлакый кыйммәтләренне сату, ана хыянәт итүдән дә яманрак патология була алмый.

Бүгенге җәмгыятьтә әхлак торышы: чиктән ашып үз-үзеңне ярату, хайвани явызлык, шайтани көнчелек, каты бәгырьлелек, үзен өстен күчкә ия санаганнарның шапырынуы, тәкәббер мактанчыклыгы — болар патология түгелмени?!

Үзенең җитешсезлекләреннән арынырга теләгән берәр кешене бүгенге көндә очрата аласыңмы? Урамда туктатып йөз бәндәне сөйләштереп кара, һәрберсе үзен фәрештәгә тиң итеп күрсәтәчәк. Һәммәсен дә, имеш, кыерсыталар, алдыйлар яисә рәхимсез ээзәрлеклиләр. Ә эзәрлекләүчеләр кем соң, кайда алар?

6

*31 март*

Бүген тагын хат алдым. Коридордагы өстәл тартмасын ачып карамаска ант иткән идем югыйсә, кулымны тыгып караудан тыелып кала алмадым. Ихтимал, мин үз-үзенә һәлакәт эзләп йөрүчеләрдәндер. Иртәдән бирле ниндидер кыргый бер көч, үҗәтләнеп, мине гел шул якка тартты. Башта карышсам да... төш җитәрәк, кинәт, коридор буйлап шул өстәлгә таба омтылдым. Менә хәзер, тозакка эләккән җәнлек сыман, изелеп басып тор инде. Кулымда — хат.

Дөресен әйткәндә, бу хатлардан куркам мин. Азагы — үлем белән тәкәнәсе бәйгегә чакыру хәбәре кебек алар. Бернинди бәйге дә кирәкми миңа. Күзгә күренмәгән караңгы көч белән даими алышка чыгу, аңа бирешмәскә тырышу миңа авыр бирелә, әгәр бу хат булмаса, мин әле азга гына булса да тын аласы идем. Хәл җыю кирәк иде миңа. Каршы тору өчен рухи көч туплар идем. Ләкин күзгә күренмәгән дошманым тагын мәкерле һөҗүмен башкарды. Менә ул — икенче хат...

*«Битаныш замандашым!*

*Сездән җавап алалмаганнан соң икенче рәт хат язамын. Көндәлегегезне рөхсәтсез укыганым өчен кичерү сорыймын.*

*Укыгач, шуны ачыкладым: Сез берьяклы, фәкать изгелеккә генә ышанасыз,*

*ә золым барлыгын танымыйсыз икән. Минемчә, икесенә дә ышану кирәк. Галеллек асылында, минемчә, икесенә дә тигез ышану ята. Дөньябызның шушы ике мәһабәт кит балыгы сыртында торуын күрмисезмени? Тормыш арбасының ике тәртәсе бар икән, һичшиксез, аның берсе — золым. Әмма аның асылы, сез уйлаганча, кешеләргә яманлык кына индерүгә корылмаган. Мисалга үлемне алыйк. Һич икеләнмичә, үлемне соң дәрәҗәдәге афәткә тиңлиләр. Әмма Сез, дустым, уйлап карагыз әле. Әгәр әҗәл килмәсә, безнең тормышыбыз ни хәлгә тарыр иде? Картайган, хаста кешеләр, явызлык кылучылар, җинаятьчеләр, бөтен кешелеккә бәхетсезлек китерү белән янаган кансыз тираннар үлмәсә?.. Җирдә коточкыч тәмуг барлыкка килер иде. Үлем аркасында гына җирдәге тормыш агышы туктаусыз янарып тора түгелме? Икенчедән, әгәр кешеләрдә үтерүгә ихтыяр көче булмаса, ике аяклы канэчкеч затлардан ничек саклана алырлар иде икән? Без менә елан агуыннан куркабыз — әмма безне сихәтләндерү өчен кулланыла торган дару да шул ук агудан ясала ич! Шулай булгач, әйтеп бирегез миңа: елан агуы «яхшы»мы, «яман»мы? Һәммә нәрсәгә, дустым, шушы ике ярлыкның берсен тагу гына ярамый. Бу халәт миңа файдагамы, әллә зыянгамы дип кенә яхшылык һәм яманлык сыйфатын бәяләргә күнеккәнбез. Чиста гына, безнең нәфес-хирыслыктан тыш, боларның икесе дә гамәлдә була алмый, дустым.*

*Хәзер инде ялган һәм алдануга килик. Тәрбияле адәмзатларга ялган — чиркангыч. Ялган әгәр дә телгә килсә, без мондыйрак сүз ишетер идек: «Әй, агай-энеләр! Минем аркада гына сез исән-саулар, минем аркада гына үзегезне ышанычлы хис итәсез түгелме? Әгәр дә сез һәрчак дөресен, фәкать дөресен генә әйтсәгез — күптән инде бер-берегезнең бугазын чәйнәшер идегез. Күпме тапкырлар минем аркада котылып калдыгыз, миңа таянып тагын күпме котылачаксыз әле! Миннән башка сез бер көн дә яши алмаячаксыз!» Менә шулай, минем битанышым. Галиҗәнап Ялган әйтсен шулай дип, сез каршы килә алмаячаксыз. Чөнки Ялган әйтәсе килгән гыйбарә асылында — чын дөреслек.*

*Көндәлегегезгә сез күңел тазалыгы турында күп язасыз. Бер танышым сөйләгән кечкенә генә вакыйгага сезнең өчен махсус тукталасым килә.*

*Зыялы кавемнән чыккан бер ханым иренә «мөгез» куйган. Кирәк бит, мескенем, венерик авыру эләктергән. Бу хәлнең ваклыкларына кереп тормыйк, ир белән хатын арасындагы хыянәт күренешләре безнең заманда гадәти хәлгә әверелеп бара. Шунысы гыйбрәтле: хыянәтчел ханым бу хәлне бик гади генә яшереп калдырса, яшерен генә дәвалану курсы алса, авыруның эзе дә калмас, вакыйга шуның белән онытылыр иде. Бүгенге көндә бу хәтәр авырудан котылу җинел хәл ителә.*

*Ләкин шундый хәлгә таруын ханым бик авыр кичерә, иремне оятка калдырдым, мин ана лаек түгел дип, кайгысына түзә алмыйча, асылынып үлә. Нәтиҗәдә, ир — хатынсыз, бала — анасыз кала. Менә шулай, дустым... Алданган ир дә нык кайгыра. Ни үкенеч! Ирен дөньяда иң намуслы затка тиңләп, аның каршында гаебемне берничек тә юа алмаячакмын дип уйлап, үз-үзенә кул салырга мәҗбүр булган хатынының коточкыч ялгышуын ире бик авыр кичерә! Югыйсә бит ул хатынын чын күңеленнән яраткан, барын да гафу итәргә сәләтле була. Үз артында да гөнаһлары булганлыктан, үзен ул һич кенә дә чисталык өлгесе итеп саный алмый. Моның белән ни әйтергә телимме? Кылган гөнаһларыңны йомып, бәхетенә күләгә төшермичә, намус һәм вөҗдан кебек мәгънәләрнең югары кимәленә омтылмыйча гына яшәргә була иде бит югыйсә. Хәзер инде янадан кайтарып кара челпәрәмә килгән бәхетенне. Каян килә бу ышаныч, алданып, юкка-барга омтылу?! Шушы нәрсә җирдәге тормышны харап итәчәк тә. Табигатьтә булуы мөмкин булмаган илаһи чисталык турында хыялланып, аныбызны агулап, ни-нәрсәгә ирешәбез соң әле?!*

*Менә шундый вакыйга, битаныш дустым. Сезгә ошыймы бу?*

*Бәхеткә ирешү өчен аләмзатка ин элек үзе өчен үзенең кем, нәрсә икәнен ачыклау фарыз. Ничек кенә унайсыз булмасын, ул үзенең әүлия түгеллеген, туганда ук хасиятенә бозыклык орлыклары салынган гадәти кеше икәнен таныргa тиеш. Мона күндәм ирешми торып, беркем дә жан газабыннан мәңге котыла алмый.*

*Шул хакта уйланган мәлемдә бәхет кошы кул сузымы арада гына тора кебек. Аны күрер өчен рухи чисталык, гөнаһсыз сафлыкка омтылу хорафатларыннан азат булу кирәк.*

*Минем фикерләремә колак салырсыз дип ышанам. Бәхет кошы учыгызга килеп кунсын.*

*Сезгә теләктәш булып, хат көтеп калам.*

*Битаныш кордашыгыз.»*

Хатның соңгы юлларын укыганда кулым дерелди башлады. «Сабыр, сабыр», дип, үз-үземне тынычландырырга тырыштым. Әмма ризасыз-ачулы уйлар өермәсе калкып, тынычланырга ирек бирми иде. Жир тетрәгән вакытта куркынган жәнлекләрнең тирә-якка ташлануы кебек, уй-фикерләрем дә тәртипсез тармаклана, зиһенне туплый алмый торам. Әкренләп башымда уйлар зилзиләсе тына башлады. Хатта язылганга аек фикергә килеп, сөземтә ясадым.

Әмма күнелне һаман яшенле болыт кебек шомлы күләгә кысып тора.

Кемдер минем жаныма үтеп керергә ниятлиме? Ни тели ул? Мине мәзәк хәлгә калдырып, мыскылларга телиме? Әллә башка бер-бер сере бармы?

Күпмедер вакыттан соң мин тәмам тынычландым һәм чираттагы хатларга игътибарлырак була башладым. Әмма һәр фикернең төбенә төшәсе килү мине тәшвишкә салды. Чөнки хатта китерелгән мисалларның күбесе дөреслектән ерак түгел иде. Куркыныч ягы да шунда: минем күнелгә икеләнү «маймылы» керде. Ул гүяки хакыйкать асылын хәбәр итәргә алынган, ә кыяфәт-рәвеше шундый күндәм-юаш — менә бит мәкере кайда аның. Ләкин бу хакыйкать түгел, ә хаклык битлеге кигән чеп-чи ялган. Иң хәтәр куркыныч шунда. Үзен дөреслек яклы, үтә гадел итеп күрсәтүчедән дә азау ярган кабахәт кеше юк. Андыйны жинә алмыйсың.

Аның төп юнәлешен дөрес сайламаган икәнлеге миңа ачык. Әгәр төбәлгән жире кояш чыгышында булып, аләмзат кояш баешына карап юлга чыкса, нинди генә тапкырлык, үжәтлек күрсәтмәсен, ул барыбер кирәкле жиренә житә алмас.

Әлбәттә, һәммә кешенең дә хасиятендә яхшылык та, яманлык та ятуын мин беләм. Ләкин бу бит әле Яхшылык һәм Яманлыкның аерылгысыз бөтенлеген исбатлый дигән сүз түгел.

Бу ике башлангычны без аерып карый белергә тиешбез. Искиткеч гүзәл һәм ярсу дөньябызда алар һәрдаим каршылыкта.

Әйтик, аклы-каралы атны без «ала төстәге ат» дип атыйбыз икән, «ала» төшенчәсе аерым, «ак» яисә «кара» мәгънәләрен юкка чыгара аламы? Әлбәттә юк. Гап-гади: бер үк атның гәүдә-буена ике төс таратылган. Яхшылык белән яманлык та шулай, ничек кенә болгатма — нинди генә комбинациядән соң да алар бүленмәс,erбөтен булып кушыла алмыйлар.

Хатта кадап ала торган фикерләр тагын да бар, аларның кызыклыгы ниндидер тирән, асыл мәгънәне ачуда түгел, ә көтелмәгән, сәер фикерләрнең эчке мәкерендә.

Канлы акыл сугышында хакыйкатькә ирешү өчен сәнгатьле күркәмлек кирәкми. Кырыс һәм аяусыз бу сугыш. Монда фәкать ялангач, бизәлешсез хакыйкать тантана итә! Матурлык — хакыйкатьнең дошманы. Чөнки ул акылны читкә юнәлтә.

Матур — әмма ахмак адәм. Матур — әмма жилбәзәк хатын. Матур — әмма ялган сүз... Күпме тапкырлар жиңеп чыкты безне матурлык пәрәнҗәсе бөркәнгән

ялган. Затлы сүз белән үрелгән ялган фикер, җинел акыллы юлбашчы кебек, күпме инсаннарны адаштырып йөри.

P.S.

*Готфрид Бенн: «Гегель, Дарвин, Ницше — мең, миллион инсаннарның һәлакәтенә сәбәпче менә кемнәр. Сүз кодрәте кеше үтерүче җинаятеннән дә хәтәррәк, әйтелгән үенның зарары каһарманнарга һәм гади халык язмышына суга!»*

**7**

*1 апрель*

Күңелдәге шик-шөһбә көн туган саен көчәя генә бара. Чарасызлыктан ни кылырга да белмим.

Минем бу «битаныш кордашым» үтә мәкерле адәм булып чыкты. Кармакка эләктерде дә ычкындырмый гына. Минем хат укып ятканымны да ниндидер ярыктан карап торадыр шикелле. Әллә инде мин кәгазьгә төшерергә өлгермәгән уйларымны да алдан ук белеп тора.

Аны эзләп табам, фаш итәм дигән уйдан кайта да башладым бугай. Үзеңнән күпкә елдам-тапкыр адәмне хәйләләп булмасы көн кебек ачык. Бәлки ул шушы мизгелдә дә янәшәмдә генәдер. Шәфкать туташы, санитарка, хәтта дәвалаучы табиб белән сүз беркетеп куюы да ихтимал. Аның белмәгәне — җир астында.

Мин бу хакта көне-төне уйланам. Үткән төндә аны төшемдә күрдем. Өстендә минеке кебек үк хастаханә халаты, чүәкләре дә охшаш.

Мина аркасын куйган:

— Менә, очраштык, гой, — ди.

— Әйе, очраштык, — дим аны үртәгәндәй.

Чыраен һич күрә алмыйм, стенага карап тора. Бер дә гаҗәпләнмәгән сыман көтәм, борылып карарга тиештер бит инде ул. Түземе төкәнер дә, борылып, мина таба килер. Әмма ул селкенми дә, балбал шикелле катып тора.

— Житте, күпме качыш уйнарга була! — дип, сабырлыгымны җинеп, иңеннән тотып борырга дип кулымны сузсам... Йә Хода! Кулым тораташ. Бар көчемне куеп кыймшатмак булам. Күпме талпынсам да булдыра алмыйм. Кулым гүя үземнеке түгел. Әллә нинди авырлык күкрәгемне кыса, тыным бетә башлады. Ыңгырашып, уянып киттем. Бастырылып ятам икән. Бөтен тәнем манма тир.

Теге төшне кайтарырга, «битанышым»ның йөз чалымын истә калдырырга теләп, күземне йомып ятам. Әмма юкка. Төш бүтән кабатланмады. Ә кабатланса? Иртәгә, ишегалдында берәүнең халат изүеннән умырып тотып: «Ә-һә-ә, мин сине төшемдә күрдем, син идең бит ул?! Син идең, инкарь итмә», — дип әйтә алыр идем микән?..

**8**

*2 апрель*

Мин шундый хәлдә: юлсыз далада кыргый җәнлек артыннан эзәрлекләп барып, үзе адашып калган аучы кебекмен. Ни кылырга? Уйлар бәргәләнә. Төннәрен йоклый алмый мазаланам. Иртән ватылып торам, баш шаулый. Юк, болай дәвам итә алмый. Чыдамым төкәнеп, мин бирелергә әзермен. Тик кемгә? Ничек?

Соң чиккәчә тартылган нервлар сугышы минем өчен түгел. Ахырда, түземем бетеп, мин ана хат язарга булдым.

*«Битаныш кордашым, — дип үзе кебек башладым мин хатымны. — Тиз генә җавап кайтармаганыма кичерүегезне сорыйм. Сез кузгаткан кайбер мәсьәләләр мина күптән билгеле, һәм аларга җавапны да үзем өчен күптән инде тапкан идем. Шулай булгач, сезнең белән бәхәскә керүнең минем өчен мәгънәсе юк дип*

*саналым. Мин үзем өчен аның мәсьәләләр хакында кайнарланып бәхәсләшергә яратмыйм. Житмәсә, сезнең уй сөрешегез минеке белән чагыша кебек. Әмма тора-бара мин алай түгеллеген аңлый башладым. Сез чын мәгънәсендә башка юнәлешне алга сөргән кеше булып чыктыгыз. Әлбәттә, жир йөзендәге бөтен адәми затларның бертөрле уй-фикер йөртүе, бертөрле үк эш кылуы чынбарлыкта була алмый. Ләкин синең инанган карашыңа тәкәллефсез кагылу, аны бозарга омтылучыларга битараф калып, кул кушырып утыру да мөмкин түгел. Менә шуңа күрә мин сезгә жавап язарга булдым.*

*Тормыш — көрәштән тора. Бу — аксиома. Әүвәле бу көрәштә кешелек тән-мускул көчен генә кулланды. Аннары хәтәр кораллар уйлап табып, аны камилләштерә барып, халыкларны рәхимсез кыру гамәлгә керде... Хәзерге чорда исә акыл сугышы мәйданга чыкты. Ул жир йөзендә кабынып, бөтен кешелеккә таралды. Бу — иң куркыныч яу. Моның ахыр нәтижәсе нинди булачак — кешелек изге башлангычын жуеп, явызлык рухыннан жиңеләчәкме?! Әгәр жиңелә икән, жиргә рухи һәлакәт-афәт дәвере киләчәк. Моннан котылу чарасы булмаячак.*

*Менә Сез икебез арасында бергә-бер акыл сугышын игълан иттегез. Мин кабул итәргә мәжбүр булдым...*

*Хәзер инде төп мәсьәләгә күчик. Сез миңе Яхшылыкка ышануым кебек үк, Золымлыкка да ышанырга чакырасыз. Эш шунда ки, хөрмәтлем, мин чынлап та кешедәге яманлыкны таныйм, әмма мин яхшылыкка и н а н а м.*

*Ышаныч ул — сайланып алынган кадер, жанның югары кимәлдәге рухи кыйммәткә кушылуы. Достоевский әйткән бит: «Ышаныч булмаган жирдә — миһербанлык та булмый», дип.*

*Бу ышанычның мәгънәсе нидә? Тормышта изгелекнең бар икәнен генә искәртүме? Юк, бу — изгелекнең жиңәсенә ышаныч. Изгелеккә ышанмаган кеше һичкайчан яхшылык кыла алмый.*

*Сез дөньябыздагы күп нәрсәне «яхшы» яисә «яман» дип бәяләүгә каршы киләсез. Адәм баласы бу ике төшенчәне аерып карарга өйрәнмәсә, акылы белән ул хайванат галәменнән өстен тора алыр идеме?! Яхшылыкны Яманлыктан аера белүдә түгелмени гуманлык, инс[illegible]ның асыл сыйфаты? Кешелеклелек кануннары шуннан барлыкка килмәгә[illegible]ме?*

*Кешелеклелек — адәми затлар, халыклар арасындагы мөнәсәбәттә бөтен заманда да төп кодекс булган, шулай бит, әңгәмәдәш? Әлеге төп канунннан тыш аерым адәм заты да, халыклар да гомер сөрә алмый. Дөрес, бу канунны ачыктан-ачык, аяусыз рәвештә бозучылар да бар, әле ярый дөньябыз андый бәндәләр иңенә таянмый, дип без Аллаһка рәхмәтле булырга тиеш.*

*Үлем турында фикер йөртүегезне зур яңалык дип әйтә алмас идем. Әгәр инде сүз, Ходай ихтыяры белән гомер соңына житеп, үзеннән соң киләсе буынга урын биреп, табигый үлү хакында барса — бер хәл, чөнки без мондый әҗәлне хак дип кабул итәргә күнеккәнбез.*

*Бүтәнчә үлем дә була бит. Ул бердәнбер якын кешеннең яшьлегендә үк гомерен аяусыз өзәргә мөмкин. Бер гөнаһсызны ниндидер явыз маньяктан мәсхәрә иттереп, жәзалап жанын кыйдырта. Канэчкеч тиранның хакими көчен тантана иттерү өчен тарихның туганнар каберлегенә һәлак ителгән меңнәрне ыргыттыра. Һәм шушы күптөрле г а д е л с е з үлемнәр Сезнең үлем турындагы тәгълиматыгызга туры килеп бетми. Чөнки сезнең юнәлешегез — Яхшылык төшенчәсенә карата шик уятуда. Хәтта, әйтер идем, еракакрак төбәлгән максатыгыз — бу төшенчәне үтерү.*

*Ялган турындагы фикерегез дә каршылыклы. Әйе, халыкларның ялган эчендә яшәве, шуның аркасында исән калуы кешелек тарихында булмады түгел, булды.*

*Хәзерге көндә дә ялган тарафдарлары юк түгел. Моның сәбәбе — җәмгыятьнең ялганга нигезләнүендә, ә ялганнын лаек биеклеккә ирешүендә түгел. Дөреслеккә таянган гадел җәмгыять төзелсә, галиҗәнап Ялган шунда ук фаш ителер иде һәм ул, сез язганча, үзен тәкәббер, һавалы тота алмас иде.*

*Хатыгыз соңында турылыклы иренә хыянәтен кичерә алмаган хатынның асылынып үлү вакыйгасын мисалга китерәсез. Ир дә фәрештә түгел, бичара хатын үзен корбан итә: ул әхлакый сафлыкка ышанган була. Ләкин мин бу мисалыгызны суфилык мутлыгы итеп кабул итәм. Акылның хәйләкәр уены. Ә бит тормышта киресенчә, яраткан хатыны хыянәт иткәннән соң, галәттә, ирләр асылынып үлә. Мона әллә күпме мисаллар китерергә була. Шуңа күрә, сезнең бөтен бәлаләрнең сәбәбе чынбарлыкта мөмкин булмаган әхлакый чисталыктан дигән сөземтәгез — нигезсез.*

*Изгелек һәм золымлык — бердәй кодрәткә ия дигән гоманлау да икеләнү тудыра. Имеш, шушы бизмәннең тигезлеген саклый алсаң, бар да әйбәт була. Ай-һай! Яхшылык һәм яманлык беркайчан да тиң була алмый. Сәбәбе — изгелекнең юлы җинүле. «Явызлык кылуның мең төре бар, ә явызлык кылмауның төре фәкать бер генә, ул — явызлык кылмау», дигән бер акыллысы. Кулыннан килгәнчә яхшылык кыл, ә яманлык кылуга тырышлык кирәкми.*

*Хатым соңында шуны әйтәсем килә: сезгә ни дә булса исбат итү яисә вәгазь уку, туры юлга өндәү уе юк миндә. Әйткәннәрем — сезнең мәҗбүриләп диярлек мине кертеп җибәргән бәхәскә җавап рәвешендә генә. Сезнең дөньяга карашыгыз чагылышында минем якты хисләремне, җанны рәнҗетү сизелә. Сезнең белән фикер алышу авыр мина, шуңа күрә якынаю яисә дусларча аралашу теләге дә юк. Мине тынычлыкта калдырып, үзегезгә тиң бүтән бер зыялы әңгәмәдәш тапсагыз әйбәт булыр иде.*

*Битанышыгыз.»*

## 9

*3 апрель*

«Битаныш кордаш»ның күңелгә болай ук тирән кадаласын башыма китермәгән идем. Гашыйк булгандай, төнен дә, көнен дә уйдан чыкмый. Тәүлекләр буе аның барлыгын бөтен тән күзәнәкләре белән сизәм, кайчакларда янәшәдә генә йөрәк тибешен ишетәм, сулыш алуын тоям кебек.

Ишегалдында һава алыштырырга чыкканнарны күзәтәм, әмма вакытымны юкка сарыф итәм бугай. Шулай итеп, һәр төнне мин йокысызлыктан интегеп, борсаланып чыгам да, таңда, кыйналып, аякка басам.

Үткән төндә коридорда аяк тавышлары ишетелде. Нигәдер үтеп китмәде, минем палата ишеге турына житкәч, тукталды да шактый озак таптанып торды. Мин ятагымнан торып, ишекне сагаеп кына ачтым. Кем дә юк. Шул мәлдә аяк тавышлары урам як тәрәзә артыннан килә башлады. Тәрәзәгә килдем, тышкы якта да беркем юк. Борылып китүем була, аяк тавышлары янадан кабатлана. Урамнан үткән машина гөрелтесе күмеп китә дә, ераклашкач, табанын ышкып, сагаеп кына басып килүе тагын йөрәккә тымызык шом сала. Ярымкараңгы коридорда берьялгызым чарасыз калып басып торам. Ишетәмме аяк тавышын, ишетмимме? Тереме мин, әллә — үлеме? Кайнар күкрәгем эчендә, яшәвемне раслап, басынкы йөрәгем тибә. Шушы ук секундта ишегалдына чыгып, йолдызлы күк астында, киерелеп, саф һава сулыйсым килде... Ләкин һәр катның ишеге төнгә ныклы йозакка бикләнә шул, ачкычы кизү табибта гына була.

Палатама кайтып, йончыган гәүдәмне ятакка салам. Калгып кына китәм, теге аяк тавышы тагын шым гына якыная башлый да дерт итеп уянам.

## 10

*7 апрель*

Иртән, поездгамы, самолеткамы сонга калып, бик мөһим нәрсәнедер куллан ычкындырган шикелле, тынычсыз уяндым да... мендәрдән башны күтәрүгә, тумбочка өстендәге хатны күреп алдым. Йөрәк чәнчеп куйды. Курку хисе тәнемне сызып узды. Куркудан тыш, «ни язган икән» дигән кызыксыну белән ашыга-ашыга хатны ачтым. Таныш язу рәвеше:

*«Кадерле битанышым!*

*Җавап язганыгыз өчен рәхмәт. Барсы да мин көткәнчә булды. Сез күптән инде калыплашкан, тотрыклы карашта икәнсез. Безнең яшәешебез очсыз-кырыйсыз базар шикелле. Һәркем шул базардан үзенә кирәген генә ала. Кешенең ихтыяҗы шул кирәклек белән билгеләнә. Сез үзегезгә бер файда китермәс әйберне сатып алганыгыз бармы? Менә шунда инде төп хикмәт. Килешәсез дип уйлыйм: мәңгеләшкән кануннар, дәлилләрне үзгәртү сезнең өчен кирәк түгел икән, яналыкка омтылуның да хаҗәте юк.*

*Әмма сез һәр үсеш-прогрессның яналыкка омтылудан туганын инкарь итмисездер ич?*

*Безнең цивилизациянең үсеш тарихын акыл белән колачлап карасаң, кешелек берәр кайчан бәхеткә ирешә алды микән, дигән нәтиҗәгә киләсең. Бу тарихның төп күрсәткечләре нәрсәдән тора: туктаусыз кан коюлы сугышлар, ачлык, афәт, үләт чире, изү-изелү. Боларга тагын бүгенге заманда техника үсешеннән килгән фаҗигаләр: җир-су, һаваның агулана баруы өстәлде.*

*Гомумиләштерүдән читкә китеп, аерым кеше язмышына тукталыйк әле. Үзебезне алыйк. Бәхетлеме без? Шәхсән үзем хакында кистереп әйтә алмыйм. Тирә-юньдә золым-җәбер, күпме гаделсезлекләр эшләнә, шуларга каршы тора алмавым белән бәхетле була аламмы? Уйлап карыйк әле: ничә гасыр буена инде яхшылык һәм гаделлеккә ышанабыз. Һәм һәрчак безнең ышаныч гамәли тормыш халәте белән чәкәшә дә, уенчык чүлмәк кебек, челпәрәмә килә. Без һаман, сантыйланып, иске карашларга тотынабыз. Сукыр кулына ни элгә, шуңа ябыша ди бит. Бәлки без дә сукырлар хәлендәдер, рухи сукырлар...*

*Безгә инану кирәк. Утка да табындык, суга да табындык. Табынмаган затыбыз калмады. Кешелек нинди генә аллаларга, пәйгамбәрләргә табынмады. Барысына да ышандык. Шуннан бичара тормышыбыз үзгәрдеме? Изгелек җинеп чыгачак, ышаныгыз! — дип чакыра безне гуманистлар. Ничә гасыр буена алар безне алдап киләләр. Әмма ул җиңү һаман күренми. Кайчан, кайсы гасырда Яхшылык җинеп чыгуын тантана итәчәк? Моңа инану бармы? Юк! Димәк, беркайчан да! Менә шулай, дустым, никадәр генә өметләнсәк тә, безнең күп кенә теләкләребез чынга ашмый. Ник алай, дигән хаклы сорау туа. Чөнки үз акылы яссылыгында кешелек күптән инде адашып калды. Бәлки, Яхшылык һәм Яманлык храмын салганда төзелеш кануннарында хата киткәндер. Хәзер инде бер генә юл кала: бөтен искене җир йөзеннән кагып төшерергә дә, яңадан кешелеклелек, намус, гаделлек хакындагы яңа карашларны ак биттән төзергә кирәк.*

*«Безнең бөтен яманлыгыбызны яхшылыкка әйләндерергә ихтыяр көчебез кайчан җитә, шунда гына бөек дәвер киләчәк», — дигән Ницше.*

*Күнегелгән, иске кагыйдәләр, тузган уй-фикерләвебез аша без чын хакыйкать йөзенә карый алмыйбыз.*

*Заманында күпме тарихи исемнәр каһәрләнде, утта яндырылды, дарга асылды, хурлыкка калдырылды, иленнән куылды — соңыннан инде кайсыларын бөек дип таныдылар, кайберләре хәтта пәйгамбәр дип игълан ителде.*

*Югары цивилизациягә ирешкән илләрдә күпме рәссам һәм әдипләрнең әсәрләренә үз вакытында җәмгыятьнең нигезен җимерә торган әхлаксызлык ярлыгы тагылды. Ә инде яңа буыннар килгәч, шул ук сәнгать әсәрләре кешелек мәдәниятенең иң шәп иҗат үрнәкләре дип танылды. Болар бар да иске карашлар әсирлегеннән вакытында чыга алмаудан. Моннан котылу белән безнең зиһенебезне югары кимәлдәге акыл алкышы биләп ала, безнең каршыда яңа яшәешнең ачык-җете киңлекләре ачыла.*

*Шулай итеп, безнең аңыбыз кысанлыктан котылуга мохтаҗ. Рухи ирек кирәк. Аны туктатыр чара булырга тиеш түгел. Фәкать чиксез рухи азатлык кына кешегә бәхет китерергә сәләтле.*

*Хөрмәт белән битаныш кордашың.»*

Яманлыкның да, яхшылыкның да җирдә орлыгы иң әүвәл СҮЗ булып шыта. Аннары, хасиятенә ышаныч кодрәте салынып, гамәлдәге эшләр булып үсеп чыга.

Ә инде битанышымның һәр хатында чагылган и д е я г ә килсәк, аны, бәлки... безнең рухи дөньябызга ташланган атом бомбасы белән чагыштырып буладыр. Шартлавыннан, радиация нурланышыннан нинди зарар киләчәк, моны бер Аллаһ белә.

Бу хакта мин тыныч кына уйлый алмыйм. Нервлар, тартылган кыл кебек, менә-менә шартлап өзелер кебек. Үз-үземне белештермичә, кычкырып, коридорга ташландым:

— Күпме түзәргә була?! Кем кертте аны палатага?! Кемнең хакы бар?!

Йөгереп шәфкать туташы килеп җитте.

— Ни карыйсыз? Ни өчен куйганнар сезне монда?! — дип тупас рәвештә кычкыра башладым. — Кем ул, нигә дип чит кешене палатама кертәсез?! Ничек кирәк алай шәфкать туташы мине тынычландырырга кереште. «Ни булды?» — дип сорады.

Ачудан калтырый-калтырый, мин аңа нәрсәдән канәгать түгеллегемне анык кына аңлата алмадым.

— Менә сезгә... Менә! Тагын сезгә нинди дәлил кирәк?! — дип аның борын төбендә хатны туктаусыз җилпим.

Ахырда шәфкать туташы төшенде бугай:

— Мин барда беркем дә бүлмәгезгә кермәде, — диде.

— Ә бу каян килгән?! — дип тагын хатны селкедем.

— Яхшы, — диде шәфкать туташы, минем белән килешкән сыман. — Сезгә тынычланырга кирәк. Бераз ятып торыгыз. Соңыннан ачыкларбыз, — дип ул мине палатага озатышты, таблетка бирде.

— Бүген һава суларга чыкмасагыз да була, — диде ул. — Кичкырын, борчу сизсәгез, кизү табибны чакыртып, укол кадатыгыз. Килештекме?

— Сез мине гафу итегез инде, — дидем, тынычланып, шәфкать туташының кулын учыма алдым. — Ачуым чыкты да кычкырып ташладым сезгә. Ышаныгыз, барысы да — өнемдә. Саташмыйм. Мин куып китереп кысрыкланган җәнлек хәлендәмен. Соңгы арада билгесез берәүдән хат алам да хат алам. Ул минем белән качышлы уйный. Хатны ташлап китә, үзе күренми. Менә бусы — чираттагы хаты. Мин аны күптәннән эләктерергә телим дә, булмый. Шул мине чыгырымнан чыгара.

Тыныч кына әйткән сүзләрем шәфкать туташына тәэсир итте бугай, ул миңа сынап карады да, бераз уйланганнан соң:

— Хатны кайчанрак таптыгыз? — дип сорады.

— Менә хәзер генә.

— Хәзер генә? — дип сискәнеп китте шәфкать туташы. — Мин монда күптән түгел генә эшкә урнаштым... Бар нәрсәне дә белеп бетермим әле... Мин сезнең зарыгызны истә тотармын. Ә хәзер ятып, ял итеп алыгыз.

Шулай дип ул ишекне сак кына ябып чыгып китте. Мин бик озак тынычлана алмадым. Сәгать унберләрдә аутотренингка киттем. Андагы сирпелеп агылган музыка тибрәнеше дә, яшь табибәнең энже тешләрен күрсәтеп, сусыл иреннәрен бөреп, җанны илаһи халәткә кертергә теләп әфсенле сүзләр кабатлавы да күңелне биләп алган шомны таратып, төшенке халәтемнән чыгара алмады.

Кичкырын мин хатка җавап язарга утырдым.

*«Хөрмәтле битанышым! Сезнең белән качыш уйнап, бер-беребезне күрмичә генә әйтешә башлаганга хәтсез вакыт үтте.*

*Әле бер, әле икенче темага күчәбез. Бөтенесен бер күчкә өюебезнең максаты — һәркем үз дөреслеген исбатларга теләүдәндер. Әгәр без уй-фикерләребезнең юнәлешен ачыклап, алшартлар куеп килешмәсәк, безнең бу бәхәс гомер азагына кадәр сузылачак.*

*Шулай итеп, сез раслаганча, кешелек узган юл фаҗигале алданудан гына тора, чөнки аның изгелеккә дәшкән рухи йолдызы — ялган, әдәми затның баштан ук табынган Тимерказыгы — кешелек максаты дөрес сайланмаган.*

*Шуннан чыгып, изгелек, мәхәббәт, нәфрәт, бозыклык, сафлык кебек төшенчәләр ялгыш калыплашкан. Моннан ни килеп чыга? Рухи омтылышыбыздан, югары идеалларыбыздан ваз кичәргәме? Әлбәттә, сез «баш тартырга» дип ачыктан-ачык әйтмисез, әмма сүз сөрешегез шуңа ишарәле бит.*

*Ә бит кешеләрнең үз хәятендә бәхетсезлеккә дучар булуы әхлакый кануннарны саклаудан түгел, киресенчә, шул кануннарны бозудан килә. Бәхетсезлекнең сәбәбе — гыйбадәтханәләрне дөрес төземәүдә түгел, без аларны мәсхәрә иттек, кадерләп, чисталык үрнәгендә тота алмадык.*

*Һәр җан иясе, шул исәптән әдәми зат та, җирдә үз ирегенә яуларга омтыла. Бу — бәхәссез. Сезнеңчә, азатлык ул — бөтен чикләүләрдән арыну. Ни кылсаң да — ирек. Ә бүтәннәр каршында үзеңнең бурычыңны тою, шәфкатьлелек, вөҗданлылык, намуслылык тойгылары әхлакый кануннар кысасында безнең гамәлләребезне чикләргә тиеш түгелмени? Ирекле булу — хәтта вөҗдан, гаделлек сүрүен дә санламыйча, бөтен киртәләрне дә инкарь итү, һәм сез мине шуңа ышандырырга тырышасызмы? Димәк, чик-чама белмәгән кешеләр кыланышыннан туган имансызлык, хыянәт, бозыклык, караклык — кыскасы, уйга ни килсә, шуны эшләү — ирек булып чыгамы? Бу мантыйкка иярсәң, борынгы Рим цезарьлары — коточкыч кабахәтлекләр кылучы Нерон, Калигула һәм башкалар, кешелек тарихында иң ирекле бәндәләр булып чыга. Нәкъ менә алар әхлакый кагыйдәләрне бөтенләй инкарь итәләр: хәтта үз әниләре белән җенси якынлык кылалар, Сенат утырышына ат җитәкләп керәләр һәм тагын әллә күпме чиркангыч бозыклыкларын мисалга китерергә була. Шундый әйтем бар бит: этнең иясе булса, бүренең — Тәңресе була. Һәммәсенә дә буйсындыру чарасы табыла. Ходай ихтыярындагы чиктән чыкканнарга иртәме-соңмы Тарих хөкеме биреләчәк.*

*Бәлкем, кешелекне бозыклыкка бирелеп, рухи таркалудан нәкъ менә дин саклап калгандыр әле. Иблисне бөтенләй авызлыклый алмаса да, һәрхәлдә, фаш итеп, хөкемгә тартты. Аллаһтан курку инсанны хайваннан аерды, сез моның белән килешәсезме? Үз кызын белән җенси якынлык кылуны шәригать законы тыя, ә шәхесне чамасыз, йөгәнсез үз ирекләгенә куйган закон түгел.*

*Әгәр, сезнеңчә, иреклелекне гамәли тормыштан аерып карасаң, ана поткa табынган кебек табынсаң, ул чакта инде без яңадан шул котырган вакханалиягә әйләнеп кайтачакбыз. Инсан инсани зат булуга ирешкәннән бирле аныбыз төпкелендәге зинданга әхлакый кануннарга таянып хөкем ителгәннәр ябылган — түбән җанлылык, хайвани теләкләләр, оятсызлык, инсафсызлык, каты бәгырьлек, рәхимсезлек кебек шушы явыз рух чирүе ирекка бәреп чыгарга ыргылып, безнең көчсезләнүне, ышанычны, уяулыкны җуюыбызны, тынын*

*кысып, күтәп ята. Чарасыз калсак, нинди куркыныч монстрлар, туктаусыз жан кыючы башкисәрләр безнең эчке хәятебез зинданыннан тышка ургылып чыгар иде.*

*Урамнан барган чибәр ханымга кызыгып күз саласың. Табигый, адәми зат фәрештә түгел. Әмма сабырлык сакла! Ул, бәлки, синең кебек үк инсафлы ирнең сөекле ярыдыр. Синең балаң кебек үк бер сабыйның кадерле әнкәседер... Хатын-кызны шундый итеп күзаллаганда, азгын теләк уянырга мөмкинме... Менә шул мизгелдә син, ихтыяр күрсәтеп, үз-үзенә «Тукта!» дип әмер бирергә тиешсең. Чөнки ирек ул бүтән кеше өчен зыян салудан кала, күп нәрсә эшләргә мөмкинлек бирә. Әгәр кырын адымыңнан вакытында тыелып кала алмыйсың икән, син хайвани теләгең колына әвереләсең.*

*«Синең патшалардан аермаң нидә?»— дип сорагач, бөек Сократ: «Алар үз теләк-хисләренең колы, ә мин — үз теләк-хисләремнең хакиме», ди. Әйе, Сократ бу кол-патшаларга караганда йөз тапкыр ирекләрәк.*

*Тормыш мәгънәсе, эчтәлеге гади хакыйкатьтән тора. Тик икебезнең бәлабез шунда: әнә шул гадилекне кабул итә белмибез. Үз ихтыярыбыз белән иң кыен, иң чуалчык юлны сайлыйбыз да, үзебез тудырган кыенлыклар белән жан аямыйча көрәшеп, башка килмәслек әллә нинди батырлыклар кылабыз. Әйтик, тәмәке тартуның сәламәтлеккә зыяны хакында кем генә белми. Мин инде олы яшькә житкән кешегә килгән табигый үлем хакында әйтмим, ә үзебезнең ахмаклык, кимчелекле гадәтләребез аркасында вакытсыз килгән үлемгә караганда тәмәке тартучыларның үпкә рагыннан һәлак ителүләре күбрәк санда. Шуңа күрә бу хәтәр авыруны жиңәр өчен күпме илләргә миллион сумлык чыгымнар тотыла, онкология өлкәсендә дөньяви индустрия эшли, ә бер уйласаң, мәсьәлә бик гади бит! Тарту зарарлы, куркыныч нәрсә булгач — тартма! Ташла тәмәкене! Юк бит. Ихтыяр көче белән жиңә торган гади генә мәсьәлә кебек югыйсә, кешелек өчен моның мөһим проблемага әйләнә баруы, аяк астыннан калыккан кеп-кечкенә жәнлекнең күз алдында куркыныч аждаһага әверелеп коткы салуы кебек («Кешеләрнең күп газапларга үз-үзен дучар итүе — хакыйкатьне санламаудан килә», — дигән сезнең яраткан Ф.Ницше). Бу бәладән котылу өчен сез бәлки тәмәке тартуны бөтен гавамга закон белән, мәжбүри кертергә кирәк диярсездер. Кешенең сайлап алу хокукы турындагы сезнең фикерләү мантыйгыннан чыгып әйтәм мин моны. Ул үзенең алама гадәтен бетерер өчен көрәшүне инкарь итәргә тиеш, чөнки бу — тәмәке яратучыларның ирегең кысу булып күренәчәк. Шулай итеп сез кешенең үз теләгән тыя алмаган басынкы кол булып калуына астыртын гына ирешмәкче буласыз.*

*Ирек ул — инсанның кальбендә, зиһенендә. Тышкы яктан кешегә нинди генә төскә манылган ирек тәкъдим итмә, әгәр ул, адәм актыгы икән, ирек аның өчен файдасыз, чөнки ул әүвәленнән үк колагы киселгән, маңгаена келәймә сугылган кол һәм алдагы дәверләрдә дә ул кол булып барачак. «Нәрсә ул — Ирек? Вөжданның сафлыгы», — дигән яңа эрага кадәр жиде гасыр элек, жир йөзендәге жиде акыл иясенең бере — Периандр Коринфский.*

*Килешәсездер, шәп әйткән бит! Димәк ки, рухи камиллек аша гына ирекле булуга ирешү мөмкин. Мондый ирек хозурына баш киемеңне салып, башны жиргә кадәр исәң дә ярый.*

*Изгелек кайсы гасырда жиңүгә иреште? Моңа дәлил бармы? — дип хәйләле сорау куйган буласыз. Изгелекнең жирдәге золымны бөтенләй тамырыннан кубарып атуына ышану сабыйлык булыр иде. Кешеләр һәрдаим яхшылык кылуның зарурлыгын аңлауга ирешкәндә генә, Яхшылыкның тантана итүе мөмкин.*

*Бу — мәсьәләнең бер ягы. Даими барган туктаусыз көрәштә без жиңү һәм жиңелүнең асылын ачыклаганыбыз юк. Бу хакта без әлегә кадәр сүз*

*дә кузгатмадык. Тар карашлылар анында җиңү — ул, әйтик, боксерның рингта, көч белән сугып, көндәшен йөзтүбән аударуы, яисә атышка корылган кинофильмда дошманның коралын өлгерлек белән тартып алган гангстерның пуля яудырып, аны юк итүе... Ягъни, һәлак ителгәннәр җиңелгән санала. Әмма Гайсә пәйгамбәрнең дошманнары тарафыннан рәхимсез үтерелүе актыкта кешелек өчен бөек җиңү булып чыкты түгелме? Тормышта шушылай җиңүгә биргесез җиңелүләр булуы билгеле.*

*Оясындагы балаларын коткарырга тырышып, тургайның зәһәр елан авызына үзе атылып керүеннән дә бөек каһарманлык бар микән? Кошчыкның үлеме — олы җиңү түгелмени?! Сокланырга лаек җиңү.*

*«Батырлык»ның асылы нидә? Кан коюдан чирканмаган иң каты бәгырьләләр безгә кыюлык үрнәге булып тоела, ә инде күпләп җан кыючылар батыр исеменә иң лаек булып чыга. Үз заманында Абай да: «Нишләп соң әле явызлык кылучы бар явызлар да батыр санала?» дип гаҗиз сорау биргән. Чынбарлыкта гел шулай булса, ул чакта рухи батырлык кылырга сәләтлеләр өлешенә ни кала? Мәсәлән, үз җитешсезлегеңне, үз хаталарыңны танып фаш итә алу, үзеңә карата каттый таләпчәнлек күрсәтү, иң мөһиме, үзеңне үзең җиңә белү — батырлык түгелме?! Хәтта ни кодрәтле арыслан да әнә үзеннән күпкә көчле, аяусыз дошманына курыкмыйча ташланган тәвәккәл тургай батырлыгына тиңне кабатлый алмаска мөмкин.*

*Шушы гөманлаулардан чыгып, бәлкем кайбер төшенчәләргә яңа бер караш ташларга кирәктер.*

*Сезнең төп идеягез менә нәрсәгә нигезләнгән: изгелекнең максаты камиллеккә ирешмәгән инсаннарга да, җир йөзендәге чынбарлыкка да туры килми, чөнки абсолют, җитлеккән камиллек беркайда да юк. Монысы белән килешәм, нәкъ менә дөньяның камилләшеп бетмәве үсешкә стимул бирә. Ә инде Җир йөзендәге тереклекнең өзлексез яшәү агымы даими үсеш кануннарына буйсына. Әйе, бу шулай. Әгәр дөньяда ни дә булса тулы бер камиллеккә ирешсә, ул инде чиксез үсеш чылбырыннан өзелеп калып, яшәүдән туктар иде. Сәнгатькярләрне алыйк, тулы камиллеккә ирешүнең Ходайдан бирелмәгәнен беләләр югыйсә — әмма иҗатта шуңа омтылыш аларны көчле итә, гүзәл сәнгать җәүһәрләре тудырырга дәрт бирә.*

*Яшәү — бөек омтылышка корылган. Куркыныч авыруларны дәвалау ысулларын табу аша, мәһабәт диварлы кирмәннәрне камап, җиңүгә биргесез җиңелүләр аша, рухи камиллеккә омтылуда ирешә алмастай максат куюлар аша кешелек үз мөмкинлегенең офыкларын киңәйтергә сәләтле.*

*Димәк, югары идеалларның җирдәге чынбарлыкка туры килмәве — кимчелеге түгел, ә өстенлеге.*

*Күк иясе җирдә менә дигән шартлар булдырган, бу дөньяны тагын да матурлар өчен безгә хис, теләк, төрле вазифалар биргән. Әмма Ходайдан бүләк ителгән изге ниятләрне без әтрафлы файдалана алмадык. Хаталарыбыз сәбәпләрен ачыклыйсы урында, чарасыз гөнаһка батып, тотрыксызлык, җегәрсезлек күрсәтеп, без инде хәзер кешелек тудырган рухи кыйммәтләрне юк итәргә тотындык.*

*Кешеләрнең яшәү канунын кешеләр үзе төзи. Аны үтәү дә үзләреннән тора. Дөрес, табигать кануннары инсаннарныкыннан күпкә кырысрак, каттыйрак; шуңа күрә безнең илаһи тойгыларыбызга, әхлак кагыйдәләренә басым ясала. Әмма, без табигатьнең бер күзәнәге булсак та, тулаем ул кануннарны яшәү шарты итеп алалмыйбыз — без хайван затыннан түгел гой.*

*Табигать канунында (дөресрәге, җәнлек-хайваннарның җан асрау канунында) — тормыш рәхәтлекләреннән баш тарту, рухи чистарыну, идеал мәхәббәт хакына, Тәңре хакына үз-үзеңне корбан итү кебек әхлак нормалары гамәлгә кергәнме?*

*Юк, әлбәттә. Бөтен җан ияләреннән кала бердәнбер адәми затта гына әүлиялеккә омтылыш бар. Әгәр без, табигатьнең язылмаган кануннары кешеләрнекеннән өстенрәк тә, чынрак та дип расласак, Ходай индергән рухият нуры — гамәлләребезне ачыклау, фаш итү, безнен өметсез гөнаһлы икәнебезне искәртү өчен бирелгән юнәлеш кенә булып чыга. Димәк, без әхлак кагыйдәләрен инкарь итеп, хайван дәрәҗәсенә төшеп, бөтен кылган әшәкелекләрне акларга тырышачакбыз. Шулай итеп, яна тәртип урнаштырабыз: начарлык әйбәтлеккә әверелә...*

*Ягъни, кеше үтерү дә хөкем ителми: «табигатьтә шулай булган, шулай була, шулай булачак» дигән гадәти хәлгә әвереләчәк.*

*Ә алда — чикләнмәгән ирек! Ни кылсаң да үз ихтыярыңда. Телисең — азгынлык кыл, намусыңны сат, изге төшенчәләрне мәсхәрә ит, карак бул. Табигать кануны шундый. Нинди рәхәтлек! Зинданнан котылган тоткын кебек — дүрт ягың кыйбла. «Бәхет кошың» кул сузымы гына арада.*

*Юк, битаныш замандаш! Яшәү дигән бөек уен кагыйдәсе борынгыдан килә. Һәм аны көчлеләр түгел, көчсезләр боза.*

*Шунысын да әйтик: тарихка күз салсаң, ээрлекләнеп, күпме каһарманнарның утта яндырылуы, еретик дип асып үтерелүе, күпме тәкъвалар, пәйгамбәрләрнең үлемгә хөкем ителүе халык тарафыннан түгел, ә хакимнәр тарафыннан эшләнә. Халык исә газап чигүчеләрнең исемнәрен генә тарих әҗәленнән йолып алып, мәңге хәтерендә саклый.*

*Хуш булыгыз! Битаныш.»*

Мин хатны коридордагы шартлы урыныбызга куеп, палатага кайттым да, язганнарым тәэсиреннән әсәрләнеп шактый озак яттым.

Кытай философиясенен төп төшенчәләре «Ян» һәм «Инь» хакында битанышым тәүге хатында язган иде бит, шуны искә төшердем. Иньның Янга, яисә Янның Иньгә күчеше — ике капма-каршылыкның берлеге — мина аңлашыла кебек. Ләкин нишләп соң әле бу ике башлангыч кушылырга һәм ниндидер берлек хасил итәргә тиеш? Житмәсә, ике көч кушылганда һәрберсе үз мөстәкыйль йөзен югалта. Нигә соң әле ак, һичшиксез, кара белән, файда-зыян, яхшы-яман белән кушып каралырга тиеш? Анык акыл белән уйласак, аш пешерү өчен казан астына ягылган учак уты да — ут, адәм затының гомер буена җыйган мал-мөлкәтен көлгә әйләндергән афәтле янгын уты да — ут. Ике очракта да яну хасиятләре бертөрле түгелме? Юк, бу «учак»ларны тиңләштереп карап булмый. Ләкин бу ике аерымлыкны бер «табакка бушату» кемгәдер файдалы ахрысы?

Файдалы икән шул, шайтан алгыры, гарип җанлыларга, отыры күбәя барган рухи гермофродитларга, шома бәндәләргә ялган һәм дөреслек дигән ике галиҗәнапкә берьюлы хезмәт итү кулай икән.

Мина хат юллаган битаныш кордашымның уй сөрешеннән шуны тоям: гүя ул кешелекнең гасыр буе төзегән рухи храмын шартлатырга план корган фанатик террорчы. Ул меңьеллар буена кешелек ирешкән рухи хәзинәне бер мизгелдә юк итәргә тели. Аннары инде без, телисеңме-теләмисеңме, хайванат галәменә кайтып төшәчәкбез.

Рухи террорчылыкка каршы көрәш кирәк.

## 11

*8 апрель*

Ялгызлык хакында уйланам. Һәртөрле кыенлыкка, хыянәт, золым-җәза кебек мең бәлагә түзеп буладыр шикелле. Әмма иң кыены — ялгызлыкка түзү.

Ярлы, яшәү шартлары түбән илләрдәгегә караганда, алга киткән бай илләрдә үз-үзенә кул салучылар саны күбрәк, диләр. Моның сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Яман чиргә юлыгу, алданган мәхәббәт, өзелгән өмет-хыял... Әмма

төп сәбәп — ялгызлыктан килә. Әлбәттә, сәламәтләнүгә ышанычы калмаган һәр авыру да үз ихтыяры белән гомерен өзүгә бара алмый. Яраткан, хөрмәт иткән якыннары янәшәсендә булганда мондый уй аның башына да килмәскә мөмкин. Инде килеп, кайгы-хәсрәтеңне, җан газабыңны бүлешер кешең юк икән, сине Ялгызлык иярләп ала. Бөтен вөҗүдеңне биләп алган гыйшкың кебек, ул тормышыңның иң аулак чатларына кадәр озата бара. Ялгызлык — синең игезәк туганың. Ялгызлык — синең аерылгысыз язмышыңа әверелә. Син аңа ихтыярсыз буйсынып, итәгенә ябышасың да, гомер соңына кадәр күндәм ияреп барасың да барасың — аннары теге дөньяның томанлы хаятенә күчәсең.

Галимнәр ерак галактикалар тирәнлегендә үзенә таба якынайган бөтен нәрсәне, хәтта яктылык нурын да үзенә суырып ала торган кара төннекләр[1] барын ачтылар. Аннан берни дә кире чыга алмый. Ялгызлык та шундый комсыз кара төннек шикелле. Җаныңдагы бар яктылыкны, яшәү җегәреңне, өмет-куанычыңны кайтарусыз суырып ала. Ялгызлык аяусыз йота барган җан кодрәтең югыйсә нинди олуг каһарманлыклар кылырга җитәр иде.

Ялгызлыкның шомлы сулышы миңа да якынлашып килә, мин аны тарыккан җаным, сагайган йөрәгем белән тоям.

Куркудан, берәр әңгәмәдәшкә тап булмаммы дип, каядыр ашыгам. Коридорда шәфкать туташын яисә берәр санитарканы туктатам да тегесен-монысын сораштырырга тотынам. Гүя аларның һәр әйткән сүзе миңа бик тә кызык, шулай озак итеп, иркенләп сөйләшеп торсыннар иде дип эчемнән ялварам. Күбесе, күзләрен зур ачып, аңы тайпылган моның дигән кебек, сәерсенеп карыйлар, кайсылары бер сүз дә дәшмичә, мыскыллы елмаеп, ары китеп баралар.

Ниһаять, мин аутотренинг сәгате җиткәнне көтеп алам. Ашыгып шунда йөгерәм, тынычландыра торган сүзләр кабатлаучы, сабыйларча ярым ачык иренле, чибәр табибәне тизрәк күрергә кирәк миңа...

Кәнәфигә утырдым да оедым. Бөтен сеанс буена йокыга салышып утырдым, инде бетте дигәч тә күземне ачмадым. Бераздан йокыдан уянган рәвеш чыгарып, күземне ачсам, ни гаҗәп! Нәкъ каршымда, сынап, туп-туры миңа карап табибә кыз басып тора, йөзендә искиткеч ягымлы елмаю балкышы! Күз карашы шундый мөлаем, җанны рәхәт җылыта торган. Кешегә күп кирәкмени! Менә шушындый миһербанлы бер караш — бәхетле мизгелгә якынайта да куя.

Әмма ул мине аптырауга салып, кинәт кенә:

— Сез бит йокламадыгыз гой, — дип әйтеп куйды. Ә мин тирән йокыга талуыма бөтенесе дә ышанды дип уйлаган идем. Табибә кыз шундый дустанә шаянлык белән мине уңайсыз хәлгә калуымнан коткарды. Их, бүтән берни дә кирәкми, менә шушылай мөлаем елмаеп карап торсын гына иде.

Капылт ул минем кулымнан тотып:

— Сез үзегезне бимазалаган уйларны миңа бирә аласызмы? — диде. Мин аптырап калдым.

— Сезгә бирергә? Ничек итеп?

Дулкынланудан уч төбем тирләп чыкты. Мин сак кына кулымны алдым. Табибә кыз: «Йәле, тынычланыгыз, мин бит сезне үпкәләтерлек сүз әйтмәдем шикелле», дигәндәй, элеккечә күз сирпеп тора.

Аның күзләре диңгез кебек тирән, таңгы дала кебек җемелди, туңган йөрәгемә илаһи җылылык агылдыра. Бу күзләр мине тынычландыра, хозурлык бишегендә юата, назлы тирбәтә.

«Күңелегезгә тиярдәй сүз әйткән булсам, гафу үтенәм, — дия иде аның шәфкатьле күзләре. — Мин сездән рәнҗүегезне теләмим. Эчтән сызланган

[1] Кара төннек — русча «черная дыра», инглизчә «black hole» (бу төшенчәне астрофизика фәненә галим Джон Уиллер керткән) — М.Г.

уйларыгызга дәва булмасмы дип кенә. Жанга жаннан башка шифа юк. Карагыз, күзләремә туры карагыз әле. Жаннын асыл чагылышы — күзләрдә».

«Сезнен яктан жанны сыйпап нәзберек жылы жил агымы килә, — дидем мин күз карашым белән. — Беренче күргәндә үк сизгән идем аны. Әмма мин ул чакта бу ягымлы жылылыкнын кемгә юнәлтелгәнен анламаган идем. Барыбызга да, шул ук вакытта беркемгә дә түгел, дип уйладым. Хәзер сез фәкать мина эндәшәсез. Әйе, мине тынгысыз уйлар борчый. Шулкадәр күп алар, шулкадәр күп мазалы уйлар. Мин аларны сезгә б и р е р г ә куркам. Аларнын барлыгын белмәвегез үзегез өчен әйбәт.

«Сезне газаплы уйлардан коткару — минем өчен бәхет»...

Анын бу сүзләре колагыма ап-ачык ишетелгән кебек тоелды.

— Нәрсә? — дип сорадым мин, ишеткәнемне раслар өчен.

— Сезне газаплы уйлардан коткару — минем өчен бәхет, — дип ачык итеп кабатлады ул.

Эчтән, тойгылар аша, тавышсыз анлашудан янгыравык сүзләргә күчүне өнәп бетермәдем. Күз карашы белән өнсез сөйләшүне ихласрак, анлаешлырак дип саныйм. Шуна күрә мин күзләр белән генә әнгәмә коруны хуп күрдем.

«Мине талкыган уйларны сезгә бирү — язмышымны тапшыруга тин», — дидем мин өнсез диалогны дәвам итеп.

«Мин барын да кабул итәргә әзер», — дип жавап бирде анын тәвәккәл карашы. Шул мәлдә йөрәгем ишетелерлек итеп тибә башлады.

— Чынлапмы? — дидем үзем дә сизмичә.

— Чынлап, — диде ул, катгый итеп.

Буасын ерып ыргылган су куәте кебек хисләр ташкыны минем коргаксыган күнел дөньяма бәреп керде. Сусап яткан чүл кинлекләре бер мизгелдә чәчәккә коенган, яшеллек кайнап күтәрелгән оазиска әверелде. Әйе, кешене югары чөеп, тормышына бөек мәгънә индерә торган кодрәт бар шул дөньяда. Андый мизгелне Ходай бирсә...

Кызган учыма кысып, анын кулын сыйпадым. Ул карышмады, чарасыз калгандай, монсулык өртелгән күзләрен түбән төшерде. Аннары кулын сак кына хәрәкәт белән тартып алмакчы булды, мин ычкындырмадым, чөнки йөрәгем ышаныч белән тибә, мона кадәр күрелмәгән гайрәттән канатланган рухым менә хәзер булачак жину тантанасын сизә иде.

Әлбәттә, бу жинел акыллылык иде. Бер минут кына элгәре, галәми ялгызлыктан изелгән мин бичараны дәһшәтле куркудан шушы назлы кызыкай йолып алды бит... Хәзер инде гадәттән тыш көчемне шушы ягымлы игелек иясенә каршы юнәлтәмме...

Мин аны үземә таба якынайттым. Затлы хушбуй исе сирпелеп алды. Анын дымланган кулы сизелер-сизелмәс кенә калтырый иде. Йә Хода, ул күндәм-карусыз була барган саен миндәге оятсызлана барган теләк, кан исен сизгән акула кебек, аяусызлык чигенә житте. Үз-үземне танымыйм, гүя мине алыштырып куйдылар. Ниһаять, күнел күзем ачыла төшә: менә ул — мин, хайвани дәрттән исергән мин, хис-тойгыларымнын ерткыч иясе, унай мизгелне чамалап, ан-акылымнын тирән зинданыннан бәреп чыктымы?!

— Юк! Юк! — дип куркынып пышылдадым. — Юк! Һичкайчан да!

Мин хайвани хисләремне көч-хәл белән зинданга куып керттем дә, жинел сулап, күтәрелеп карасам... анын каушавын, бит очларынын алсуланып чыкканын күрдем.

— Сезгә түгел. Үземә әйтәм. Үземә, — дип хәлсезләнгән күкрәгемә бармак белән төртә-төртә табибә кызга анлатам. Ул оялчан гына елмайды. Анын яшь, чиста йөзендәге тан алсулыгы — күнел сафлыгы, назлылык билгесе

иде. Гомумән, кешеләрнең кызара белгәне эчке матурлыкка, иман нурына ия була.

Ул янәшәмә утырып, нидер әйтергә теләде, әмма мин иреннәренә сак кына бармак очларын тигездем. Аның күперенке йомшак ирен кайнарлыгы канны кытыклап куйды.

— Кирәкми, — дип пышылдадым. — Жан белән жан аңлаштылар. Сүзләр артык монда. Берни дә әйтмәгез...

Ул янгыратып көлеп жибәрде, өнсез әнгәмәбезгә нокта куярга теләгәндәй, нурлы күзләре белән шундый да ягымлы итеп карады ки, күңелемне тагын сусыл-яшел тажы ачылган тылсымлы оазис биләп алды.

Бу тормыш — үзе бер әкият.

## 12

*9 апрель*

Мин озак вакыт тынчу-караңгы бинада ятып, кинәт кояшка, шаулап торган якты дөньяга чыккан шикелле, ниндидер бер куаныч кичерәм.

Яшерен хатларын калдырып китүченең кем икәнен беләсе килү уеннан да әкренләп суына барам шикелле.

Маңгай чәче күзенә төшеп торган, үтә ябык гәүдәле яшь бер егеткә генә шигем калган иде, чөнки ул мине күрүгә палатасына кереп шыла, баксаң, ул беркемнең күзенә дә туры карый белми, һәркемнән читләшә икән.

Шулай да... Күпмедер вакыт үткәннән соң, «битаныш кордашым»а кагылышлы уйлар кабаттан әйләнеп кайтты. Аны ничек табарга соң дип күңелемнән ятьмә кора башладым.

Бәлки бүген табылыр, дигән уй белән ишегалдына һава суларга чыктым. Мин берничә көн чыкмаган арада, ишегалды хәятендә шактый үзгәрешләр булган икән. Сугышырга яраткан мәһабәт гәүдәле сакал да күренми, аның каршында муенын бөгеп, чарасыз кыйната торган жиз чәчле сәләмә адәм дә юкка чыккан, атаклы нәсел-нәсәбен бармак бөгеп саный торган Жирән дә гаип булган. Иске танышлардан фәкать үз-үзенә вәгазь укып утыручы «Иисус» кына күренә. Калганнар — яңа килгәннәр, басынкы кыяфәт белән, беркем белән аралашмыйча, сукмаклар буйлап тик йөриләр. Сүз катып карасам да, яңаларның берсе дә ачылып китмәде. Болай йөрү үземә дә унайсыз була башлады, әйтерсең лә мин аларның йөзенә сынап карап, нинди дә булса гаеп эшләрен фаш итәргә жыенам.

Кичкә кадәр шулай килеп сарып йөргәннән соң, талчыгып, палатама кайттым да, ятагыма авып, йокыга талдым.

## 13

*13 апрель*

Күңел иләс-миләс. Башым авыртып жәфалый. Көндәлекне язарга да кулым бармый.

Билгесез кордашымны жир упты инде әллә. Хәбәре юк. Хөсетле уйларын минем башыма кертеп калдырды да — югалды. Нигә борчылам соң әле? Үлсә ни дә, яшәсә ни. Әмма аның мина б и р г ә н усал уйлары жанымны тынгысызлый.

...Үндырышлы жирләрне ком явы басып килә, шуның кебек үк дөньяви явызлык чирүе дә кешелекнең отыры тарая барган әхлакый оазисына һөжүм итә.

Сәнгать әсәрләре, китаплар, кинофильмнар никадәр тупас, әдәпсез булса, аларның базар хакы шулкадәр югары бәяләнә. Бетховенны кем тыңлый хәзер, коточкыч шаулы, йөрәктәге бөтен хис-тойгыны кубарып ыргыта торган кыргый

музыка тирәсенә кешеләр кырмыска кебек җыелыша. Бөек сәләткә ия режиссер үз картинасын дөньяга чыгару өчен мөмкинлек таба алмыйча ун еллар буена интегә, ә порнофильм төшергән шома бәндә алтын яңгырында коена, дөньяның мәдәни элитасына керә. Бу ни хакында искәртә? Димәк, әхлаксызлык — безнең заманда иң шәп тауар. Әгәр югары үсешкә ирешкән зур илнең атаклы мадоннасы журналларда анадан тума рәсемен чыгарып, җенси якынлык кылганда ничә тапкыр оргазм кичергәне хакында интервью биреп, укучылары каршында «ялангач телдә» сөйләшә икән, шул илнең парламенты хатын-кызга үз җенесендәге, ир-атка — үз җенесендәге кеше белән никахлашырга мөмкин дигән закон кабул итеп, моны демократия казанышы дип кабул итәбез икән, моннан соң ничек инде Яхшылыкның Яманлыкны җиңүе хакында сөйләргә мөмкин? Бу — изгелекнең җиңелүе түгелмени?!

Ләкин империяләр көчсезләнгән дәвердә гореф-гадәтләрнең бозылуы бөтен кешелеккә хас яшәеш законнарының чагылышы дигән сүз түгел әле. Бу законнар эчтәлеге катгый, математик мантыйкка корылган, ә заманыбызның тоташ бозыклыкка баруында мантыйк юк. Моның эчке асылында — үз-үзеңне бетерергә омтылыш һәлакәте. Гади генә чагыштыру китерик: үзе тудырган афәттән котыла алмаган наркоман яисә өметсез эчкече ахыр чиктә үз-үзенә кул сала. Җир йөзендәге кешелек тә шулай, рухын җуеп, түбәнлеккә төшүдән глобаль суицидка барып кына котыла ала. Җан һәм акылны яулау сугышында Яхшылык чынлап та җиңелә икән, ахыргы нәтиҗәләр турында бүтәнчә фаразлар булу мөмкин түгел.

Әйе, атом коралы яисә галәмнән килеп төшкән астероид кебек тышкы көчләр генә кешелекнең һәлакәтенә сәбәп була алмыйдыр. Кешелекне үз бозыклыгы харап итәчәк.

Гомум бу көчкә буйсынгандай рухи таркала баруның нинди дә булса төп сәбәбе булырга тиештер бит. Әлбәттә, ул — кешенең минминлегендәге яман авыру. Бездәге иң кодрәтле, җиңелү белмәс, йөгәнсез «Мин». Бу коточкыч «Мин»не авызлыклау кирәк дип саныймы кеше дигәнең? Югары камилләге омтылыш, үз-үзен җиңә алу сәләте аз булса да калганмы анарда?

Ерткыч гепардны мисалга китерик. Ул үз көчекләренең авызыннан ит кисәкләрен тартып ала. Биологлар моны хайвани эгоизм, комсызлыктан дип бәялиләр иде, ә ул, кинәт күп ашап ташламасыннар дип, үз балаларын үлемнән коткарып кала икән бит. Табигать җәнлекләрне кыргый эгоизмнан, комсызлыкка барудан коткарып калган, ә менә иң югары акыл бирелгән адәми затны күз уңыннан ычкындырган. Нихәл итәсең, кешеләр дә бит шул гепард көчекләре кебек, әмма аларны һәлакәткә илтүче комагайлыктан берәү дә коткара алмый, фәкать үзләре үзләрен генә... Әйтик, бөтен аерым «Мин»нәрне «Без» бергәлегенә туплап, «Мина» дигән нәфестән ваз кичеп...

Тәхет мина булырга тиеш, дип саный хаким. Юк, мина, ди хакимлеккә дәгъва кылучы, шулай итеп иллә капма-каршылар сугышы башланып китә.

Гаиләләр ни өчен таркала — чөнки ире үзе турында гына, хатыны — үз мәнфәгатен генә кайгырта. «Без» түгел, ә «Мин» хакими көчкә әверелсә, анда инде мәхәббәт тә, туганлык та, итагатьле килешеп яшәү дә була алмый. Ана буйсынып гомер сөрүчеләр, тыштан караганда бәхетле күренсәләр дә, асылда беркайчан да бәхеткә ирешә алмыйлар. «Мин»нең дөньяны җиңәргә көче җитми, ул җиңелүгә дучар була. «Тормыш ул һәрчак корабның һәлакәтенә юлыгуы кебек», — дигән Х.Ореге-и-Гассет.

Кораб һәлакәте?... 1912 елның 14 апрелендә булган фаҗига — «Титаник» дигән кораб батканны һәркем белә. Яңа төзелгән, мәһабәт, затлы лайнер айсбергка бәрелеп, бик тиз арада океан төбенә китә. Дөньяның ике меннән артык бәхетле байлары үлем исереклеге белән палубада бәргәләнә. Ничек исән калырга «Мина?» — дип куркудан, алар тәкәббер үз «Мин!»ен оныткан, һәрберсендә фәкать котылу

уе. Миллионерлар коткару көймәләрендә урын алу өчен әллә никадәр суммалар тәкъдим итәләр. Әмма капитан көймәләргә ин башта балаларны һәм хатын-кызларны утыртырга боера. Коткарырдайларга ярдәм иткәннән сон капитан житәкчелегендәге команда һәм мен ярым пассажир батып баручы корабта калалар. Музыкантлар тездән суда, оркестр соңгы мизгелгә кадәр уйный. Алар шулай һәлак булалар. «Без»ләрнең бердәм кодрәтен тантана иткән бөек гимн авазы мәңгелек канатында салкын дәрья упкыны өстеннән галәмгә аша.

Олы афәт килгәндә, котылгысыз үлемнең күзенә карап, чарасыз кызганыч «Мин»нәр әнә шулай бөек, үлемсез «Без»ләргә берләшә ала.

## 14

*9 апрель*

Акылым аек килеш мин бу ятьмәгә эләктем дә, хәзер инде үзем дә, иләсләнеп, шушы халәтемә күнегә барам кебек. Менә әле өстәл тартмасында чираттагы хатны күргәч, гүя ул бик күптәнге танышымнан, хәвефсезләнми генә алдым да укый башладым.

*«Хөрмәтле кордашым!*

*Бу арада хат язарга жаем булмады. Авырып алдым (бу урында мин үзалдыма мыскыллы елмаеп куйдым: кендекләребез береккәнмени, аның авырган вакыты да минекенә туры килә). Соңгы хатыгызны укыгач, канәгать калдым. Әлбәттә, бөтен фикерләрегез белән дә килешә алмыйм. Сез яхшылык төшенчәсен абсолют югарылыкка житкерәсез, югыйсә бит Абсолют бердәнбер Ходайга карата кулланыла торган төшенчә. Икенчедән, чынбарлыкка туры килмәгән канун үтәлә алмый. Сез әйткән Яхшылык кануннары тормышка аша алмаячак, чөнки асылда алар үле туган кануннар. Яхшылык кануннары үтәлерлек булмагач, җәмгыять тотрыксыз хәлгә килә, каршылыклар көчәя, халыкта өметсезлек уяна, иртәгесе көнгә ышаныч бетә, тормыштан канәгатьсезлек туа, бер-берен белән ярышып яшәүнең кызыгы бетә. Бу хәлдән чыгу өчен яхшылык белән яманлык арасында компромисска бару, бу ике төшенчәнең кешелек яшәешенең башлангычыннан ук туган зарурлыгын тану кирәк. Борынгы дәверләрдән үк акыл ияләренең Яхшылык һәм Яманлыкны зур хәрефтән күзаллавы бүгенге заман таләпләренә һич туры килми. Борынгы, искергән фәлсәфи реликтлар урынына тискәре һәм унай көч дигән яңа төшенчәләр кулланылырга тиеш («плюс» һәм «минус» дигән электр зарядлары кебек).*

*Шушы ике көчнең дә бердәй кирәклеген таныган чакта гына безнең яшәешебез икегә аерылудан, капма-каршы лагерьларга бүленүдән туктар иде.*

*Безгә кадәр, калерле дустым, бик күптән инде, Яманлыкның эчке асылын ачып бирүче акыл ияләре булган. Француз шагыйре Бодлер бер китабын юкка гына «Яманлык чәчәкләре» дип атамаган. Япон әдибе Акэтагава: «Кеше гомере Бодлерның бер шигырь юлына тормый», дип язган. Әгәр без фикер йөртүебездә шулай эчкерсез булсак, бихисап сәсемтәләр чыгаруыбызда «гуманизм» дигән дөньяви төшенчә үзгәрер, демократик эчталеккә якынаер иде...*

*Менә хәзер минем сезгә «син» дип дәшәсем килә. Каршы булмассыз бит? Пикассоның «Ареналагы Минотавр» дигән картинасын хәтерлисеңләр? Анда үгезләр сугыша торган аренаның уртасында авыр яралы Минотаврның, күккә карап, бүре кебек улавы сурәтләнә. Барьер аша кемдер ана кулын сузган да (аңыбызда яшәгән Яманлык төшенчәсе куркытмаган яшь егетләр, бәлки), Минотаврны кызганып, башыннан сыйпый. Шашынып котырынган тамашачыларга караганда, шушы яшь егет иманлы идеалга бер адым якынрак торадыр сыман.*

*Шулай итеп, яхшы һәм яманга, ягъни ике лагерьга бүленмәү аркасында гына жан ияләренең гомуми якынаю идеясе туарга мөмкин. Менә син*

*гомосексуалистларны куралмыйсың, кешегә дә санамыйсың — ләкин алар да кешеләр ләбаса! Алар өчен демократик илләрнең парламентлары махсус законнар кабул итә икән, бу — тормышның үз таләбеннән чыгып эшләнә (көндәлегендәге яна язган юлларыңны укыганымны сизгәнсеңдер. Элек син яшереп куя идең, ә хәзер, карыйм, көндәлеген, хәтта ачылган килеш, өстә ята. Күз йөгертеп чыгудан тыела алмадым. Гафу ит. Минем язган фикерләрем дә анда урын алган. Хәзер инде бу — безнең уртак көндәлегебез диярга дә була. Шулай бит?!)*

*Бер уйласаң мәзәк тә, син миңа ничектер чирканыбрак карыйсың шикелле. Табиблар хаста кешедән, гадәттә, чирканмыйлар бит, шуның кебек изгелек юлындагы ялкынлы вәгазьчеләргә дә әхлаксызлык нәжесенә борын җыерып карау килешми. Синең шикелле үгет-нәсихәтчеләр, изгелек сагында торучыларда чиркану хисе булу — әдәпкә туры килми, дип уйламыйсыңмы?*

*Кешелекне данлауга зур өлеш керткән бөек шәхесләр арасында гомосексуалистлар булганлыгын да онытмыйк.*

*Их, шіркін — ай, күрешеп, сөйләшергә җай чыксын гой!...*

*Хат көтеп калам.*

*Битаныш кордашың.»*

Ни көтә бу байгыш миннән — бер Ходай белә булыр. Палатама кайтып фикерләремне тупладым да ашыгып җавап язарга керештем:

*«Таныш түгел кордашым!*

*Үз-үзеннән сафлык-чисталык таләп иткән тойгы-төшенчәләр бар. Мәсәлән: мәхәббәт, вөҗдан, гаделлек, намуслылык. Тугрылык-хыянәт кушылып, ярым-ярты була алмый, вөҗдан исә ялган корымы белән, мәхәббәт исә хыянәт тәмсезлеге белән кушыла алмый. Чиста килеш — йә бар, йә юк! Игелеклелек идеалы — көндәлек яшәү кагыйдәсе түгел, халәткә карап, бөтенләй капма-каршыга үзгәрә алмый. Идеал ул — морадына житәсе җир түгел, ә кыйблага юнәлтүче. Тимер казык рәвешле рухи йолдыз. Шуңа күрә юлыңны саташтырып морадына житә алмаган өчен күгендәге юнәлеш бирүче йолдызны гаепләргә ярамый. Яшәешне камилләштерү өчен идеалларны алыштырырга түгел, ә үзеннең мәсләгенне хак юлга кертергә кирәк. Изгелек, золымлык кануннарын яңадан таркатып карау гөнаһы имансызларга хас. Фәкать шушы юл гына аларның маңгаена сугылган кара тамгадан коткара ала. «Акларга мөмкин, җәза бирмәскә мөмкин, әмма золымлыкны золымлык дип өзеп әйтергә кирәк», — дигән Достоевский. Шулай әйтүе хак түгелмени?*

*Бәхәсләшмим, бөтен адәми затларга, аермаенча, яхшы караш чын мәгънәсендә әйбәт идея. Әмма сез искә алган Минотавр золымлык символы була аламы? Аны җәлләгән егет Золымлыкның башыннан сыйпамый, ә золымлык тырнагына эләгеп, яралы хәлгә тарыган җан иясен кызганып сыйпый түгелме? Ул картинаның мәгънәсе — нәкъ менә шушында ачыла. Ә сезнең уй-фикерләрегез исә Яхшылык һәм Яманлык арасындагы чикне бетерүгә корылган. Әҗәле житкән авыру кешене кызгану — чирнең үзен түгел, ә терелә алмыйча, сүнә барган кешене кызгану.*

*«Гөнаһлы белән түгел, ә гөнаһның үзе белән көрәшергә кирәк», дигән Маһатма Ганди. Гөнаһ кылырга күнеккәннәр мондый көрәшкә чыга алмый.*

*Адәми затларның намусы-оятына бәйләнешле төшенчәләрнең беркаршылыксыз шулкадәр кире сыйфат ала баруы мине аптырашта калдыра. Бу хакта озак уйланганнан соң, бер токтамга килгәндәй булдым...*

*Мәсәлән, караклык барлык халыкларда да мәсхәрә, җинаять булып исәпләнелә. Әмма урлашуга күнеккәннәр өчен бу мәсхәрә түгел. Иренә хыянәт итүдән тәм тапкан хатын-кыз өчен бу гөнаһ, зина кылу дип саналмый. Аны гөнаһ кылу түгел, ә бозыклыгын фаш итү куркыта. Бөтенесе дә ияләшүдән тора. Тәмәке тарту,*

*хәмер эчү, наркотик куллану, азгынлык — боларга күнектенме, май кискән кебек җинел бара. Намус ызанын бер атлап чыккан кеше өчен һични оят түгел. Анын баш очында үзгә күк, аяк астында — үзгә җир. Анда барысы да рөхсәт ителә. Нишләп сон мин боларны элегрәк белмәдем икән дигән үкенү генә кала.*

*Намус ызанын атлап чыгу, чыкмыйча калуга караганда, йөз тапкыр җинелрәк. Мона көч соралмый. Хайвани инстинктына ирек кенә куй. Ә тукталып калу өчен ихтыяр көче, әхлакый тотнаклык кирәк.*

*Әхлак ул һәрчак рөхсәтсез-нисез керә торган ташландык йорт түгел. Аны үз кагыйдәсе булган гыйбадатханә белән тинләргә мөмкин. Бу храмнын ишекләре кагыйдәсен ихтыяри кабул иткән тыйнаклар өчен генә ачык. Бары тик бер генә мәртәбә намуслылык ызанын атлап чыкканнан сон, ни куркыныч булсын инде, дигәннәр анда керә алмый. Шул бер адымны атлаганнар — намусын гомерлеккә җуйганын белмиләрдер дә бәлки.*

*Чиркану ярамый, дисен син. Чиркануынны беллерү әдәпсезлеккә керә дисен (күрәсендер, үзем дә көтмәгәндә «син»гә күчә башладым). Чиркануынны ятка сиздерү-сиздермәү — этика мәсьәләсе. Бу җәһәттән караганда табиб та, вакытына карап, җирәнү тойгысы кичерергә мөмкин. Намуслары чиста, оялā белгәннәрнен дөньядагы шакшылыктан чиркануы — табигый. Синен дә шул фикеремә кушылуынны теләп калам.*

*Битаныш кордашын».*

Хатны тәмамлагач, җавабымны дөрес яздыммы дип, битаныш кордашымнын хатын алып тагын бер күз йөгертеп чыктым.

Баксам, хатнын үзәген тоткан фикерне күз унынннан төшереп калдырганмын икән. Анын уенча, гомосексуализм — гомер-гомергә җәмгыятьтә булган күренеш, шуна күрә аннан чирканырга ярамый, имеш. «Их сез!...» Туктале, тукта! Шул мизгелдә, мона кадәр уема да килмәгән бу фикер, ток суккандай, миемне сызып үтте. Әстагъфирулла! Бу чукынмыш үзе гомик түгелме сон?! Ул чакта бары да анлашыла. Нигә дип әллә нинди хәйләле дәлилләр китерә дисәм, үзенен бозыклыгын аклар өчен икән бит! Менә ни өчен Яхшылык белән Яманлыкны бер казанга салып, шакшы — шакшы түгел дип үҗәтләнә!

Элекке хатларында язылган фикерләрен дә күз алдымнан үткәрдем. Уй арты уйдан көтелмәгән хакыйкать ачыла башлады. Мин, җүләр, баш миемне бураздалап, ана лаек дәрәҗәдә җавап язам дип күпме тырыштым. Оятын кая куясың!... Кабахәт! Нинди итагать, игътибарлык... Укшыта. Җаннын болай ук та керләнеп калуын минем беркайчан да кичергәнем юк иде әле.

«Ярый, син минем белән очрашырга телисен. Мин каршы түгел. Бу мәсхәрәләвен белән миндә нинди аяусыз бүре уятканына шаһит булырсын. Минем куркыр нәрсәм юк. Максаты шикле, фигыле ят җаннар курыкса курыксын!»

Мин баягы хатымнын сонына шушындый сүзләр өстәдем: «Иртәгә 20 сәгать 30 минутта подвалнын хуҗалык ягында көтәм».

Хатны шартлы урынга алып барып куйдым. Иртәгесе көннен кичке сәгатьләре җиткәнен ашыктырып көтү халендәмен. Безгә һичшиксез күрешергә кирәк, дим, әледән-әле тәкатьсезләнеп.

Күренмәгән дошман — күренгән дошманнан яманрак.

## 15

*20 апрель*

Дәвалаучы табиб укол билгеләде. Шәфкать туташы шулкадәр телмәр булып чыкты, укол кадаганда гел быжгып торды:

— Курыкмагыз, менә хәзер була... Тәнегез буйлап кайнар дулкын йөгерер... Бер дә куркыныч түгел... тиз үтә ул.... Менә, менә...

Аның сүзләре мине тынычландыра алмады, киресенчә, бөтен тәнем калтырый башлады, тыным кысылды. Кан басымы югары сикерде, ахрысы, урындыгымнан капылт торыйм дигәндә артка авып киттем.

— Үл-лә-әм... — Карлыккан тавышым үземә дә ят иде.

Ул арада шәфкать туташы йөгереп китеп, тагын бер ак халатлы ханымны чакырып килде. Икәүләп тагын укол кададылар да, урындыкларны бер рәткә тезеп, мине шунда яткырдылар.

Ярты сәгатьләп үткәч кенә, мин ныклап аңыма килгәндәй булдым. Тәнгә көч керә башлавын сизгәч, кәефем дә күтәрелде. Куркуым хакында, үз-үземне мәзәк итеп сөйләп, шәфкать туташларын көлдерә башладым. Әмма алар минем болай дәртләнеп китүемә бик үк ышанып бетмәделәр, палатама кадәр култыклап алып килеп, урынга яткырдылар.

Төш алдыннан табиб керде. Таныш рәвеш, уклау йоткан кебек төз гәүдә, күзлек пыялалары салкын ялтырый. Башта ул пульсымны тикшерде, аннары теләр-теләмәс кенә маңгаема дымлы учын куеп торды. «Барын да беләм, шулай булырга тиеш иде, алда да шулай булачак», дигән кыяфәт белән, бер сүз дә әйтмичә, чыгып китте.

Көндезге аштан соң йокыга киткәнмен. Төш күрдем. Биек түшәмле мәһабәт бина эчендә халык ыгы-зыгы килә. Чиратка басканнар. Мин дә кушылырга телим, әмма чиратның азагын күрмим. Аптырагач, тышка чыгам, очсыз-кырыйсыз чират шәһәр кырыена житеп сузылган. Биек йорт түбәсенә менеп карагач, хәйран калам: бу чиратның кара чылбыры әллә кая, җир читенә кадәр сузылып бара да томанлы офык артына кереп югала, имеш. Нәүмиз бер өметсезлек хисе белән аска төшеп, берәүдән сорыйм: «Ничек чиратка басарга мина?» Әлеге адәм: «Бу чиратның соңына берәү дә житә алмас. Күпләр чиратын баласына, баласының баласына калдырып китә», — диде. Текәлебрәк карыйм, олы яшьтәге базык гәүдәле бу кеше таныш та кебек. Кайда, кайчан күргәнмен — хәтердә юк. «Әй, бәгырь, ташла син эзләвенне, ияр минем арттан», — диде ул. Тавышы йомшак, ышанырга була мона. Кешеләр арасыннан кысыла-кысыла үтеп, ниндидер рәсмирәк бүлмәгә килеп керәбез. Монда чират тармакланып, төрле кабинет ишекләренә килеп төртелгән. «Минем урыным шушында, — ди танышым. — Шушында утырып көт», — дип китеп барды. Урын җайлангач, куанычым эчемә сыймады. Шәп бит, мәңгелек чиратта торасы идем. Шул мәлдә башыма килде: ул кабинетның мина ни кирәге бар? Кердем ни, аннары? Нинди сорау бирерләр? Мин ни дип әйтермен?.. Бу чиратка нинди ният белән басуымны да белмим ич мин. Уңайсыз булып китте. Шул мәлдә, башымны күтәреп карасам, кабинет ишегендәге табличкада үземнең фамилиямне күреп алдым. Сәркатиб кызга: «Мин бит бу, минем исем язылган гой!» — дим. Сәркатиб кыз: «Сез булгач, керегез үзегезгә», — дип, ирен чите белән мыскыллы елмайды. Йөрәксенеп урынымнан тордым да тагын каушап калдым. Артымда чираттагы халык көч биреп тора: «Кыюрак бул, егет, бар, кер, кем булуына карап торма, кер!» Бүтән төрле тавышлар да ишетелеп куя: «Сак бул, үзенә зыян китермә». Ниһаять, мин тәвәккәллим. Ишекне ачсам... Йә Хода! Өстәл яныннан чыгып, каршыма килүче... киеренке халәттә, ап-ак чырайлы, усал карашлы... Бу — мин бит, мин! Куркудан артка чигенеп куйдым. Ул мина таба килә. Ара шундый якын. Тыны йөземә бәрелә. Күрешергә дип сузылам, каты кулы үле салкын. Мин кычкырып, үз тавышымнан шашынып уянып китәм.

Күземне ачуга, ятагым кырыенда шәфкать туташы тора. Мине уятырга теләп, кулы белән кагылган икән. Ә кулы боз кебек, яна гына крандагы салкын су белән юынган, ахрысы.

— Гафу итегез, — диде ул уңайсызланып. — Куркыттым бугай. Сезгә чәй китергән идем... Суынганчы эчеп куегыз.

— Рәхмәт, — дим, аның салкын кулын җибәрмичә.

Болгавыр төштән уянып, чынбарлыкка кайту нинди рәхәт, бар да аңлаешлы: менә, янәшәмдә шәфкать туташы, менә ул чәй китергән.

Кичкырын һава бозылды, яңгыр сибәли башлады. Кинәт көчле җил кубып, хастаханә ишегалдын бер итеп, тузгытып алды. Ә мин палатада утырам, битанышым белән күрешәсе сәгатьне дулкынланып көтәм.

Кичке аш тамактан үтмәде. Кечкенә палатамда әрле-бирле йөрендем дә коридорга, аннары ишегалдына чыктым. Яңгыр инде үтеп киткән, әрсез җил генә исә. Берьялгызым, үз-үземә пышылдап йөрим: «Көчеңне бер йодрыкка төйнә, башыңны күтәр!»

Шулай күпме вакыт үткәндер, уй-хисләремне тәртипкә китереп, тотрыклы бер халәткә кердем. Ниһаять, мин очрашуга әзер.

Сәгать тугызынчы яртыда подвалга төштем. Кирәк бит, тузган кием-салым, матрас, мебель ватыклары өелгән, тагын шундый иске-москылар саклаган хуҗалык ягында ут янмый иде. Сүндергәннәрме, әллә инде лампочкасы янып чыкканмы. Куе караңгылык. Шушы тирәдә иске урындык булырга тиеш иде, аны бу караңгыда ничек табарга — Ходай белсен. Очрашу урынын дөрес билгеләмәгәнмен. Ә бәлки ул, алдан килеп, утны махсус сүндереп куйгандыр...

Әнә бит якында гына аяк чыштырдавы ишетелә. Мин катып калдым. Стенага аркамны терәп, сагаеп тыңлыйм. Чыштырдау баягы төштән түгел, ә бөтенләй икенче яктан килә. Тагын мәзәк чыгарырга уйлыймы минем белән бу таныш түгел бәндә! Бәрелү, чыштырдау, шаку авазлары, буталып, төрле яктан ишетелә башлады.

Ахыры чыдый алмадым, сабырлыгымны сакларга тырышып, кычкырдым:

— Мин барын да белеп торам. Син монда бит! — Тавышым подвал караңгылыгында шом салып яңгырады. — Күрешүне теләгән идем. Менә мин... — «Килдем» дигәнне әйтергә тыным җитми торды, бөтен көчемне җыеп, ниһаять:

— Килдем, — дидем.

Тавышым, бетон стеналар арасында кайтавазлар белән буталып, бу кадәр көчле яңгырар дип уйламаган идем. Куркып куйдым.

Аннан соң кабер тынлыгы иңде. Бу тынлык — төрле тавышлар яңгыраудан да шомлырак иде. Кулларымны як-якка җәеп, капшанып кына караңгылыкны ерып атлыйм. Коридор чатына җиткәнемне шәйләп борылуга, янәшәмнән өрәк шәүләсе чагылып китте... Айгылдап кычкырып җибәрдем дә, куркудан, йодрыгым белән шәүләгә кизәндем. Кулым каты әйбергә килеп бәрелде дә, чатнап, чылтырап пыяла ualган тавыш чыкты.

Дөм караңгыда тезләнеп утырам менә. Мин ялгыз. Мин бәхетсез. Өрәк дип көзгедә чагылган үз шәүләм белән сугышырга калдыммы... Күземнән яшь бәреп чыкты. «И Ходаем, нигә мине газапка саласың? Минем ни гаебем бар?»

Кулымны җәрәхәтләгәнмен икән. Кан ага, сызлый башлады. Урынымнан тордым, аяк астында пыяла кисәкләре шыкырт-шыкырт килә. Стеналарга тотына-тотына килеп, подвал баскычыннан өскә күтәрелдем. Палатага керүемә, шәфкать туташы йөгереп килде. Минем кайтуымны көтеп торган ахрысы.

— Ай-вай, ни булды? — диде куркынып.

— Ишегалдында... Анда юеш, таеп егылдым, — дидем. Тавышым үземә дә ят тоелды.

— Чыраегыз ап-ак. Хәзер табибны чакырам.

— Кирәкми, — дидем көч-хәл белән. Бөтен тәнне хәлсезлек биләп алды. — Табибны мәшәкатьләмәгез. — Тирән сулап, соңгы сүземне көчкә әйттем. — Кулымдагы ярамны бәйләсәгез...

Шәфкать туташы палатадан йөгереп чыгып китте дә, бик тиз генә дежур табибны ияртеп, килеп тә җитте. Ул ярамны юып бәйләде, табиб кан басымын үлчәп, йөрәкне тыңлады, ниндидер сораулар биргәләде, әмма мин дәшмим, тәндә

хәлсез битарафлык, жаным бу ыгы-зыгылардан биеккә, бик еракка олаккан иде. Табиб кушуы буенча шәфкать туташы йомшак жиремне чәбәкләп куйды да укол энәсен батырды. Мин боларны гүя читтән битараф кына күзәтеп торам.

Алар палатадан чыгып киткән мизгелдә үк мин йокыга талганмын. Төнге сәгать унберләрдә уяндым. Йокым алай озынга сузылмаса да, тирән булган ахрысы. Кайда ятып, кайда торганымны оныткнмын. Булган вакыйгалар бераздан берәмберәм искә төшә, ачыклана башлады. Беренче уй сискәндереп килде: «Ни сәбәпле күрешергә килмәде икән?... Бәлки... Ул минем соңгы хатымны алмагандыр?»

Капылт сикереп торып, мин коридорга атылдым. Тумбочка тартмасын ачып кулымны тыксам... Нәкъ шулай булып чыкты. Хатым аның кулына төшмәгән. Ни сәбәпле ала алмады икән? Йөрәгем нык кага башлады, янәшәмдәге урындыкка барып чүмәштем. Менә бит... «Алмаган гой, алмаган...», дип борын эченнән үз-үземә дәшәм. Хәзер менә аңлашыла. Ә мин, мескен, жил тегерменнәре белән сугышып йөргән жүләр кебек газапка баткан идем...

## 16

*21 апрель*

Бүген исә, кичәге вакыйгаларны хәтер жебеннән үткәреп, үз тәртибемнең килешсез якларын ачыкладым. Беренчедән, кешенең «ярый» дигән жавабын алмаган килеш, киләме-юкмы икәнен алдан белмичә, үзең билгеләгән очрашу урынына ашыгалармы?

Икенчедән, мин бит аның каян килеп чыгуы белән дә кызыксынмадым, шушы хастаханәдәнме ул? Ә бәлки бөтенләй читтән килеп кергәндер? Чит кеше булса, аны шайтан үзе аягын сындырырлык подвалга очрашуга чакыру — үзе бер жүләрлек түгелме?... Күрәсең, язган хатлары буенча, мин аны бөтен нәрсәне белүче, теләсә кая керә алучы, теләсә кай вакытта пәйда була торган елгыр бәндә дип уйлаганмын инде.

Өченчедән, бу очрашу мина кирәк идеме соң? Ике арада кабынган акыл көрәшенә монын нигә кирәге бар? Хәер, кем белә... Бу алышның психологик ягы бар бит әле. Уеннын тәртибе фәкать анынча барды, мин исә күндәм буйсынып, анын ихтыярына жайлаштым.

Хат язышу рәвешендә фикерләшүебез, коридордагы махсус яшерен урын, минем эчке дөньяма аның басып керүче, үзе турында көне-төне уйлатып, төшемә кереп, маза бирмәүче, жанымны яралап интектерүче — боларны башлаучы — ул иде бит. Моның бер соңы булырга тиештер инде. Мина да, ниһаять, үз шартларымны куеп, аны үтәтергә мәжбүр итәргә кирәктер.

Нәкъ көн уртасында мине табиб кабул итте. Һәрвакыттагыча, ул сүзсез генә сынап карап утырды. Мин дә дәшмәдем.

Бераздан ул:

— Хәлләр ничек? — дип сорады. Дөресрәге, сорау да түгел иде ул, үтешли, битараф кына, «исәнмесез» диләр бит әле, андый чакта, гадәттә, «исәнбез әле» дигән жавап бөтенләй көтелми дә.

Урындыкка кагылган кадак кебек утырган табибка мин бер сүз дә кайтарып әйтмәдем. Күпмедер шулай тын утырганнан соң, ул:

— Барыгыз, кайтып ял итегез, — диде.

Мин палатама кайттым да, битаныш кордашнын хатларын алып, кабаттан укып чыктым. Уйлап карасаң, тәүге хат белән соңгысы арасында гүя тоташ бер гомер узган. Шул вакыт аралыгында күңелемдә нинди дер үзгәрешләр булганын тоям. Юк, мин үз мәсләгемнән һич тә баш тартмадым. Әллә каян тирәннән сызып күтәрелгән ямансу гамь борчый мине. Яхшылыкка, изгелеккә каршы көчнен тамыры болай ук тирән киткән дип уйламый идем элек.

Кешелек дөньясының омтылышы ике юнәлештә бара: беренчесе — хайвани теләгенә буйсынып, үз хаҗәтен генә кайгыртып, үз мәнфәгате өчен генә җан асраучы түбән кавем юлы; икенчесе — рухи, әхлакый югарылыкка ирешкән сирәкләр юлы. Без бүгенге көндә тормыш кызыгын ачыктан-ачык, әллә нинди ялангач алымнар белән пропагандалыйбыз, димәк, түбән кавемнәр юлы белән килешә барабыз. Гүя тормыш мәгънәсе гел хозурлыктан, кәефләнү, рәхәт-ләззәт алудан гына тора. Ләззәт — шәраб кебек. Кем инде затлы, хуш исле шәрабтан баш тартсын. Ул бит кәефенне күтәрә, тәненә йөземле кояш нуры йөгертә. «Бер генә яшәлгән кыска гомердә тагын ни кирәк?» — дигән уй бу очракта табигый да шикелле. Әмма шәраб хозуры эчендә нинди куркыныч посып ятканын да онытмыйк. Эчүгә бирешеп, үз язмышын гына түгел, якыннарыныкын да харап иткән күпме кешеләр гамәл дәфтәренә языла килә. Чамасыз ләззәт алуга корылган тормыш итү рәвеше, иртәме-соңмы, бозыклыкка, әхлакның таркалуына китерә. Туктаусыз кәеф алу тарафдарлары, комагайлар, кеше башларыннан хакимияткә үрләүчеләр, фәхешлек кылучылар, бозыклар, «йомырка пешерү өчен күрше йортын яндыручылар» — болар бар да тотнаксызлык үрнәген сурәтләүче галереяны тәшкил итә. Шунысы кызганыч, кешеләрнең күпчелеге бу явызлыкның утлы лава кебек тарала баруын күрми яисә күрмәмешкә салыша. Мона хәтта каршы тору нияте дә юк, фидакарьләрчә көрәш хакында әйтеп тә тормыйм. Шуңа күрә хәтәр дошманның исеме аталмый, төсе ачыкланмый, яшәү урыны күрсәтелми...

Намусыңны салып таптап, нәфеслектә, комагайлыкта, көнчелектә чама, канәгатьләнү белмичә исерү, йөгәнсез, иләс тормыш бу. Әйе, иләс тормыш! Башкача атау мөмкин түгел.

Минем битаныш кордашым да бөтен чикләрне үтеп чыккан. Яхшылык барына ышанмау, битараф булу — золымлыкка ирек кую дигән сүз; моның белән әле аңлашырга, уртак тел табарга мөмкин. Ләкин золымлык белән ачыктан-ачык килешү, аңа ызандаш булу — бусы инде дошманлыкның килешеп булмаслык авыр төре.

Минем таныш түгел кордашым Яманлыкны яклап кына калмый, ул аны дәртләндерә, максатка әверелдерә, табына, үз инанганын кешеләргә тарата. Моннан да куркыныч ни бар тагын?!

Явызлыкны, үтерешне, кара көчләрне шигырьгә салган Бодлерны укуы белән мактана. «Кеше гомере Бодлерның бер юлына тормый», имеш. Бу фикер белән нинди бөек шәхес әйтүенә карамастан, килешүе авыр. Ә Бодлер турында мактап та, сүгеп тә язганнарны укыганым хәтердә, әмма үз китабы кулыма кергәне булмады.

Төштән соң, ишегалдына һава суларга дип чыгышлый, китапханәгә сугылдым. Идәннән түшәмгә кадәр китаплы киштәләр тезелгән зур гына бүлмә. Тәрәзәләре кояш якка караган, эсселек бәреп тора, җитмәсә, буяу исе борынны ярып керә, каядыр янәшә бүлмәдә ремонт бара ахрысы. Китапханәче кореялы кыз эсселектән изрәгән бугай, кешеләргә борылып карамыйча гына, турсаеп, сорауларга теләр-теләмәс кенә җавап бирә.

Мин өстәлгә таратылган газет өемнәрен актаргалап, рәсемнәренә, мәкалә исемнәренә күз төшереп алгаладым. Шул саран гына сүзләрдән дә сизелеп тора: дәүләт чәчәк ата... Күрелмәгән җиңүләр... Вакытлы каршылыклар... Чит илләге вакыйгалар... Тәкатьсез калдыра торган белдерүләргә, сискәндерә торган хроникаларга күз дә салмадым, гөнаһлы корымы йогар да, ялган юшкынын юып та бетерә алмассың.

Бераздан, газеталардан башымны күтәреп, китапханәче кыздан:

— Сездә Бодлерның шигырь китабы юкмы? — дип сорадым.

Төксе генә карап торды да, робот-автомат сыман җавап бирде:

— Бар. Хәзерге вакытта кулда, — дип картотека әрҗәсендә актарына башлады. — Тапшырасы вакыты үтеп киткән. Китап унынчы палатада, — диде, үзалдына сөйләнгәндәй итеп.

Мин сискәнеп киттем.

— Ничәнче палатада? — дип сорадым тотлыга язып.

— Унынчы, — дип китапханәче кыз, миңа гаҗәпләнеп карап куйды.

— Ничек алай? — дидем тыныма кабып. — Унынчы... ул минем палата гой. Мин берүзем генә. Андый китапны алганым да, күргәнем дә юк.

Барып, китапханәче кызның кулыннан карточканы тартып алдым да... карыйм, берни күрмим: «Нәрсә бу? Болай булганы юк иде. Берни күрмим, — дип борын астыннан мыгырданам. — Нишлим? Күзләрем күрми...» Шул мәлдә хәтәр бәла килгәнен чамалыйм, әмма аңлап бетерә алмыйм.

— Ни булды сезгә? — дигән курыкынган тавыш ишетәм. — Хәлегез авырайдымы әллә?.. Хәзер табиб чакыртам. Утырып торыгыз. Кузгалмагыз...

«Нигә кузгалмаска, — дим эчтән аптырап, — кузгалсам ни була?»

Яныма кешеләр җыелганын сизәм. Шәфкать туташының тавышын таныйм: «Башыгыз әйләнмиме? Йөрәгегез ничек? «Юк, юк» диюдән ары берни дә әйтә алмый утырам, чөнки үз хәлемне үзем дә тоймыйм.

Инемнән кочып, шәфкать туташы палатага алып керде, урынга җайлап яткырды. Шул арада табиб килеп керде. Нәрсә булганын сораштыра башлады. Теләмичә генә, ничек кирәк алай сөйләгән сыман иттем:

— Мин ул китапны алганым юк, — дим, чарасыз калып. — Ант итеп әйтәм, күргәнем юк ул китапны. — Гүя шуны дәлилләсәм, бар да элекке хәлгә кайтыр кебек.

Табиб нидер төшенгән сыман булды, шәфкать туташына күрсәтмәләр бирде дә ашыгып чыгып китте. Ниндидер таблеткалар йоттыргач, тынычлана башладым шикелле, калтырау гына, өшеткеч дулкын булып, бөтен тәнгә тарала. Кичке ашка да кагыла алмадым. Укол кадагач, тирән йокыга талганмын.

## 17

*22 апрель*

Төш житкәндә генә уяндым. Әбәтне палатама китерделәр. Йокы исереклегеннән тәмам айнып, каты-каты басып йөренеп, юынып алгач, ризыктан авыз иттем. Кичәге вакыйгалар хәтерне кузгатты, тагын дулкынлана башладым. Ул арада шәфкать туташы килеп, мине табибка алып китте. Табиб фәкать мине генә көткән шикелле өстәл янында ялгызы утыра иде. Мин кергәч тә әле, өстәлгә бармаклары белән барабан кагып, шактый утыргач кына телгә килде:

— Сезнең белән ачыктан-ачык сөйләшәсем килә. Әгәр сез әзер булсагыз, — диде, якын кешемнең бәлагә таруын хәбәр итәргә теләгән шикелле, чыраен сытып.

— Әзер булу өчен мин нишләргә тиеш? — дидем, соравын аңышып бетермичә. Табиб мондый сорауны көтмәгән иде, башын иеп, бераз уйланып утырды да, кинәт кенә калкынып:

— Алай булгач, әңгәмәне сез башлагыз, — диде күзлек өстеннән карап. — Миңа әйтәсе нинди сүзегез бар?

— Бар, — дидем мин, кинәт кенә, үз сүземнән үзем курыккандай, кабаланып, әйтеп калырга ашыктым. — Хастаханәгә эләккәннән бирле мин ниндидер таныш түгел бәндәдән хат алам.

— Каушамагыз, — диде табиб, беренче тапкыр елмаеп карап. — Тартасыгыз

килмиме? — дип алдындагы сигарет кабын мина таба шудырды. Мин баш селкедем:

— Юк, рәхмәт... Әйтәсе килгәнем шул: теге хат иясен, күпме тырышсам да, һич белә алмадым. Ул миннән качып йөри. Соңгы арада бөтенләй оятсызланды, хатларын палатама ук ташлап китә. Бусы әле бер хәл, иң аяныччысы — биленә шартлаткыч бәйләгән террорист кебек, ул үзенең хәтәр идеяләре белән бик куркыныч кеше. Андый идеяләр үләт кебек, бик тиз тарала. Чөнки аның тарафдарлары рәтле яшәү җаваплылыгыннан гайре хайвани иркенлекне тормыш шарты итеп нигезләп, шуны гавамга таратачаклар. Миллион гомерләрне харап иткән чума-үләт чире дә бит конкрет бер кешенең авыруыннан башлана. Шуның кебек, бер адәмзатның башында оялаган идея алдагы көндә бөтен кешелек дөньясына фаҗига китермәс дип кем ышандыра ала?! Менә шуна күрә, хат язучыны кичекмәстән табарга кирәк. Ана каршы торырга минем дәлилләрем җитәрлек. Ләкин ул очрашудан тайчынып йөри. Иң соңгысы — бер хатында ул золымлык җырчысы буларак танылган француз шагыйре Бодлерның җыентыгын укып ятам, дип язган иде... Кичә китапханәгә керсәм... ул китап унынчы палатада, диләр... «Унынчы» — минем палата... Ул китапны күргәнем дә юк, мин алмадым... — Еш-еш сулыш алып, тагын дулкынлана башладым. Әмма уйлаганымны ничек тә менә хәзер әйтеп калырга кирәк иде. — Нәрсә әйтим, ул кеше, бик елдам булса да, бу нәрсәләрне берүзе генә башкармый, ана кемдер ярдәм итә. — Мин башымны күтәреп, табибның күзләренә туры карадым. — Әйтегез дөресен, сезнең моңа катнашыгыз бармы?

Кабинетта үле тынлык урнашты. Табиб, башын иеп, үз эченә йомылып, бармаклары белән өстәлне тукылдатып, күпмедер утырганнан соң, капылт:

— Бар... — диде.

Урындыгымнан сикереп тордым. Телем бәйләнде, әйтеләсе сүзләр, уй хәлендә калып, башымда буталды. Сулыш җитмәгәндәй, авызымны бер ачам, бер ябам.

Аның караве, күзлекле табиб-казакъ тыныч иде, серле елмаеп, мина утырырга ишарә ясады. Анардан күземне алмыйча урындыкка чүмәштем.

— Сезнең баштан үткән хәлләрнең барын да беләм мин, — дип тыныч кына башлады ул сүзен. — Хәзер мине игътибар белән тыңлагыз. Фикеремне ерактан алып башлыйм. Медицинада кеше психикасы иң серле, иң катлаулы өлкә. Анда әле бик күп ачышлар ясалмаган. Шуна күрә бу өлкәдә асыл фәнгә караганда мистика күбрәк. Мәсәлән, шәхеснең икегә бүленүе күренешен алыйк. Мин сезгә элегрәк бу хакта әйтеп үткән идем. Фәннең әлеге өлкәдә тулы аныкламасын таба алганы юк. Гаҗәп бит, бер үк кешедә бөтенләй капма-каршы «ике мин», ягъни ике субъект барлыкка килә. — Табиб, аңлыймы бу, юкмы дигәндәй, күзлек пыяласы аша мина үткен карашын төбәде:

— Менә сезгә психиатрия тарихында күптән билгеле берничә мисал китерәм. 1887 елның гыйнвар аенда урта яшьләрдәге бер ир кеше Американың Норристаун шәһәренә килә. Үзен Браун дип таныштыра. Чиркәүгә вакытында йөри. Сату итә. Әледән-әле Филадельфиягә тауар алырга бара. Ачык күңелле, тыныч холыклы бу кеше тиз арада шәһәр халкының хөрмәтен казана.

Ләкин март башында, бердәнбер көнне, танышларына ул үзен, канцелярия тауарлары сатучы мистер Браун дип түгел, ә Грин каласыннан килгән рухани, чиркәүдә хезмәт итүче Берн дип бәян итә. Әлбәттә, моңа күпләр шикләнеп карыйлар. Ә ул, бичара, ялынып-ялварып, ышандырырга тырыша. Озак та үтми, шәһәргә хәбәрсез югалган иренең — мистер Браунның ниндидер юллар белән эзенә төшкән хатыны килеп төшә. Шулай итеп, аның чынлап та рухани Берн икәне раслана. Хатыны ирне үзе белән

алып китә. Бу тарихның дәвамы да бар, әмма анысы безнең өчен әһәмиятле түгел. Монда иң мөһиме, — дип, сүзеннән туктап, табиб сигарет кабызды, кәнәфигә җәелебрәк утырды, аерым якын кешесенә генә әйткән кебек, уйланып, сүзен ялгап алып китте. — Бу мәсьәләнең социаль тамырлары тирәнгә яшеренгән дип уйлыйм. Медицинада патология дип бәяләнсә дә, моңа охшаш очраклар менә дигән сәламәт кеше белән дә булырга мөмкин. Үзенең табигатенә, холык-фигыленә ят эш майтарып ташлаган кеше, үз-үзен битәрләп яисә үкенеп: «шайтан аздырды», «җен котыртты», «пәрие килде», дип әйтә бит әле... Бу — чынлап та эчке хакимлегеңнең вакытлыча икенче «мин» кулына күчеп алуы. Дөресен әйткәндә, без барыбыз да икегә аерымланган шәхесләр. Безнең «мин»нәр алышынуы һәр адымыбызда сагалап тора. Мисалга, без «әйе» диясе урынга, күрә торып, «юк» дибез. Күрәлмасак та, «яратам» дибез. Түрәләрнең шикле башлангычларын, эчтән бөртек тә ышанмаган килеш, хуплап чыгабыз.

Шушы очраклы мисаллар гына да кешенең икейөзлелеген раслый түгелме? Әйтик, шундый әдәпле, ягымлы кеше баеп китеп, хакими урынны биләп алуга ирешә дә, бөтенләй үзгәреп китә, үзеннән түбәнрәкләргә карата ул тәкәббер, тупас, ә инде үзеннән югарыракларга карата кушканны карусыз үтәүче мыштымга әверелә. Моны икейөзлелек яисә икегә аерымлану дип атыйсыңмы — барыбер, асылы үзгәрми.

Табиб бу сүзләрне чирканган кебек әйтеп, көллеккә сигаретын какты, аннары, онытылып торып, әле генә искәргәндәй, миңа күз төшерде:

— Толстойның «Мәҗлестән соң» дигән хикәясен хәтерлисеңме? Полковник турында әйтәм, кичен мәҗлестә нинди нәзакатьле кавалер, затлы мөгамәләсе белән күпме ханымнарны биһуш итә, ә иртән, плацта, солдатны җәзага тарту мәрәкәсендә ул — канга сусаган ерткыч, коточкыч башкисәр. Менә бу — икейөзлелеккә мисал түгелмени?!

Шул мәлдә мин, түземлегем бетеп, табибны бүлдердем:

— Ярый, әйткәннәрегез белән килештем дә ди. Ә минем «хәлгә» боларның ни катышы бар?

— Мин болай озак итеп, сезгә кызык булсын өченгә сөйләмим. Сез ай буена хат алышкан таныш түгел кеше әллә кайда яшеренеп йөрми. Ул — кальбегездә. Ул — сез үзегез бит!

— Ничек алай? — дип урындыгымнан сикереп торуга, иңемә кулын куеп, табиб кире дән утыртты.

— Шулай, — диде табиб тыныч кына. — Өч-дүрт көн аралыгында сез иртән — бөтенләй икенче зат, әйтик, битаныш кордашыгыз булып уянасыз. Менә хәзер минем каршыда утырган сездән ул күпкә эчкерсезрәк, җиңел аралаша белә. Ул үзенең нинди хәлдә икәнен дә, диагнозын да яхшы белә. Сезнең белән хат язышуны да үзе уйлап тапты. Шулай итеп, сез үзегезнең элгәргегезне онытып, ул хатларны үзегезгә үзегез яздыгыз. Дәвалау барышына кире тәэсире булыр дип, без моны сиңа әйтүдән курыктык. Комачау итмәдек, читтән генә күзәтергә булдык. Хәзер инде менә упкын читенә килеп җиттек. Чигенергә дә соң. Безгә дә, үзегезгә дә хәзер фәкать үзегез генә ярдәм итә аласыз. Сезнең акыл, ихтыяр көче...

Кинәт, бөтен тәнне калтыратып, йөрәгемә көчле ташкын убыла башлады. Бөтенесе дә ташлар астында калып сытылды, пычракка батты. Ничек тә сынмаска, сыгылмаска дип эчемнән ялварам. Әмма теге афәтле идеяләр минем үземнән чыккан икәнлеге искә төшеп, чаң кага да, мин өметсез сыгылып төшәм.

Һуштан язганымны анга килгәч кенә белдем.

Әчкелтем ис яндырып борынга керде — борын астына куелган нашатырь исеннән айный башладым.

— Тәрәзәне ачыгыз! — дип әмер бирде табиб, үзе учы белән яңакларымны чәбәкли башлады.

Инде тәмам исемә килгәч, шәфкать туташы мине палатама озатып куйды. Булып узган вакыйгалар саташулы төш кебек хәтеремнән узды. Ул арада табиб күренде. Минем диагнозны ачыктан-ачык әйтүе авыр булганлыгы, хәзер инде иң хәтәр мизгел үткәч, гипноз ярдәмендә дәвалап карарга ниятләве хакында һәм тагынниләрдер сөйләде. Мин исә игътибарымны җәлеп итеп тыңлый да алмыйм, гүя ул боларны бөтенләй икенче кешегә сөйли. Инде шул мәлдә хат язучы битаныш адәмнең үзенчәлеге турында, аның, гадәттә, миндә иртәнге якта уянуын әйткәндә, мин куркудан сулышыма буылдым.

— Кайчан... тагын пәйда булачак? — дип тынымны куырып, чак әйтә алдым.

— Бүген дүртенче көнгә чыктык бугай, — диде табиб, уйчан күзләрен төбәп. — Әйе, иртәгә иртән, димәк...

Менә шундый курку иңде... Дөньяны тетрәтеп, «А-аа-аа!» дип инрәп кычкырырга, бер бушанырга иде. Сулышым кысылган, өнем юк. Акылга сыйдырырлык түгел, иртәгә, таң белән, имеш, менә шушы ятакта мин түгел, ә ниндидер әдәпсез, минем төмсә холкымнан аермалы буларак, тиз аралашучан, чиркангыч «битаныш кордаш» уяначак монда. Моңа ничек ышанырга мөмкин?!

Инде йокы сәгате суккач, палатага аутотренинг алып баручы чибәр табибә килеп керде. Ул бүген төнлә кизү торачак икән. Бүтән вакытта килсә, нинди куанган булыр идем, хәзер исә аны күрү теләгем дә, дәрманым да юк иде. Ул да элеккечә түгел. Ягымлы, назлы, чибәркәй урынында күпне күргән ят карашлы, кырыс хатын-кыз басып тора.

— Сезнең белән ни булганын без барыбыз да белә идек, — дип гаепле сыман башлады ул сүзен. — Хәлегезне тулысынча ачыклар өчен, көндәлек белән дә танышырга туры килде...

— Ә кем ул — «без барыбыз да»? — дип сорап куйдым, сагаеп кына.

— Без — монда эшләүчеләр. Табиблардан башлап шәфкать туташларына кадәр бар нәрсәдән дә хәбәрдар булырга тиешбез.

— Күзаллыйм, көчек белән тәҗрибәләр үткәрү — кызыктыр ул.

— Сезнең җан сызлавын аңлыйм, хәлегезгә керәм, — дип башлады табибә моңсу карашын төбәп. — Ә шулай да... Көндәлек дәфтәрегез белән танышу минем гомеремдә иң якты, иң мәгънәле көннәр булып калыр. Әйе, аварга торган бик борынгы, мәһабәт сарай дивары кебек, җир йөзендә затлылык, гүзәллекләр искергән инде. Аны аударудан сезнең шикелле азамат ирләр саклап кала алыр иде дә... Ялгыз, ялгыз булмый шул... Сезнең кебекләр... бәлки әле нәкъ сезнең аркада мин рухи дөньябызның җазибәле матурлыгын тоеп калганмындыр. Мин сездә әүлия сыйфатлары бар дип саныйм. Чиста җанлы сез. Мин сезгә ышандым. Нишлисең, дөньябызда изгелек инде аномалия санала. Кешенең изгелеге — гариплек түгел, мутантлар тууы ишәйгән заманда бигрәк тә табигый.

Мин табибәнең сүзләрен бик ирелеп тыңламадым. Уем — теге көндә, өнсез генә, күңел ымы белән сөйләшүебезне хәтерләүдә иде.

— Сез миңа ошыйсыз. Бүгенге сез түгел, ә элеккеге — энҗе тешләрен күрсәтеп елмаючы фея, — дим үпкәмне белдереп. — Иң авыр минутымда килдегез дә, күңел ымы белән сөйләштереп, мине коткарып калдыгыз. Хәзер сез

бөтенләй бүтән. Акыллы, белемле, житди. Ә мин сезнең өчен фәнни тәжрибәләр объекты. Сез мине рәнжетәсез... Бу — сез түгел... Ул юк инде.

— Ул кеше минем жан сараемда, — диде ул кайнар пышылдап, күкрәгенә учын куйды.

Үткәндәге сыман өнсез генә сөйләшәсе килеп, күз карашы белән аңа дәштем: «Мин аны сагынам».

Ул «ишетмәде». Гүя безнең күнел ымын гомерлеккә оныткан.

«Мин аны мәнге сагынырмын!» — дип кычкырдым мин уемда гына.

Ул тагын «ишетмәде». Башымны иеп, тын гына утырдым. Табибәнең бераз карлыккан, ят тавышы мине тыңларга мәжбүр итте:

— Без барыбыз да өрәкләргә әйләнгәнбез. Сабый чактан бирелгән фәрештәгә тиң чисталыкны, сафлыкны беркем дә саклый алмый. Фауст шикелле, шайтанга намусын, сафлыгын саткан миллионнарның берсе без. Сирәк кенә безнең күнел бишегендә сабый сафлыгының инәлеп елавы ишетелгәләп ала. Әмма йөрәкне кысып булса да танырга кирәк: аңа бу бозык, шакшы дөньялыкта урын табылмаячак.

— Йә Хода!

— Шулай, әүлиям. — Тавышы калтырап куюыннан сискәнеп, башымны күтәреп карасам, күз яшьләре яңагыннан тамып төште.

— Йә Хода... — Гүя мин янгырлы томан эчендә калдым.

Ул, урыныннан күтәрелеп, әйле-шәйле торды да, актык сүзен әйтергә кыенсынгандай, ашыгып палатадан чыгып китте.

Ул киткәч, нишләргә белмәдем. Тар палатамда арлы-бирле йөренәм. Ишек янындагы көзгедә чагылышымны күрдем дә... күптән инде көзгегә караганым булмаган икән. Күз төпләре шешенгән, ике каш арасында тирән сызык пәйда булган. Кинәт «дерт» итеп киттем, көзгенең теге ягыннан миңа кемдер төбәлгән кебек. Йөрәгем кысылды. Тизрәк көзгене әйләндереп куйдым.

Утны сүндерергә курыктым. Караңгыда калсам, кемдер шушы тар дөньяма хужа булып: «Инде минем чират житте!» дип кычкырыр кебек. Табибның: «Иртәгә сез башка кеше булып уяначаксыз», дигәне колагымда кабат янгырап куйгандай булды. Димәк, иртән монда мин түгел, мине изгән, мине түбәнсеткән бәндә тән-вөжүдемдә уяначак.

«Юк! — дип кычкырам. — Юк! Юк! Һичкайчан да...»

Тирән сулыш алып, бераздан тынычландым. Тумбочкадан чиста сөлге, мунчала, сабын алып, коридорның аргы башындагы ванна бүлмәсенә киттем. Менә шулай, барысы да гади генә булырга тиеш. Гади дә, аңлаешлы да. Сабын, сөлге, мунчала. Ваннаны яхшылап чайкатырга кирәк. Ялтырап торсын. Менә шулай...

Тәнемне ышкып, рәхәтләнеп юынганнан соң, суын жибәреп, ваннаны тагын чистартып алдым. Кайнарлыгын чамалап, янадан су тутыра башладым.

Палатама кереп, сакал-мыекка тимәгән өр-яңа бритваны алып чыктым. Күнелдә беркемгә рәнжү дә, кинә дә юк. Уйлаганымны тизрәк гамәлгә ашырырга дигән нәүмиз теләк кенә бар. Хәзер менә, ваннага кереп утырасы да, беләзек турыннан кан тамырын бритва белән сызып жибәрәсе дә... Сызлавы сизелмәсен өчен су никадәр кайнар булса, шулкадәр әйбәтрәк. Аннары... талгын йокы дингезенә этелеп, әкрен генә ойый-ойый, сүнә барасың, сүнә барасың... Кан төсен күрмәс өчен, күз кабакларын чытырдатып йомасың да... Бераз гына түзсән, бөтен дөньяны каралтырга адарынган битаныш туганым, син дә алсу шәфәкъка манылып, бер дә уяна алмаслык мәнгелек йокыга талырсың. Чарасыз, синең харам үлемеңне уртаклашам. Тәкъдирдән һичкем качып котыла алмый шул...

***

Хыялым бар минем,
Шундый хыялым бар үзенчә;
Яхшылык явып,
Бөтен дөньяны сил итсә,
Явызлыкның, яманлыкның барын
Колачлап алып китәм кирәксә.
Кешелекнең бөтен гаебен
Аркалап алып,
Газабын үзем кичерер идем.
Яманлык баскан дөньямны
Яндырасы, туңдырасы, тәмугка
Барысын жыеп төкерер идем.

Бөтендөнья яманлыкларын
Салыгыз ингә, күтәрәмен!
Бурычым итеп, үтәргә әзер мин:
Явызлык әгәр минем белән бергә үлсә,
Бүген үк үләргә әзермен.

Соңгы аманәт: каберем авызын
Тигезләп япкачтын,
Яманлык эзләп, исәннәр бакмасын.
Яманлык мәете яткан зиратның
Капкасын һичкем килеп какмасын!

***

Көндәлек шушылай акын М.Макатаевның күнелгә авыр тәэсир итә торган шигырь юллары белән тәмамлана.

...Беркайчан да үз иманына каршы бармый торган, ялгыз-яклаучысыз бу шәхеснең алдагы язмышы хакында берни дә белмим. Әгәр ул бүгенге көндә дә исән икән, кыйбласын җуймасын, изгелек юлыннан тайпыла күрмәсен. Адәм баласының сүнеп барган ятим өметен тергезә белгән әүлия җан кайда йөрсә дә, аман йөрсен.

Әгәр инде бу дөньяда юк икән, анда... әмәле күпме, иманлы рухы сау булсын.

Амин!...

*Астана, 2002 ел*

*Казакъчадан* **Марсель ГАЛИЕВ** *тәрҗемәсе.*

**Али ЖУШКУН,**
*төрек шагыйре*

## Минем Дөньямда юк инде җирең[1]

Биргән вәгъдәләр кай җирдә калды?
Юкка көтәсең — ышанмам сиңа.
Ялган сүзләрдән күңел кырылды,
Юк инде жирең минем Дөньямда.

Бөреләнүгә безнең сөюләр,
Миндәге рәсмең күчте ят кулга.
Бәхетле көннәр узганда калды,
Юк инде жирең минем Дөньямда.

Безнең сөйләшер ниебез калды?—
Сиңа сөйләрлек юк инде сүзем.
Хыяллар жирен чынбарлык алды,
Минем Дөньямда юк инде жирең.

*Р.Рахман тәрҗемәсе*

**Сабир РӨСТӘМХАНЛЫ,**
*азәрбайҗан шагыйре*

## Ватандарлар үлми

Житкәннән соң билгеле бер чиккә,
Төшеп калам гомер атыннан,
Үлчәп куй син миңа, туган жирем,
Өч аршын жир — авыл артыннан.

Аерылмас өчен туган жирдән!
Бу өметем көлке кебек тә,
Ышанычның көче калмас иде,
Сүнсә әгәр шушы өмет тә.

Аз да, күп тә түгел — өч аршын жир,
Якты, жылы булыр түбәндә.
Туган авыл, нәкъ элекке кебек,
Гөрләп торса минем түбәмдә.

Иркәләсә мине әнкәм теле,
Чишмәм суы торса табында,
Болыннарда инеш дулкынланса,
Кайтачакмын, димәк, тагын да.

[1] жирең — урының

Елармын мин бишек жырларыннан,
Еллар узар, ә жыр йокламас.
Нәселемдә мин әллә кем түгел —
Мин үлгәннән нәсел туктамас!

Туйлар гөрләр тауда — авылларда,
Дәвам итәр нәсел минем дә.
Чөнки Ватан тарихлардан зуррак,
Ватандарлар үлми илемдә.

Миңа дигән гомер йолдыз кебек
Сүнсә әгәр, мин ул чагында
Терелермен бодай бөртегедәй,
Туган җирем, синдә тагын да!

*Р.Миңнуллин тәрҗемәсе*

**Әхмәт СОЗАЕВ,**
*балкар шагыйре*

## Шигырьчегә

Гөл тамырын
сугарырлык булмаса,
ялагай телен
тешләтерлек булмаса,
сүзең юлга хәстәрләмә,
чыгарма —
өйрән чыдарга!

Таң нурына
җыр өстәрлек булмаса,
йә бәладән
бер искәртү булмаса,
сүзең юлга хәстәрләмә,
чыгарма —
өйрән чыдарга!

Бөркетләргә
көч бирердәй булмаса,
үч йодрыгын
ачтырырдай булмаса,
сүзең юлга хәстәрләмә,
чыгарма —
өйрән чыдарга!

*Р.Харис тәрҗемәсе*

**Тамара ГАНИЕВА,**
*башкорт шагыйрәсе*

## Төн

Күксел тауга таба якынлашкач,
Бурлат кызыл булды ак Кояш.
— Куеныма чум да, — диде Кыя, —
Җангынамны җылыт, карендәш.

Омтылганы — Кояш.
Һаваланып,
Кире үрли язгы күкләргә.
— Таң атканчы гына, — диде күк Тау, —
Сыенышып яллар итәргә.

Төн куены белән Тау куены
Ике ялгызакны иш иткән.
Тәкәбберләр ничек кавышсын, дип
Әйтүләре юкка, буш икән.

Уйлама да икән, бу гомерләр
Табыштырмас диеп, юк җирдән.
Ялгызлыктан өшеп кайчакта мин,
Үз-үземнән учак тергезәм.

Кояш белән Тауда эшләре юк,
Ойый галәм җирдә изерәп.
— Бүген төнлә көт, — дип пышылдаган
Берәүнең мин куркам килереннән,
Килмәсеннән куркам бигрәк.

*Г.Бәйрәмова тәрҗемәсе*

**Диләвәр ОСМАНОВ,**
*кырымтатар шагыйре*

## Туган телем

Туган телем — бәгърем минем,
Кара көнемдә терәгем.
Корбан сина җаным, гомрем,
Анам теле — син йөрәгем.

Туган телем — туган нигез,
Саклап калдың читтә мине.
Анам теле — халкым теле,
Рәнҗеттермәм, җаным, сине.

Анам теле — тау һавасы,
Чүл чәчәге, дингез яры...
Туган телем — таң йокысы...
Көн туганда, кошлар җыры.

Иң мөкатдәс сазым, сине
Дөньяларга алыштырмам.
Туган телем, соңгы тыным
Ватанымда — Кырымымда
Алсам иде, дип ялварам!



Әмирҗан
Моталлапов

# ГАМЬ

РОМАН

***

...Бу көннәрдә Хәлимәнең күзе йокы күрми. Икмәк өчен көрәш сугышчан бурыч итеп куелганлыктан, авылда берәүгә дә тынгылык юк. Аланбашта ашлык суктыру байтактан ике сменада алып барыла. Ындыр табагында көнозын колхозчылар бил бөксә, төнгелеккә хуҗалык активы һәм интеллигенция вәкилләре тырма-сәнәккә тотына.

Ике сменалы эшкә аланбашлылар районда беренчеләрдән булып күчте. Аларның башлангычын район газетасы күтәрде. Хуҗалык җитәкчесе Һашимова белән үткәрелгән әңгәмә бирелде. Аның авызыннан: «Җиңүне якынайту өчен без дә фронттагыча аяусызлык күрсәтеп эшләргә тиешбез. Шул максаттан без ашлык суктыруны ике сменада оештырдык. Суктырылган барлык ашлык дәүләт амбарларына озатыла», — дигән сүзләрне әйттерделәр.

Вәгъдә бирү дип атала бу. Хәлсез иңнәргә тагын бер өстәмә йөк күтәрү. Райкомның беренче секретаре Әхмәт Хәмзин Аланбашта эшнең барышына шәхсән үзе күзәтчелек итә: һәр иртә телефон элемтәсенә керә, ике көнгә бер тапкыр авылдан урап китә.

— Мир алдында сүз биргәч, сынатмаска кирәк. Сезнең күрсәткечләр башкаларныкыннан өстен булырга тиеш, — дип кисәтеп кенә тора.

«Үзем теләп әйткән сүз түгел, миңа әйттерделәр», — дип аклана алмый инде Хәлимә. «Әйттерүнең» кем кушуы буенча икәнен яхшы аңлый хатын. Беренченең таләбеннән башка мондый башлангычларга алынмыйлар, билгеле. Хәзер артка чигенергә чама юк, җигелергә генә кала...

Кичә яңгыр сибәләп үткән иде, бүген көн аяз торды. Шушы килештән көннәр утырып китмәс микән дигән ышаныч та уянган иде, әмма кояш баеганда болытлар куера төште. Язмышы җиргә бәйләнгән халыкның күңеленә тагын төер утырды. Кәефе кырыкка үзгәргән көйсез килен шикелле тотанаксызга әйләнгән табигатьне күпләр чын-чынлап каһәрләделәр. Кытлык өстенә кытлык китерүеннән хәвефләнеп борчылдылар...

Бәндәләрнең ялварулы өметенә теләктәшлек күрсәтергә омтылгандай, караңгы төшеп килгәндә табигать үз торышын кинәт үзгәртергә кереште: җил

*Дәвамы. Башы узган санда*

күтәрелде, тау-тау болытларны өере белән офык артына куып томырыкларга керешге. Төн уртасында болытлардан арынган күк йөзендә күптән күренмәгән ай пәйда булды, берсеннән-берсе уздырып йолдызлар җемелди башлады. Иртән чык төшәсен хәбәр итеп, уйсулыклар өстенә томан җәймәсе эленде...

Иртәгә көннең аяз булачагына шикләнергә урын калмады. «Безнең хәлне аңлавың өчен мең-мең рәхмәт, Ходаем!» — дип, ике кулын югары күтәреп, ихлас сөенечен белдерми кала алмады Хәлимә. Төнге ашлык сугучылар янында арып-талып кайтып килеше иде аның...

...Ул Тимерһади исемле малай белән бергә уйнап, бергә укып үсте. Җиденчене дә бергә тәмамладылар. Тимерһади мәктәптән соң ук тракторчылар курсына укырга керде, механизатор булды.

Хәлимә белән Тимерһади арасында кечкенәдән урнашкан дуслык, еллар узу белән, олы мәхәббәткә әверелде. Унсигез яшькә аяк басу белән алар парлы тормыш корып җибәрделәр. Бер елдан малайлары туды. Ана Хантимер исеме куштылар.

Тимерһадиның зарланып, сыкранып йөри торган гадәте булмады. Күз алдында сызып, йөзенә көзге яфрак төсмере керсә дә, хәленең мөшкеллеген яшерергә тырышты. Хәлимәнең йөрәге барыбер сизенде, иренең хәлен тоемлады. Табибларга күренүдән күрәләтә баш тартса да, Тимерһадины хастаханәгә алып барды хатын. Табибларның хөкеме катгый иде: ир төзәлмәс чиргә тарыган, яшәү көннәре санаулы гына калган.

Ир соңгы чиләсенә килеп терәлде. Болай да чандыр гәүдә кыртыш таягы шикелле какланды. Тынын да көч-хәл белән генә ала Тимерһади, кан төкерә. Алдагы көннәренең санаулы икәнлеген үзе дә чамалый, терелеренә өмет юклыгын аңлый...

...Тимерһади авылның беренче гармунчысы иде. Ундүрт телле тальянда йөрәкләрне җилкетерлек, моңсызларның күңелендә дә тирән хис уятырлык итеп уйный иде. Авыл кичәләре, туй мәҗлесләре аның катнашыннан башка үтмәде. Өйләнгәч кенә гармуннан бизә төште, тракторда эшләгәндә тальянын кулына сирәк алды. Соңгы вакытта аның барын-югын онытты.

— Гармуныңны бер сыздырсаң, өйгә ямь керер, күңел күтәрелеп китәр иде, — диде Хәлимә, ире уйлар томанына уралып утырган бер мәлдә.

— Миннән гармун кайгысы китте инде, үз хәсрәтем көчлерәк... Тальянга бүгеннән Хантимер хуҗа дип исәплә. Хисләндерерлек итеп уйнарга өйрәнсен. Егет кешегә кирәкле һөнәр ул... Минем сүзләрне ата васыяте дип кабул итсен, — диде Тимерһади, яткан урыныннан хәлсез кулын селкеп.

Хәлимә гармун хакында аның исенә башкача төшермәде. Уйнау хакында сүз кузгатуына да үкенде. Ирендә яшәү өмете сүнеп баруны күреп тора югыйсә...

Шушы сөйләшүдән соң берничә көн үткәч, Хәлимә эштән кайтып кергәндә, өйдә гармун тавышы ишетеп, ирексездән туктап калды. Элеккечә үк моңлы, аһәңле яңгырый иде тальян тавышы. Бары Тимерһади гына шушылай өздереп уйный ала. Җитмәсә, гармунга кушылып үзе җырлый да бит әле! Тик тавышы хәзер көчсез инде. Тынын еш-еш алып, көйне өзеп-өзеп җырлый. Шулай да тавышында җанга ятыш мөлаемлык һаман сакланган. «Моңлана, мескенем!» — дип көрсенеп, Хәлимә эчтән килгән тавышка колак салды...

Алма бакчасына керсәм,
Алма ашыйсым килә;
Син агачы, мин чәчәге
Булып яшисем килә...

Егет чагыннан ук моңланып җырлый торган җыры бу. Ничә кат ишетсә дә, сүзләрен ятлап бетерсә дә, Хәлимәнең бу җырны тыңлаудан ялыкканы юк...

Алма биреп ашатырлар,
Ашама, жаныкаем;
Ашатырлар, ташлатырлар,
Ташлама, жаныкаем...

— Ташламам, жаныкаем! Мәнге ташлыйсым юк та... Тик менә үзен генә... — дип Хәлимә күз яшьләренә тыгылды. Жылаган килеш эчкә үтәргә кыенсынып, баскан урынында торып калды.

Жыр тынды. Хәлимә өйгә керде. Стенага сөялгән мендәргә аркасын терәгән килеш гармун тарта иде Тимерһади.

— Кайттынмы, карчыгым? — дип, ялгызлыктан котылуына сөенгәндәй, кәефләнә төшеп сорады ир һәм гармунын үзе белән янәшә стенага терәп куйды.

— Кайттым, жаным, кайттым... Ник туктадын? Бик матур уйный иден, — дип, тальян тавышын ишетергә тансыклаганын сиздереп әйтте хатын.

— Болай да озак кычкырттым. Бармаклар бизенгән, басарга карышалар. Гармун белән тарткалашырга хәл дә юк икән инде, — дип жавап кайтарды Тимерһади.

Ялгызлык мәжбүр итте аны гармунга тотынырга. Ул урын өстенә яткач, чире йогудан хәвефләнеп, Хантимерне сонгы вакытта Хәлимәнең аналарында тоталар. Хантимерне аеры яшәтүне үзе дә хуп күрде Тимерһади. Улын алдына утыртып, тупылдатып сөясе бик килгән чакларда да, язмыш белән ризалашырга мәжбүр булды. Сабый белән якыннан аралашырга ярамаганлыгын анлый иде ул.

...Тимерһади гармунга бүтән кагылмады. Сонгы уйнавы һәм жырлавы шушы булды. Февраль тирәләрендә ул еш өзлегә башлады. Гомерен тартып-сузып озынайту өчен әжәл белән якалашып ятуын якыннары күреп-белеп тордылар. Хәле көннән-көн мөшкелләнүенә карамастан, язга хәтле яшәренә исәп тоттылар. Кышкы салкында тун жирне киткәләп кабер чокунын ач-ялангач бәндәләр өчен гайре газап икәнлеген белгәнгә күрә, табигатьнен миһербанлы көннәре якынлашуын көттеләр.

Апрельгә чыкканда Тимерһадида аләм төсе калмаган иде инде. Айнын беренче атнасында ныклап өзлекте һәм шуннан рәтләнә алмады. Сүз әйтмәслек, күз ачмаслык хәлгә төште. Шулай да хатынына: «Малайны кеше итәргә тырыш... Үзенә терәк булыр», — дип сонгы васыятен көч-хәл белән житкерә алды.

Жылы һәм аяз көнне жирләделәр Тимерһадины. Анын япь-яшь килеш гүр иясе булуына авыл халкы бик кайгырды. Мәетне гүргә индергәндә хәтта каты бәгырьлеләрнең дә күзләреннән яшь бәреп чыкты...

...Атасын жирләгәннән сон ике ел үткәч, биш яшьлек Хантимерне дә жир куенына салдылар. Нәселдән килгән галәмәт идеме, атасыннан йогып калдымы — сабыйда да үпкә чире иде. Балакайны да шул алып китте. Бала-чага кызамыктан кырылган бу заманда үпкә чиреннән аралап калу турында уйлыйсы да юк иде. Илаһидан ярдәм көтеп, аннан да килмәсенә өметләре киселгәч, күзгә карап тилмереп, якты дөнья белән бәхилләштеләр газиз сабыйлар...

***

Октябрь ае якынлашты. Рәсимнен укырга китәренә санаулы көннәр калды. Әзерлек курсларыннан кайтканнан бирле ул колхозда эшләде. Югыйсә, Тимәк мәктәбе директоры Саттаров: «Монда кил, юллык акча эшләрсен», — дип чакырган иде. Бармады. Колхоз хезмәт көненә исәп-хисап ясый алганда икмәк тимәсме дигән исәптән чыгып, авылда калуны мәслихәткә санады егет. Быел сенлесе дә укырга керде, педагогия училищесына имтиханнар биреп кайтты. Ялгыз калган анага авырга туры килмәсен дип колхоз тәртәсенә жигелүе иде Рәсимнен...

Оксана да быел урта мәктәптә укый башлаячагы турында язган.

«...Мин синнән калышмаска исәп тотам. Урта белем алу белән институтка

керәчәкмен... Рәсим җаным, өйләнергә ашыкма берүк. Мин укып бетергәнне көт. Ашыксаң, мин читтән торып укуга күчәргә дә әзер...» — дигән юллар бар иде аның хатында.

Җавап хатында Рәсим өйләнү хакында өзеп бернәрсә яза алмады. Үзенең дә дүрт ел укыйсы бар бит әле. Институтны бетермәгән килеш өйләнү аның планына кермәгән. Шуңа күрә ул хатында:

«...Оксана, укы син, укы. Сугыш тынып, тыныч көннәр башлангач, укымышлылар кайда да кирәк булачак. Мин дә укып бетерим. Язмышларны бәйләү турында аннары уйлашырбыз...» — дигән юлларны язып, кызны тынычландырырга теләде.

... Рәсимнең китәренә өч көн кала амбарны бастылар. Кура-каралты эченә угрылар гадәттә идән астын чокып йә түбәне күтәреп төшә торганнар иде. Амбарга исә йозакка ачкыч яратып ачып кергәннәр. Келәт эченә күз йөртеп алу белән нәрсәләр югалуын чамалады Фәния. Былтыргыдан калган биш кило бал юкка чыккан, ярты капчык онның күпмедер өлеше алынган. Ерак әвендә эшләүчеләргә аш пешерү өчен суелган сарык итен дә чәлдергәннәр....

Районнан тикшерүчеләр килми торып, келәткә ревизия кертмәскә кушты Хәлимә. Кисәтүенең сәбәбен шулай аңлатты:

— Төрлечә гайбәт таралмасын өчен, орган кешеләре күз алдында ревизия үткәрәбез. Тикшерүчеләр килмичә торып бер әйбергә дә сүкәлмәскә кирәк.

Погонлы кешеләр авылга аяк басканчы ук гайбәткә тартым сүзләр барыбер таралып өлгерде.

— Йозакны ачып кем керергә мөмкин соң инде?.. Кемнең кулында ачкыч — шул кеше генә йогынырга мөмкин, — дигән юрау башка төрле гоманнарга караганда өстенлек алды. Көнчеллек беләнме, ахырын уйламыйча-нитмичә Фәния өстенә турыдан-туры шик ташлау иде бу.

— Каравылчы кайда булган? Ул нишләп күрмәгән? — дигән сораулар да куерды. Анысына җавапны тиз таптылар.

— Нишләсен тагын. Йоклаган! Каравылчының исеме генә бит. Таяк белән бур куркытырлык кешемени ул! Мылтык та бирмиләр шуңа ичмасам...

Район вәкилләре озак көттермәде. Шәпле атка утырып, өйлә вакыты якынлашканчы ук килеп җиттеләр. Алар икәү иде. Берсе авылда калды, икенчесе юлын дәвам итте. Кайдадыр кибет талаганнар икән, шуны тикшерәсе ди.

Авылда калган милиционер Габсаттар атлы иде. Фамилиясе — Галәвиев. Шушы участокка җаваплы, урындагы халык өчен таныш түрә. Аланбашка еш килә. Бернинди шикле вакыйга килеп чыкмаса да урап китә. Нинди йомыш белән йөрүен авыл җитәкчеләре дә күп чакта белми кала...

Ревизия комиссиясе әгъзалары оешып эшкә керешкәнче, Галәвиев Фәния белән гәп корды. Шикләнерлек кешеләр турында сораштырды, кемнең кемлеген үзе яхшы белеп торса да, авылда андыйларның булуы-булмавы белән кызыксынды. Завхозны ияртеп, басылган келәтнең эчен-тышын җентекләп карап чыкты, тик мәсьәләгә ачыклык кертердәй дәлил күрмәде. Тирә-якта бернинди эз калмаган. Дыңгычлап тәелеп, су сибеп шомартылган, ялтырап каткан ындыр табагында кешенеке түгел, ат тоягы эзе дә калырлык түгел шул.

— Күнелең берәүгә дә йөгермиме? — дип кабатлап сорады Галәвиев хатыннан.

— Юк шул... Тик шуны әйтә алам: келәткә ир кеше кергән булырга тиеш.

— Ни өчен андый фикердә?

— Йозакка ачкыч ярату хатын-кыз кулыннан килми. Аннары, урланган әйберләрне алып китү өчен хатын-кызның куәте җитми.

— Бәлки, икәү булганнардыр?

— Ана охшамаган. Ярты капчык онны утыртып калдырмаслар иде, — диде Фәния, тирә-ягына он сибелеп калган яртылаш капчыкка күрсәтеп...

— Алай уйларга нигез бар, — дип килеште милиционер. — Оннын купмесен алганнар, синенчә?

— Калдыкны үлчәмичә каян әйтәсен?..

Шулчакта ревкомиссия әгъзалары күренде. Алар килә-килешкә эшкә дә керештеләр...

Галәвиев, колхоз рәисе Хәлимә һәм хужалык мөдире Фәния белән генә күзгә-күз сөйләшеп, башка берәүне дә чакыртып тормастан, районга китеп барды. Хатыннар белән гәпләшкәндә бары бер сорауны ачыкларга теләде: «Ачкыч яратып, кем керергә мөмкин?» Сорау жавапсыз калды. Йозакка ачкыч ясардай, хәтта урлашырга көч-куәте житәрдәй ирләр дә авылда юк кебек иде хатыннарга.

— Каравылчыны алыштырырга кирәк. Келәт ишеге ачылганны сизмәслек хәлгә төшеп йоклаган бәндәне тотуда хикмәт юк, — диде Галәвиев, чигәсен кашып. Бурнын эзенә төшәрдәй берниндн дәлил таба алмавына үртәлә иде ул.

Икенче көнне иртән халык эшкә кузгалганчы ук кибет алдындагы игъланнар тактасында эре итеп язылган, шундый эчтәлектәге белдерү эленеп тора иде:

*«ХӨРМӘТЛЕ ГРАЖДАННАР!*

*Келәт басучыны ачыклауда сездән ярдәм көтәбез. Әгәр анын кемлеген белсәгез, яки шикләнсәгез, авыл советына яисә мина хәбәр итегез. Үзегезнен кемлекне күрсәтәсе килмәсә, имза куймыйча язып, почта тартмасына салырга мөмкин.*

*Участок вәкиле Галәвиев.»*

Язу бер атна эленеп торды, әмма берниндн хәбәр-хәтер алынмады. Почта тартмасы төбеннән сул кул белән таныр-танымаслык итеп язылган кечкенә кәгазь кисәге генә чыкты. «Бурны әллә каян эзләмәгез, кулында ачкыч булган кеше талаган келәтне», — дигән сүзләр иде анда.

Шушы хәбәрнен чынлыгына инанылмы, әллә бүтән дәлил таба алмавына ачынуданмы, милиционер Галәвиев төп игътибарны хужалык мөдире Фәния Нәбиева тарафына юнәлтте. Үз янына ике пүнәтәй ияртеп, анын өенә тентү белән керде. Актармаган, тортенмәгән жире калмады, тик шикләнердәй берни дә таба алмады.

— Кая яшерден урлаган әйберләрне? — дип жикеренеп сорады ул хатыннан, мангаена бәреп чыккан тирне жине белән кат-кат сыпырып.

— Кая куя алам сон мин аларны? Юк ул! Ихатага кергән булса, тапмый калмас идегез бит. Төртенмәгән урыныгыз калмады югыйсә, — дип, үзен тыныч тотарга тырышып, жавап бирде Фәния.

— Башка берәүгә яшергәнсендер?

— Кечкенә авылда сер тормый. Әгәр алай икән, тиз табарсыз. Тикшерегез... Анысы — сезнен эш, — диде хатын, катгый гына итеп.

— Балаларны нинди хисапка укытасын инде?

— Ике сарык сатып, шул акчага жибәрдем мин аларны. Күршеләрдән белешергә мөмкин. Бу хакта алар беләә...

Сорауны төрлечә боргалап бирел караса да, Габсаттар максатына ятышлы жавап ала алмады. Һәр сорауга нигезле жавабы әзер иде хатыннын. Тикшерүченен пүнәтәйләр алдында көчсезлек күрсәтәсе килмәде. Урыныннан күтәрелде. Билендәге пистолетын кат-кат тоткалап, гимнастеркасын рәтләде, фуражкасын киде. Әмер биргән командир шәенә сөрән салды:

— Әйдә, жыен! Тегендә баргач, икенче төрле сайратырбыз сине!

Галәвиев Фәнияне авылдан ат янәшәсендә атлатып алып чыгып китте. Хатыннын мин-минлегенә төкерү, ихтыяр көчен сындыруның үтемле бер чарасы итеп санады ул бу алымны. Карап калган халыкка үзенен кемлеген күрсәтәсе килү

омтылышы да көчле иде анда. Фәния җебеп төшәр, хәленең котылгысызлыгын чамалар, күндәмгә әйләнер дигән ышаныч та юк түгел иде Габсаттарда.

Авылдан чыгып, тауны күтәрелгәч, милиционер хатынга сүз катты:

— Ну, карак, хәлләр ничек?

Фәния ләм-мим аваз чыгармады. Башын түбән игән килеш, тәртәгә тагылган колын шикелле, аттан тотам да калмыйча, атлавын дәвам итте.

— Нәбиева, сиңа әйтәм, саңгырауландыңмы әллә?

— Мин бур түгел. Анның хәлен беләсең килсә, үзен тоткач сорарсың.

— Кем соң син?

Сорау җавапсыз калды. Фәния, кимсенүдән туган ачуын көч-хәл белән тыеп, тавыш-тынсыз гына яшь коя иде. Галәвиев әйткәннәр үзенә кагылмый да төсле иде хатынга.

Галәвиев атны туктатты. Хатын, әйләнеп тә карамыйча, атлавын дәвам итте. Хатынның бу кыланмышы Габсаттарны чыгырдан чыгарды.

— Слушай, син нәрсә? Капризланган булып ни кылмак буласың? Менә бу камчы синең белән бергә тумаган... Сыртыңны каезларга да күп сорамас, — дип сөйләнә-сөйләнә, камчысын кулында җилтерәтеп, Фәниянең каршысына чыгып басты.

— Хатын-кызга гына ухталмасаң, башкага көчең җитмәс, — диде Фәния, сүзләрен теш арасыннан сөзеп. — Хатын-кыз белән сугышырга кирәк булган өчен синең кебек бәндәләрне фронтка алмаганнардыр инде...

— Теләнә бет әле! Авызыңны ни өчен ачканыңны оныттырырмын, — дип зәһәрләнеп, хатын каршында таптанып алды Галәвиев. Фәниянең беләгеннән җилтерәтеп тотып, аны тарантаска таба тарткалый башлады. — Әйдә, утыр!

— Мин җәяү йөрергә күнеккән, болай да барам, — дип тешләкләнде хатын.

— Синең аяк белән барып җиткәнче, төн үтеп, таң атачак... Утыр диләр сиңа!..

— Миңа барыбер. Төрмәдә кунганчы, юлда таң аттыру хәерлерәк.

— Минем белән төн үткәрәсең киләмени? Төнне көтмичә дә синең өскә кунаклый алам , — дип, Габсаттар Фәнияне кыскалый башлады. Фәния гәүдәгә үз шәендәге бәндәгә, аеруча, «капка тәләкәсе» кушаматы тагылган Габсаттарга бирешердәй хатын түгел иде. Сиксәнешәр килолы капчыкларны җилтерәтеп йөртә торган хатын әле ул. Галәвиевнең кыланмышын җавапсыз калдырмады, ачу тулы көч белән бер селтәнүдә ирне аяктан бәреп екты.

— Сукәлеп кенә кара! Бугазыңны чәйнәрмен! Начальнигыңа әйтеп, эшеңнән кудырам мин сине, — диде хатын, Габсаттарның борын төбендә бармак янап.

— Әйт, әйт... Начальник кисеп тоттырыр, тәгәрмәч итеп тәгәрәтерсең...

— Күрербез, кем тәгәрәтер икән әле?

— Хуҗа синең бер сүзеңә ышанмаячак.

— Ышаныр.

— Дәлилең кая? Шаһитларың бармы?

— Миңа дәлил кирәк түгел...

Тарантаска менеп кунаклап, Габсаттар атын кузгатты. Хатын белән турылангач, әйтте:

— Юләр син! Ризалашсаң, коткара идем.

— Ирекне итәк асты белән алмыйлар. Намусым чиста минем. Синең кебек булдыксыз бәндәләргә тап төшертәсем килми.

Хатын адымын дәвам итте. Габсаттар белән бәхәс корунын файдасызлыгын аңлый иде ул...

Фәнияне алып китү хәбәрен Хәлимә аны күреп калучылардан ишетте. Галәвиевнең, авыл җитәкчеләре белән килешмичә, хуҗалык мөдирен үз белдеклеге белән алып китүен берничек тә бәяли алмады ул. Келәт ачкычларын да тапшыртмыйча торып,

завхозны кулга алырга ана кем хокук биргән? Колхоз эшенә кирәләтә аяк чалу була бит бу, дигән нәтиҗәгә килеп, Хәлимә районга юл тотты.

НКВД тирәсенә аяк басканчы, райкомның беренче секретарен күреп, аның белән киңәш-табыш итешүне кулай санады. Келәтнен талануында Фәниянең гаебе юклыкны аңлатасы килде беренчегә.

Әхмәт Хәмзин Хәлимәне дикъкать белән тыңлады. Аннан НКВД начальнигына шалтыратты, Аланбаш колхозы хуҗалык мөдиренең ни өчен кулга алынуы белән кызыксынды. Начальник завхозны гаепләү өчен төпле дәлил юклыкны яшермәде бугай, аны тыңлагач, Беренче:

— Шулай булгач, колхоз өчен сәгать саен кирәк кешене нигәябып яткырасыз? — диде, шелтәле тавыш белән.

Начальникның ничек җавап бирүен Хәлимә ишетмәде. Секретарьның йөзе ачыла төшмәүдән мәсьәләнең бер селтәнүдә чишелмәячәген сиземләде.

— Иптәш Һашимова, ачкычларны барып алыгыз. «Кайбер сорауларга ачыклык кертү белән чыгарачакбыз», — дип ышандыра начальник. Озак тотмаслар, дип уйлыйм, — диде Хәмзин телефон трубкасен куйгач.

...Фәния ачкычларны өендә яшереп калдырган иде. Хатыннарны кизү торучы милиционер алдында күрештерделәр. Алар арасында барган әңгәмәне, дәүләт күләмендәге житди мәсьәләләр буенча оештырылган яшерен сөйләшү барышын күзәткәндәй, колагын торгызып сагалап торды тәртип сакчысы.

— Минем гаебем юк. Тиздән азат итәрләр, — дип калды Фәния, ачкычларның кайдалыгын әйтеп, Хәлимә белән саубуллашканда.

Өмет — шайтан. Һәм ул шайтанлыгын еш кына күрсәтеп куя. Фәниянең тиз арада кайтып китүгә корылган өмете акланмады. Атна буе туктаусыз сорау алдылар аннан. Көндезләрен дә төпченделәр, йокысыннан уятып, төннәрен дә колак итен чәйнәделәр. Төп максат — келәтне үзе басу турында таныту иде.

Көчсез зат дип тормады тикшерүче, хатынга берничә тапкыр кул күтәрде — яңагына чәбәкләде. Авыртудан түгел, кимсенүдән кычкырып елыйсы килсә дә, яшь чыгармады Фәния. Сәгать теле шикелле үз каршында әрле-бирле таптанучы шәүләне йомшаклык, җебегәнлек күрсәтеп сөендерәсе килмәде. Эшләмәгән җинаятьне үз өстенә алудан катгый рәвештә баш тартты.

...Фәнияне тагын сорау алуга чакырдылар. Бүлмәгә аяк баскач, хатын аптырап калды — тикшерүче мона кадәр күзгә-башка ташланмаган таныш түгел яшь егет иде. Ул, мөлаем генә исәнләшеп, Фәнияне үз каршына утыртты. «Игътибарлы кылануы юкка түгелдер, юха телләнеп, гаепне үз өстемә алуны өмет итә торгандыр», — дигән уй йөгереп үтте хатын башыннан...

— Сөйләп җибәрегез, апа, сезне ни өчен монда тоталар? Нинди җинаять кылдыгыз? — диде егет, Фәния аның каршыдагы урындыкка җайлап утыргач.

Чит кеше мине, бәлки, аңлар дигән өмет белән, Фәния булган хәлне төкми-чәчми сөйләде. Тикшерүче ул әйткәннәрне төрткәләштереп барды, ара-тирә сораулар биреп алды. Хатын тынып калгач:

— Апа, укып чыгып, имзагызны куегыз, — дип, Фәния сөйләгәндә язып барган кәгазьне сузды. Хатын язманы дикъкать белән укып чыкты. Шикләнерлек урын юк, ул сөйләгәннәрдән тыш бүтән фикер кертелмәгән иде. Икеләнмичә имзасын салды һәм әйтте:

— Үскәнем, миһербанлы бәндәгә охшатканга күрә сорыйм әле: бер гаебем юк килеш, мине тагын күпме ябып яткырырлар икән?

— Бүген үк җибәрергә кушармын...

Үз колакларына үзе ышанмыйча чыгып китте Фәния бүлмәдән. Озата килгән милиционер аны элек утырган камерасына китереп япты.

...Райкомның беренче секретаре Хәмзин соравы буенча башкаладан җибәргәннәр

иде яшь тикшерүчене. Сүзендә торды егет. Шул ук көнне төштән соң Фәнияне чыгардылар. Гаебе булмау аркасында азат ителүен житкерделәр, тик бер гөнаһсыз килеш ябып яткырылуы өчен гафу үтенү түгел, рәтләп сөйләшүче дә булмады...

Хәлимә бүлмәсенә ыспай киенгән егет килеп керде. Күзгә-күз карашып сөйләштеләр. Егет кемлеген һәм ни өчен килүен әйткәч, келәт басуда шикләнерлек кешеләрнең исемлеген алды. Идарәгә чакыртып сөйләшергә исәбе юк, өйләренә үзе барачагын әйтте һәм кемлеген, ни йомыш белән йөрүен берәүгә дә сиздермәскә кушты.

Әүвәлге эш итеп, тикшерүче каравылчы картка кагылды. Ул сүзгә хирыс кеше булып чыкты. Керүченең кемлеге, нинди йомыш белән авылга килеп чыгуы турында кызыксынды.

— Мосафир мин, бабай. Үтеп барышлый гына, юл уңай бу авылга тукталдым. Кундырып чыгармаслармы дигән уй белән сезгә кергән идем, — дип җавап бирде егет.

— Урын житәрлек анысы. Тик өйдә кандала дигән канэчкеч дошман бихисап. Төннәрен тәкатьне корыталар, — диде карт. Кандала хәзер дә тәнендә йөргән шикелле, күлмәк итәгеннән кулын кертеп аркасын кашып алды.

— Ул ягы яманрак икән шул, — диде керүче, хуҗаның хәленә керергә теләгәндәй, башын чайкап.

— Әйдә, утыр, берад тын ал. Сәфәрең арыткандыр, — дип карт ишек төбендәге бүкәннән урын күрсәтте. Утыргач, «юлаучы» сорады:

— Берьялгызың яшисеңме әллә?

— Карчык белән икәү бед.

— Балалар юкмы?

— Ике малаемның икесе дә фрунтта.

— Үзең эшлисеңме?

— Селкенгән булам шунда.

— «Селкенү» ничек була инде ул?

— Каравыл торам.

— Фермадамы?

— Амбар саклаем мин.

— Бик җаваплы хезмәт икән бит, бабай. Куркыныч та. Бу заманда ни булмавы бар? Каракларның һөҗүм итүе дә ихтимал... Амбарларны күп басалар бит хәзер.

— Әйтәсе юк, улым. Күптән түгел үдебеднекен дә бастылар.

— Менә, әкәмәт!

— Әкәмәт шул. Элекке дафхуд керде кичтән каравыл өенә. Бергә эшләдек бит. Сүләшеп утырдык. Тегенең бер шешә дәмдәм суы да барие. Шуны да чөмердек. Сафи кайтып китте, мин калай мич ягып калдым. Каравыл өе дә җылынган, мин дә оеганмын... Вәт, шул. Минем чаманы белгәндәй, төнлә келәтне дә басканнар. Исерек баштан каян сидәсең?

— Бурны тоттылармы соң? — дип кызыксынды егет.

— Каян тотсыннар инде? Эдли белүче дә, күрүче дә юк. Дафхуд хатынны алып китеп, ябып яткырганнар иде, аны да чыгарганнар.

— Тикшерүчеләр синнән сораштылармы соң?

— Ничек кенә әле!

— Шушыларны сөйләдеңме?

— Кая инде! Сафи иртән: «Әгәр кичтән бергә эчкәнне ычкындырсаң, келәт басуда беднең икебедне гаепләячәкләр», — дип кисәтте.

— Дөрес әйткән, — диде керүче, карт фикерен яклагандай итеп.

— Мин дә шул уйда...

...«Юлаучы» Сафетдин өенә шыпырт кына килеп керде. Хуҗа берьялгызы чәй

эчеп утыра иде. Керүчене шәйләми калды, өстәлдәге балны да, түгәрәк кечкенә ипине дә яшерергә өлгерә алмады. Чакырылмаган «кунак»нын таныш-белеш түгел кеше икәнлеген чамалагач, бераз тынычлана төште. Үткән-сүткәннен анын ни ашавында, ничек яшәвендә нинди катнашы бар, янәсе... «Юлаучы» кунарга фатир юллап керүен әйткәч, күнел төбенә утырган хафасы гел юкка чыкты.

— Бүген үзем дә өйдә кунмыйм шул. Күрше авылдагы апаларга китәм, — дип сылтау тапты Сафетдин.

— Мондый хәлдә нишләмәк кирәк? Икенче берәүгә кагылып карыйм инде, — дип «юлаучы» чыгып китте һәм авыл советына килеп, Сафетдин хужалыгына тентүгә керү өчен, совет житәкчесеннән пүнәтәйләр билгеләвен сорады...

...Сафетдиннен өй эчен, каралты-курасын, ихатасын бөртекләп күздән кичерделәр. Бер караштан, бернинди гаеп-кыек юк төсле иде, тик тәжрибәле караш «юк»тан «бар» ясады. Өй базыннан он табылды, сарык ите тозлап кисмәккә салынган иде. Аны чолан астыннан чыгардылар. Бал бәрәнге бакчасындагы иске киртәләр астына савыт белән яшерелгән иде...

Эзләнү вакытында тикшерүченен кулына шикле кәгазь кисәге килеп эләкте. Анда: «Ачкыч кемнен кулында...» дип язылa башланган иде. Почта тартмасына салынган язунын караламасы булырга тиеш. Егет шул фикергә килде һәм, кульязманы төп нөсхә белән чагыштыру өчен, кәгазь кисәген үзе белән алды...

***

Хужалык мөдире хезмәтеннән баш тартып, амбар алдына аяк басмаска үзенә сүз биреп кайтты Фәния тоткынлыктан. Өй ишеген ачып, эчкә атлаган гына иде, әйтерсен көтеп кенә торган, ялт итеп Хәлимә килеп керде.

— Исән-имин котылып кайтуын белән, малайкаем. Бүтән ул юлларны таптарга язмасын, — дип тезеп алды рәис.

— Рәхмәт изге теләгенә, — дип жавап кайтарды хужабикә, авыр көрсенеп. Үзенен иректә икәнлегенә ышанып житә алмый иде әле ул.

— Синен белән ничек кыланулары хакында сораштырып тормыйм, үз вакытын белән сөйләрсен әле, кимсетүләрсез, мыскыл итүләрсез булмый калмагандыр. Зәгыйфь зиһенле бәндә акылдан шашар урын шул ул, — диде Хәлимә, тоткынлык афәтләрен үз башыннан кичергән бәндә шикелле ачынып.

— Әйтәсе түгел, малайкаем! Дустына түгел, дошманына да күрсәтмәсен ябылу газапларын, — дип килеште Фәния.

— Бүген чыгарынны ишеткән идем. Кайтып күренүенне көтеп кенә тордым. Иртәгә иртүк районга жыелышка китәм. Амбар ачкычларын тапшырырга керүем, — дип, Хәлимә каеш бауга теркәлгән ачкычлар төргәген өстәл өстенә куйды. Бер ачкычларга, бер Хәлимәгә карап, Фәния фикерен ничек житкерергә белмичә аптырап торды.

— Малай, мин бит амбар алдына бүтәнчә аяк басмам дигән нәзер белән кайттым. Башка кеше табарга туры килер, — дия алды ул шулай да.

— Бу хакта янадан сөйләшербез. Бу минутларда гына икенче кеше таба алмыйм бит инде. Идарә утырышына куймыйча торып, сине эштән азат итеп булмый... Эшләү ягын кара әле син. Дошманнарны сөендермә. «Гаебе булган анын, югыйсә китмәс иде», — дип артында чәйнәнеп йөрмәсеннәр.

— Анысы шулай да... Адәм хурына калдырдылар бит. Авылда күренү дә оят сыман мина хәзер... Ярый әле икенче тикшерүче килеп...

— Беләм. Аны Әхмәт Хажиевич чакырттырды. Син түгел, Габсаттарлар, НКВД түрәләре үзләре адәм көлкесенә калды. Районнан очыртмакчылар аларны. Белеп тор: андыйлар өчен дә закон бар...

Бу сүзләрне ишеткәч, Фәниянен күнеле йомшый төште. Ин баш түрәләр дә гаепсез икәнлеген белгәннәр, ана ышанганнар икән ләбаса...

— Әчкерсез рәхмәтемне житкерәсем бар икән әле Әхмәт Хажиевичка, — диде Фәния, уйчанлана төшеп. — Минем ише гадиләр турында да кайгырткач, асыл бәндәләрнен берсе икән.

— Ул озакламый килергә тиеш, рәхмәтенне шунда әйтерсен, — диде дә, кергәндәге шикелле капылт кына чыгып та китте Хәлимә.

...Фәния казан астына ут тергезде, кайнатырга су куйды. Хафалы юлдан кайткач, тынычлана төшеп чәй эчеп алу иде исәбе. Әмма өйдә авызга кабып чәйнәрлек тәгам ризык юк. Ярый бәрәнге бар. Жәһәт-жәһәт кенә юып, аны казан артындагы чүлмәккә салды. Күбрәк итте. Кемдер килеп керер сыман тоелды анын күнеленә. Әлбәттә инде, Сафасын көтте. Кайтарып жибәрәләр, дип байтактан хәбәр салган иде, ни өчендер озаклады. Хәбәр-хәтере дә юк ичмасам...

Фәниянен кимсетелгән күнеленә янәдән моңсулык өстәлде. Берьялгызы бер өйдә. Янда сүз алышырлык жан иясе юк. Ашыйсыны китереп, бәрәнге исе өйгә таралгач, хатын уйларыннан арына төште. Суын сыккач, чүлмәкне пешергән урынга кире утыртып, эчендәге калдык суны саркытып алды да, бәрәнгенен бераз өлешен агач табакка салып, өстәлгә куйды. Кыздырылган кишер кисәкләреннән чәй пешерергә йөргәндә, кинәт кенә өй ишеге ачылды. Кабаланып кереп килүче малай нәрсәдер әйтергә теләп авызын ачкан иде, өлгерә алмый калды, бусагага абынып, эчке якка тәгәрәде. Фәния жәһәт кенә килеп малайны күтәрде дә сорады:

— Нәрсә булды, улым? Бу тикле нигә кабаланасын?

— Фәния апа!.. Сафа... Сафа абзый кайта... Титаклап безнен очтан үтте, — дип, сүзләрне йота-йота, ашыгу сәбәбен көч-хәл белән анлатты малай.

Сөенечле хәбәр китерүче малайга ике йомырка тоттырды да анын артыннан үзе дә урамга чыкты. Ике култык таягына асылынып, аркасына солдат капчыгы кигән Сафа, титаклый-титаклый атлап, үзләре турына якынлашып килә иде. Фәния йөгереп барып иренен муенына асылынды. Күкрәгенә башын куеп, кимсетүләр кичереп тә акмаган күз яшенә ирек куйды. Сабый балаларча ярсып елады. Аркасыннан сыпыра-сыпыра, Сафа аны тынычландырырга тырышты.

— Тынычлан, карчыгым. Мин исән-имин кайттым. Нигә шулкадәр үксисен? — дип туктаусыз кабатлады.

Фәния бераздан айный төште. Иренен аркасындагы капчыкны салдырып, үзе күтәрде. Култыклашып, сүзсез генә атлап, яна пешкән бәрәнге исе таралган өйгә аяк бастылар.

— Менә кайтыр, менә кайтыр, дип күнелем сине көтте. Нигәдер нәкъ бүген сине күрермен төсле иде, — дип, кылбырзактан килеп табын әзерләргә кереште хатын.

Бәрәнгене тәмләп ашадылар. Сафанын капчык төбендә башланмаган бер буханка ипи бар иде. Озак саклanudан ката төшкән-төшүен. Әмма ир белән хатынга аннан да тәмле ризык юктыр сыман иде. Авызга ипи эләккәндә талымлап торырлыкмы?!

...Көенечләр генә түгел, сөенечләр дә парлап йөри икән. Сафа белән Фәния өстәл артыннан кузгалырга өлгергәнче, Рәсим кайтып керде. Һәр икесе белән кочаклашып исәнләшкәч, ничә ел күрешмәгән атасынын хәл-әхвәле белән кызыксынганчы, беренче сорауны анасына бирде:

— Әнкәй, син нинди казага тарыдын? «Безнен институт төрмә ристаннары балаларын укыта торган урын түгел», — дип мине укудан чыгардылар, — диде ул.

— Элгәре юынып, тамак ялгап ал, аннары икегезгә берьюлы сөйләрмен. Әткән дә әле генә кайтып керде. Ул да яналыклар белән таныш түгел, — диде ана, улын тынычландырырга теләгәндәй, анын аркасыннан сөеп.

Улы житкергән хәбәр күнеленә төер утыртса да, үз хәлен сиздермәде Фәния. НКВД түрәләренен мәгънәсезлегенә, кешелексезлегенә генә әрнеде, үртәлде...

***

Рәсимгә Оксанадан хат килеп төште. Егетнен институттан китүен белмәгәнлектән, уку урынына адреслаган. Рәсим белән бергә укыган егет хатны авылга җибәргән иде.

Ялгызы калган бер очракта укырмын, дигән исәп белән хатны ачарга ашыкмады Рәсим. Хамия исә түзмәде:

— Нигә тизрәк укымыйсың? Аның яңалыкларын беләсе килә бит, — дип бөтергәләнә башлады.

— Анда сиңа кагылышлы хәбәр юк. Юкка эч пошырма, — дип сеңлесе сүзенә кул гына селтәде Рәсим.

— Кызык бит!

— Үзең хат алыш, бөтенесен белерсең, — дип Рәсим укылмаган хатны түш кесәсенә салып куйды.

Өйдәгеләр йокларга яткач, сукыр лампа яктысында укыды хатны Рәсим. Хат элеккеләренә караганда күпкә кыска язылган иде. Сөйгәненең аптыраячагын сизенгәндәй, хатның беренче юлларында ук Оксана кыска язуының сәбәбен аңлаткан...

*«...Рәсимкәем, бу юлы хатны кыска язам. Гаепләмә. Вакыт тарлык өстенә, башка сәбәп тә чыкты. Без шәһәргә күченәбез. Шуннан фатир бирделәр.*

*Фашистлар безнең авылны җир белән тигезләгән, дип язган идем бит. Аны кабат торгызып, колхоз оештырганчы кечкенә гаиләләрне шәһәргә күчерәләр. Теләгәне яңадан кире кайта, теләмәгәне — кала. Әнидә әлегә анык фикер юк. Шулай да: «Шәһәрдә сиңа укырга уңайлырак булыр иде», — дигән сүз ычкындырды. Ничек килеп чыгар тагын?..*

*Барып урнашкач, яңа адрес белән хат язармын...*

*Бик сагындым сине. «Көндез истә, төнлә төштә...» дип җырлыйлар иде бит сезнең авылда. Сагыну газабын үз башыннан кичергән бәндә чыгара ул җырны. Минем халәтем дә нәкъ шул җырдагыча. Хыялланмасам гына ярар иде, дим...*

*Хуш, җаным. Хат көт. Җавап яза торсаң да ярый.*

*Синең Оксанаң. 28 октябрь, 1944 ел.»*

Хатны укыгач, Рәсим уйга калды: институттан китү сәбәбен ничек аңлатырга? «Шомартырга»мы, әллә дөресен язаргамы?

Дөресен яшермәскә булды егет. Чөнки бер ялган икенчесен тудыра, ул күпкә китсә, төпсез сазга кереп чумган хәлгә төшәчәкмен, дип фикер йөртте. Иң якын кешесен алдарга аның намусы да җитмәс. Оксана белән дә уртаклашмагач, эч серләрен кемгә бушатырга тиеш соң ул? Әлбәттә, дөресен язачак!

## Икенче кисәк

Сафаның кайтуына ярты ел вакыт үтсә дә, батырып эшкә керешә алганы юк. Кар төшкәч, ат җигеп, болыннан печән ташырга тотынган иде, атна үтүгә ташларга мәҗбүр булды. Тездән бөгелмәгән аяк белән чанага утыру-төшү, йөк өстенә күтәрелү мең газап иде. Төзәлеп бетмәгән яра отыры сызлый башлады, таяк ярдәменнән башка атлый алмаслык хәлгә төште.

Эш ташлау турында бригадирга мөрәҗәгать иткәнче Сафа хатыны белән киңәште. Иренең хәлен күреп-сизеп торган Фәния:

— Азапланма, авыр эш сиңа төс түгел. Озак чыдый алмассың. Кыска арада да төс ташладың. Ары таба сәламәтлегеңнең отыры какшавы бар. Ихата арасында селкенеп йөрсәң, бик җиткән. Ныклап сихәтләнгәч, үзең карарсың тагын, — диде хатын, иренең ниятенә теләктәшлек белдереп.

Авыл эшче кулларга мохтаҗлык кичергән чакта, Сафа кебек аяк өсте йөргән ирләрне кайсы җитәкченең хезмәттән читләштерәсе килсен инде?!

— Атлы эштән азат итәрбез, әмма өйдә ятарга туры килмәс, Сафа абзый. Кулыңнан килердәй шөгыль табарбыз, — диде бригадир Тәлига, Сафаның зарын тыңлагач.

— Мин булдырырдай гамәл килеп чыкса, бер каршылыгым юк, — дип килеште ир.

— Бау ишәрсең...

...Аркан, дилбегә, аркалык, бавыргалык ише баулар ишеп кыш үткәрде Сафа. Җае туры килгәндә Рәсим дә ярдәмгә килде. Кыш буе идән өсте юкә кабыгы белән тулы булды. Аяк астын аера-аера өйгә кереп-чыгып йөрделәр. Бау ишүдән тыш, Сафа кыш буе чабата ясады. Аны Урта Кул авылы базарына илтеп сатып, ризык юнәтү өчен азмы-күпме акча эшләде.

Гадәттә, язга чыгу белән бау ишү туктатыла. Җәйге айларда яфрактагы агачларны кисүгә рөхсәт юк. Ифрат кирәк булган очракларда да колхозларга махсус күрсәтмә буенча гына юкә агачларын бераз кисәргә рөхсәт бирәләр.

Сафага эш бетте. Калдык юкәдән чабата ясап, март аен өйдә үткәрде. Язлыкта чәчүгә чыгармый калмаслар дип торганда, бөтенләй көтелмәгән хәл килеп чыкты. Аны колхоз идарәсенә чакырттылар.

— Сафа абый, идарә белән уйлашканнан соң, сине укырга җибәрергә булдык. Бу тәкъдимгә ничек карыйсың? — диде Хәлимә, Сафа килеп керүгә.

— Кырыкның өске ягына чыккач та укыйлармыни? Чын сүзме соң бу? — диде ул, нәрсә уйларга белмичә.

— Сине Минзәләгә ветсанитарлар әзерләү курсына җибәрергә уйладык. Иң кулай кеше син булырсың, дигән фикергә килдек.

— Киңәш-табыш итешмичә торып, бу торыштан бернәрсә дә әйтә алмам бит. Өйдәгеләр ни диярләр? — диде Сафа, арт чүмечен кашып.

— Бер каршылык юк, киңәш. Иртәгә иртән сүзеңне, түлке, өздереп әйт. Ату, вакыт бик кысан. Берсекөнгә барып җитәргә кирәк, — дип кисәтте Хәлимә.

Өйдәгеләр каршы килергә уйламадылар. Мондый җай чыгуына сөенделәр генә. Гарип кеше башкару өчен иң кулай хезмәт булыр, дигән нәтиҗәгә килделәр.

Ике көннән Сафа юлга кузгалды.

***

Гадәти таң иде бу. Татлы йокысыннан уянып, авыл аякка басты...

Идарә әгъзалары да иртә кузгалды. Кичтән тәгәлләнми калган утырышны дәвам иттеләр. Соңгы көн тәртибен тикшереп, карар кабул итәргә өлгерә алмый калдылар. Шуны бүген иртә белән йомгаклап куярга кирәк иде хуҗалык активларына.

Җыелышны ачарга өлгермәделәр, авыл советы бинасында кизү торучы хатын, тыны-көне бетеп, идарәгә килеп керде.

— Туганнар! Су-гыш бет-кән! Дө-мек-кән Гит-лер, — дип, сүзләрне иҗекләп, зарыгып көткән шатлыклы хәбәрне җиткерде ул.

— Каян ишеттең бу хәбәрне? — дип сорады барыннан алда һушына килгән Хәлимә.

— Районнан шалтыраттылар. Авылда митинг үткәрергә куштылар. Районнан вәкил дә килергә тиеш, — диде дә хатын китәргә ашыкты.

Утырыш кайгысы китте. Барысы да аяк өсте басты. Кемдер кул чаба, кемдер «Ура!» кычкыра... Идарә бинасы тәртипсез малайлардан гына торган класс төсенә керде. Ләкин шатлыктан туган шау-шу иде бу. Тынычлыкка сусаган бәндәләрнең күңеленнән ургып чыккан табигый халәт...

Колхоз идарәсендә җан иясе калмады. Барысы да тышка чыктылар. Шатлык

чиктән ашса да, хәбәрнең чынлыгына икеләнү тойгысы барыбер тынгылык бирми иде әле.

— Әнә, әнә, Исхак флаг күтәрде! — дип арадан берәү сөрән салды.

Карашлар авыл советы бинасы ягына юнәлде. Авылда гына түгел, бөтен илдә олы бәйрәм башлануын хәбәр итеп, совет йорты өстендә кызыл флаг талгын гына җилферди иде. Янә «Ура!» тавышлары яңгырады. «Сугыш беткән! Сугыш беткән!» — дигән авазлар, иртәнге тынлыкны ярып, еракларга таралды...

...Рәсим Оксанага хат язды да уйга калды. Якын арада очрашу өчен аларга бернинди мөмкинлек юк. Ике арада поездлар да юньләп йөрми. Юл чыгымнары да уйланырга мәҗбүр итә, сәфәр кылудан әлегә тыеп тора. Эшкә яңа гына керешкән Рәсимнең дә, укып йөргән Оксананың да рәтле-башлы акча таба алганнары юк бит әле...

Алар барыбер күрешергә тиешләр. Ике яшь йөрәк шуны тели. Тормыш бераз утырып, юл йөрү өчен мөмкинлекләр генә ачылсын, Рәсим ике дә уйламыйча юлга кузгалачак. Хатында да шул хакта Оксанага җиткерергә тырышты.

Рәсим чираттагы ялга чыкты. Мәктәп директоры Фаяз Саттаров аңа укытучылар институтына керергә киңәш бирде. «Кайсы факультетта уку ягын үзең карарсың, ә мин синең югары белемле укытучы булуыңны телим», — диде директор, егетне ялга җибәргәндә. Атасы да, анасы да Саттаров тәкъдимен икеләнүсез хупладылар, укуына фатиха бирделәр.

Ике көн үтүгә Рәсим документлар әзерләргә кереште. Бу мәшәкать күп вакыт алмады. Элек тупланганнарының кайберләрен яңартырга гына туры килде. Оксанага да, Хамиягә дә хат язган иде. Районга баргач, аларны почта тартмасына салып кайтты.

Хамияләрне быел, практика узу өчен, пионер лагерена җибәрәләр икән. «Юлламаны кайсы районга алсам әйбәт булыр икән?» — дип киңәш сораган иде. Шушы районга, Тимәк мәктәбенә кайтырга өндәп язды Рәсим. Директор абый да сине көтә, дип ышандырды.

...Гимнастерка түшендә ике орден, җиде медаль ялтыратып, Хаҗи Әмиров авылга кайтып төште. Солдат Хаҗи ике тапкыр яраланган. Соңгысында снаряд кыйпылчыгы аягына тигән. Ярасы ныклап төзәлеп бетмәгән бугай — игътибар белән караганда аның җинелчә аксавын чамаларга мөмкин. Сәламәтлегенә зарланмый солдат. «Авылны, тыныч хезмәтне сагынып кайттым», — дип еш кабатлый үзаралай сөйләшкәндә.

Хаҗиның исән-имин кайтуы бер могҗиза булса, ничә еллар буш торган өенең тутык йозагын ачып кереп, шунда яши башлавы тагын бер гаҗәеп вакыйга сыман кабул ителде. Ялгыз башын алып чыгып китеп, шәһәр тирәсендә төпләнеп калуын колакка санаучылар авылда җитәрлек иде. Ни әйтсән дә анда яшәү җиңелрәк бит.

Икенче берәүләр үз тәненә хуҗа була алмыйча иренә хыянәт иткән Гашияне каһәрләделәр. Төптән юан чыккан, тотса тимер бөгәрлек ирне санга сукмаган Гашияне хәтта уйнаштан бала тапкан хатыннар да яманлады. «Безгә ярый инде... Ирсез хатын — йөгәнсез ат, дигәндәй, ә бит Гашия тере ире өстеннән гөләйт итте», — дип үз гамәлләрен акларга тырыштылар.

Авыл халкы авызында йөргән сүзләрне Хаҗи да ишетте. Урам буйлап йөргән гайбәткә исе китмәде, колагына элмәде. Таркалган тормышны яңадан корып җибәрү өчен нишләргә дигән уй иде иренең башында. Сугышка кадәр колхоз активларының берсе иде Хаҗи. Терлек азыгы склады мөдире булды, аннары фермага җитәкчелек итте. Фронтка киткәндә бригадир иде. Талига аның урынына калды...

Берничә көн ял итәр дә эш сорап килми калмас, дип көттеләр Хаҗины идарәдә. Ике-өч көн генә түгел, атна үтте — ир идарә тирәсенә аяк басмады.

Авылда да сан-сирәк күрделәр аны. Районга барып, МТС каршында эшләүче курслар белән кызыксынып йөрде солдат. «Биредә курслар кышкы айларда гына оештырыла. Ул чорга чаклы көтәргә теләмәсәң, Чаллыга җибәрәбез. Анда сугыштан кайтканнарны укыту өчен махсус курс ачыла. Анда барсаң, көзгә кадәр үк тракторчы таныклыгы алып кайта аласың», — диделәр аңа МТСта. Ризалашты Хаҗи һәм юл хәстәрен күрә дә башлады.

Хаҗиның ниятен авылда белмиләр иде. Кич белән аны идарә утырышына чакырдылар. Эндәшүләренең сәбәбен чамалады ул. Әлбәттә, колхоздан эш тәкъдим итәчәкләр. Шулай килеп чыкты да.

— Хаҗи абый, идарә әгъзалары белән киңәштек тә, сине ферма мөдирлегенә тәкъдим итәргә дигән карарга килдек. Синең өчен яңа тармак түгел, сүз китерми эшләрсең, дип ышанабыз, — диде хуҗалык җитәкчесе Һашимова, Хаҗи алдагы эскәмиядән урын алгач ук.

— Хаҗига икеләнәсе юк. Тоткан урыныннан өзә торган егет, — дип «чөй» кыстырып куйды хисапчы Салих.

— Шулай, — дип килештеләр идарә әгъзаларының калганнары.

— Иптәшләр, тәкъдимегез өчен рәхмәт. Минем план икенчерәк. Чаллыга тракторчылар курсына китәргә ризалашып кайттым МТСтан. Минем ише, сугыштан кайтканнарны җыялар икән, — диде Хаҗи, колхоз активларының колакларын шомрайтырдай яңалык ирештереп.

— Авылга кул селтисеңмени? — дип сорады беренче бригада җитәкчесе Хафиз.

— МТСныкы булып исәпләнсәм дә, мин үзебезнең колхозга кайтып эшләрмен. Борчылмагыз, сезне дә, авылны да ташлау исәбе юк миндә. Авылдан бер тракторчы чыкса, хуҗалык өчен зыян булмастыр, минемчә, — дип үз дәлилен әйтте Хаҗи.

— Дөрес сукалый...

Идарә утырышы икенче эзгә күчте. Авыл советы рәисе Исхак Гатин сүз алды:

— Җәмәгать, — диде ул, Хаҗига текәлеп бераз карап торгач, — Хаҗи абыйның нияте изге. Каршы төшмик без аңа.... Хаҗи абый, кулларыңны күтәреп күрсәт әле? — Совет җитәкчесенең нәрсә теләвен төшенмәгән килеш, Хаҗи ике кулын берьюлы баш өстенә күтәрде.

— Әнә, аның кулларына гына карагыз, — дип дәвам итте Гатин, — алар тракторчы хезмәтен башкару өчен генә яралган. Бер-берсе кувалды чаклы бит. Әллә кайчан тракторчы буласы калган аңа... Укысын, максатына ирешсен. Мин ышанам: ел саен үзебезнең колхозга кайтып эшләр ул...

Хаҗи, аның белән килешүен аңлатып, баш какты. Тумар кадәр йодрыгына, уклау юанлыгындагы кыска бармакларына карап куйды.

Аның куллары авыр хезмәт башкару өчен яралганнар шул. Сугышта да пулемёт сөйрәп, күтәреп йөрүдән арынмады ул...

Укырга китүчеләр өчәү булып чыкты. Ике иптәше белән Хаҗи МТСта танышты. Егетләр шактый яшь күренсәләр дә, сугышта катнашырга өлгергәннәр.

Запас частьлар алып кайту өчен Чаллыга машина бара икән. Курска китүчеләрне шул машина белән озатмакчылар. Шофёр, эшлекле кыяфәт белән тегендә-монда чабуласа да, машинаны юлга чыгарлык итеп әзерләп бетерә алмаган. Үзен көтеп торучылар яныннан үткән саен ул:

— Хәзер кузгалабыз. Бераз гына көтегез. Бакчага кереп утырып торсагыз да була, — дип, житешә алмавы өчен гафу сорагандай, әйтеп китә.

Шофёр киңәшен тыңлап, ике егет бакчага юнәлде. Хаҗи да аларга иярмәкче

иде, майга катып төсен югалткан киндер алъяпкыч бәйләгән, бөкләп тоткан чыбыркысы белән итек кунычына ара-тирә суккалап килүче таныш кыяфәтне күреп, туктап калды. Ул сугышып йөргәндә завхоз Сафетдин белән «типтергән» хатыны Гашия иде бу. Юл кырыенда басып торган иргә игътибар да итмичә, җәһәт кенә үтеп китмәкче иде, Хажи аны эндәшеп туктатты. Кайчандыр яраткан кешесе иде бит ул аның. Хатын әле дә төс ташламаган, ирләрнең карашын җәлеп итәрлек матурлыгын саклаган.

— Гашия, кая ашыгасың? Исән-сау йөрүме? — диде Хажи, урыныннан бераз күтәрелә төшеп.

Кинәт килгән тавыштан сискәнеп, ялт карады да ни җавап бирергә белмичә каушап, каккан казык шикелле катып калды хатын. Хажи аның янына якынайды. Хатынның авыр эштән тупаслана төшкән, хәтсез яргаланган уң кулын ике учына алып, туктаусыз селкеп, озак кына җибәрми торды.

— И-и-и, Хажи, синең тавышны ишетүгә бөтенләй коелып төштем бит. Сине монда очратырмын, дип кем уйлаган... Исән-имин йөреп кайттыңмы? — дип тезеп алды Гашия, әле күптән генәме аның ире булып саналган кешесенең йөзенә кыяр-кыймас кына күз ташлап.

— Сихәтлек зарланырлык түгел, күргәненчә, — диде Хажи, көч-куәт барлыгын сиздереп торган калын инсәләрен турайтып.

— Кайту хәбәреңне ишеткән идем.

— Хәл белергә килмәдең тагын...

Хатын бу сүзләрне шаяртуга кабул итсә дә, җавапны житди тотты:

— Бер киселгән телем кабат ябышмас инде, Хажи. Ул хакта уйлыйсы юк. Язмышыңны бүтән белән бәйләп, үз бәхетеңне таба күр берүк. Тугрылыклы хатын була алмадым бит... Каһәр суккан шушы сугыш... — дип тотлыгып калды хатын. Күз яшьләренә тыгылды, теләгәнен әйтеп бетерә алмады.

— Нишлисең, Гашия, кайгы ил белән килде. Берәүләрнекен генә түгел, меңнәрнең язмышын ботарлады, — диде Хажи, аны тынычландырырга теләп. Күңеленнән бөтенләй икенче төрле фикер йөртте: «Хатыннарның күпчелеге хыянәт юлына басмаган бит. Хәтта ирләре үлеп калганнары да бүгенгә хәтле баштагы мәхәббәтләренә тугрылык саклый», — дигән уй иде аның башында.

— Ярый, булган — беткән, искә алмыйк вафасызлык вакыйгасын. Ертлач нәфесне тыя алмагач, җәзасын да үтәргә кирәктер. Хәзер мин үз хатамның дөмбуын татыйм, — диде хатын, авыр көрсенеп.

— Биредә нәрсә майтарып йөрү? Ирләр хезмәтенә алынгансың түгелме соң? — диде Хажи, хатынның ни белән шөгыльләнүен чамаласа да, сүзне икенчегә борырга теләп.

— Өстәл артында утыра торганы гына булмаса, авылда җинел эш бармыни? Тотынырга туры килә инде...

Сүз шушында өзелде. Чаллыга китүче машинадан өзек-өзек кычкыртып, Хажины килергә чакырдылар.

— Сез яшьрәк, кузовка менәрсез. Анда да йомшак, аска салам түшәдем. Бу абыйны кабинага алам, — дип күрсәтмә бирде шофёр.

Кузгалдылар. Авылны чыкканчы сүзсез бардылар. «Сүзгә саранрак бугай», — дип уйлаган иде Хажи башта, егет телчән булып чыкты.

— Гашия апаны беләсеңмени? — дигән сорау белән телен ачты шофёр, олы юлга борылу белән.

— Бераз гына, — диде Хажи, кинәт кенә таралып китәргә теләмичә. — Ә син аны каян беләсең?

— Бәй, белмәскә! Ул минем авылдаш бит, — диде егет, ничек инде шуны да чамаламаска дигән кыяфәт белән инбашын җыерып.

— Бик белсәң, әйт әле: нindирәк кыз соң ул?

— Һы, кызган, ди! Ирдән кайткан ул.

— Аерылганмы?

— Шул чама. Ире сугышта чакта мужиклар белән гүләйт иткән. Иренең кайтасын ишеткәч, авылны ташлап качкан.

— Качмаска иде.

— Ир бәреп үтерер дип шөлләгәндер. Үгезне мөгезеннән каерып егардай гайрәтле кеше, диләр ирен. «Исән чакта китеп калыйм», дип сыпыргандыр Гашия апа.

— Алай икән, — диде Хаҗи, бу сүзләрнең үзенә кагылышы булмаган төсле битарафлык белән.

— Шулай-шулай, абзый. Сугыш тәмам азындырды хатын-кызны. Безнең авылда уйнаштан бала табучыларның чуты юк.

— Арттырасың син...

— Күп инде, күп. Урам саен кимендә дүрт-биш хатын.

— Азгынлыкка юл куелгач, гүләйт тә итәрләр, бала да табарлар, энекәем.

— Дөрес әйтәсең, абзый. Хөкүмәт акча түләп бала таптыра башлады бит. Баласызларга налуг сала... Сугышта үлгәннәрне каплату өчен шулай кыланалардыр?

— Гашия апаң ирләр белән чуаламы соң? — дигән сорау белән Хаҗи әңгәмәне баштагы эзгә төшерде.

— Сизелми. Әллә мин генә белми торганмындыр... Алай әйтергә дә урын юк сыман. Ирләр белән чуалса, халык теленә менми калмас иде, — диде егет, үз сүзенә үзе ышанып.

Азгынлык, тормыш бозыклыгы турында гәп шуның белән өзелде. Юлның калган өлеше МТСның эчке хәлләре турында фикер алышып узды. Егет биредә байтактан эшли икән. Кемнең ничек хезмәт куюын, кемнең көн үткәрү өчен генә йөрүен биш бармагы шикелле белә. Гаилә хәлләре белән дә таныш. Шофёр сөйләгәннәрне тыңлаганнан соң, Хаҗи үзен шушы оешманың төп кешесе итеп саный ук башлады.

***

Сугыш миллионнарның язмышын челпәрәмә китерде, башларына иксез-чиксез кайгы-хәсрәт өйде.

Хаҗи үзен язмышлары җимерелгән бәхетсезләрнең берсе итеп саный. Сугыш туктауга бер ел тулып килә, ә аның ялгызлыктан котыла алганы юк. Икенче тапкыр өйләнеп тә бәхетен таба алмастыр төсле. Хаҗи тракторына гына гашыйк, аның күзенә хатын-кыз чалынмый, дигән сүзләр дә йөрештерә авылда. Гашияне кабат алып кайтыр әле, дигән икеләнүләр дә юк түгел иде.

...Тормышны җайга салу ягыннан Гашия өлгеррәк булып чыкты. Аның иргә бару хәбәре Аланбашка да килеп ирешге. Берәүләр: «Миргә яраган — бергә ярый», — дип Гашия белән булашса, икенчеләр: «Кемгә дә ярарлык хатын ул. Үз бәхетен тапкан икән — бик хуш, рәхәтләнеп яшәсен», — дигән фикергә килделәр...

Алтаф Хаҗиев районга эшкә кайтты. Офицер буларак, аны райкомның хәрби бүлегенә мөдир итеп алдылар. Куптарай Алтаф, эшкә урнашу белән, бүгенгегә караганда киләчәк турында төпләбрәк кайгырта башлады. Җай чыкса-чыкмаса да үзен югары урын биләргә сәләтле кадр итеп күрсәтергә тырышты, җитәкчеләрнең күз кырыеннан тайпылмау ягын карады. Сугыш шаукымы тыну белән хәрби бүлекнең юкка чыгачагын чамалый иде егет.

Яшь һәм актив хезмәткәр буларак, Хаҗиевны райком бюросы утырышына материал әзерләү өчен авылларга еш йөрттеләр. Атналар буена куна-төнә яткан

чаклары булды. Зарланмады. «Михнәтен татымыйча торып, рәхәт күреп булмас», — дип фикер йөртте һәм сыкрануын сиздермәү ягын карады...

1946 елның Яна елын беренче тапкыр тыныч шартларда үткәргәч, Алтафка Калмаш авылына барып, терлекчелекнен торышы мәсьәләсен бюро утырышына әзерләү бурычын житкерделәр. Колхозга шалтыратып, икенче көнне иртүк үзен алып китү өчен ат жибәрүләрен сорады. «Иртән йокыдан уянуына ат шунда булыр. Кучерның да менә дигәнен жибәрәм», — дип ышандырды рәис.

Иртән, райком кешеләре чиратлап кия торган таушалып беткән иске толыпны култык астына кыстырып, Алтаф авыл атлары туктый торган урынга килде. Анда жигүле ат тора иде. Байтактан көтә ахыры, кучер аякка кергән «таракан»ны куу өчен бер урында сикергәли.

— Энем, син Калмаштанмы? — диде Алтаф, якынайгач.

— Әйе.

Толып якасы астыннан малай тавышы түгел, хатын-кызныкы янгырады. «Колхоз рәисе әйткән «менә дигән кучер» шушы була микәнни?» — дип гажәпсенеп куйды Хажиев. Сорады:

— Син мине алырга килденме сон?

— Мин синен кемлегенне каян белим? «Хажиев дигән кешене алып кайтасын», дип жибәрделәр инде, — дип жавап кайтарды ат хужасы.

— Мин ул. Әйдә, кузгалыйк алайса, — диде Алтаф, канәгатьлек тоеп. Сугыш туктаганнан бирле хатын-кыз жиккән атта йөргәне юк иде әле анын...

Унөч чакрымдагы Калмаш авылына барып житкәнче, ике арада барган әнгәмәдән ат тотучының Гашия исемле икәнлеген дә, ирдән кайткан тол хатын булуын да, ялгызы бер йортта яшәвен дә белергә өлгерде Алтаф. Көн яктыра төшкәч, ул хатынның йөзенә игътибар итте һәм кечкенә бер авылда шушындый чибәр затның ятим яшәвенә аптырап куйды. Иртәнге салкында кызара төшкән бит очлары болай да сөйкемле Гашияне тагын да матурайтканнар иде.

— Ялгызлыгына аптырыйм... Сине нишләп ирләр күрми? — дип соклануын яшерә алмыйча әйтеп куйды Алтаф хатынга.

— Кем күрсен? Мина түгел, кызларга да юк бит алар. Сугыш йотып бетерде, — дип кырт кистереп жавап кайтарды Гашия.

— Кызганам сине, кызганам...

— Ник кызганасын? Мескен хәлгә төшкән юк әле.

— Яшь, чибәр башын белән ирләр йөгенә жигелгәнен өчен кызганам.

— Хәзер тол хатыннарның язмышы шундый. Тормыш көтәсен килдеме — ат жигәргә туры килә.

— Бәхетне башка урыннан эзләргәдер, бәлки?

— Каян, инде ул, ягъни мәсәлән?

— Район үзәгеннән... Һичьюгында...

— Анда мине кем көтә?

— Мин.

— Икенче хатынлыккамы?

— Түгел. Минем хатын юк.

— Ышанасы килми.

— Чын әйтәм. Фатирга үзенә керт, ныклап торып танышып та китәрбез...

— Килгән-киткәнне урнаштыру өчен авылда махсус фатир бар, — диде Гашия, тавышына горурлык төсмере чыгарып. «Ирләр күрү белән бәлтерәп төшә торган хатын икән» дигән караш уятасы килми иде анын район вәкиленда.

— Бәлки кич килеп чыгармын...

— Башынны очсызлап йөрмә. Халык сизсә, данын таралыр. Жыеп бетерә алмассын.

— Шулай да киләм.

Гашия җавап кайтармады...

...Шушы очрашудан соң бер ай вакыт узгач, Гашияне хәлсезлек борчый башлады. Авыз тәме үзгәрде, күңеле болганды, азык талымлады.. «Әллә авырга уздым микән?»— дигән шигә туган иде, ләкин бу хәлгә ышанасы килмәде. Ир белән торып та, Сафетдин белән чуалып та баласы булмады бит. Алтаф белән үткәргән берничә төн эчендә генә үзенең мондый хикмәткә таруына икеләнде ул. Районга килеп, табибка күренде. Яшь кенә кыз кабул итте аны. Җентекләп тикшергәч, әйтте:

— Апа, син авырга узгансың. Атлы эштә йөрүдән баш тартырга туры килер. Баланы сакларга кирәк, — диде.

Коелды да төште Гашия. Кая барырга, нәрсә кылырга, кемгә серен түгәргә белмәүдән югалып калды. Районда сүзе үтәрдәй, киңәш бирердәй таныш-белеше дә юк ичмасам. Кая барырга тиеш ул бу хәлдә? Авылга кайтудан тыш бүтән чара барлыгын башына да китерә алмый ул бу очракта.

Бәйләнгән урыннан атын ычкындырып, кайту ягына каермакчы гына иде, каршыга таба килүче Хәлимәне күреп, туктап калды. Бу мәлдә аңа кирәкле кеше шушыдыр кебек тоелды ана. Аңласа, ул гына аңлар, ярдәм кулын сузудан да тарсынмас.

— Хәлимә, берничә минутка вакытың юкмы? — дип эндәште Гашия, аны-моны абайламыйча килүче хатынны туктатып.

— Бар... Бәй, Гашия, син түгелме соң?

— Мин, Хәлимә... Исән-сау йөрүме?

— Мин әйбәт. Ә үзең?

— Бик үк шәптән түгел...

— Чирләдеңме?

— Яманы эләкте... Хатын-кыз башына кайгы астан менә бит...

... Гашия тарыган хикмәте турында яшермичә сөйләп бирде. Бу мәлдә ни кылырга кирәклеге турында элекке авылдашыннан киңәш сорады.

— Хаҗиев үзе беләме бу хакта? — дип сорады Хәлимә.

— Каян белсен? Бу арада күргән дә юк үзен.

— Кичекмәстән хәбәрне үзенә җиткер.

— Файдасы тиярме?

— Тияр. Райком работнигына теләсә кайда бала ясап йөрергә рөхсәт бирелмәгән. Әхмәт Хаҗиевич ишетсә, койрыгын шартлатып кысачак.

— Өйләнер, дисеңме?

— Ничек кенә әле! Хатыны юк ләбаса. Бар, хәзер үк Алтаф янына ычкын. Ык-мык килә башласа, «Беренче секретарь янына керәм, ул нинди киңәш бирер», — диген. «Беренче» дигән сүзне ишетсә, шыбырдый алмас, — диде Хәлимә, соңгы киңәшен биреп...

...Хәлимә планы тормышка ашты. Райком яучылыгында һәм аның турыдан-туры җитәкчелегендә Гашияне Алтафка хатынлыкка бирделәр. Чор өчен гадәти күренеш иде бу. Гаилә эчендә килеп туган күп төрле мәсьәләләрне хәл итүдән райком ничек читтә калсын инде?!

***

Хамия өйгә күтелмәгән яңалык алып кайтты. Сафа өйдә юк иде, хәбәрне башта анасына җиткерде. Әтисе булмаудан файдаланып, элгәре әнисе белән киңәшләшүне кулай күрде. Анын ризалыгы булганда гына ата белән сөйләшү урынлы чыгардай тоелды кызга.

— Әнкәй, бер егет мине кияүгә чыгарга сорый. Син нәрсә диярсен? — диде Хамия, тамак ялгап, өстәл артыннан күтәрелгәч...

Укуны тәмамлап кайткач, Хамияне Тимәк мәктәбенә билгеләделәр. Директор Фаяз Саттаров колач җәеп каршылады кызны. Шушында белем алган баланың үз мәктәбенә эшкә кайтуы куанычлы вакыйга иде директор өчен.

— Озакламыйча безнең укытучылар шушы мәктәпне тәмамлаучылардан гына тормас микән әле. Институттан кайткач, Рәсимне директор итеп куярбыз. Мина сезнең эшне читтән күзәтеп, уңышларыгыз өчен шатланып яшәргә генә калыр, — диде ул, Хамиягә фатиха биргәндә...

Хамия кияүгә бару турында авыз ачкач, ана каушап калды, хәлсезләнеп киткәндәй булды. Урындыкка авырлык белән утырды да:

— Кызым, иртә түгелме соң? — диде ул, баласының житкән кыз булып өлгерүен дә сизми калганына аптырап.

— Унсигез бит инде, әнкәй...

— Абзыкаң өйләнгәнче сине кияүгә бирү килешеп җитмәс бит.

— Аның бер ел укыйсы бар бит әле...

— Бер елга түзәрсең, әткәң дә ризалашмас. Бернинди әзерлегебез юк. Кеше арасында кешеләрчә озатасы килә бит.

— Камил кабаландыра, әнкәй. Ярты ятим яши.

— Карт бианайга хезмәткә җыенасыңмы?

Фәния Камилнең төпчек малай икәнлеген, ике абыйсының сугышта һәлак булуын белә. Күптән түгел атасын җирләделәр, анасы яталы-торалы гына йөри. Жигелеп хезмәт итәргә туры киләчәк Хамиягә. Төп эшенә зыян килүе бар... Бу кадәресен ничек аңламый икән соң ул?

— Шыр ятимгә барсаң да, кул кушырып утырып булмый, әнкәй. Авылда яшәгәч, мал-туарын тотарга туры килә. Өстәвенә, бакча, ихата шөгыле... Өй эшләрен башкару туганчы ук хатын-кызның маңгаена язылган, — диде Хамия, тормыш тәҗрибәсе туплаган хатыннарча фикер йөртеп.

— Бу яктан сүзең хак...

— Менә бит, үзең дә килешәсең.

— Хикмәт анда гына түгел... Балаларны башлы-күзле итү өлкәненнән башлана. Абзыкаң үпкәләмәсме?

— Үпкәләмәс. Ул өйләнергә җыенмый.

— Каян беләсең?

— Оксана укый. Аның институт бетерүен көтә.

— Тач шуның белән азаланыр микән?

— Азаланганнар инде. Аларның мәхәббәтенең кайнарлыгына кул пешмәле, — диде кыз, көлемсери төшеп.

— Яшьлек мажарага бай. Һәркемнең башыннан үтә торган хикмәт ул, — диде ана, тегүче Фаяз белән ике арада яшен тизлегендә кабынып, йолдыз атылган мизгел эчендә юкка чыккан яшьлек мәхәббәтен искә төшереп.

— Боларныкы сүрелә торганга охшамаган, — диде Хамия, әнисе әйткәннәргә икеләнеп.

— Үзеңнеке ничек соң? Яратасыңмы Камилне? Гомер юлы үтү басма аша елга кичү түгел, тормышта төрлесе килеп чыга. Еллар үткәч кенә ялгышыңны аңлыйсың, әмма соң була, — дип, ана үзе кичергәннәрдән чыгып, киңәш бирүен дәвам итте...

Ике бөртек кенә алар. Кайсы ананың үз баласын бәхетсез итеп күрәсе килсен! Кызының мәхәббәт бусагасына абынмавын ихлас күңелдән тели Фәния. Җаваплы адым ясарга ниятләгәндә җиде кат үлчәп кисәргә кирәклеген тәкрарлый.

— Әткән кайткач тәпләп сөйләшербез тагын, — дип, ана соңгы сүзне Сафага калдырды.

Хамия шуны белә: әгәр әнкәсе үз сүзендә тора икән, атасының ризалашмый хәле юк. Сафа яраткан кызының теләгенә бервакытта да каршы килми...

***

Аланбаштан фронтка туксан алты ир-ат алынган иде, шуның утыз бише авылга үз аягы белән кайтып керде. Агач аяк, ясалма кул белән кайтучылар гарипкә дә саналмады. Үлеп калучыларның, гаилә әгъзалары якыннарын кулсыз-аяксыз килеш кабул итәргә дә риза икәнлекләрен белдереп, яшь коюдан туктый алганнары юк. Хәбәрсез югалганнарны: «Менә кайтыр, менә кайтыр», — дип көн саен көтеп яшиләр.

Өенә сугыш афәте кермәгән кыз-кыркыннарга да кыргынлык килде. Аларга яучы җибәрердәй егетләрнең күпчелеге яу кырында ятып калды. Кызларның байтагына иргә бармаган килеш картаерга язганлыгы көн кебек ачык. Шунлыктан әле генә өлгереп килүче ябь-яшь кызлар да җай чыгу белән кияүгә бару ягын чамалыйлар. Хамиянең кабалануы да шул нияттән түгел микән, дип икеләнгән иде анасы, әмма кат-кат уйлангач, кызының теләгенә каршы килердәй сәбәп юклыгына инанды...

Ире белән киңәшләшүне озакка калдырмады Фәния. Сафаның кәефле чагын эләктереп, сүз кату ягын карады. Тимерне кызуында сугу ниятендә иде ул.

— Кызның атасы — мин, анасы — син. Егет килеп баштa бездән кыз сорасын. Ничек сөйләшә бит әле? Планы нинди? Никах көнен кайчанга билгелиләр? — Болар турында уртага салып сөйләшмичә булмый бит. Синең белән миңа монда тумаган колынның билен сындырып утыруда файда юк, — диде Сафа, үз фикерен җиткереп...

***

Сафетдин кайтты. Тәрәзәләренә һәм тышкы ишегенә аркылы сугылган иске такталарны кубарып кереп, ике ел ташландык торган өйгә җан өрде.

Сафетдингә халыкның үпкәсе юк. Кеше әйберенә сукәлгән булса, җандошман санарлар иде, ә колхозныкы иялегә саналмый. Сугышка чаклы кешеләр колхоз тарафыннан ярдәм һәм хөрмәт күргәндә гомуми байлыкка үз итеп карыйлар иде. Үзләре иген игеп, ачлыкта газап чиккәч, ышаныч югалды, колхоз малына кул селтәп карау гадәте көчәйде.

Кытлык еллар халыкның ышанычын чәрдәкләде. Сугыш туктаган елның көзендә бераз ашлык бүлеп бирү өзелгән өметне ялгагандай итте. Ипи ашау турында хыялланып булмаса да, кайнатылган суга көнгә өч тапкыр умач, бәчмәчә, ярма ише икмәк ризыкларын салырга мөмкинлек туды.

Сафетдиннең хәерчелеккә чумган авылда каласы килми иде. Кайтуына өч көн үткәч, ул авыл советына, Исхак янына килде.

— Энем, районнан әйләнеп кайтасым бар иде. Барасың булса, мине дә утыртмассың микән? — диде, килү сәбәбен аңлатып.

— Бүген-иртәгә чакырмыйлар әле. Сина кайчанга кирәк соң? — диде совет җитәкчесе.

— Ашыгыч иде шул... Органнарга теркәләсе...

— Иртәгә укытучы Рәлия барачак. Колхоздан җай чыкмаса, үземнең ат белән җибәрәм. Күреп сөйләш, килешерсез, шәт.

— Рәхмәт, энем. Әбәзәтелнә сөйләшәм, — дип Сафетдин совет бинасыннан чыгып китте.

Ызанбаш авылы кызы Рәлия Шәмсиеваны, училище тәмамлагач, Аланбашка билгеләгәннәр иде. Биредә бер ел укытып, тәүге чыныгуын алды. Тәҗрибәсе өстен булганлыктан, мөдирлек хезмәтен Нәсимә алып барды.

Ике кыз, үзара хәтәр килешеп, тату гына эшләп киттеләр. Авылны, мәктәпне якын кабул итсә дә, Рәлия китү исәбендә тора. Ызанбашта яшәүче, биш кыз табып үстереп, төрлесен-төрле якка тараткан ата белән ана олыгая төште. Ярдәмчесез яшәү кыенлашты. Картлык көнебездә безнең янәшәдә булсаң иде, дип төпчекләре Рәлияне үз яннарына чакыралар. Туган авылына эшкә кайтаруларын сорап биргән гаризасының язмышын белешү өчен мәгариф бүлеге мөдире янына бару ниятендә иде кыз.

Икенче көнне иртән авыл советы айгыры җигелгән тарантаска утырып, Рәлия белән Сафетдин юлга кузгалдылар. Кайтулары да бергә булырга тиеш иде аларның.

Рәлиянең йомышы минутлар арасында хәл ителде. Мәгариф бүлеге мөдиренең бүлмәсенә керү өчен генә чират торып, күпмедер вакыт үткәрергә туры килде. Мөдир кызның нинди йомыш белән йөрүен истән чыгармаган иде. Рәлия әчкә аяк басуга ук:

— Сезнең сорауны үтәү өчен җай чыгып тора. Ызанбаш мәктәбе мөдире быел укытучылар институтына укырга китә. Шуның урынына күчәрсез. Мөдирлекне дә алырга туры килер, — диде район укытучылары җитәкчесе, мәсьәләне көткәннән дә җиңел хәл итеп.

Бүлмәдән күтәренке кәеф белән чыкты Рәлия. Күчерү турындагы приказ кулга эләккәч, башы күккә тигәндәй булды. Ат куйган ихатага кош тоткандай очынып кайтты. Сафетдиннең дә йомышы тиз хәл ителгән иде. Айгырны җиктеләр дә юлга чыктылар. Ат ыргылып-ыргылып тарта башлады.

— Кайту ягына ашкына хайван, — диде Сафетдин, атның пырдымсыз кылануының сәбәбен аңлатып.

— Һәр җан иясе туган җиренә кайтырга ашкына шул, — диде Рәлия, җавап урынына. Үзе турында уйлап әйтүе иде кызның.

Сафетдин Рәлиянең кайсы авылдан икәнлеген дә, Аланбашка кайчан килүен дә белми иде. Барышлый сораштырмады, кайту юлына чыккач төпченә башлады. Әүвәл ни өчен китәргә җыенуы белән кызыксынды.

— Авылны өнәмәгән өчен түгел, әткәй белән әнкәйнең кул арасына керергә кеше булмаган өчен кайтып китәм, — дип чынбарлыкны аңлатты кыз.

— Башка туган-тумачаң юкмыни?

— Авылда берсе дә юк. Шәһәрдә яшиләр. Берсе дә кайту исәбендә түгел.

— Хәлләрең яман икән... Кияүгә ата-ананны ташлап китәрсеңме, әллә йортка кертерсеңме?

— Ул хакта уйларга иртә әле.

— Уйларга кирәк. Вакытның койрыгы юк — тоттыра торган түгел: килеп тә җитә, узып та китә... Карт кызга әйләнүеңне дә сизми калырсың.

— Бәхеткә язганы табылыр.

— Ничек булыр? Егетләрне сугыш кырды, һәр кызга ир җитмәс, — диде Сафетдин, кызның йөзендәге үзгәрешне чамалау өчен, каш астыннан кырын карап.

— Нишләрсең? Тимәсә, язмыш белән ризалашып яшәргә кала, — дип сүз үзе турында бармагандай битарафлык белән җавап кайтарды Рәлия.

— Сине үзем алырмын, — дип, тапкыр сүз әйткәндәй канәгатьлек белән, шаркылдап көлеп куйды Сафетдин.

«Кеше ышанмаслык сүзне чын булса да әйтмә», дигән мәкальгә тартым килеп чыкты Сафетдиннең авызыннан кинәт ычкынган бу тәкъдим. Кыз аны шулай кабул итте һәм җавап сүзе әйтүне кирәк санамады. Ирнең үзеннәнме,

сүзеннәнме чирканып, гәүдәсен читкәрәк алу өчен, тарантасның кырыенарак елышты. Кызның бу гамәлен кимсетү сыман кабул итте Сафетдин һәм кызны көч белән үз янәшәсенә тартты. Тәнен чемердәтеп, гәүдә буйлап аккан бозык кан, йөрәге аша үттеме-юкмы, бәреп кереп, миен томалады. Ихтыяры белән идарә итә алмаслык хәлгә төште.

— Кулыңны ал, Сафетдин абый. Өлкәннәрнең бала-чага белән шаяруын яратмыйм, — дип Рәлия ирнен сынар кулын беленнән сыпырып төшерде.

— Син сабый, мин бабаймы?.. Этлек кылырга яшь мишәйт итмәй, — дип, Сафетдин атны куаклар арасына каерды.

— Кая борасың? Хәзер кычкырам! — дип, Сафетдиннең эчендәге мәкере котырынуын чамалап, кыз сөрән салды.

— Авызыңны гына ачып кара! Күрәсеңме менә моны? — дип Сафетдин итек кунычыннан орчык озынлыгындагы пычак тартып чыгарды.

Куркуыннан кыз кутәреп катты. Сафетдиннең котырган этнеке шикелле майланган күзләренә, ач бүренекечә килбәтсез чыраена күз салды да гомеренең кыл өстендә икәнлегенә төшенде. Барыннан да бигрәк үзенә үпкәләде: шушы бандит белән юлга чыгарга ничек җөрьәт итте соң ул? Мулла песие шикелле хәтәр ипле кыланып йөргән була үзе авылда. Чын йөзе бөтенләй икенче икән аның...

Нишләргә? Бу сорауга җавап табу өчен аның вакыты юк иде. Сафетдин кызны үлән өстенә сузып салып, үзенең чалбарын төшереп, Рәлиянең итәген кармалана-кармалана күтәрергә кереште. Авыр гәүдәсе белән, сытардай итеп, кызның өстенә ятты.

— Абзыкаем, үзем-үзем... Тор... Хәзер... — дип, ризалык белдергәндәй, кыз үз өстенә ауган ирне этәрә төште. Хатын-кызны ихтыярына буйсындырырга күнеккән ир, җиңүче кыяфәтенә кереп, кызның аяк очына тезләнде. Мизгел арасында барлыкка килгән шушы арынудан файдаланып, җан көчен җыеп, кыз һөҗүмчесенең эченә типте. Сафетдин бөгелә төшеп, кырыйга ауганчы Рәлия урыныннан атылып торды да, аягындагы туфлиләрен як-якка чөеп, томырылып йөгерергә кереште. Чатан Сафетдиннең җәяүләп куып җитә алмасына ышана иде ул. Ат атланып куа чыгуыннан шөлләде кыз. Шунлыктан башта куаклар эченнән чапты. Күпме йөгергәндер, каршында өйләр күренгәч кенә аның эченә җан керде. Аланбашка түгел, Шомыртлыга килеп чыккан иде ул...

Айгырның буш тарантас белән кайтып туктавын күргәч, Исхакның йөрәге, төзәлмәслек фаҗига тууын тойгандай, җу итте, ашкынып тибәргә кереште. Үзен-үзе белешмичә, капка катына ашыкты. Атның байтак ара кешесез кайтуы күренеп тора: дилбегә җирдән сөйрәлеп барудан тузанланып беткән. Исхак тарантас башына тыгылды, аннан Рәлиянең кечкенә сумкасын табып алды. Аның эчендә Рәлияне күчерү хакында приказ күчермәсе һәм күпмедер акчадан башка берни юк иде.

Кызның Сафетдин янәшәсендә утырып китүен күргәч, Исхакның күңелендә үзе дә аңлап житкермәгән томанлы фикер уянып алды. Сафетдиннең хатын-кызга талымсызлыгын белсә дә, япь-яшь балага кул сузмас, андый хәлдә ни буласын чамалый бит, дип, яман уйларны башыннан куарга тырышкан иде. Ә хәзер...

Көчләп, үтереп ташламаса гына иде, дигән шик торган саен ныграк били төште Исхакны. Кабаланырга кирәк иде. Тарантаска сикерде дә айгырны колхозның атлар утары ягына борды. Атны алыштырып, юлга чыгарга җыенды Исхак. Эзләреннән районга чаклы бармакчы.

Колхоз рәисе Хәлимәгә сүз тиште дә юлга кузгалды. Рәлиянең кечкенә сумкасын хатынга калдырды. Сафетдиннең ихата тирәсенә сак куярга кирәклеген әйтте. «Әгәр кайтып күренә икән, кулларын бәйләп келәткә япсыннар да, аннары милиция чакыртырсыз», дип өстәде...

***

Авылга кайтуының беренче көннәреннән үк Хәлимә турындагы уйлар Хажиның күңеленә тынгылык бирми башлады. Хатын ошый иде аңа. Аның урынында башка бүтән булса, хисләрен әллә кайчан җиткерер иде. Җитәкче түрә бит, бер авыл халкына баш кеше. Шомыртлыдан кайтышлый, ярый әле кыюлык табып, күңелендәгесен җиткерә алды. Тел ачу өчен Хәлимә үзе сәбәп чыгарып куймаса, барыбер ачылып китә алмаган булыр иде...

Хәлимәнең эшкә кул селтисе килгән чаклары еш була. «Шушы хәлсез бәндәләр колхозны тагын күпме тарта алырлар? Өстәгеләр халык язмышы турында ни өчен ныклап торып уйланмыйлар икән?» — дип үзалдына сорау куеп, бер фикергә килә алмыйча аптыраган чаклары күп.

Җитәкчелектән китәсе килә хатынның. Катлаулы елларның авыр йөген тарту арытты аны. Ачлыктан сулып калган йөзләр, «Мина, зинһар, ике йөз грамм гына он бирмәссезме?» — дип каршысына сузылган, сөяккә калган куллар әле дә төшләренә кереп газаплый.

Тәлиганың абыйсы Хәкимҗан кайткач, Хәлимәнең җитәкчелектән баш тарту уе тагын да көчәйде. Эштән китү теләген райком секретарена да җиткерде. Хәмзин, хатынның хәлен аңлап, аның соравына каршы килмәде. Шулай да отчёт-сайлау җыелышына кадәр эшләп торырга киңәш итте. Димәк, ике-өч ай көтәргә кала. Вазыйфасыннан азат ителүнең икенче көнендә үк Хажи белән уртак тормыш корып, бергә яши башлау планы корганнар иде алар.

«Хәмзин белән кабат сөйләшеп карыйм әле, бәлки, отчётка кадәр үк китәргә рөхсәт бирер?» — дигән уен Хәлимә кичә Хажига җиткергән иде. Ир хатынның үз ихтыярына куйды: «Үзең кара. Ничек уңайлы саныйсың — шулай эшлә», — диюдән башканы әйтмәде. Ә үзе бүген иртүк идарәгә килеп керде.

— Син районга барырга ашыкма әле, — диде ул, кереп исәнлек-саулык алышкач.

— Ни өчен? — дип аптырап сорады хатын.

— Нигә безгә отчётны көтәргә? Бүген үк никахлашыйк та, бергә яши башлыйк. Тартып-сузып вакыт үткәрүдә хасият юк, — диде Хажи, ниятенең катгыйлыгын сиздергәндәй, һәр сүзенә басым ясап.

— Өйләнешкәч, мине азат итәрләр, дисеңме?

— Шул хакта уйла син: отчёт-сайлау җыелышында халык сине җибәрмәү өчен аяк терәп каршы килергә мөмкин. Ир хатыны булгач, рәис бул, дип артыгын кыстамаслар. Минем көне-төне тракторда эшләвемне беләләр бит. Хатыным була торып, хатынсыз яшәргә юл куймаслар, дим...

— Килешәбез, Хажи абый, — диде Хәлимә, энҗедәй тешләрен күрсәтеп елмаеп...

...Ярты сәгатьтән алар авыл советына язылышырга килгәннәр иде.

Аларның никахлашуына хатын-кызлар аеруча канәгать иде. Иң авыр елларда да кеше хәленә кергән, мөмкинлектән чыгып ярдәм кулын сузарга һәрвакыт әзер торган җитәкченең авылда төпләнеп калуы шатландырды халыкны...

***

Хисапчы Салих Баяновның чырышлыгына авыл халкы хәйран кала. Сыңар кулы белән ул ни җитте ирләр шаенә эшли. Кемнеңдер ярдәм итүенә өметләнеп яшәми: сыңар кулы белән ат та җигә, утын да кисә, печән дә чаба, йөген дә төйи. Узган ел хатыны белән икәүләп өй салдылар. Хәтта матча утыртканда да ярдәмгә кеше чакырмады.

Авылда шөгыль тавык чүпләсә дә бетмәле түгел. Узган ел Салих урам як киртәне

янарткан иде, чиратка икенче өлеш басты. Бәрәңге бакчасының арткы читәне авып төште. Көтү кайтканда Салих белән хатыны бакча артында чиратлап кизү торалар. Читәнлек талны кисте Салих, казык өчен имән агачларга кагылырга рөхсәт юк. Урман чистарту исәбенә беләк юанлыгы тирәсе чаган, чикләвек агачларын кисәргә ризалык бирделәр анa. Анысы өчен дә шатланып ризалашты.

Озакка сузмыйча гына, җай туры китереп, Бүләк урманына китте Салих. Чакрым ярым арадагы әрәмәлеккә тиз килеп житте ул. Ат алдына печән салды да урман каравылчысы күрсәткән агачларны аудара башлады. Үзенә тиешлесен кисеп бетереп арбага төягәч, йөкне кысып, кайту ягына кузгалды. Урманны чыгарга якынлашып килгәндә, чигәсенә текәлгән авыр карашны тоеп, ялт борылып карады һәм юлның бер ягыннан шыпырт кына килүче гәүдәне шәйләп алды. Чыраен сакал-мыек басып, киемнәре теткәләнеп бетсә дә, Салих арттан иярүченең кемлеген чамалады. Сафетдин иде ул.

«Ник качып йөри икән соң ул?» — дигән сорау туды Салих башында. Көтеп алып, әллә сөйләшергәме, дигән уй да килгән иде, үзе якынаерга теләмәгәч, күрмәмешкә салышып, атын атлата бирде. Кирәген тапса туктатыр иде, йомышын әйтер иде, дигән нәтиҗәгә килде ир.

Орган кешеләренең Сафетдинне эзләүләре турында ишеткәне юк Салихның. Рәлия дә жалу-мазар белән йөрмәгән, диделәр. Авыл советы рәисе Исхакның гына: «Судсыз-нисез бәреп үтерәсе бар ул бандитны», — дип сукранганы ишетелде. Өстенә гаеп ташланмаган килеш Сафетдиннең качып йөрүе икеләндерде Салихны.

Районга чираттагы баруында участок вәкиле Габсаттар Галәвиев белән Сафетдин мәрәкәсе хакында сөйләшергә булды Салих.

— Нишләп йөрисен? Әллә чакырдыларммы? — дип каршылады ул Салихны.

— Чакырмадылар. Сине күрергә кердем, сүз бар, — дип җаваплады Баянов.

— Тынлыйм, сайрап жибәр, — диде Габсаттар, бирeдә эшләүчеләрнең күпчелегенә хас тәкәбберлек белән.

— Минем шуны гына беләсем килә: Сафетдин ут булды да су булды. Өе кагаеп утыра. Тәрәзәләренә такта сугылмаган. Малайлар таш белән чүкеп, пыялаларын ватмагае, дим. Утырмый торгандыр бит, Сафины әйтәм?

— Әлегә юк. Ләкин кулга капса, томырыклаячакбыз, — диде Галәвиев, төйнәлгән йодрыгын өстәл өстенә биетеп.

— Гаебе зурмыни? — диде Салих, качып йөрүче авылдашының мәрәкәсен белмәгәндәй.

— Тау кадәр... Кыз баланың башын очлый язган бит... Сафи эзләүдә. Күзгә чалыну белән кулга алыначак.

— Ишек-тәрәзәләрен кадакларга ярамыймы?

— Сукәлми торыгыз. Жае бар.

— Аңлашылды, — дип Салих, Галәвиев белән саубуллашып, бүлмәдән чыгып китте.

*Ахыры киләсе санда*

**Нурлан ОРАЗАЛИН,**
*казакъ шагыйре*

## Коралай

Жырмыни соң бу? Бу бит — калтырау.
Йөрәгем өши ник әле болай?
Юкса җиһанда күптән инде Май!
Жанны каһәрле суык Коралай.

Чатнама суык! Сагыш күкләрдә.
Йөрәк сызлана. Афәт тирәмдә.
Чия чәчәге өшеп каралган,
Йөрәк сыкрый аңа карауга.

Агачлар мәхшәр күрә төшендә,
Яшел басулар — матәм төсендә,
Тауларны сагыш карасы сарган,
Жирне Коралай уратып алган.

Еракта таулар тора күренеп,
Салкын көбәгә гүя төренеп.
Коралай шулай ел саен килә.
Күнегә алмыйм аңа мин генә!

Башбаштаклана жирдә Коралай,
Тауларны айкап йөри Коралай.
Тупаслана хис, чуала фикер:
Жанны боргычлый,
Мине бораулый.

Юк! Мин ышанмыйм! Бу — бер төш кенә.
Ышанам яшел Язның көченә!
Жәй килер жиргә, ямьләп дөньяны,
Алтын нурларга төрер ул аны!

Аһ син, өметем! Хыялым кошы!
Могжиза булып кил миңа очып!
Тизрәк жиргә жылы Жәй житсен,
Туйдырды инде, суыклар бетсен!

Коралай йөри иңләп даланы,
Хакиме булып гизә каланы.
Яшәрменмени шулай тоткында?
Инде жырлыйм соң нәрсә турында?!

Суык Коралай гизә даланы.
Суык Коралай томалый аңны...

*Р.Корбан тәрҗемәсе*

**Жолдас СӘЕТНАЗАРОВ,**
*каракалпак шагыйре*

## Каен төбендә

Өй янында бөдрә чәчле,
И зифа каен! —
Үзе төсле сылу каен
Үстерде Айым.

Үстерде каенны Айым
Матур булсын дип,
Тирә-юньне, күңелләрне
Ямьләп торсын дип.

Язлар саен ямь-яшелгә
Каен төренә.
Көн саен кич чыга Айым
Каен төбенә.

Аның яшел яфраклары
Серле селкенә...
Ә егетнең җаны шунда,
Шунда җилкенә.

Айым каенга кагылмый
Үтмәде бер дә,
Ләкин очрашуларны да
Көтмәде бер дә.

Ә беркөн каен аны
Дәште үзенә...
Егет төбәлде Айымның
Яшьле күзенә.

Үбеп алды аны егет,
Оялды Айым.
Оялтты егет каенны,
Оялтты аен.

Әй бәхетле, карагызчы
Айымга гына!..
Чү, бу сөю билгеле тик
Каенга гына!

*Р.Миңнуллин тәрҗемәсе*

**Шеймит АЛИШЕВА,**
*кумык шагыйрәсе*

## Берәүгә

Укыганда
Шигырьләрем,
Нигә борынын чөясең?
Сөюне куй,
Башка нәрсә
Язып кара, диясең.

Мәхәббәттән
Авырыйм мин,
Ләкин котмим азагын.
Хәзер язмый
Бу сөюне,
Әйт сон, кайчан язармын?

**Турар КОЖОМБЕРДИЕВ,**
*кыргыз шагыйре*

## Кыргызлар

Әй тирбәлә жилдә кыргыз жыры,
Иннәренә салып бар моңын.
...Керә алсаң кыргыз йөрәгенә, —
Дөнья сөйләр акын барлыгын.

Таулар бездә — күккә ашкан дивар.
Ә болытлар — дөя көтүе.
Кем көнләшмәс кыргыз турсыгына! —
Кымызында күк һәм жир тәме.

Хәтта күлләр шигырь яза монда,
Алатаудай хыял югары...
Күкрәгенне тутырып бер суласаң,
Очып китәр коштай жырларың.

**Мурат КАЛМЫКАЕВ,**
*ногай шагыйре*

## Сагыну

Кайтсам икән, Жиленчәгем, катына,
Күрсәм икән дулкынында ай юлын.
Күмәр идем хәсрәтемне комына,
Бүләр идем жан дусындай кайгымны.

Кайтсам икән, Жиленчәгем, ярына...
Шифа суын жан гөлемә охшаган.
Кобан иле сенгән минем каныма,
Тамырларым эсселектән сусаган.

Кайтсам икән, Жиленчәгем, янына...
Күңелләрем тартыла гел аклыкка.
Бер утырсам дулкын юган ташына,
Тулыр иде киң күкрәгем шатлыкка.

Жиленчәгем хәләл сөттәй кадерле,
Ул мәңгегә тугры калган ярына.
Жырчы килеп сиңа колак сала да
Яңа моңнар таба үз жырларына.

*Р.Вәлиев тәрҗемәләре*



Зиннур
Хөснияр

# ГАРАСАТ

РОМАН

## Кырмыска оясы

Ә каберне кем актарып атканны авыл халкының да беләсе килә иде. Әллүкинең, бигрәк тә Әбелхәят чишмәсенең кая китеп юк булганлыгын беләселәре килә. Соң! Шулай булмыйча! Соңгы вакытларда Байтамак гел табышмакка әйләнде. Полиция, үзләре әйткәнчә, Борисны үтергән җинаятьчене дә көне-төне эзли. Менә-менә очы табылды дигәндә генә — әйтерсең, әлеге серле йомгак белән тол хатын Саниянең ата мәчесе уйный! — ул шундук югала да. Тагын эзли башлыйлар. Халык: «Элеккеге Хәйбүш милиционер малае полиция Мирза да тапмагач инде җинаятьчене!» — дип шаклар ката. Чөнки моңарчы участковый булып торган милиционер Хәйбулланың малае туганда ук шымчы булып туган, аның борыны этнеке кебек ис сизә, күзләре исә лачыннникы сыман үткен дип сөйлиләр! Тик Хәйбүш малаенын башы-аягы илә җинаятьне ачу белән шөгыльләнергә вакыты җитеп бетми: ул өйрәнә! Башкалардан! Телевидениенең барлык каналларыннан да инде икенче дистә ел барган милиция-полиция турындагы фильмнарны җентекләп карый, кинодагы һәр ачылган җинаятьне анализлап, үзенең кызыл тышлы дәфтәренә теркәп бара!.. Кирәк урында кино төшерүчеләр белән бәхәскә керергә дә ярата, аларның дөрес түгел, үзенең хаклы икәнлеген дәлилләп, сценарий авторларына, режиссёрларга озын-озын хатлар яудыра иде...

Байтимер, аптыраганнан, җинаятьчене табучыга бер миллион сум бүләк вәгъдә итте. Бу бик зур акча иде. Авыл халкы бу юлы Хәйбүш малаена көнләшеп карады: «Табачак һәм теге миллионны кесәсенә тыгып та куячак!»

Ә Әллүки күлен кире үз урынына кайтарган кешегә нинди бүләк булачак? Бу хакта Байтимергә Камай әйтеп ташлады һәм шундук нигә әйткәненә үзе дә үкенеп куйды: Әллүки Борис фаҗигасе кебек үк Баймурзинның бәгырь үзәгендә таш булып каткан бер кайгы иде. Чөнки әнә нинди сүзләр йөри бит: имеш, Байтимер кайтып, үзенең агрофирмалары, агрошәһәрчекләре белән бу як халкының башын катырмаган булса, мондый хәлләр, бәлкем, килеп тә чыкмас иде! Кырмыска оясын шул кайтып бутый башлады бит! Самолётларында гына очса иде шунда канә! Очалар бит әнә! Чуваш теге заманда ук галәмгә менде! Хатын-кызлар очты

*Ахыры. Башы 5, 6, 7 саннарда.*

галәмгә! Типсә тимер өзәрлек Байбулат малае, космонавт булып күкрәк киереп йөрисе урынга, тирес корты кебек жирдә казынырга кереште!

Халыкның теле ачы иде, усал иде һәм, бәлки, алар хаклыдыр да әле? Алайса нигә космонавтлар төркеме турында бер дә сөйләми ул Камайга?! Шул хакта сүз чыгуга, кинәт кенә тел яшерә, сер саклый, янәмәсе! Ул сер түгел, сер ул, әнә, элеккеге Әллүки урынында, сер ул зират буенда Борис гәүдәсе табылган урында, сер ул Алтын Бәртәскә кайтып оялаган «шайка»ның кыланышлары! Вәт ичмасам болар чып-чын серләр!..

— Бүләкне ике миллион итмисенме, Байтимер абый? — диде Камай.

— Өч итәбез! — диде Байтимер ачу белән. Байтимер бик итагатьле, әдәпле кеше булса да, соңгы вакытта холкында дуамаллык төсмерләре дә чагыла башлады. Бала башы кадәр йодрыгы белән бер китереп сукса, кабан дуңгызын бәреп үтерә алыр иде. Ләкин монарчы беркайчан да тугарылганы булмады, хәзер менә исә еш кына, иреннәрен кысып, тешләрен чыкырдата торган булып китте. Чөнки Байтамактагы бу сәер хәлләрнең сәбәпчесе итеп, чыннан да, үзен саный башлаган иде бугай ул?!

Нәрсә булса да эшләргә кирәк иде! Монысы көн кебек ачык мәсьәлә! Халыкның тамагын ипи белән туйдырып кына гасыр буе җыелып килгән тузанны кагып булмый, күрәсең. Җәмил хәзрәт хаклыдыр: Гарасат төтене бар Рәсәй күген каплап алган да Җиргә аның аша Кояш нурлары үтеп керә алмыйлар! Нурлы фәрештәләр үтеп керә алмый адәм балалары янына! Җәмил хәзрәт элеккеге күл булган урынга барып Коръән чыгарга ниятләде. Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен!.. Байтимернең саулыгы-сәламәтлеге өчен... Аллаһы кабул итсен!.. Сәдакасын Байтимер үз куллары белән бирергә дип ниятләде...

Тик аңа кадәр... Әйе, Алтын Бәртәстәге «Эл-Рахим-Иуда» шайкасы аның бик эчен пошырды. Ул, хәрби офицер буларак, бер план корды. Әлеге план аннан башка тагын Камайга гына билгеле. «Кырмыска оясын тузгытырга вакыт!» дигән карарга килде алар.

Ишегалды өстендә вертолёт асылынды, шунын артыннан ук тирә-юньне ак төтен каплап алды! Камай биек таш койма аша кулындагы соңгы «төтен җайланмасын» ыргытты да:

— Гарасат төтене килә өстегезгә! Кача алсагыз, тизрәк качып котылыгыз! — диде.

Вертолёт коттеджга терәп салынган махсус мәйданчыкка төшеп утырды. «Әллә Абрек Хөллиев янадан терелеп кайтканмы?!» — дип аптырашты алтынбәртәсләр. Чөнки вертолёт белән шул рәвешле өенә элек ул гына кайта торган иде. Шунын артыннан ук ишегалды өстендә икенче вертолёт пәйда булды һәм аннан бау баскыч суздылар. Беркавымнан әлеге баскычның очында чәбәләнгән бер адәм күренде, аны вертолёт ишегеннән эчкә суырып алдылар.

— Мин хәзер үк Эл-Раисоффка шалтыратам! Җибәрегез мине! — дип боерды вертолёт эчендәге Радий.

— Хет шунда әллә кемгә шалтырат! — дип җавап кайтардылар аңа!

— Сез ни имеете право! Миңа шалтыратырга мөмкинлек бирегез! Ул сезгә барысын да аңлатыр!

— Кем соң ул синең Эл-Раисоффын?

— Сөләйман Эл-Раисофф ул — КГБшник!

— КГБ?! Син нәрсә, абзый, ычкындыңмы әллә?! КГБ күптән юк инде ул! ФСБ! ФСБ диген ичмаса, адәм актыгы! Бәлки, ЦРУ яки Моссадтыр?!

— Юк! ФСБ түгел! ЦРУ да, Моссад та түгел! КГБ! — дип, аның саен үзенекен тукыды Радий. Аның яшькелт күзләрендә аллау чаткылары сизелмәде, күрәсең, ул ниндидер бер житди оешма хакында сүз алып бара иде.

— Җиргә төшкәч, шалтыратырсың! Хәзер без синең теләгенне үтәп, кире җиргә төшерәбез. Тик парашютсыз гына!

— Бәхти абый! Алла хакы өчен дим, шалтыратырга рөхсәт ит, зинһар!

— Ah, шайтан, син минем исемне каян беләсең әле?

— Беләм... Аннан соң сөйләрмен!

Ул изүен аерды һәм аннан бауга эленгән тәре алып:

— Ышанмасаң, менә тәре үбеп ант итәм!

Бәхти йодрыгы белән аның колак төбенә томырды һәм ачулы тавыш белән:

— Әйдә, мари сазлыгына ташлыйбыз моны! — дип кычкырды. — Беркем дә эзләп таба алмасын!

## Үч алучылар

Хөллиев коттеджыннан җәмгысе утыз өч кешене җыеп алдылар. Законсыз коралланган өчен боларны шундук полициягә озатырга кирәк иде. Ләкин Байтимер ашыкмады, чөнки ул алар арасында үзенә таныш булган егетләрне, ир уртасы кешеләрне очратты. Ин гаҗәбе шул: аларның һәркайсында Радий сейфында мәгълүмат бар һәм үз куллары белән язылган ике-өч битлек кәгазь төпләнмәләре сакланган.

Байтимер әүвәл үзенә таныш өч егетне чакыртып кертте. Болар теге вакытта фермер хуҗалыгы ачабыз дип кредитлар юнәтеп йөргән һәм җир алган Мөсәлим, Хафиз һәм Ясәви атлы егетләр иде.

— Сезгә нәрсә җитмәгән инде, егетләр? — диде ул, аларны каршысына утыртып. Алар өчесе берьюлы аның өстәлендә таралып яткан кәгазь төпләнмәләренә төртеп күрсәттеләр. — Анда барысы да язылган!

— Язылганны укыдым мин. Менә, Ясәви, син үзең дә аңлат әле? Син зур суммада фермер хуҗалыгын өчен кредит алган идең. Бар нәрсәң дә бар иде югыйсә?

— Ул кредит башымны ашый язды минем. Акчаны алган чакта банк белән төзелгән договорны игътибар белән укымаганмын. Хәер, алар адәм танырлык түгел иде, вак хәрефләр белән кырыйда язылган искәрмә буенча минем кредитның проценты, банк ягы ихтыяры буенча ай саен арттырылырга мөмкин икән! Өстәвенә мин кредит алган банк банкрот булды, аны икенче зуррак банк үзенә кушты һәм теге договор нигезендә процентны биш тапкыр арттырып куйды! Мин нишләргә тиеш идем? Бауга менәргә! Асылынырга мы?! Рәхмәт, Радий коткарып калды, дөресрәге, аның янына качтым. Мин югалгач, гаиләм өстенә ябырылганнар, карт анам белән хатыным йөрәк чирләре башланып, җан тәслим кылдылар. Радий акча бирде, көчкә түләп котылдым дигәндә, тагын мин белмәгән «неустойка» килеп чыкты. Ике баламны туганнарга яшереп, Радий янына качтым. Ул тагын акча бирәм дигән иде. Менә шундый фермер инде мин, Байтимер туган!.. Әнием белән хатыным хакына! Әйе, мин хәзер барысына риза! Югалтыр нәрсәм юк! Шул... балалар инде!

— Аңлашылды, — диде Байтимер күңелсез генә. — Бу Радийга андый акча кайдан килде икән соң?

— КГБ биреп тора иде! — диде Мөсәлим атлы икенче «фермер».

— ФСБ?

— Юк, КГБ! — дип кабатлады ул һәм чират үзендә булганлыктан, өстәмә мәгълүмат бирде:

— Минем җирне зур инвестор үзенә оформить иттерде! Минекен генә түгел, без җирләре янәшә булган икәү идек, икенчесе — элеккеге колхоздан сакланып калган «Чишмә». Аның рәисен дә, директор дип атала иде инде ул, мине дә китереп кыстылар. Глава сүзенә ничек каршы барасын?!

Мөсәлим сөйләп бетергәч, Хафиз дигәне сөйли башларга керешкән иде, Байтимер аны шунда ук туктатты:

— Анладым, туган, анладым. Монда син бик тәфсилләп язгансың! — диде һәм өстәп куйды: — полиция-мазар килеп чыкканчы, тизрәк өйләрегезгә сыпыртыгыз! Мин сезне берничә көннән чакыртырмын, — диде ул аларның һәркайсына кул биреп. Тегеләр куанышып таралыштылар. Байтимер калганнары белән очрашып сөйләшеп тормады, дәфтәр-төпләнмәләрдә барысы да язылган иде. Беркавымнан егетләрнең Ясәви атлысы кире әйләнеп керде һәм, Байтимер каршына килеп:

— Байтимер абый, Сезгә дә алтыннарны, нуу, агрофирма өчен акчаларны Мәскәү ФСБсы биргән бит, әйеме? — Шулай дип сөйлиләр бит, Байтимер абый. Сине, космоска очырмыйча, җирдә генә калдырыр өчен!.. — диде.

— Ә нигә нәкъ менә мине? — Бу хәбәр Байтимернең үзенә дә бик кызык тоелды. — Нигә нәкъ мине? — дип кабатлады ул соравын.

— Чөнки син татар бит! Татарлар тырыш, үҗәт халык, космоска менгерсәң, элек безнең бабалар бар җирне үз кулында тоткан кебек, космосны да басып алырлар дип курыкканнар, ди, имеш?

— Имеш кенәме? Син чынлап та шул әкияткә ышанасыңмы, Ясәви?

— Халык сөйләгәч инде... Җирдә генә эшләсен дип, сиңа күп алтыннар биргәннәр, ди. Кирилл попка биргән шикелле.

— Нәрсә, Кирилл атакайга да биргәннәрмени?

— Ул чиркәүгә йөргән һәр кешегә алтын тәре өләшә. Радийда да бар андый. Ул аны махсус тикшерттерде, чын алтыннан коелган ди...

— Ә мин алтыннарны үзем таптым, җир астыннан, — дип куйды Байтимер, әлеге хәбәрдән уйга калып. Ясәви ишек ягына таба борылды.

— Ә сезнең максат нинди иде соң? Шулай гомер буе качып яту идеме? — дип сорады аннан Байтимер.

— Юк, — диде тегесе. — Җәберләүчеләрдән үч алу иде!..

— Сәнәк сугышына күтәрелепме?

— Нигә сәнәк сугышы?! Безнең чын автоматлар бар иде!

— Алай икән, — дип куйды Байтимер һәм, чыгып кит дигәнне аңлатып, кулы белән ишеккә ишарәләде. Янәсе, бәласеннән баш-аяк, югыйсә әллә нинди сүзләр сөйли башладың!.. Боларны һич кичекмәстән полициягә тапшырырга кирәк, дигән карарга килде ул Ясәви белән сөйләшкәннән соң. — Нигә мин алардан тикшерүче кебек сорау алып утырам әле? Бу полиция эше бит.

Бу вакытта полициядә эшләүче Хәйбүш малае үзе дә ишектән килеп кергән иде.

— Байтимер Баймурзин! Нинди башбаштаклык бу? Нигә бандитларны безгә тапшырмыйча монда җыеп ятасың?!

— Җыеп ятмыйм. Син килгәнне көтеп утырабыз менә... Бар, алып кит һәммәсен җыеп.

Хәйбүш малае мәсьәләнең шулай җиңел генә хәл ителәсенә ышанып бетмәгән иде, күрәсең, ул өстәлгә якынрак килде һәм бу юлы тыныч тавыш белән генә, хәтта мескенләнгән кыяфәттә:

— Байтимер абый, әйдә, сөйләшик әле. Сиңа проблема кирәк түгел бит, әйеме?! Хәзер бит синнән сорау алулар башланачак, тинтерәтеп бетерәчәкләр үзеңне. Әйдә, болай эшлибез: бу банданы мин... ну, тагын ике-өч полицейский белән инде, мин, без тоттык. Син бары шаһит кенә булып катнашасың! Ничек бу фикер, ә? Байтимер абый?

— Алар — КГБ кешеләре, — дип куйды Хәйбүш малаеның бу оятсызлыгына ачуы килгән Байтимер.

— КГБ? Чынлапмы? Шаяртасыңдыр?

— Миңа ышанмасаң, үзләреннән сора!

Бу хәбәр Хәйбүш малаеның колагына да килеп ирешкән иде инде, тик ул аңа ышанмады. КГБ чаклы КГБ нигә боларга акча биреп торсын инде! Бандитлар бит болар? Ләкин Байтимер дә шулай дип торганда, ышанмыйча да булмый! Беркавымнан ул телгә килде:

— Байтимер абый! Синең КГБда танышларың бардыр инде? Синең акчаң күп бит хәзер. Атаклы кеше.

— КГБда юк, ФСБда бар, — дип куйды тегенең тел төбен анлап алган Байтимер.

— Юк, — диде беркатлы Хәйбүш малае, — ФСБ кирәк түгел, НКВД, то есть КГБ кешесе кирәк. Будто бу операцияне без бергә әзерләгәнбез...

— Бар, энем, мешать итеп йөрмә монда, бандитларыңны моннан җыеп алып кит тә! — диде Байтимер, янә ишеккә күрсәтеп. — Болай да күпме эшемне калдырдыгыз!

— Байтимер абый, ә син шаһит булып барырга ризамы соң?

— Риза! — диде Байтимер һәм янә ишек ягына таба ишарәләде.

Дөрестән дә, аның вакыты тар иде, чөнки өстәл тартмасында калганнарның да дәфтәр-төпләнмәләренең күчермәләре бар, Байтимернең тизрәк шулар белән дә танышып чыгасы килде. Бу якларда инде хуҗа кеше буларак ул барысын да белергә тиеш бит!.. Байтимер ишекне эчке яктан бикләп куйды да, янә өстәл артына барып утырып, баягы тартманы ачты һәм укый башлады: «Минем максатым — үч алу! Карагыз әле сез Галин дигән көтүче малаеның ничек кылануын! Янәшәсендә сынар телем ипигә тилмергән авыл кешеләре яшәп ята. Ә ул җиде миллионга биотуалет эшләтте! Унсигез миллионга коттедж түбәсен яптыртты! Бу бит күрә торып мыскыл итү! Боларга каршы көрәшкә күтәрелер вакыт җитте!»

«Турханов малае исерек килеш кинодан кайтып барган бер төркем яшьләрне таптатты. Минем кызыма, бәхеткә каршы, зыян килмәгән иде. Калганнар барысы да һәлак булды. Кызым шаһит булып барырга җыенгач, безнең гаиләне эзәрлекли башладылар. Әүвәл акча тәкъдим иттеләр. Без баштарак риза да булган идек. Кызымның сөйгән егетенең атасы килеп, әгәр шул кабахәтне якларга уйласагыз, балаң мәңге бәхет күрмәячәк, дип каргап китте. Кызым кире уйлады. Акча алмадык. Шуннан соң кызымны тотып көчләделәр, аннан соң көчләүчеләргә каршы да судка гариза язгач, бөтенләй урлап ук киттеләр. Мин кызымны кайда яшереп тотканнарын беләм! Барыбер табачакбыз! Радийга рәхмәт! Ул булышам, диде! Түрә малае төрмәдә черергә тиеш!»

«Без, татар, чуваш, удмурт Үзәкнең 309-ФЗ (01.12.2007) карарына каршы! Ул безнең милли хисләребезне мыскыл итә! Ябалак мәктәбендәге хәлләр (Бар милләтләрнең татар телен өйрәнә башлаулары) ул диңгездәге бер тамчы гына!

Татарстанның 80 процент байлыгын суырып яталар!

БМО Генераль Ассамблеясенең 1966 елның 19 декабрендә кабул ителгән халыкара пактын Рәсәй хөкүмәте кайчан тормышка ашырырга уйлый?! Без бу илнең лаеклы халыклары, без телебезне күрәләтә кисүгә, гильотина астына куюга каршы! Радийның элемтәләре бик зур! Ул бергәләп көрәшик диде!»

«Америка белән Аурупа әүвәл Әфганстанны, Гыйракны канга батырдылар, аның артыннан Ливия, Сүрия! Без аларга каршы терактлар оештырачакбыз! Радийның коралы күп!»

«Әтинең байлыгын җыен әтрәк-әләм талап бетерде. Фамилиям Хөллиев булмаса да, мин аның барыбер бердәнбер малае. Миндә аның каны ага. Байтамактагы, Алтын Бәртәстәге коттеджларына минем тулы хокукым бар! Докажу мин моны, докажу! ДНК дигән нәрсә бар бит әле! Чәчен кисеп алам да... Кабере монда гына бит!..»

Түбәндәге язма ни өчендер кызыл кара белән аркылы-торкылы сызылган иде: «Минем җаным икегә бүленде, кыл урталай бүлендем. Мин үземнең динемнен

сафлыгы өчен ахыргача көрәшәчәкмен! Радий син хаклы, ди. Мин ана ышанам. Ул — мине анлаган бердәнбер кеше! Әтине минем үтергәнне Радий белә. Ә башкалар мине тилегә санадылар!..»

Байтимер әлеге дәфтәрләрне укып чыкты да уйга калды. Нишләргә болар белән дигән сорау битәрләргә керешкән иде аны. Шулчак ул, җәһәт кенә урыныннан торып, каминга ут элдерде һәм әлеге күчермәләрнең барысын да диярлек утка ташлады. «Бәласеннән баш-аяк...» — дип пышылдады ул. Кулында бер генә дәфтәр сакланып калган иде, ул аны башкалар белән бергә утка атмады, яшереп куйды. Әлеге дәфтәрдә атасын үтерүченең язуы иде...

Нәкъ шул кичне районның полиция бүлеге башлыгы Колоколов та дәфтәрләрнең төп нөсхәсен утка атты. Ул да Байтимер кебек берсен генә саклап калды. Анда Америкага каршы өндәүләр язылган иде... Дәфтәрләр төтенли-төтенли яндылар да әлеге аксыл төтен, моржа аша һавага чыгып, күккә күтәрелде һәм үзенә бертөрле аерым болытлар хасил итте. Алар кайчандыр, кайдадыр барыбер җиргә яңгыр булып явачак иде... Әлегә бу аксыл болытлар башкалары рәтендә күк хозурында йөзә һәм алар һәммәсе бергә, Җәмил хәзрәт әйткән гарасат төтеннән оешкан болытлар кебек ишәеп, күбәеп, авыраячаклар, төсләре каралачак һәм яшен утлары белән күк гөрелтесе аларны Җир шары өсте буйлап таратачак иде...

Берничә дин нигезләрен яхшы үзләштергән Радий Гарасат мәйданының ни икәнлеген яхшы белә. «Без бит халыкны Гарасат мәйданына этәрүчеләр түгел, киресенчә, күк йөзебездәге Гарасат төтене, болытлар хасил итеп, өстебезгә яумасын өчен көрәшүчеләр!» — диде ул Байтимергә, икесе генә калгач. «Син демогогия белән шөгыльләнәсең, Радик! Үзең сафлык өчен көрәшәбез дисең, үзең сатлык Әл-Рәисофф командасында икәнсең!» Радик Байтимернең бу соравыннан соң көлемсерәп куйды: «Алар безгә күп итеп акча бирә! Без үзебезнең максатларны тормышка ашыру өчен, дошманның байлыгыннан файдаланабыз! Мин бу сүзләрне беркемгә сөйләмәскә «подписка» бирдем! Ә менә сиңа сөйлим!.. Беләсеңме, нигә сөйлим? Әйтәм, чөнки син үзең дә «подписка» биргән кеше! Бик теләсәң дә, мине сата алмыйсың син, туган!» Байтимер аптырап башын чайкады, Радикка каршы әйтерлек сүз тапмады ул. «Син, мөгаен, психический авыру кешедер?» — дип кенә куйды. Тегесе аның бу сүзләренә каршы үпкәләр дип уйлаган иде, ләкин киресенчә килеп чыкты: Радик ямьсез дәү авызын чабата чаклы итеп ерды һәм: «Син дә сау-сәламәт түгел, Байтимер коллега!..» — диде. Бу сүзләрне шундый ышаныч белән әйтте ки, әйтерсең, ул авыруга иң дөрес диагноз куйган табиб иде. Бигрәк тә Байтимерне Радикның оятсызлыгы шаккатырды! Нигәдер ошый башлады ана бу башкисәр егет. Әнә, нишли, рөхсәтсез-нисез барып ачык тәрәзәне ябып куйды, әйтерсең, аларның сөйләшкәнен урам якта тыңлап торалар иде. Алар шуннан соң да байтак сөйләштеләр, дөресрәге, Байтимер тыңлап кына утырды. Соңыннан Радик урыныннан торды да: «Маргарита Ситдыйкованың, сине уйлап, Парижында саргаеп ята анда. Каенатаң полковник Ситдыйков отставкага китте!» — дип куйды. Байтимер: «Тәмам ычкынган икән инде бу!» — дип уйларга да өлгермәде, тегесе сүзен дәвам иттерде: «Үз акылымда шул мин, Баймурзин! А это плохо, для меня плохо... Урысны урыс үзе юкка чыгара, татарны — татар... яһүдләр дә шулай ук. Тик алар, урыс белән татардан аермалы буларак, үз-үзләрен корәлгә ашамыйлар, кыланмышлары юкка чыгарачак аларны. Котырган урыс аюы таптап китәчәк аларны... Урыс аюы гына түгел... Гитлерны искә төшерегез, аның яһүдләргә булган мөнәсәбәтен... Грузин Сталинның!.. А это плохо, очень плохо...»

Байтимер Радий-Радикны полициягә тапшырмады. «Әлиф. Ләм. Мим», — диде тегесе, ишектән чыгып киткәндә. «Әлиф. Ләм. Мим», — дип кабатлады Байтимер авыз эченнән генә...

Бу хәлләрдән соң Байтимернең кәефе китсә дә, тора-бара әлеге вакыйгалар аны

кайбер уйларга да этәрде. Беркөнне Илдар Гыймаевка ничек язарга кирәклеген өйрәтеп торган Камай хаклы. Нәрсә ди бит: әгәр син җир эшкәртү турында язасың икән, сука турында гына түгел, аны уйлап чыгарган «Плуг» фамилияле немец турында да белергә тиешсең; җирләрнең барысын да сукаларга ярамаганлыгын, ягъни кайбер урыннарда өсне йомшарту да җиткәнлеген сиңа агрономнар үзләре аңлатыр, баш ватып торасың булмас, тик менә син шул җирдәге суалчанның нинди файда китергәнен, тракторчының кәефе нидән яхшы икәнлеген дә искә алып язсаң, чынлап та җир турында, игенче хакында җүнле әйбер яза алырсың. Бу гына түгел әле, тракторчы тире белән җиргә ялгыш тамган бер тамчы солярканың, әлеге җирдә үсеп җитеп, фураж яки печән булачак культураларның ахырда, сыер корсагында эшкәртелеп, барыбер сөткә әйләнәчәген һәм теге әйткән солярка тамчысы белән бер стакан сөтнең бәһасе нигә тигез түгел икәнлеген дә исбатлап бирә алсаң, син чынлап торып әйбәт журналист, ләкин язучы-әдип түгел әле. Әдип булып сүз әйтү өчен, солярка белән сөт бәһасенең гаделсез аермасын яхшы белгән тракторчының арып өенә кайткач, хатыны нигә тавыш чыгарганлыгын ачыклап, ахыр чиктә тракторчының барысын да ташлап, шәһәргә күченеп китү турындагы уйларын сурәтләп бирә алсаң, син почти язучы. Тик чын язучы түгел әле. Чын язучы булыр өчен, җирдәге әлеге икмәкне үстергән Кодрәт иясенең Җәбраил фәрештәсе аша сиңа, нәкъ менә сиңа вәхи килүе кирәк. Җәбраил фәрештә әйтеп тора, әдип дигәнең язып кына бара. Чын язучы менә шул булыр. Син күккә кара да колак салып тыңлап бак: берәр нәрсә ишетәсеңме, юкмы? Юк, ишетмәячәксең: әгәр син чын язучы булсаң, әлеге вәхи сине өстәл артына үзе куып китерәчәк!..

— Камай, син алай бик акыллы булгач, әйт, нишлибез бу күл белән? Теге фермер кисәкләре белән? — диде Камайның күп сөйләшүенә эче поша башлаган Байтимер.

— Байтимер абый. Мин бит боларны юкка сөйләмим. Үзем сөйлим... сөйләгәндә башка вәхи килә тора.

— Пәйгамбәрме әллә син вәхи килергә?!

— Пәйгамбәр түгел, Байтимер абый, соңгы пәйгамбәр җиргә килеп киткән инде. Менә тыңлале син: бер яһүд бала коляскалары чыгара торган заводта слесарь булып эшли, ди. Хатыны моңа әйтә икән: «Абрам, син көн саен булса да берәр деталь кыстырып чык, алайса бу хезмәт хакыңа гына яшәрлек түгел», дип. Хатын дөрес әйтә бит, дип уйлый Абрам. Мин көне-төне эшлим, барыбер җүнләп акча түләмиләр. Ә үзләре хезмәт хакын премияләре белән бергә капчыклап алалар. Күршедәге берни эшләмәгән малайлары затлы машиналарда утырып йөри! Ә минем хәтта яхшы велосипед алырга да рәтем юк! Шуннан соң яһүд булачак балаларына коляска җыяр өчен көн саен заводтан берәр деталь чәлдереп чыга башлый. Шулай бер капчык тимер-томыр җыелгач, яһүд алардан коляска җыярга утыра. Берзаман Абрам хатынына әйтә: «Карале, Сара, ничек кенә җыеп карасам да, барыбер пулемёт килеп чыга бит болардан», — ди! Дөньяга ачулы яһүд бала коляскасын да пулемёт эшләгән кебек эшли...

— Бер дә кызык түгел, морале нидә?

— Миңа да кызык түгел, кызганыч, аяныч бу! Байтимер абый, шуңа күрә сөйләвем дә. Син агрофирмадагыларга никадәр генә яхшылык кылма, алар барыбер көн саен берәр көрәк сабы булса да сындырачаклар. Әллә, мин әйтәм, үзләренә атап җир бүлеп бирергәме икән?

Байтимер үзе дә шул хакта уйлана иде, Камайның фикере күңеленә хуш килде:

— Андый исәп бар минем, — диде ул.

Камай янә шаяртырга керешә:

— Әйттем бит мин сиңа, Байтимер абый, мин Илдарга юкка гына акыл

сатмадым. Үземнен дә шундый нәрсә башка килде минә. Тагын... теге мәзәктәге яһүд малае кебек. Сөйлимме?

Камай җавап көтеп тормады, чираттагы мәзәген сөйли башлады:

— Атасы малайны кибеткә балга җибәрә, ләкин акча бирергә оныта. Малай кибетчегә чүлмәген суза да: «Тутырып бал салыгыз!» — ди. Кибетче чүлмәкне тутыра. Шуннан малай мона: «Үзем белән акчам юк икән, иртәгә әти китереп түләр!» — ди. Кибетче кычкырып җибәрә: «Беләм мин сезнең иртәгәгезне! Бир чүлмәкне кире!» — ди дә балны янадан бушата. Малай буш чүлмәкне алып әченә карый һәм: «Дөрестән дә, әти хаклы булган бит! Монда мина ике-өч бутербродлык бал калган әле!» — ди. Юкка акыл сатмадым мин Илдарга, так что... безгә дә калды бер-ике бутербродлык, Байтимер абый.

Кем әйтмешли, теләгән — әмәлен, теләмәгән сәбәбен табар. Байтимернең урман буенда әле кул җитмәгән шактый җир кишәрлекләре бар. Ул әүвәл теге өч егетне — Ясәви, Мөсәлим һәм Хафизны чакыртып алды. Әлбәттә, болар биш куллап риза булдылар, чәчебез белән җир себерсәк себерәбез, менә дигән хуҗалыклар оештырабыз дип вәгъдәләр иттеләр. Шуннан соң Байтимер калган халыкка да җир кишәрлекләре хакында игълан итте. Әлбәттә, мона төрле карашлар булды. Күбесе агрофирмада эшләп, акчасын гына алырга күнегеп киткән һәм андыйларның муеннарына камыт кияселәре килмәде. Хәер, андыйларның гаиләдә булышыр кешеләре юк иде. Моны ишетүгә, иң беренче булып кытай Минҗан колагын торгызды: янәсе, кешеләр табабыз, табабыз. Чөнки Кытайда аның туганнары, кардәшләре байтак әле. Тик Байтимер аны шунда ук тыйды: «Кытай туганнарың Нөкрәттән дә качып киттеләр», — диде. Әлбәттә, Минҗанга каты бәрелергә ярамый, Байтимер җайлап әйтте: янәсе, Рәсәйдә әлегә кануннар тәртипкә китерелеп бетмәгән, кытайлар, имеш, демократиягә өйрәнгән халык, түзә алмаслар, аларга бик кыен булыр. Соңрак, соңрак килер кытай туганнарың... Дөньялар иминләнгәч, Рәсәйдә чын демократия башлангач... Ә үзе башкача уйлый иде: Себердә менә дигән татар яшьләре бар! Күбесе марҗа итәге астында әчеп яки наркотиклар белән кырылып бетеп бара! Менә шул егетләрне чакыртырга кирәк! Шәһәр ерак түгел, теләгәннәре югары уку йортларына керер! Әгәр дөнья буйлап сибелгән татарны монда тартабыз икән, моның бернинди сәяси дә, икътисади да гаебе юк лабаса! Чөнки аларның күбесенең бабалары Столыпин вакытында китеп урнашкан, аннан соң инде, әлбәттә, кулак оныклары! Рәхмәт Минҗанга! Бу план шәп план иде! Чү! Мондый максат әтисе һәм Илдар Гыймаевта да бар иде түгелме соң? Себердән сәяхәттән кайткач, шулай дип хыялланып утырганнары хәтерендә әле. Хәтта Илдар Гыймаев кайбер яшьләрне монда кайтарырга дигән уйлар белән янып та йөрде. Араларында бик талантлы аспирантлар бар, өстәвенә үзләре шигырьләр дә яза. Илдар менә шуларны тартырга уйлаган иде Казан тарафына. Тик монда аның әлеге фикеренә колак салучы булмады бугай, егет соңыннан үзе дә суынды. Кыскасы, себердәге егет-кызларны бу якларга кодалау уен Байтимер күнеленә ныклап салып куйды. Әүвәл авылдашлары белән мәсьәләне хәл итеп бетерәсе бар, чөнки, гаиләләре ишле булганнар Байтимернең ошбу фикерен күтәреп алдылар. Бер түрә, аның бу фикерен тынлап торганнан соң, бармагын чигәсенә куеп күрсәтте, янәсе, нигә үз җирләреңне таратасың?! Ләкин Байтимернең карары катгый иде: аның агрофирмасында аннан башка да җитмеш сигез мең гектар җире бар. Агрофирма өчен шуннан да артыгы кирәк түгел, моның шулай икәнлеген тормыш үзе күрсәтте лабаса! Аннан... аннан соң аның исәбе — акрынлап агрошәһәрчек төзү. Моны югары җитәкчелек биш куллап күтәреп алачак, моның өчен башка җирләр дә табылачак! Галин никадәр генә бай һәм элемтәләре көчле булса да, югары җитәкчелектән узып, берни кыла алмаячак! Байтимернең башы «Наполеонныкы кебек эшләде», соң чиктә, әгәр бу

планнар барып чыкса, ул Галинны да үз итәге астына җыеп кертәчәк, чөнки теге җир белән берни эшләми, бөтен максаты — бәя арттырып, кишәрлекләр сату. Әмма әлегә бу аның яшерен сере иде, ул ошбу фикерен бер генә кеше белән, ул да булса, Камай белән генә уртаклашты. Дөрес әйтә, Камай мең тапкыр хаклы: халыкны җиргә беркетү өчен, башка ысуллар хакында уйларга кирәк, югыйсә, агрофирмада көрәк сабы сындырырга йөрүчеләр байтак бит. Үзе күреп тора. Аларны гаепләп тә булмый, инкыйлабтан соң халык җирдән бизгән, дөресрәге, биздерелгән иде бит инде! Әнә, урыс халкының канында «крепостное право» дигән коллык хисе һаман бар әле. Урысны ялкау дип сүгәбез сүгүен, тик аңларга кирәк, «крепостное право» вакытында халыкның кабыгы гына калган иде бит! Ә бу исә берничә гасырга сузылган чир, бәла, фаҗига!

Байтимер Баймурзин җир кишәрлекләрен һәр теләгән гаиләгә ун елга арендага бүлеп бирде. Ун елдан соң алар аны арзан бәягә (һәрхәлдә базар бәһасенә түгел!) сатып алырга хокуклы иде. Бу хакта килешү төзелде һәм бу килешүне ун елдан соң да үзгәртеп булмаслык иде. Шуның белән халык күңеленә ныклы ышаныч салысы килде аның. Ә үзенең күңелендә шик-шөбһә сакланып калды...

Әлеге шөбһәләрнең хаклыгы кыш көне үк беленә башлады. Теге өч фермер һәм тагын дүрт гаилә (егерменең дүртесе генә!) кыштан үз җирләрендә кар тоту хәстәрен күрделәр. Кыш буе юлдан кайтып кермичә, арзанрак ашлама юнәтү, кредит мәсьәләләрен кайгыртып йөрделәр. Калганы кыш буе мич башында түшәмгә төкереп ятты. Ләкин шулай да Байтимер өметен өзмәде. «Ләм, мим. — диде аңа теге вакыттагы галәм тавышы. — Әлиф. Ләм. Мим...»

Кайбер кешеләр аның ниятенә шик белдереп карасалар да, Байтимернең күңелендә исә авылдашларына карата барыбер ниндидер ышаныч бар иде әле. Нишләтәсең, бер дә шөбһәләрсез булмас инде ул... Әле күптән түгел генә күңелгә ятышлы тагын бер яңалык билгеле булды: Ясәви фермер, күздән үк елга буеннан бака кашыклары җыеп урнаштырып куйган, кыш буе хуҗалыклардан тавык тизәге, күл җыйды ул. Тавык тизәге дигәннән, бу хакта Изольда Рафинадовна белән махсус килешү дә төзегән: тегесе кыш буе фермадагы тизәкне махсус урыннарда җыеп бара да, аннан соң кирәге булган саен, Ясәви килеп алырга тиеш. Ясәви бик җир җанлы кеше булып чыкты: ул үзенә тигән җирләрдән күздән үк туфрак җыеп чыккан һәм кыш көне аны лабораториягә алып барып тикшерткән. Ул хәзер кайсы басуга нинди ашлама кертәсен һәм нәрсә чәчәсен белә. Байтимер уңышыгызны беренче елны үзем сатып алам, ул турыда кайгырмагыз, дигән иде. Ясәви аңа гына ышанып ятмаган: экологик чиста яшелчәгә шәһәр рестораннары белән килешүләр дә төзеп кайткан. Шуңа күрә ул органик булмаган ашламалар урынына яшелчәләрдәге «химикат»ларны үлчи торган приборлар юнәтү артыннан йөрде, булган акчасын шуларга сарыф итте, күп итеп төрле этикеткалар бастырды.

Әгәр аның фермерлары үз җирләреннән яхшы гына уңыш җыеп ала икән, хакимият аларга киләчәктә эшләрен стимуллаштыру өчен грантлар да вәгъдә итте, хәтта бу буш вәгъдә генә булмыйча, һәркайсы белән якынча килешү дә төзелде.

Әле яз җитмәгән, җир кардан ачылмаган, мондый матур хәбәрләр белән кәефне кыра торганнары да булмады түгел, әлбәттә. Нәкъ шундый вакытта Гыймаев аңа бер язмасын китереп тоттырды. Байтимер Илдарны бик хөрмәт итә, аның төпле егет булуы ошый, язганнарын да бик теләп укып бара иде. Бигрәк тә, Батырша бунты хакындагы мәкаләсе гыйбрәтле, аннан да бигрәк Батыршаның патшабикәгә язган хаты өскә салкын су койгандай итә иде. Шуңа күрә «крепостное право» хакындагы мәкаләсенең кульязмасын да теләп алды, укып чыккач, сөйләшербез, диде. Ләкин, кызганычка каршы, әлеге язма аның күңеленә бер дә өмет чаткылары өстәмәде. Камай да укыган иде, бер кичне алар бу хакта өчесе җыелып сөйләштеләр.

Крепостное право хакында тарих дәресләрендә дә мәгълүматлар бар,

алар берсә дә яңалык түгел иде, ләкин Гыймаев аны үзенчә шәрехләгән. Чөнки Рәсәйдәге әлеге галәмәт сәясәтчеләр, галим-белгечләр тарафыннан да төрлечә бәяләнә, бертөрле генә караш юк. Бер караганда, крепостное право дәүләткә житештерүне арттырырга, ул вакытта илдә хөкем сөргән төрле авыр мәсьәләләрне хәл итәргә мөмкинлек биргән. Чөнки ул менә дигән чыбыркы һәм шунын өстенә богау да бит әле.

Мәскәү дәүләте крестьянны кол итүдән баштарак файда күргән кебек булса да, «колларнын» хезмәт житештерүчәнлеге түбән булу сәбәпле, авыл хужалыгы тагын да арткарак тәгәри. Ин мөһиме — ничә буын халыкта, жир кешеләрендә битарафлык дигән бик яман чир тәрбияләнә. «Ашау — байдан, үлем — Ходайдан», дигән психология сеңә. Ә инде милләткә, анын менталитетына берәр төрле зарарлы психология сеңә икән, аны бер генә патша указы белән дә юкка чыгарып булмый, ул буыннан-буынга күчеп, гасырлар буена дәвам итәчәк. Әгәр крепостное право булмаса, Сталин да хужалыкларны жинел генә колхозлаштыра алмаган булыр иде.

— Йә, шунын белән син мина нәрсә әйтергә телисең инде, Илдар туган? — дип, Байтимер каршында утырган Гыймаевка карады.

— Халыкка жир таратып дөрес эшлисеңме икән?

— Ә монда татарның ни катнашы бар сон? Крепостное право урыста гына булган бит ул?!

— Бар, — диде Илдар, — ничек кенә бар әле! Безнен халык ул чорда да, аннан сон да рус белән бергә гомер итте. Руснын хезмәткә карата булган мөнәсәбәте татарга да күчте! Мин бит монда милләтне ялкаулыкта гаепләмим! Аны дәүләт шул хәлгә төшерә. Ә без исә бер дәүләттә яшибез!

Илдар, күрәсең, бу хакта кат-кат уйланган, бәлкем, кемнәр беләндер киңәшкәндер дә, чөнки ул үз дигәнендә нык тора иде.

— Бер дәүләттә яшибез шул, — дип куйды Байтимер. Анын сүзен Камай эләктереп алды:

— Әлегә... — диде ул, бу сүзенә ниндидер эчке мәгънә салырга тырышып.

— Элек тә, әле дә, иртәгә дә, — диде Байтимер. Бу сөйләшү анын нигәдер эчен пошыра башлаган иде. Ләкин егетләрнең сүзләренә колак та салмыйча булмый, киңәшле эш таркалмас, ди. Камай исә үз киресен тукуын белде:

— Рәсәй империясе таркалачак!

— Син моны конкурска жибәрәчәк трактатыңда язарсың! Бәлки, сүзенә мәскәүләр колак салыр! Тик әүвәл ФСБ кызыксына башламаса! — дип куйды Байтимер ана каршы.

— Яздым инде мин аны, чүплеккә ташласалар ташларлар, барыбер, колакларына булса да кереп калсын, дип яздым. ФСБ кызыксынса, рәхмәт кенә әйтер идем әле. Чөнки дәүләт иминлеген сакларга тиешле оешма бит ул һәм алар, беренче чиратта, империянең таркалмавын тәэмин итәргә тиешләр. Эшләсеннәр! Мин аларга менә дигән тема бирәм бит! Әлеге оешманың аналитик бүлегендә штаттан тыш эшләргә дә риза мин. Барыбер исбат итәчәкмен үземнең хаклыкны! Теориядә генә түгел, төгәл мисаллар белән! Рәсәй ул, үзенең жирләре белән бергә, башкаларны һәрвакыт майлы калжа кебек кызыксындырып торды. Маргарэт Тэтчер, Рәсәйдә унбиш миллион гына халык калдырабыз, дип әллә кайчан бөтен дөньяга кычкырды бит инде! Моңа каршы берәр җавап булдымы сон? Булды, пычагым, Рәсәй байлары һаман инглизләрнең бюджетын арттыру өстендә эшли. Ул Абрам малайлары футбол командасын сатып алырлык акчаны халал юл белән тапкан дип уйлыйсызмы?! Шулай дисаләр, тавыклар көләр иде, билләхи! Һәммәсе дә майлы калжага ташланды! Шуңа күрә, әлеге ач күзләргә нык отпор бирү өчен, Рәсәйне, беренче чиратта, эчтән ныгытырга кирәк! Әгәр анын үзәгендә милләтләр

## Казанга мәдхия

**Йәле, Казан,**
**Туган телдә биш таҗлы сүз-исем язам:**
**Мәгърур кала, шаһи шәһәр, ул син — Казан.**
**Күкләреңне нурландырсын моңлы азан.**

**Йәле, Казан,**
**Хәтер уяу: манаралы заманнардан,**
**Айлы йөзең каралтырга кемнәр базган?!**
**Кичергәнсең — Карфагендай афәт-казаң...**

**Йәле, Казан,**
**Үз көлеңнән калыккансың кабат Казан,**
**Тәкъдир безгә тагын күпме сынау язган,**
**Фидаилык уяныр мы, дөрләп, аздан?!**

**Йәле, Казан,**
**Кодрәтләр ал нәүрүз туган һәммә яздан,**
**Татар рухын кәгъбә итү сиңа язган.**
**Раббы, шөкер; безнең яклы, әй фаразан.**

**Йәле, Казан,**
**Идел-Йортны яңгыратып — син дан казан,**
**Чордан-чорга дастанилык гамәл казган,**
**Мәңгелеккә яшьтәш булып яшә, Казан!**

***Марсель ГАЛИЕВ***

кысылып ята икән, читләргә отпор бирү урынына ул әле тагын өстәвенә үз өенен нәкъ уртасында, нигезен шартлатырга дип, бомба әзерли дигән сүз! Кысылган нәрсә бер шартламас дип уйлыйсызмы! Мало не покажется! Шуна күрә һич кичекмәстән Идел-Урал дәүләте оештырырга, татар дәүләтен ныгытырга кирәк! Тарихтан мәгълүм, Рәсәйне тәре йөртүчеләрдән бары тик Алтын Урда гына саклап калган. Шулай булмаса, бүген Рәсәйдә Рязань, Тверь һәм башка шәһәрләр урынында Аурупа байларынын көтүләре генә утлап йөрер иде! Иван Грозныйны сүгеп дөрес эшлибездер, бәлки. Ләкин анын үрнәк алырлык яклары да бар, мәсәлән, Мәскәү түрәләре өчен! Юкка гына аны ике ел буена үз урынына патша итеп татарны куеп торган дип уйлыйсызмы? Юк, юкка түгел, татар кулы белән тәртип оештырырга теләгән ул Рәсәйдә! Үзе бит боярларны асып-кисеп чыкса да, барыбер җүнле тәртип урнаштыра алмый!.. Дөнья күләсә, бер әйләнә, бер баса дигән кебек. Тарих та шулай ук күләсә инде ул: бер әйләнә, бер баса!..

— Монолог Чацкого булды бу! — диде Байтимер, көлемсерәп.

## Аем—көнем туганда...

Ул Жир йөзенә яраткан Адәм пәйгамбәр балалары һәрбер серне белергә тели. Алар шул юлда. Алар һаман Аллаһны һәм анын хикмәт-могжизаларын танып белү юлында... Бу эштә аларга Аллаһның нурлы фәрештәләре ярдәм кыла.

Баймурзин берничә кешене, шул исәптән Илдар белән Жәмил хәзрәтне дә Сингапурга командировкага жибәрде. Аңа кадәр Германиягә барып фермер хужалыкларының эшләре белән танышып кайттылар. Австриягә бару планнары да бар. Әлбәттә, Сингапурга жибәрү фикере анын фәкать үзеннән чыкты, чөнки моннан берничә ел элек, әле космонавтлар отрядында вакытта ук, ничектер юл төшеп, әлеге илдә туристик сәяхәттә булып кайткан иде. Әле бик яшь чакта, сиксәненче еллар ахырында барды ул анда. Һәм авылдашларына авыл хужалыгы өлкәсендә тәжрибә уртаклашу максаты түгел, кыска гына вакыт эчендә бер шәһәрнен нинди куәтле ил булып үсеп китүен күрсәтү, әлеге рухны тоярга ярдәм итү иде; соң чиктә жирнен нинди кадерле нәрсә икәнлеген үз күзләре белән күреп кайтырлар.

Сингапур анын үзенә сиксәненче елларда ук нык тәэсир итте. Бу шәһәр дингез өстендә салынган икән ләбаса! Бер балыкчылар авылыннан шәһәр, ил үсеп чыккан! Адәмнәрнен ниятен аңлаган дингез, аларга үзенен хәерфатыйхасын биргәндәй, һаман чигенә бара. Менә ул жирнен кадере кайда? Жир кадерен белмәгән ашын югалтыр, ил кадерен белмәгән башын югалтыр, ди. Монда илнен дә, жирнен дә кадерен яхшы беләләр.

Мондагы яналыклар гына түгел, яшәеш рәвеше үзе дә, тәртипләр дә аларга нык тәэсир итте. Кайткач та жаннары тиз генә утыра алмады. Илдар белән Камай бертуктаусыз әлеге ил һәм андагы гадәтләр хакында сөйләсәләр, Жәмил хәзрәт исә бөтенләй сөйләшмәс булды. Нәрсәдер аеруча тәэсирләндергән иде хәзрәтне, анын сәбәбен берничә көннән соң гына белә алдылар. Ул кайтуга татар халык мәкальләре китабына чумды. Бу китапны нигә кулына алганлыгын әүвәлрәк хәзрәт үзе дә аңлап бетермәде; теләде дә актара, укый башлады инде менә! Тиктомалдан, эче пошканнан гына... Ә эче нилектән поша башлады соң әле чит илләр, ят дөньялар күреп кайткан хәзрәтнен? Тиктомалдан гынамы? Жил исми, яфрак селкенми, тик торганнан гына түгелдер, түгелдер... Берьяктан, хәзрәтнен башында Сингапур житәкчеләренен илне алга жибәрү ниятеннән чыгарылган указлары булса, икенчедән, андагы берничә ел элек башланган яна тәртипләр, кагыйдәләр, күрсәтмә-таләпләр кайнады. Тик нәрсәдер, ниндидер тылсым көче хәзрәтне янә бер мәртәбә шәригать канунарын күздән кичерергә, фольклор китапларын кулына алырга мәжбүр итте. Нәрсә булды соң бу?

Аэропортка кайтып төшүгә, телевизорның зур экранынннан Хәрби эшләр министрлыгында миллиардлар урлану хакында хәбәр итәләр иде. Ил язмышын, миллионлаган кешеләр язмышын үз кулында тоткан, алар өчен җавап бирә торган министрлык ләбаса! Сөяркәләре, туган-тумачалары белән бергәләшеп, ил кадәр илне талап ятканнар!!! Башка сыймаслык хәл иде бу!!! Алган — бер языклы, алдырган — мең языклы, диләр түгелме соң? Бу бер министр гаепязыгы гына түгел, бу дәүләт гаебе, аның өстендә торучылар гаебе ләбаса! Сингапурда алар коррупциягә каршы көрәшнең тарихын да белделәр, бүгенге торышын да күреп кайтып киләләр. Бу ил җитәкчеләре кемнеңдер нәрсәдер урлавында баштан ук үзләрен гаепле санаган һәм бар эшне дә үзеннән башлаган!.. Җәмил хәзрәт тирләп чыкты, күз алдында яшелле-зәңгәрле утлар сикерешә башлады... Ул кайтуга мәкальләр китабын эзләп тапты... Менә хикмәт, Алла бәндәсе, нидә икән бит! Менә кайда икән могҗиза!!! Сингапур президенты Ли Куан Юның күрсәтмә-указлары, карарлары, нигезләмәләре... һәм! Һәм... халыкның бик матур тел белән әйтеп биргән мәкаль-әйтемнәре!.. Шулар белән бер рәттә шәригать кануннары, Аллаһыдан вәхи ителгән китаптагы сүрә-аятьләр — болар барысы да, фаразан, бер үк яссылыкта, бер үк нәрсәләр, төшенчә-аңлатмалар, яшәү рәвешен көйләү, җайга салу өчен уйлап чыгарылган тәртипләр түгелме соң? Сингапур президенты аларны чагыштырмача күптән түгел генә тормышка ашыра башлаган булса, безнең халыкның мәкальәйтемнәре гасырлар төпкеленнән килә, ислам кануннарына да шулай ук дистәләрчә, йөзләрчә, меңнәрчә еллар!.. Без читләр янына яшәргә өйрәнергә барабыз!.. Баксаң, алар безнең үзебездә күптән бар икән ләбаса! Үзебезнеке булгач, без аларны күрмибез, читтәге безгә ялтыравыклырак булып күренә... Ли Куан Юның һәр күрсәтмәсен, һәрбер указын халыкның бер әйтеме белән дә аңлатып биреп булыр иде һәм шулай ук алар Коръән Кәримдә акка кара белән язылган: «Угрылык итүче иргә, карак хатынга бер җәза: гыйбрәт өчен аларның куллары киселер...» яки карак, югалган әйбернең хуҗасына (Иленә) кол булып, бер ел хезмәт итәргә тиеш!

Шушыларны, халык җәүһәрләрен һәм дә Коръән Кәримдәге аятьләрне балалар бакчасыннан ук сабыйларыбызга сеңдерсәк, шул рухта тәрбия кылсак, зур үскәч, беркем дә угрылык турында уйламас иде канә!.. Соң... ахыр чиктә максат җәза бирү түгел, дөрес тәрбия бирү ләбаса!..

Президент сагыз чәйнәүгә каршы указ чыгаргач, Америка янкиләре дә, бөтен Аурупа халкы да аннан шаркылдап көлә! «Би-би-си»ләр көн саен Лины мыскыллап сөйли. Шул сагыз аркасында уку йортларының эскәмияләренә утырып булмаганлыгын аңламый алар. Урындык артларына, кырыйларына кат-кат сагыз каткан була. Указдан соң бу хәл бетә. Көлүчеләр үзләре дә шакката. Сагыз чәйнәп май чыкмас, ди татар халык мәкале! Президент указына тач туры килеп торган татар халык мәкальләрен искә төшергәч, болар да, бот чабып, шаклар катты!..

Шулай ук урамнарны чүпләү буенча да махсус күрсәтмәләр чыгара Сингапур президенты. Аурупа тагын көлә моннан. Ләкин дөнья чистарып калгач, янә шакката болар! Себерке килсә, чүп качар, ди татар халык мәкале. Димәк, җүнле «себерке» кирәк! Әлеге дә баягы һаман да бер балык башы: рәтле патша кирәк дигән сүз түгелме соң бу? Яисә булганыннан кыю һәм җүнле гамәлләр сорала дип шәрехләсәң дә була!.. Мисаллар күп: үзең торасы җирне үзең себер;идәндәге чүп түргә менәр; күзгә элмәгән чүп күзгә төшәр; шапшак киленнең себеркесе чүп астында булыр!!!

Сингапурда дүрт телле милләтнең теле дәүләт теле булып санала. Сугышмыйлар, ызгышмыйлар, аларга һәр тел дә тәмле, кадерле, кирәкле булган заманда безнең Җөмһүрияттә кайбер адәм актыклары татар теле кирәкме, юкмы дип бәхәсләшеп ята. Ачкүз кара йөрәкле түрә-түләмәләре, аяк терәп, кулларына

кусәкләр тотып, халыкның туган теленә каршы көрәшә, аны мыскыл итә, кисә, йолка! Сингапур президенты бу хакта махсус указ чыгарган. Бу турыда меннәрчә еллар элек Җәмил хәзрәтнен бабалары: «Бер телдә ун хикмәт, ун телдә йөз хикмәт; туган телне кадерләгән халык кадерле булыр; туган тел үзем өчен, чит тел көнем өчен; теленне сакласаң, дәүләтле булырсың; денемнән дөнәрмен, телемнән дөнмәм», — дип һәм тагын меннәрчә мәкальләр әйтеп калдырган. Һәр кавемне, милләтне Илаһының төрле балчыктан яратуы турында да Мөхәммәд (с.г.в.) пәйгамбәргә иңдерелгән булган! Татар өчен яңалыкмы соң бу?!

Үз кавеменне хөрмәт итсәң, ят кавемгә кол булмассың, ди халык мәкале. Сингапур халыклары, инглизләр изүеннән котылып, үз кавемнәрен кайгырта башлый. Шуннан соң алар бәхеткә ирешә. Ә без дүрт гасыр ят кавемгә хезмәт итәбез, бил бөгәбез, коллар кебек «баш өсте» дип торабыз. Бу гамәлебез үз кавемебезне хөрмәт итү җитмәүдән килмиме икән соң, ә?! Йа Хода! Шулай бит бу канә! Шулай бит!..

Илем-көнем булмаса, аем-көнем тумасын, дигән элек дәүләт тоткан борынгы бабайлар...

## Чабата буе җир...

Экспертиза Сәхаби тапкан чалгыдагы канның Борисныкы икәнлеген ачыклады!.. Чалгының хуҗасын гына табасы калды. Хәзер, бер уйлаганда, төп шик Сания күршесенең капка астына таба тәгәрәгән иде...

Борис Айсинның чалгы белән суеп үтерелгәнен ишеткәч, күрше Чокрылы авылының Таз кушаматлы элеккеге милиционер Хәйбүш малае — хәзер инде «полиция» — Мирза Рәхимҗановның авызыннан сулар килде: хәзер ул җинаятьчене эзенә төшәчәк! Табачак ул кабахәт җинаятьчене, кулларына богау салып, әүвәл Байтамак халкы алдына китереп бастырачак! Аның тапкырлыгын, булганлыгын күреп шаклар катачак байтамаклар! Бигрәк тә авылның иң чибәр, тупырдап торган, сөйкемле сөякле, бер кашык су белән кабып йотарлык Сания атлы йомшаккай янында дәрәҗәсе үсәчәк Мирза полицайның! Мәхәббәткә манка мишәйт итмәгән кебек, погоннар да комачауламый! Погонны аны булган ир-атлар гына тагып йөри!..

Мирза полицай (Мирза үзен «полицай» дип атауларын ярата һәм халыктан да шуны таләп итә. Ниндидер бер кинодан отып калды ул бу сүзне) туп-туры Сәхаби янына алма бакчасына китте. Ни дисәң дә, чалгыны ул тапкан бит! Участок полицаеның «УАЗик» машинасы да бар, тик ул күбрәк «Урал» мотоциклында йөри һәм һәрвакыт башына каска кия иде. Идарә башлыгы подполковник Колоколов, полициянең дәрәҗәсен төшереп, матайда йөрмә дип күпме генә кисәтү ясаса да, Мирза «Урал»дан төшмәде һәм моның үзенең яшерен сәбәбе дә бар иде. Мирзаның башы тишек! Чынлап та, шулай бу! Атасы Хәйбүш — элеккеге участок милиционеры таз иде: аның нәкъ баш түбәсендәге биш тиен акча зурлыгы урында чәч үсмәде, шуңа күрә «таз» кушаматы күтәреп йөрде. Ә малае исә туганда ук «тишек» башлы булып туды, ягъни аның лепкәсенең баш бармак бите кадәрле урынында сеңгер-сөяк ныгымады. Малайның ул төше бала вакытта ничек йомшак булса, шул килеш калды! Ходай Тәгаләнең бер сере иде бу, күрәсең. Гаиләдә аны милиция династиясенең дәвамлылыгыннан күрделәр. Халыкта татарча белгән урыс турында: «Аның янында чамалап сөйләшегез, ул һәммәсен дә аңлый, башы тишек аның», — дип әйтүләре дә юкка түгел, ягъни ул барысын да белеп, ишетеп тора! Милиция-полиция булып эшләгән кешегә исә башның «тишек булуы» бик кирәк!.. Җинаять турындагы мәгълүмат шул «тишек» аша керә иде аңа. Нәкъ шул сәбәпле Мирза беркайчан да баш киемен салып йөрмәде, тикшерү белән барганда исә башына каска кия иде. Ә

матайдагы кешегә исә каска кию гаеп түгел... Теге чакта печәнлектә Фәйрүзә белән чуалганда да... Әлеге йомшак урынга ялгыш кына нарат күркәсе килеп төшсә дә, эшнең ни белән бетәсен әйтүе кыен, диде табиблар. Кыскасы, ул йә аның югалтырга, яисә бөтенләй үк жан-тәслим кылырга мөмкин иде! Ләкин Мирза бу табигать ялгышы — кимчелегенең файдалы якларын да тиз тапты: беренчедән, ул жинаять кылынган урынга килүгә, каскасын салып, мүкәли дә башын аска ия һәм шуннан аңа мәгълүмат агыла. Анысыннан да бигрәк, шул жиргә хатын-кызның чәнчә бармагы тиеп китсә дә, Хәйбүш малаеның отыры дәрте кузгала һәм ул озак вакытка әлеге чибәркәйгә башы-аягы белән гашыйк булып, гыйшык-мыйшык дөньясында яшәп ала торган булып китте. Кемнең кулы тиеп китсә, шул кыз-хатынга гашыйк була Мирза полицай. Беркөнне, Саниянең капка төбендә матаен туктатып, каскасын салды да: «Сания, урманга миллек жыярга баргач, башка талпан кадалды бугай, шуны тартып ал әле, зинһар!» — дип үтенде. Капка төбендә утырган хатын, аны-моны уйламыйча, Мирзаның чәч араларын карый башлады, бер бармагы теге «тишек»кә дә тиеп китте шулчакны. Талпан табылмаса да, Мирзаның күңеле булды: ул Саниянең биленнән тотты, үбәргә дип үрелде һәм шуның артыннан ук хатынның каты кулы аның яңагыннан ут чыгарды. Әле ярый башына сукмады! Эшне аңлаган Мирза полицай, тиз генә каскасын киде, хатынга янап, ачы итеп сүгенде, аннары авызына тәмәке капты, сигаретына яңактан чәчрәгән очкыннан гына ут элдерде дә матаена атланды. «Күрсәтәм әле мин сиңа күрмәгәнеңне! Колхоз саламын урлаганда тотсаммы!» — дип янап китеп барды. «Тоттырганнар ди сиңа!» — диде хатын аңа йодрык арасыннан бер бармагын күрсәтеп.

Алма бакчасында Сәхаби ялгызы гына иде.

Ул аңа чалгыны кайда һәм кайчан тапканлыгы хакында бәйнә-бәйнә сөйләп бирде.

— Чалгы белән хәзер печән чапмыйлар. Бәрәңге сабагы чабалар... көз көне... Яз көннәрен, жәй буе бакча кырыйларындагы кычытканны чабарга мөмкиннәр... — дип сөйләнде Мирза үзалдына. — Димәк, хужалык рәисеннән бу турыда сорап булмый. Байтимер печәнне хәзер кешегә кирәк кадәрле үзе китереп бирә. Печәнне комбайннар чаба... Ә Байбулат ага? Ул бит элеккеге колхоз председателе? Аның заманында хәтта колхоз борчагын да чалгы белән чапканнар бит! Кем бик актив йөргән ул вакытта колхоз эшләренә? Байбулат ага белергә тиеш!

Мирза, бая карар кылганча, Байбулат ага янына түгел, күңеле нидер сизенеп, Сания йортына таба китте. Тик авыл башына житкәч, мотоциклын кирегә борды. Тиз генә райүзәккә кайтып, матайны машинага алыштырды һәм үзе белән участоктагы лейтенант Максимовны да алды. Санияне ишегалдында туры китерделәр, ул эт оясы янында кайнаша иде.

— Этем картайгач, менә моны алган идем, — диде ул, бәйдәге бер яшьлек эткә таба ымлап. — Ата дип калдырганнар иде, ана булып чыкты. Капка асларын томалап бетердем инде ата этләр кермәсен дип. Берсе төнлә тәки койма астын казып кергән бит. Ярар инде, ни булса, шул булыр. Бик акыллы эт, бәлки, балаларын алучы булыр әле. Мирза, наным, ул урам этләренә берәр хәл тартып булмыйммы соң? Бигрәк азындылар бит?

Мирза аның сүзләренә бик теләп кушылды. Теге көннән бирле Саниягә карата егетнең күңеле битараф түгел, кай жирендер нәрсәдер кытыклап тора...

— Алан Бәртәстәге килмешәк этләр алар. Хужалары ташлап киткән этләр. Эт аулаучыларга күптән заявка биргән идем инде, никтер күренмиләр әле, — диде Мирза аның сүзләренә каршы.

— Абау! Урыс малае кунакка килгән булды микән алайса безнең Сарбай янына төнлә белән? Койма астын казып кергән дидем бит әле?..

— Этләрнең милләте юк аларның, — дип сүзгә кысылды татарча яхшы белгән «тишек» башлы лейтенант Максимов. Саниянең бүген кәефе шәп күренә, андый вакытта хатын бик үткен телле, чая була.

— Югын юктыр да... Балалары хәләл булыр микән соң? — дип, Мирзага төрттерде хатын. Чөнки күптән түгел аларның кибетенә бер эшмәкәр арзан бәядән генә кабан дуңгызы дип алдап, гап-гади чучка ите калдырып киткән булган. Эшнең нәрсәдә икәнлеген ахырдан гына сизгән (тиешле кәгазьләре дә тәртиптә булган югыйсә) яшь кибетче кыз, соң булса да әлеге эшмәкәр өстеннән полициягә гариза язып илткән. Мирза тикшерүчеләр белән теге шома эшмәкәрне ай буе эзләде, тик таба алмадылар. Бер-ике кеше әлеге иттән шашлык кыздырып өлгерде. Саниянең шуңа төрттерүе иде бу. Ләкин Мирзаның аның әлеге сүзләренә бер дә исе китмәде, ул хатынга чалт итеп җавабын да бирде:

— Ул мясникны бүген үк табам мин! Әйтте диярсең миңа! Тәк... ярый. Сания, синең чалгың бармы? — диде Мирза. Хатын чак кына югалып киткәндәй булды, ләкин аның бу халәте озакка бармады, ул сорауга дөресен җавап бирде:

— Бар иде бер иске чалгы... Чыгарып ташладым инде мин аны, — диде.

— Алайса безнең белән районга барырга туры килә сиңа? Для опознания вещдока! — диде Максимов. Хатынны машинага утырттылар.

Үз чалгысын таныса да, шуннан артыгын хатын әйтә алмады.

Бу очракта фактларның барысы да аңа каршы сөйли: чалгының хуҗасы — ул, сынык чалгыны чокырдагы чүплеккә дә ул чыгарып ташлаган, аның бәрәңге бакчасы зират коймасына — Борисның үле гәүдәсен тапкан урынга килеп терәлә. Бер караганда, башка фактлар җыеп азапланасы да юк кебек. Бүтән тикшерүче булса, мөгаен, шулай эшләгән дә булыр иде. Тик Мирза әүвәл җиде кат үлчәргә, барысын да җентекләп тикшерергә булды. Ә үзенең күңелендә әлеге җинаять табышмагының бер очы чишелгән иде: Сания үтерүче түгел! Бу очракта ул үзе корбан!..

Мирза Сания ябылган бүлмәгә керде. Авыл хатыны үзенең нинди бәлагә тарганын һаман аңлап җиткерми булса кирәк, ул тыныч булырга тырыша, ләкин күзләреннән, тавышыннан шактый курыкканлыгы сизелә. Мондый йортка беренче кат килүе, күбрәк шул нәрсә куркыта бугай. Мирзаның аны бик тә тынычландырасы килде, ул хатын янына килеп, аның кулыннан тотты, җылы сүз әйтергә теләде. Тик тегесе һаман чыгымлады:

— Мине тотып кочлаү өчен, шундый җинаять тагып, монда кадәр алып килү кирәк иеме сиңа, мент?! — диде ул, ысылдап. Хатынның бу гаярьлегеннән беравык каушап калган Мирза тешләрен кысты, ләкин аңа авыр сүз әйтә алмады. Киресенчә, аның бу чибәр кыз-хатынны кочаклап үбәсе килә иде. Тик нишләргә соң? Мирза бермәл инде тынычланган хатынга карап-карап торды да:

— Сания, син миңа үпкәләмә, пожалыста! Бер сүз әйтергә мөмкинме? Рөхсәт бирмәсәң дә, барыбер әйтәм: чык миңа кияүгә, ә!

Сания, күзләрен зур ачып, Мирзага карады:

— Кияүгә?!! Прәме монда укмы, хәзер үкме?

— Уйларга вакытың бар. Уйлап бетер. Мин чынлап әйтәм.

— Уйларга вакыт күп шул монда, — диде хатын күңелсез генә.

— Юк, мин сине хәзер үк кайтарып куям. Гафу, мин түгел, ашыгыч эшем бар минем. Максимов илтеп куяр өеңә, яме?

Сания «УАЗик»ның алдагы утыргычына кереп утыргач кына «Аллага шөкер!» — дип куйды. Аның бүтән теге каһәр суккан чалгы турында да, хәтта Мирзаның тәкъдиме хакында да уйлыйсы килми. Күңеле бушап калган кебек. Әйтерсең, ул чынлап та, моңа кадәр булган тормышын сызып ташлап, яңа хәяткә әзерләнә, шуңа күрә күңел дигәнен дә бушап калгандыр, мөгаен. Ләкин аңа үткәннәрен онытырга ирек бирмәделәр, полиция машинасы станса яныннан узганда, тәрәзәдән урамны

күзәтеп барган хатын Максимовка машинаны туктатырга кушты. Стансадан үзәккә таба абына-сөртенә килгән танышын күреп алган иде хатын. Әйе, танышын!.. Аның тормышын җимереп, чәлпәрәмә китереп ташлаган күптәнге бер танышын — элеккеге ирен!.. Элек ул аны күрүгә югалып кала, аннан соң ботарлап атардай булып ачуы килә дә әлеге ачу, Фәрәдиснең «бомж» кыяфәтен күргәч, кызгануга әйләнә. Тик соңгы хис озакка бармый, хатынның аңа тагын ачуы кабара, сугып егасы килә башлый. Ахырда ул, барыбер Фәрәдисне түгел, үз-үзен битәрләргә керешеп, җаны атналар буе урынына утыра алмый. Үзен дә аның алдында ничектер гаепле итеп сизә шикелле Сания. Тик әлеге гаебенең нидә икәнлеген генә аңлап бетерми, әмма сизенә, күңеленең кайсыдыр төше белән сизенә.

Фәрәдис Санияне шундук танып алды һәм, тешсез авызларын ачып, елмаерга тырышты. Элеккеге хатынын күрү сөенеченнән елмаямы бу сәрхуш, әллә йөз граммга акча сорарга җай чыкканлыгына сөенәме? Әлбәттә, икенче сәбәп чынга якынрак иде... Сания артык хискә бирелеп тормады, шундук ярып салды:

— Пәрәдис-Пәри! Мин кияүгә чыгам! Син каршы түгелме? — диде, аның каршысына килеп басуга. Тегесе бермәл аптырап торды, аннары, авыз куышлыгында берничә генә калган сары төшләрен күрсәтеп, янә елмаерга тырышты.

— Мин каршы! — диде ул, беркавымнан исенә килеп. — Син — минем хатын! Әйдә өйгә кайтабыз! — дип җикеренергә кереште Фәрәдис. Сания, сумкасыннан бер иллелек алып, аңа сузды:

— Түлке сине туйга чакырып торып булмас инде. Чакырсам да килергә вакытың булмас, әнә бит, эшең күп икән, шешә җыясың бар! — диде, әлеге акчаны Фәрәдискә сузып. Тегесе акчаны тиз генә кесәсенә яшерде дә:

— Кемгә чыгасың кияүгә? Сине бәхетле итә алырмы соң ул? — дип сорап куймасынмы! Сания полиция машинасына таба ымлады: янәсе, кияү шунда утыра.

— Ризалыгыңны бирәсеңме соң, Фәрәдис? — диде Сания, хәзер сәрхуш белән шаяртуга күчеп.

— Ә калым?! — Фәрәдис кулын алга таба сузды. — Аннан сорыйммы?

— Үзем бирәм, — дип офтанды хатын һәм сумкасыннан бу юлы йөзлек акча тартып чыгарды. — Фәрәдис, минем бәхетле булуымны телә, яме, — дип пышылдады хатын. Фәрәдис дәшмәде, аның әле генә Сания янында иске-ертык киемнәрдән басып торуы исенә төшкән кебек, ул таушалып беткән кәчтүмен сыпыргандай итте, тезеннән аерылып, бер кисәге асылынып торган чалбарын тартып куйды, бер кулы белән сирәк чәчләрен сыпырды.

— Телим, Сания... Теләрмен... Бәхетле бул! Син бәхеткә лаек хатын, — дип пышылдады Фәрәдис. — Булдыра алсаң... гафу ит инде син мине, Сания- Сандугач... Һәй, ихтыяр көче җитмәде... үземдә. Җир кадәр җирне акчага алыштыралар димени инде бу заманда?! Нинди җир иде бит әле ул! Ипигә ягып ашарлык!.. Һәм чабата буе гына да түгел, гектарлап иде бит... Дурак мин!.. Хатын аның йөзенә күтәрелеп карарга курыкты, чөнки элеккеге ире тын гына елый иде...

Алар Фәрәдис белән Казан арты зонасының җыр фестивалендә таныштылар. Икесенең дә унынчы сыйныфны тәмамлап йөргән вакытлары иде. Фәрәдис гитарада үзе уйнап, бик матур җырлый. Сания исә — яшьтән җырчы кыз — былбылдай сайрый иде. Мәктәп тәмамлауга күрше район егете Фәрәдискә кияүгә чыгып куйды ул. Фәрәдис өйләнүгә, моның белән тормыш алып барып булмас дип, гитарасын чөйгә элде дә элеккеге колхоздан үз паена тигән җирләрне алды, аның янына пенсионер күршеләренеке өстәлде. Шулай матур гына тормыш башлап җибәрде алар. Тик бу бәхетле тормыш озак дәвам итә алмады, районга зур инвестор килеп керде дә, элеккеге колхоз җирләре генә җитмичә, төрле юллар белән Фәрәдис кебек

фермерларның җирләрен дә үз итәк астына җыеп тыкты. Фәрәдискә алтын таулар вәгъдә иткелде, җире өчен учлап акча бирделәр, теләсән, район үзәгендә үзеннен эшенне ачарга ярдәм итәбез диделәр. Дөрес, Фәрәдис, тешен кысып булса да (тегеләргә каршы барырлык түгел, инвестор Түлле түрәнең шәҗәрә агачында бер юан ботак иде!), үзәктә агач эшкәртү, тәрәзә рамнары ясау фирмасы ачып җибәрде. Тик булышырбыз дигән вәгъдәләр онытылды, ике еллап азапланганнан соң, салым һәм кредитлар аны тәмам буды, муеннан бурычы җыелды. Аны эзәрлекли башладылар, үтерү белән куркыттылар. Тик Фәрәдис бирешә торган егетләрдән түгел иде, ул җан-фәрман тырышты, кирәк урында сугышты, кирәк урында чәче белән җир себерергә дә әзер иде. Ләкин ул рәвешле генә акча эшләп булмый, димәк, банктан алган кредитларны да түләп булмый дигән сүз. Фәрәдиснең каты тешле икәнлеген белгән кредит бирүчеләр, ана башка яктан һөҗүм оештырдылар. Көннәрдән бер көнне Сания юкка чыкты. Аны урлап киткәннәр иде. Санияне өч көннән соң кире кайтарып ыргыттылар. Әйе, чынлап та ыргыттылар! Чөнки яшь хатынны, анын сөйгән йөрәк җимешен мәсхәрәләгәннәр иде. Моның белән генә дә тукталмады теге бәдбәхетләр, Фәрәдискә яна һөҗүм башланды. Аптырагач, ул качты, шәһәргә, бомжлар арасына... Менә әлеге бәхетле гаиләнен тарихы шунын белән тәмамланды. Хәер, Сания үз авылына — Байтамакка кайтып китте, анда атасыннан калган йорт исән иде...

Шундый заман иде бу: ул, беренче чиратта, ир-атларны тукмый, әгәр тегесенең хатыны уяу булып, шул чакта иренә терәк була алмаса, тукмак буласы гаилә башлыгын җир белән тигезләргә мөмкин!.. Ләкин Саниянең ул вакытта эшмәкәр хатыны гына түгел, сәхнәләр тутырып җырлыйсы да килә иде шул. Очып йөргән чагы иде... Ләкин тормышның гравитация көче аны җиргә тартып төшерде. Ул хәзер бер авыл хатыны... Чибәр, булган, уңган, ләкин ялгыз авыл хатыны иде... Сания әүвәл, тол хатын буларак, кеше ирләрен аздырырга да каршы түгел иде, әмма бу озакка бармады. Тиктомалдан яшь хатынны алыштырып куйдылармыни: ул андый максат белән йөргән ир-атны капкасыннан уздырмас булды. Әлбәттә, шуннан соң гайбәтләр отыры ешайды гына. Әмма хатын анын саен ужым эзләп йөрүчеләргә катырак торды. Моның үз сәбәбе бар иде, бер караганда, юк кына сәбәп тоелса да, хатын-кыз буларак анын бәгыренә утырды: гомер булмаганны! Авылда ирләре өстеннән яшь киленнәр типтерә торган заман башланды!..Саниядә хатын-кызда гына була торган эчке горурлык уянып, ул авылның, авылның гына түгел, бар Җир шарындагы кыз-хатыннарның дәрәҗәсен саклыйм дигән илаһи хис белән гомер итә башлады, янәсе, гомум хатын-кыз кавеменең дәрәҗәсе өчен көрәште! Бу хис-тойгы чынлап та илаһи иде, чөнки Сәхаби атлы бакча каравылчысы, туганы белән көрәшкәннән соң, шундыйга әверелде бит ул!.. Әлбәттә, гашыйк булып алулар ара-тирә булгалады, ләкин аларны бер кулдагы бармак белән дә санарлык түгел. Бәхти, Камай... Бәхтигә булган мәхәббәте клубта оештырылган хөкем белән тәмамланды. Камайны да тиз онытты... дөресрәге, малайсытты ул аны. Ә менә Мирза? Элек капка төбеннән матаен тырылдатып узганда, ул анын артыннан таш атып калырлык дәрәҗәдә күрә алмый иде, анын ирен яклый алмаган милиция-полиция токымыннан булганы өчен генә, әлбәттә!.. Теге көнне, бармагы белән егетнең башындагы «тишеккә» орынып алганнан соң, хатынны әллә нишләттеләр, алыштырып куйдылармыни! Үзгәрттеләр, бар җаны, күңелен кузгаттылар! Кемнәр? Бары бер кеше, Мирза атлы, полиция булып эшләүче таз Хәйбүш малае... Теге бармагы һаман кызышып тора әле. Рәхәтлек биреп кызыша. Әлеге бармак аша кан тамырлары буйлап ниндидер серле кайнарлык таралды, йөрәгенә чаклы барып житте әлеге кайнарлык, шуннан бирле йөрәге тиктомалдан еш-еш тибә башлады, «аритмия», диде фельдшер кыз. Сания ана:

«Үзең аритмия син!» — диде. «Мирзага булган мәхәббәтем» дип әйтмәде әйтүен. Бары «мәхәббәт аритмиясе» дип кенә сүзне шаяртуга борды. Шул рәвешле, Мирзаның «тишек башы» харап итеп ташлады Сания атлы яшь, чибәр, тутырган тавык кебек түгәрәк, дәртле хатынны. Бер аны гына түгел, Мирзаның үзен дә... Ел саен күрше Сәлим анын бакча кишәрлеген кыса, яз житүгә берәр буразнасы булса да тегенең ягында адашып кала иде. Менә моннан соң анын бер карыш жиренә тиеп карасын ач күзле күрше! Милиция үзендә генә булачак... Хатынның хыял-уйлары татлы, бик тә татлы иде... Аллага тапшырдык инде...

Ә Хәйбүш малаен исә Ябалакта тагын да кызыклырак хәлләр көтеп тора иде! Авылның бер кешесе чиркәү гөмбәзенә менеп кунган да шуннан жиргә сикерәм дип куркыта! Имеш, Галин дигән адәмгә шул рәвешле үзенең ризасызлыгын, каршылыгын белдерә!.. Берничә ел элек Галин, аның һәм башка күршеләренең пай жирләрен алдап-йолдап алган да хәзер, ялган документлар ясап, ул жирләрне бик кыйммәт бәядән үзе кебек икенче бер банкирга сатарга жыена икән. Үземнең пай жиремдә фермер хужалыгы оештырам дип, бу кеше Галинның приказчигы янына барган икән, аны куып чыгарганнар, бездә синең жирең юк, тагын килсәң, муеныңны борып атып, башыңны кесәңә тыгып жибәрәбез, дигәннәр!..

Чиркәү Ябалак авылына карамый, ул элек күрше генә булган Зур Күл дип аталучы рус авылына карый иде. Тик хәзер, ике авыл бергә кушылып, чиркәү бер башта, мәчет икенче якта калса да, белмәгән кеше өчен ике Алла йорты да бер авылда кебек тоелырга мөмкин. Мирза бу тирәләрне яхшы белә, хәтта чиркәү гөмбәзенә менеп кунаклаган тракторчы Галләмне дә шундук танып алды.

— МЧС чакырттыгызмы? — дип сорады ул авыл советы сәркатибеннән, килә-килешкә.

— Нинди МЧС ди монда! Ул сикерәм дип кенә түгел, чиркәүне үзем белән бергә шартлатам дип яный бит. Вәт тинтәк! Салып алган да!..

— Шартлатам, дими! Бернинди бомбасы да юк аның! Ут төртәм, ди! Әнә, үзе белән шешәләр дә алып менгән! Бензин яки керосиндыр! — дип сүз кыстырды аның янында торган икенче берәү. Мирза шулай да, тиз генә участокка шалтыратып, шәһәрдән ярдәм чакыртырга кушты. Үзе, төшеп китмәсен дип, бер кулы белән каскасын тотты һәм Галләмгә кычкырды:

— Син нигә чиркәү башына менәргә булдың әле! Чиркәү причем монда?!

— Урыслар!.. Галин кебек комсыз урыслар басып алды безнең жирләребезне! Менә, карап торыгыз, хәзер чиркәүләрен юк итәм мин аларның! Үзем дә бетәм! Болай яшәгәнче! Ә син, Хәйбүш малае, Галинның әнчекләре белән сөйләшүләр алып бар лучше! Монда терәлеп торганчы! Урысларны жыеп алып бар Галин янына! Жиремне кире бирсә, тимим чиркәүләренә! Гөмбәзенең буявы да кубып беткән инде. Әгәр Галин жиремне үземә кайтарса, моны буяп төшәргә дә могу мин! Менгән менгән инде!.. Йә алып менгән буявымны калдырам!..

Жыелган халык арасында иң пошаманга калган кеше, әлбәттә, поп иде. Ул, ара-тирә чукынып-чукынып ала да, чиркәүне яндыра күрмә дигәндәй, Галләмгә ялвара, аннары ярдәм өмет итеп, жыелган халыкка карый.

— Ә Галин причём монда?! — дип кычкырды Мирза. — Ул урыс түгел бит! Үзебезнең татар! Галиев аның фамилиясе! Мәннәви исемле ул, атасының исеме — Мансар!

Әлеге хәбәрдән соң Галләм, авызын ачып катып калды, кулындагы бер шешәсе аска тәгәрәп, үлән арасына килеп төште. Сары башлы бер малай, жәһәт кенә йөгереп барып, шешәне алып килде дә полициягә сузды.

— Бензин исе килә моннан!

— Алдамыйсынмы син мине, малай актыгы? — диде беркавымнан ис-хушын жыеп өлгергән Галләм.

— Билләһи менә, Галләм абый! Татар ул! — дип кабатлады Мирза.

— Ник... нигә?.. Татар татарны талый башладымыни инде хәзер?!

— Давай, төш кире, Галләм абый!

Мирза килгән шәпкә игътибар итеп өлгермәгән икән: әлеге тамашаны карарга җыелган халык тыныч иде. Хәтта араларында бармак төртеп хихылдап көлеп куючылар да бар. Баксаң, тракторчы Галләмнең мондый гадәте күптән килә икән инде. Ул өйгә исереп кайткан саен, хатыны, мин әниләргә китәм дип, капкага йөгерә икән, Ә Галләм, аннан да житезрәк, капка түбәсенә менеп баса да:

— Мине ташлап китсәң, хәзер үк баш белән җиргә кадалам! Синнән башка берәү дә кирәкми мина, Мәйсәрә! — дип куркыта башлый. Хәзер инде иргә, үлә күрмә, синнән бүтән кемгә кирәк соң мин дип, хатын ялварырга керешә. Шуннан үзара низаг, кул белән юып алгандай, юкка чыга. Галләм, үрмәләп, тик бу юлы бик озак, көч-хәл белән ишегалдына төшә, аңа баскыч алып килеп өлгергән хатыны янында күгәрчен кебек гөрли. Аннан соң бер култык астына Мәйсәрәсен, икенчесенә баскычны кыстырып, лапаска таба теркелди. Анда исә кичә генә чабып алып кайткан хуш исле йомшак бәти печәне таратылган һәм шул тирәдә җаен-кышын йомырка салудан туктамаган унсигез тавык кына кайнаша.

Менә Галләм янә телгә килде:

— Попкаем! Гафу ит мине, зинһар! — дип кычкыра ул һәм беркавымнан әлеге сүзләренә өстәп куя: — Мин монда гөмбәз буярга буяу гына алып менгән идем!

Тракторчы Галләм үзе белән эләктергән алтынсу буяу савытын тимерчыбык ярдәмендә тәрәгә асып куймыйча җиргә төшмәде. Хәзер менә начар ният белән менгән дип әйтеп карасыннар! Кем әйтә ала шулай дип? Хәйбүш малаемы? Дәү корсаклы поп атакаймы? Юк, поп атакай әнә чукына-чукына ана рәхмәт укый!.. Читлек артына ябып кара инде син Галләмне моннан соң, Хәйбүш малае!..

Тракторчы Галләмне райүзәккә илтеп япмасалар да, әлеге вакыйганың кайтавазы булмый калмады. Чөнки, Галиннан зарланып, тагын дистәләгән авыл кешесе интернетта үзләренең дәгъваларын урнаштырган иде. Интернет заманы килде дигәч тә, халыкның аннан файдаланып, азуы түгел иде бу. Әүвәл язмача хат җибәреп карадылар. Тик ана каршы килгән җавапны аңлый алмыйча бик озак интеккәч кенә, бер мәктәп баласы әлеге шикаятьне интернетка урнаштырды. Ә теге җавап түбәндәгедән гыйбарәт иде, арагызда, бәлкем, аңлаучы табылыр, авыл халкының төшенеп җитмәве гаҗәп түгел, авыл кешеләре гомер-гомергә надан бит инде алар! *«Хөрмәтле Каргалар авылы (Ябалакны шулай дип татарчадан татарчага тәрҗемә кылганнар!) кешеләре! Федераль законның №000 маддәсен күздә тоткан хәлдә, регионнар мәнфәгатен кайгырткан канунның беркайчан да булмавы һәм булмачаклыгы сәбәпле, РФның №0000нчы маддәсенә нигезләнеп, сезнең мөрәҗәгатькә җавап йөзеннән, РФның №00000да күрсәтелгән маддәсенә таянып уйлап чыгарылган пунктың тормышка ашыру өчен һәм аны ахыр чиктә гамәлгә ашыру нияте белән, сезнең хатка җавап итеп түбәндәге җавапны юлларга мәҗбүрбез, чөнки халык белән эшләүнең тәртибе буенча бер ай эчендә без сезгә теләсә нинди җавап җибәрергә бурычлыбыз.*

*Хөрмәтле каргалар! Элек фәлән колхозның сөрү җирләре булу сәбәпле, әлеге җирләрнең ошбу колхозга Фәләнов алпавыттан калган булуын истә тоткан хәлдә, тагын да арырак тикшереп, әлеге алпавытның Иван Грозный патшаның бу җирләрне талап алу фактларын да бер тарихи вакыйга икәнлеген теркәп, архивта озак актарынганнан соң да алпавыт Фәләнов хакындагы мәгълүматлар Мәскәү шәһәрендә 1912нче Урыс-француз сугышы вакытында Кутузовның Мәскәүне махсус яндыруы сәбәпле, архив эшенең тәртибе югалган һәм шул сәбәпле анда бүгенге көнгә чаклы рәт-баш булмау аркасында табылмады. Димәк, сез хатта телгә алган Галин әфәнде бу җирләр белән үзе теләгәнчә файдалана*

*алмый. Үз чиратында каргалар да әлеге кишәрлекләрдән файдаланырга хаклары булмауларын белергә тиешләр. Яна жир кадастры законы уйлап чыгарылганга кадәр, әлеге жирләр буш жирләр дип игълан ителгән булу сәбәпле, без бернинди төгәл жавап юллый алмыйбыз.*

*Имза*
*Мөһер*
*Дата»*

Хәйбүш малае, Галләмгә бармак янады да, матаена атланып, Байтамакка чапты. Борис Илсин эшенең вакыты чыгып килә, Колоколов аны бүген шул хакта жавап тотарга чакыртты.

Пай жирләре аркасында килеп чыккан тавыш-гауга моның баласы гына булган икән, әлеге ызгышның «анасы» алдарак көтеп торган Галинны! Шәһәрдән кайтуга, Кызыл канат әлеге вакыйга турында Мәннәвигә түкмичәчми сөйләгән иде. Тегесе кулын гына селтәде дә:

— Бетмәс монда бетле хәерче! — дип кенә куйган иде. Кызыл Канат дөнья күргән кеше буларак:

— Мәннәви Мансарович! Бәлки, бераз акча биреп, авызын томаларгадыр ул Галләмнең, ә? — диде. Бу тәкъдимгә каршы да Мәннәви тузынды:

— Адым саен!.. Нинди бетмәгән акча бирү ди бу! Син нәрсә, шулай итеп дөньядагы бар хәерчене дә туйдырып бетерермен дип уйлыйсыңмы?! Эшләсеннәр әнә!

— Ул эшләргә риза, Мәннәви Мансарович! Тик жире юк, без алдык аның пай жирен!

— Бушка түгелдер ич? Үз вакытында түләгәнбездер бит?

— Түләдек түләвен дә...

— Биргән саен күбрәк сорый алар, берсенә бирсәң, капка астыннан икенчесе кереп житәчәк! Белгән инде аларны! — дип әлеге мәсьәләгә нокта куйды Мәннәви Мансарович.

Кичкә Баш түрә кинәшмә жыйган дип ишетте Галин. Әлбәттә, андый кинәшмәләрдә катнашырга Галин кебек азган байларның башлары «яшьрәк» иде. Үзләре катнашмаса да, андагы һәр әйтелгән сүз-жөмлә мизгел эчендә килеп ирешә, әгәр мәсьәлә алар «токымы» хакында була икән, араларыннан берәр «соры кардинал» (кыскартып үз артында «соры корт» дип атаучылар да бар) вертолёт биеклегендә очучы «лачын-козгыннарны» аерым жыярга гадәтләнде. Андый жыенның чираттагысы Галин фазендасында булырга тиеш икән. Мәннәвигә шундый карар килеп ирешТе. Бу инде бик афәтле, куркыныч сигнал иде: нәкъ менә Галин ихатасында жыелалар, димәк, сүз турыдан-туры Мәннәвигә кагылачак, Баш түрәдәге зур кинәшмәдән соң мондый ашыгыч жыен шулай ук тикмәгә генә булмас! Аннан соң Илбашы артык сүз чәйнәп торучылардан түгел! Әйтте икән — үтәми кара! Чөнки ул беркайчан да юк-бар сүз сөйләми, һәр тырышканы Жөмһүрият һәм халык өчен!.. Талканы коры аның!.. «Халык өчен» дип ассызыклау да модага иярүдән генә түгел. Үзе көнетөне ат кебек эшли торган Илбашы шуның өстенә бик гадел дә, аңа мөрәжәгать иткән кешенең әле беркайчан да, төшенкелеккә бирелеп, кул селтәгәне юк. Ин әһәмиятлесе, Илбашы өчен зур һәм вак мәсьәлә дигән әйбер юк. Гади халык мәнфәгатенә кагылышлы булган һәр нәрсә аның өчен мөһим! Шулай булмаса, Жөмһүриятнең даны шулай тиз арада бөтендөньяга тарала алыр идеме икән!.. Кыскасы, Жөмһүрияткә мондый Илбашын Ходай үзе бирде!..

«Соры корт» жыйган кинәшмәләрдә, гадәттә, төрле дәрәжәдәге эреле-ваклы түрәләр белән бергә зур эшмәкәрләр дә катнаша һәм әлеге жыендагыларның

саны һәрвакыт төрлечә иде: йә иллеләп кеше була ул, кайчакларда егерме-утыздан да артмый. Шунысы шомлы: бу юлы жыенда ничә кеше катнашасы алдан әйтелмәгән иде.

Галин тиз арада зур кунакларны каршы алу, кунак итү хәстәренә кереште. Дөрес, алар монда бәйрәмгә жыелмыйлар, сүзләре кыска, ләкин нәтижәле булачак! Монда кылынган карарны үтәмәгән өчен байлыгың белән генә түгел, башың белән дә жавап бирәсе!.. Галинны барыннан да бигрәк шунысы шүрләтте!.. Ул шундук үзенә Изольда ягыннан туган тиешле булган Гафунга шалтыратты: янәсе, «темадан» син хәбәрдәр түгелме? «Жизни! — диде тегесе ачулы тавыш белән. — Син нинди бардак оештырып ятасың анда?! Жавап тотарга әзерлән!» Гафун белән сөйләшкәннән соң, отыры ачуы килгән Галин кыйммәтле телефонын таш диварга бәрде һәм ачы итеп сүгенеп куйды да Кызыл канатны чакыртты. Гафун Галинга каената тиешле кешенең бертуган энесенең малае иде.

Каенатасы Рафинад Хәләфовичның озак еллар жәелеп утырган кәнәфиенең аяклары үзләреннән үзләре озынаеп китеп, түлле түрәбез туксанынчы елларда Мәскәү тарафларына ук китеп барган иде. Мәскәү кулы жөмһүриятләр белән һәрвакыт шәп идарә итте, шул сәбәпле Рафинад Хәләфовичның шәжәрә агачындагы «карга оялары» да туздырылмыйча әйбәт яшәделәр, кеше арасына чыктылар, шул кешеләрнең башларына баса-баса, һаман югарыга, кояшка таба үрмәләделәр. Капка төбенә яңа гасыр килеп туктагач, нилектәндер Рафинад Хәләфовичның дилбегәсе берара (ун еллап булыр) йомшарып алды. Ләкин ул арада Галин кияү кебекләр инде үзләре «кеше» булып житеште. Гафун шикелле яшьрәкләрнең үсү юлы «бозлавыкка» туры килеп, алар әле күптән түгел генә, Рафинад Хәләфович, янадан монда кайтып, иске нигезендәге оясын янарткач кына, ошбу юлларга «ком сибелде», малайлар тернәкләнә башлады.

«Кара! Ничек сөйләшкән була! Манка! Күрсәтермен әле мин сиңа бардакны!» — дип эченнән генә сүгенеп алуы Галинның бары үз-үзен юату гына иде. Чөнки Гафун кебекләр «пароход»ның артына инде төяләп өлгергән һәм матур гына тирбәлә-тирбәлә йөзүләрен дәвам иттерәләр. Һәм каената тиешле кеше дә хәзер элек зур өметләр баглаган кияү балакаена түгел, шуныңише якын туганнарына таяна, әлегә кулыннан килгәндә, үзе дә аларга ярдәм итәргә тырыша. Чөнки бу малайлар Мәннәви кебек сәнәктән көрәк булмаган, болар үскәндә үк туганнарының һәм аталарының кыланмышларын күреп, бабаларының нәсел шәжәрәсен өйрәнеп үсте һәм алар язмыш һәм Ходай кушуы буенча да бары «очарга тиешле» аксөяк кошлар иде. Ни әйтсәң дә, көтүче малайлары түгел иде болар...

Галин соңгы чиктә каенатасына шалтыратты. «Мин дә киләм. Син кунакларны әүвәл теге серле күлен янына алып барырсың. Борчылма, калганын үзем жайларга тырышырмын. Чиркәү башына менгән авыл кешесе дә янында булсын. Акча бир, күнелен күр», — диде. Каенатасының әлеге сүзләре Галинны жиде кат күккә күтәреп куйды. Димәк, бу юлы «чиркәү вакыйгасы» Рафинад Хәләфович ярдәме белән йомып калып булырына ышаныч бар!.. Тик озак та үтмәде, «разведка» Галинга яңа хәбәр ирештерде: аның ике йөз мең гектар жирен бер Мәскәү оешмасы үз кулына алырга жыена икән! Рәсәйнең Ерак Көнчыгыштагы иң ахыргы ноктасыннан алып Көнбатышка чаклы булган жир кишәрлекләренә Федераль үзәк һәрдаим үз казыгын кага бара, мона кадәр аның бу жирләргә кызыкмавы, бер караганда, гажәп иде, әлбәттә. Галин, тора-бара, тагын да тулырак мәгълүмат алды: аның ул жирләрендә «Чиста басу» («Чистое поле») оешмасы эшләячәк икән. Әлбәттә, бу заман таләбе диярләр: фән-техника прогрессы әледән-әле яңа алым-ысуллар уйлап чыгара тора — басудагы сыер тизәкләреннән ягулык эшләүнең инновация ысулына киләсе елда Федераль үзәктән яңа махсус программа нигезендә берничә миллиард сум акча каралаçы

ди. Узган ел гына эшли башлаган «Авылның каймаклы сөте» («Деревенское отборное молоко») программасы нигезендә бөтен Рәсәй җирләрендә көтүлекләр арттырылды. Бу БСО (ВТО)га каршы тору өчен дә кирәк, янәсе... Көтүләр арту сәбәпле, басулар пычрана (тизәккә бата!) башлады. Алай гына да түгел, әлеге тизәкне эшкәртеп, Аурупа өчен менә дигән ягулык әзерләп була икән! Әлеге мәсьәләне яна программа тулысынча хәл итәргә тиеш. Өстәвенә аның өчен Рәсәй бюджетыннан күп акча бүленәчәк... Шул сәбәпле Иделле федераль округы белән Растав крае «Чиста басу» махсус берләшмәсе составына кертелде. Әлеге берләшмәнең житәкчесе итеп Петербург эшмәкәре билгеләнде. «Сулкуллы» дип аталган компьютер программалары оешмасында бер сыердан елына күпме тизәк жыеп алу мөмкинлеген ачыклау өчен, яңа программа эшләнә башланды һәм ана да «Чүбәй-Чүбек» нәни технологияләр фирмасынннан берничә миллиард күчереләчәк икәнлеге мәгълүм булды... «Чиста басу»ның яңа житәкчесе Пётр Иофанович Сидуров төркеме әлеге игелекле эшкә алдан ук әзерләнде, чөнки бүгенге заманда надан халыкка яңалык-инновацияләрнең асылын төшендерү шактый озак һәм мәшәкатьле эш булса, югарыдагы житәкчеләргә шуны исбатлап бирү тагын да катлаулырак иде. Растав крае аңлашыла: әлеге җирләрнең һәр аршынында ныклы күзәтү һәм тәртип булырга, һәр басу, һәрбер үгез һәм сыер төгәл исәптә булырга тиеш, чөнки алда олимпиада уеннары тора. Италия һаман олимпиада ярышларына, аерым бер спорт төре буларак, үзенең «матадорларын» кертергә маташа бит! Үгезләргә дә кытлык булмаячак! Ә менә төшемле җирләрне биләп утырган Иделле белән нишләргә? Моның да жае бик тиз табылды: анда махсус оештырылган дини секта үзенең эшен яхшы башкарырга тиеш. Исеме дә жисеменә бик туры килеп тора: «Әр-Рахим Иуда»!!! Һәрбер әгъза өчен махсус кенәгә ясатылды: КГБ, ягъни «Коммунары Гражданской Безопасности». Радий үзенә йөкләнгән эшнең беренче этабын уңышлы башкарып чыкты, хәзер аның кирәге юк. Ул төрле тарафларга жибәргән сектачыларга SMSкалар гына жибәрәсе калды. Аннан соң, һәрхәлдә, монда ил житәкчелегенең турыдан-туры бернинди катнашы булмаса да, янәсе, жөмһүриятттә тынычлык юк, дилбегәне кысарга кирәк дигән сәясәт үзеннән-үзе баш калкытачак!.. Англиядә белем алган Сидуров әфәнденең башы яхшы эшли. Өстәвенә Америка илчесе белән дуслыгы да бар аның!.. Колледжда бер парта артында утырып укыдылар. Шул сәбәп белән бюджеттан миллиардлар «суыруның» менә дигән ысулы иде бу!.. Бер очтан регионнар да «тизәккә» батачак...

Хәйбүш малае Мирза — полиция офицеры, әлбәттә, әлегә бу хакта белми иде. Ул Сания янына ашыкты, чөнки телефонына хатыннан SOS килде. Ул телефонда чагылган хәбәрне тагын бер мәртәбә тикшереп карады: юк, ялгышмаган, экранда ике SMS күренә, берсе — Галинның бурзае Саввадан, икенчесе — ашыгыч ярдәмгә чакырган хәбәр, тәгаен Сания номерыннан.

Ул килгәндә, Сания бакча күршесе Сәлим белән пыр тузып ызгыша иде. Хатынның кулында сәнәк, тегесе дә таяк ише нәрсә тоткан. Сәлим авыз эченнән нәрсәдер быгырдана, сүзләре аңлашылмый, Саниянең исә һәр әйткәне колакны ярып керә:

— Син, яз житкән саен, минем бер буразнамны үз ягында калдырасың! Атаң да шундый иде, бабаң да шулай булган! Бетле хәерчеләр сез! Элек алабута ашы ашап кына исән калгансыз! Эшегез һаман кешенекен урлауда! Нәрсәгә минем жиремә кул сузасың! Минем бабамнан калган жир ул! Хәзер менә милиция чакырттым! Унбиш суткыга яптырам мин сине бу караклыгың өчен! Запой вакытында күзенне акайтып кереп жітәсең бит! Хәзер жир кирәк булдымыни?

Элек булса, Санияне алай тиз генә һич тынычландырып булмас иде, бу юлы Мирза эндәшүгә, ул, кулындагы сәнәген ике межа арасына ташлап, лапас

капкасы янына килде һәм мөлдерәмә яшьле күзләре белән Мирзага карады, таяныч эзләп, аның күкрәгенә башын куйды. Ир-атның һәркайсы да хатын-кызга терәк булырга әзер, Ходай Тәгалә ошбу затны шул рәвешле махсус яраткан. Мирзага бик ошый иде хатын-кызның аннан ярдәм өмет итүе... Полиция сыйфатында гына түгел, нәкъ менә ир заты буларак... Әлбәттә, хатын-кызга әүвәл жир түгел, ир кирәк, жир аннан соң гына... Ир булса, бар да була: ир янына өстәп жирне дә, өйне дә бирә Ходай Тәгалә... Беренче хатыны, алар авылында әйтмешли, «ир давай» иде, ягъни, ирдәүкә холыклырак булды. Һәр нәрсәдә үзе башлап йөрергә яратты, Мирза эшләгән эшне сүтеп жыюдан тәм тапты, кыскасы, кайчагында чүкеч тотарга өйрәтергә дә тайчанмады хатын. Андый хатын белән озак тора алмады ир: алар балалары булганчы ук аерылыштылар. Ә менә Саниянең аннан ярдәм көтеп сыенуы, күкрәгенә башын салуы Мирзага рәхәтлек бирә, ул шушы минутта гәүдәсенә аның өчен таулар күчерерлек гайрәт ингәнен тоя. Тик бу юлы гайрәте башка нәрсәгә сарыф ителде, хатын бары шуннан соң гына тынычланып, күршесен сүгүдән туктады.

— Яз көне жиренне үзем бүләрмен. Межага тимер казык кагам, — дип юатуын дәвам итте Мирза.

— Берәр бураznaга кермәсә, күнеле булмый инде аның. Нәселләре белән шундыйлар. Элек хәерче булган алар, безнекеләр исә атлар, тарантаслар тоткан. Гомер буе көнләшеп караганнар, адым саен нинди дә булса этлек эшләргә тырышканнар. Бабам да шулай дип сөйли иде, — диде инде тынычланган Сания. Мирза да сүзне инде шаяртуга борырга теләде:

— Кулыңа сәнәк тотып чыккансың. Ачудан ялгыш чәнчә күрмә тагын!

Сания матур итеп елмайды һәм:

— Ә-әә, сәнәк ул болай гына ла. Андый вакытта кулга нәрсә туры килә, шуны эләктерәсең инде, — дип куйды.

Мирза торып киенде дә, караватта әле һаман изрәп яткан сылу хатын ягына күз ташлап:

— Сания, бәрәңге бакчасына чалгы да күтәреп чыккалыйсыңмы? — дип сорады.

— Әйтәм бит, кулга нәрсә эләгә инде. Чалгы белән бакча башындагы кычытканнарны чаба торган идем. Аннан соң көз көне бәрәңге сабакларын... Ник сорыйсың?..

Мирза җавап бирмәде, ашыга-ашыга киенде дә саубуллашып чыгып китте. Аның башында төрле уйлар кайный. Ләкин капка төбенә чыгып, башына шлемын киюгә, әлеге уйларны телефон шалтыравы бүлде, телефонда Галиннын бурзае Савва гөрелдәде:

— Кайда йөрисең син? Срочно килеп жит, давай! Сине Мәннәви Мансарович көтә! — диде ул боерулы тавыш белән. «Һе, Мәннәви Мансарович!.. Гектарлаган жирләрне сатып ята анда Мәннәви абзаң!.. Ә монда бер бураzна өчен пычакка пычак киләләр», — дип уйлап куйды полиция офицеры. Ләкин фәлсәфәгә бирелү полиция эше түгел, ул тәртип сакларга, ягъни закон бозучыларга каршы көрәшергә тиеш! Ошбу кагыйдәне эшкә кергән көннән яхшы үзләштергән Мирза шул фикерендә тукталып калды. Аның каравы матае Ябалакка таба очты. Ярты юлда, урман авызында, аны бүлек башлыгы Колоколов машинасы туктатты. Ни гажәп, Колоколов машинада ялгыз башы һәм рульдә дә үзе утыра. Бу юлы тән сакчылары урынына йөргән сержантларын нигәдер ияртмәгән?! Югыйсә «иудалар» вакыйгасыннан соң бу якларда, бигрәк тә урман юлында ялгыз йөрү куркыныч, һәр агач артында «ваххабитлар» сагалап торуы мөмкин. Мирза шулчак тиз генә янә үз фәлсәфәсенә бирелеп алды: «Ябалак урманы бик зур бит ул, чакрымнарга сузылган. Анда йөзләгән-меңләгән агач үсә... нужәли

һәр агач артында качып торырлык «ваххабит» бар икән бу якларда?!» Әлеге уйларын Үзәк аппараттагы берәр түрә белсә, әйтер иде: «Син нәрсә, Хәйбүш малае! Без һәр шикле кешене шул исемлеккә кертергә тиеш! Инструкция шундый!» — дияр иде. Тик ул «инструкциянең» кайдан «төшкәнлеге» генә караңгы иде аларга: агач башыннан гынамы, әллә Мәскәү ягыннан искән җилләр куып китергән болытлардан ук явамы? Хәер, полиция уйлап баш катырырга тиеш түгел, Мәскәүнең «баш мие» бик сырлы аның: ул һәркем өчен үзе уйлый. Син үтә генә. Күкрәгенә орден тагасың килсә, гаиләңне премия акчасы белән сөендерергә теләсәң инде әгәр...

Колоколовның «кыңгыравы» бу юлы бик тавышлы чылтырады:

— Кайда йөрисең син, лейтенант? Сине абзаң үзе эзли! — диде ул, Хәйбүш малаеның мотоциклына гына түгел, башыннан салып кулына тоткан шлемына чаклы җирәнеп карап.

— Сон!.. Үзегез Илсинны үтергән җинаятьчене табарга куштыгыз бит! — диде тегесе, түрәсе янында акланып.

— Чукыныплар китсен лә Илсиннарың! Борислары, Варислары белән бергә! Син аның, Илсин малаеның дим, ваххабитлар шайкасы башлыгы икәнлеген беләсеңме?

— Шайка?! Нишләп шайка булсын? Бер башы бит ул! Анысы да бары саташып кына йөри! Әйбәт малай диләр аны...

— Бүлдермә! Һәр сектант үзе бер шайкага тора ул! Менә шуны юк итәргә кирәк! Аңладыңмы? Әлбәттә, әүвәл тотарга кирәк! Урманга качканнар, ди.

— Качканмы, качканнармы? Иптәш, полковник!

— Какая разница! Менә шул, табасың да юк итәсең! Һәммәсен дә! Аларны тапкан урын кып-кызыл канга баткан булырга тиеш!

— Бер кешене тоткан урынмы?

— Галин син әйткән урынга бер көтү сыер кудырып китертәчәк! Шуларны кыр!

— Пистолеттанмы?

Полковник машинасының арткы утыргычыннан автомат алды:

— Мә! Бу заданиене башкарып чыга алсаң, син сразу капитан! Һәм бер уч... юк, ике уч премия! Тик бу хакта беркемгә сөйлисе түгел!

Түрәсе бик гаярь һәм таләпчән булса да, Хәйбүш малае да төшеп калганнардан түгел: ничек итеп бер көтү гөнаһсыз сыерларны кырып салырга кирәк, ә? Хәтерли: узган ел ашлама ашап бердәнбер сыерлары күбенеп үлгәч, әнисе өзгәләнә-өзгәләнә елаган иде. Шуннан соң ул аякка баса алмады, бик каты чирләп китте дә, хәзер урын өстендә. Шуның өчен дә тиз генә тотып Саниясен килен итеп алып кайту уе белән яши иде Мирза. Әнисе бер сыер өчен хастага калды! Ә монда бер көтү, ди!

— Иптәш полковник! — дип сүз кушты шулчак беркатлы Мирза. — Ә ул сыерлар урынына дим... Алтын Бәртәстәге попның дуңгызларын гына кыр итсәң, булмыймы соң? Дуңгыз дуңгыз инде ул, барыбер сыер түгел. Ә Галинның сыер көтүенә урын табар идем мин!

— Син нәрсә, Рәхимҗанов?! Беләсеңме син дуңгыздан нинди шәп шашлык булганлыгын! Бигрәк тә молочныен кыздырсаң! Аларны әрәм итәсе түгел!

— Ә ул түшкәләрне шашлыкка Сезгә озатсам!

Колоколов, үзенә кара дигәндәй, кулын селтәде һәм Мирзага кесә телефоны сузды:

— Кара аны! Менә шушы телефоннан, бары шушыннан гына минем белән сәгать саен хәбәрдә торасы! Аннары Мирзаның матаена төртеп күрсәтте. — Ә бу таратайканны машинага алыштырып кил!

— Ярый, анысын үзем карармын... — дип калды эченнән генә Мирза аның

артыннан. — Кирилл атакайның дуңгызлары — шәхси милек! Ә милиция-полиция шәхси милеккә кул сузучыларга каршы көрәшергә тиеш дип өйрәттеләр безне! Мин сина лучше кабан дуңгызлары түшкәләрен җибәрермен! Галин бу яклардагы урманда махсус үрчетә аларны! Машина-машина сатып алды! Олигарх дуслары белән бергә ауга йөрү өчен... Алар күп монда! Мин урыннарын да беләм! Менә сина шуннан соң сектантлар каны да булыр! «Кыңгыраулы» полковник Колоколов иптәш-товарищ!» — дип пышылдады полиция өлкән лейтенанты Рәхимҗанов...

Дөресен генә әйткәндә, Колоколов Рәхимҗановка йөкләгән эш Галин планы иде. Бу якларда болай да бик тынычсыз, урманнар төрле сектантлар белән мыжгып тора. Ул «Чиста басу»ны оештырырга теләгән Мәскәү абзыйлары ни рәвешле аяк басарга җөрьәт итәрләр икән монда? Ничек курыкмыйлар диген! Әйе, әйе, әлеге хәлләрдән соң алар тәгаен куркырга, бик каты шүрләргә тиешләр иде... Ни әйтсән дә, бу — бай абзыйларның сыналган алымнары, сәясәткә ачыктан-ачык аларны ничек кенә якын җибәрмәскә тырышсалар да, бу илдә бары сәясәт «дулкыннары» өстендә генә гамакта тирбәлгән кебек тирбәлеп, яшәп була торгандыр, ахрысы?..

Химия заманы һәр корткычка каршы үз агуын уйлап чыгара: Җөмһүриятләрнең болай да биштән дүрт өлеш байлыгын үзенә суырып торган һәм шуның белән үзәккә үткән Үзәкнең комсызлыгын бары әлеге ысул белән генә тыеп була торгандыр, күрәсең!..

## Алтын эзләүчеләр...

Элек Хәсәнбай тегермән тоткан елга буендагы сөрелгән басу өстендә кара каргалар утыра. Шул алтын кояш көлтәсе, нур көлтәсе каргаларның да, суалчаннарның да күзләрен чагылдыра кебек. Кара карганың күзе чагылудан файдаланырга өлгергән суалчан кире җир куенына шуыша, суалчанның күреп житкермәвен форсат иткән кара карга берәр суалчан эләктереп кала. Һәй, Тәнре булып килеп, җаннарга Илаһ булып урнашкан бөек Аллаһы Тәгалә! Бу синең бер искиткеч матур гамәлең ләбаса!..

Байтимернең уенын-чынын кушып әйткән сүзен җор телле Камай авыл өстенә сипте: Баймурзин элек Хәсәнбай тегермәне янында булган басуларны байтамакларга бүлеп бирә, җир казыганда алтын тапкан кешеләрнең хәзинәләре үзләренә булачак, имеш!.. Бу хәбәр чынлап та чынга охшаган сүзләр иде. «Ышанмасагыз, Байтимернең үзеннән барып сорагыз! Ул алпавыт Апанаев алтыннарын тапты бит әле! И шуның белән менә хәзер рәхәт чигеп яши!» — дип тә өстәде Камай. Халык кузгалды. Өлкәннәрне матур әкият балаларга караганда да күбрәк үзенә тарта, күрәсең. Әллә инде ак патшаның яһүд кавемле финанс министры Виттенең заводта ясалган әйбернең кыйммәтен авыл хуҗалыгы тауарыннан (хәзер исә ягулык белән сөт бәһасе!) уннарча тапкыр арттырып куеп, җир кешесен махсус бөлгенлеккә төшергән гамәл-карарыннан соң дистәләрчә еллар буе изелгән крестьянның, үзенең Ходай тарафыннан яратылган адәм баласы икәнлеген тагын бер кат искә төшереп, тагын бер мәртәбә бәхетен сынап карарга уйлавы идеме бу? Кыскасы, халык җиргә ябышты. Халык дәррәү алтын эзләде.

«Елның ел саен җирләр һәйбәтләп эшкәртелде, Ходай Тәгалә рәхмәте белән ел матур килгәндә, уңыш котырып уңды, тамаклар ипигә тую белән беррәттән, кешеләрнең кәмиткә дә вакыты калды, алар Тәңре-Табигатьтән борын заманнан ук килгән гореф-гадәтләрнең якты нурларын сирпеп кенә газиз баласын тәрбия кылды, Аллаһы Тәгалә хакы өчен дога кылды, күнелен нурландырырлык гамәлләр ясарга керешге, акланды, сафланды, пакьләнгәннән пакьләнә барды, Аллага шөкер!..»

Җир эшенә керешкән авылдашларына сөйләгән вәгазен Җәмил хәзрәт әнә

шундый сүзләр белән тәмам кылды. Чынлыкта исә, бар кешенең дә эшләре тәгәрәп кенә бармады, кайбер гаиләләр баштарак ыгы-зыгы да килеп алдылар. Озын Хәсән белән Фәһимә дә читтә калмадылар.

Малаен Казанга циркка алып баргач, Хәсәннең урыс җизнәсе Николай каенәнесенә йомыш кушып җибәрде. Аның алар авылыннан берәр буш яткан иске нигезне сатып алып, җәй тору өчен шунда йорт салырга исәбе бар икән. Күрше авылдан булса да ярый, диде. Әлбәттә, күрше авылдан, Байтамакта сатлык йортлар күптән юк. Хәсәнбай тегермәне янындагы болын-басуны да гаилә хуҗалыкларына бүлеп бетереп киләләр.

Ә циркка алар аюлар биегәнне карарга бардылар. Машина-трактор паркында инженер булып эшләгән Хәсәннең уттай эш өстендә кыл кыймылдатырга да вакыты булмаса да, улы белән хатынының теләкләренә каршы килә аламы соң?! Өстәвенә нәни Наилне әнисе: «Әтиеңнең аю биеткәнен син хәтерләмисең, улым! Кечкенә иден», — дип, шул турыда сөйләп, кызыксындырып та куйган булган. Аю карарга зоопаркка барабыз дип әзерләнеп чыгып киткән җирләреннән циркка эләктеләр. Анда да шундый программа бара икән. Аларга Хәсәннең бертуган апасының малае Шамил дә иярде. Наил юл буе авылда әтисенең ничек итеп аю белән көрәшкәнлеге турында сөйләде. Әнисе сөйләгәннәргә үзеннән дә өстәп, матур итеп хикәяләргә кайдан өйрәнгән бу? Югыйсә, аларның яңа өйләнешкән вакытлары гына иде бит? Хәер, хатыны Фәһимәнең тырышлыгы күренеп тора. Камай аю биеткәндә, аның «койрыгын гына тотып торган» иреннән чын баһадир ясаган да куйган!.. Ничекләр итеп боларның теләгенә каршы киләсең ди?! Ни йөрәгең белән сүзләрен тыңламыйсың инде!..

Кунак ашы — кара-каршы дигәндәй, Шамилне үзләре белән авылга кунакка ияртеп кайттылар. Хәсәннең бертуганы Фәридә гаҗәп хатын: язмыш кушуы буенча урыс Николайга кияүгә чыгып, тупырдап торган кыз белән малай алып кайтты, икесенә дә үзе теләгәнчә татарча исемнәр кушты. Тик, исемнәре татарча булса да, әлегә аларның туган телдә сөйләшкәннәрен ишеткән кеше юк. Хәсәннең әтисенең энесе Рәшит Рәкыйпович — тирә-якта дан казанган умартачы. Умарта оясында ана кортның ни дәрәҗәдә әһәмиятле икәнлеген белгәнгә генә түгел, үзенең күнеле кушкангадыр, алар гаиләсендә хатын-кызның хәяттә тоткан урыны гел бүтәнчә булды: Ир — баш, хатын — муен дигән, исламнан килгән борынгы гадәтне саклаган хәлдә, кыз-хатынның бәхетле гаиләне җыеп торучы ана бал корты кебек булуы сеңдерелгән иде, күрәсең. Алай гына да түгел, хатын ир-атка ни рәвешле ихлас, бирелгән булса, ир дә шундый кимәлдә җавап бирергә бурычлы дигән «мин — сиңа, син — миңа» тойгы-хис гамәле генә дә түгел, кыскасы, аларның ике катлы авыл өендә гаилә тормышы күбрәк хатын-кыз тирәсендә әйләнде, әлеге «әйләнеш» нәселнең рухи халәтенә, сафлыгына, бала тәрбиясенең нигезенә кагылды. Яһүдләрдә нәсел дәвамы хатын-кыз ягыннан бара дигән идек. Татар хатыннары, әгәр японга кияүгә чыкса, «Кобэ» атлы бәби таба, урыс-улак белән бәйләнсә, улы «Штапан» була. Яһүд хатыннары кайсы милләт белән ярәшсә дә, алардан һәрвакыт «Абрам» туар. Татар хатыннарының ирләренә артык тугрылыгыннан киләме бу? Ошбу тугрылыкның күренмәс җепләре исламга, шәригать кануннарына бәйләнгәндер, бәлки? Яһүдләр, күрәсең, бары алар кавеме өчен генә булган затлы зәңгәр канны башкалар белән уртаклашасы килмәүне алга сөрә торгандыр? Бу гаҗәеп һәйбәт гамәл ләбаса! Нәкъ менә әлеге холык-гореф-гадәт-сыйфатның җитенкерәмәве аркасында без башка милләтләрне үрчетеп ятабыз түгелме?

Күрәсең, татар хатыннары бал корты анасы кебек булырга тиеш. Рәшит Рәкыйпович гаиләсендәге кызлар әнә шул рухта тәрбияләнде. Уртанчы кызы Фәриданең Николайга кияүгә чыгуында исә очраклы хәл сәбәп булды. Сөйгәне

Әхмәт, Ичкерия сугышында каты яраланып, үлем исереклеге белән: «Минем Фәридәмне ташлама!» — дип әйтеп калдырды. Анасы — татар, атасы рус булган Коля-Николайның, Фәридә белән танышканнан соң, мәрхүм дустының кызына баш-аягы белән гашыйк булуы очраклы хәл түгел иде, әлбәттә.

Казаннан кайтып кергәч тә, хатыны Фәһимә ире Озын Хәсәнгә сүз катты:

— Казан җизни булып Казан җизни авыл ягына карый башлаган. Әллә без дә Байтимер абыйдан җир сорап карыйбызмы? — диде ул назлы тавышы белән. Фәһимәнең тавышы бу юлы да үтә ягымлы, җылы иде.

— Аны алып карап, соңыннан кая куярбыз соң? Шалкан чәчәрбезме?

— И, Хәсәнем! Теләсәң, син шалкан чәчеп тә аны алтынга әйләндерә аласың бит!

— Әзерләгәннәр ди сиңа, бар!

— Йә, ярар... Синең нәселне белгәнгә күрә генә әйтүем инде. Үзең дә нәрсәгә тотынсаң, шуны булдырасың бит, Хәсәнем...

— Җонлы кулың булмаса, бу заманда җир белән ни майтарасың! — дип карышты Хәсән.

— Аның каравы сезнең нәсел җинел куллы. Әгәр шуннан Хәсәнбайдан калган берәр чүлмәк алтын да килеп чыкса?

— Тоттырганнар ди сиңа!

— И, син бит, кирәксә, үзең дә әйбәт тоттырасың! Төшеп калганнардан түгел, Аллага шөкер!

Әлеге сөйләшү ишегалдында капканың эчке ягына куелган эскәмиядә бара иде. Кунак малае Наил белән шул тирәдә уйный. Шулчак ишегалдында очып йөргән бал корты Шамилнең муенын чакмасынмы! Тегесе бер кулы белән корт чаккан урынга ябышып: «Аллай!» — дип кычкырып җибәрде дә Хәсән абыйсы янына йөгереп килде: «Меня укусила! Абау авырта! Ал әле шуны!» — дип, баскан урынында сикереп тора башлады. Корт чагудан бигрәк, алар Шамилнең кинәт кенә татарчага күчүенә аптырап, авызларын ачып торалар иде. «Хәсән абый! Авырта бит!» — дип, малай тагын да чәбәләнә башлагач кына, Хәсән бал корты угын тартып алды. «Бетте! Бүтән авыртмый инде! Авыртмый бит, име, энем?» «Авыртмый!» — диде батыр малай, тешләрен кысып.

— Энем, бал корты синең теленне чакты ахрысы. Кинәт безнеңчәгә күчтең? — диде көлеп Хәсән. Күрәсең, авырту басылган иде, малай үзе дә көчәнеп елмаерга тырышты, аның туганнары янында, бигрәк тә яшьтәше Наил янында сынатасы килми иде. Ни дисәң дә, шәһәр малае бит әле ул!

— Бал корты телне чакса, кеше үлә! — диде ул белдекле кыяфәттә.

— Юктыр инде, үлми торгандыр! Кайдан беләсең ул чаклысын?

— Әти белән без кыш көне бал кортлары турында күп китаплар укыдык.

— Бал кортлары турында?

— Әйе, без аның белән бал кортлары алачакбыз! — дип, малай үзләренең гаилә серен туганнарына чишге. Шуңа өстәп тагын әйтеп куйды: — Авылда татарча сөйләшергә кирәк. Алайса бал корты чага!

Аның бу сүзләреннән дәррәү көлешә башладылар.

Шул вакыйгадан соң күп тә узмады, Озын Хәсән, урман буеннан җир алып, умарталар куйды. Күп итеп алмагачлар утырттылар, шомырт, балан кебек агачлар да калмады, өстәвенә карабодай белән рапс та чәчтеләр. Җир байтак иде, Фәһимә дару үләннәре үстерәм дип хыяллана башлады. Шул рәвешле урман буенда «Әллүки» дигән шәхси хуҗалык барлыкка килде. Тик Әллүки күле үзе генә һаман күренми, хәер, күл ярында, элек Әбелхәят чишмәсе типкән урында, су саркый башлады инде. Җәмил хәзрәт күлгә Коръән чыгуын дәвам итә иде әле.

Камай тәкъдиме белән күл буенда яшьләр өчен элеккеге кебек кичке уеннар

оештырыла башлады. Клуб мөдире төрки халыкның Тәңре заманыннан килгән төрле йола уеннарын табып алды. Әүвәл яшьләрнең моңа исләре китмәс, кул селтәп, барыбер үзләренчә генә сикерерләр дип уйлаганнар иде, тик киресенчә килеп чыкты: ошбу уеннар бик кызык, һәркемне кызыксындырырлык, үзенчәлекле иде.

Яшьләрнен чыр-чулы тавышын төнге авыл еракларга таратты. Бер кичне урманда качып йөргән Варис та ишетте аларны һәм, кызыксынып, төн пәрдәсе астында авылга да барып килергә уйлаган иде, тик курыкты. Аннан соң телефонына хәбәр җибәрәбез дигәннәр иде. Хәбәр дә килми, урманга качкан бер төркем егетләрнен инде ашарларына да такы-токы гына калып бара. Менә бер дә бер көнне урман аланында алар утлар күрделәр. Гарик атлы сакаллы качкын тикшереп килмәкче иде, Варис аны җибәрмәде, күреп калуларыннан курыкты. Берәрсе күрсә, икенче көнне таң атуга эзләп табачаклары мәгълүм, алай гынамы соң, тапкач, исемнәрен дә сорап тормыйча атарга дигән приказ бар! Шуңа күрә куркулары да бик урынлы. Бәхетләре, аларны бүген шәһәрдән эзлиләр, чөнки юллары калага бару ягында югалган иде.

Урман аланында умарта бакчасы барлыгын да яхшы белә Варис. Иң яхшысы: төнката шунда барып килү, корт бакчасында ашарга да тапмый калмаслар дип уйладылар.

Элеккеге күл буеннан ишетелгән тавышларны тынсыз калып тыңлады Варис. Аның авылдашлары, яшьтәшләре бит! Әле кайчан гына ул алар белән кечкенә уеннарда катнаша, муллалыкка укырга киткәнче, әлеге уеннарның уртасында булды!..Чү! Нишләп бүген генә балачакның төрле такмак-такмазалары, кичке уеннар исенә төшә соң әле Варисның? Әллә алар казып кергән землянканың бер сихере бар инде: ул бик еш төшендә әнисен күрә башлады. Бала чагы кинодагы кебек күз алдына килә, әнисенең мөлаем йөзе, малаена бик еш сөйли торган такмаклары бүгенгедәй күз алдында.

Әмәл көнне яз булыр,
Күктә болыт аз булыр!
Былбыл кош иртән сайрар,
Карганың эче кайнар!

Зур үскәч белде: әлеге әйтем Себер татарларыныкы икән, әнисе — Тубыл кызы, сабыена туган ягы җырын көйләгән булган...

Алар — хәзер урман кешеләре, алар — качкыннар, алар — җир асты кешеләре!.. Землянкада яшәүнең җир астында булуга карамастан, өстенлекле яклары бихисап икән: тирә-юньдәге авыррак баскан аяк тавышларын аермачык ишетеп була, өстәвенә табылдык торбалар — елга буенда элек су сипкән «Волжанка»ның калдык торбалары хәзер бер кирәксезгә аунап яталар — эшкә ярап куйды, Гарик алардан менә дигән «колак аппараты» ясады. Торбаның землянкага төшерелгән авызыннан якын-тирәдәге куаклыкта кыштырдаган куян тавышы да ишетелә, билләһи! Алар куяннарга землянкадан ерак түгел тозак куйдылар, әлеге хәйләле тозакны да Гарик әмәлләде, егетнең андый эшләргә кулы ята иде. Шуннан соң качаклар көн дә куян ите белән сыйлана башладылар. Шул ук Гарик каяндыр аю өчен эшләгән тозак та күтәреп кайтты. Аның теге чакта авылдашы Камай онытып калдырган тозак икәнлеген Варис та белми. Күл буенда авылдашлары аю биеткәндә, ул чит илдә укып ята иде. Иң әһәмиятлесе: бу урманда теләсә кем йөрми дә, шәхси милек булганлыктан, ана керү-чыгу юлларын саклыйлар. Аларны исә монда махсус яшерделәр. Кигәвен белән чебенне исәпләмәгәндә, монда җәннәт кебек иде качакларга.

Иптәшләре арасында иң сабыр холыклысы — урыс егете Виталий. Баштарак

Гарик анын тәмам теңкәсенә тиде:

— Без ярый инде, аңлашыла, рус милләтеннән түгел! Без дин өчен көрәшәбез! Ә сиңа Радий командасында нием калган? Мәскәү сезнең христиан динен кысмый бит! Киресенчә, түрәләр бәйрәм саен чиркәүдән чыкмыйлар. Син нишләп үзенне кигәвенгә тешләтеп йөрисең монда, Виталий дус?

Әлбәттә, Гарик үзенең соравына җавап көтми, чөнки Виталийның язмышын барысы да яхшы белә. Аның әтисенең Кызыл карьерда арендага алган җирләре булган, ул шунда эшмәкәрлек белән уңышлы гына шөгыльләнә башлаган. Ләкин берзаман әлеге җирләрне төрле юллар белән Петербург түрәсе үзенеке иткән, хәзер анда кызыл кирпеч заводы салып яталар! Виталий, җаен туры китереп, үзе ясаган «пугач» пистолеттан әлеге түрәгә каршы һөҗүм оештыра, тик аңа зыян сала алмый, үзе исә көч-хәл белән качып котыла. Ярты ел буе Радий белән аралаша торгач, егет сәясәтчегә әйләнә башлады, аның авызыннан төрле гаделсезлекләргә каршы шактый кискен тәнкыйть сүзләре чыккалый. Мәсәлән, ни өчен Үзәк җөмһүриятнең бар байлыгын, салым дигән булып һәм башка кырыкмаса кырык төрле юллар белән үзенә суырып ята? Урыс авыллары бетте! Чиркәүләр ярым җимерек хәлдә!

Виталий Гарикның чираттагы бер бәйләнүенә каршы әйтеп куймасынмы:

— Син, Гарик, минем башны катырма, яме! Бог один! Мин ислам динен кабул итәргә бер дә каршы түгел! Ислам дине гади халыкны бер йодрыкка җыярга ярдәм итә ул! Чисталык-пөхтәлек турында әйткән дә юк! Аракы эчүгә дә каршы! Мин честно говорю, исламны рәхәтләнеп кабул итәм мин! Тик бу гаделсезлеккә генә чик куелсын! Минем әтием тирә-юньдә атаклы кешеләрнең берсе иде! Хәзер беләсеңме нинди хәлгә төште ул? Белмисең, эчүгә сабышты, алкаш ул хәзер! Мин теге Капраловның барыбер башына җитәм әле! Аннан Радийдан алган бар акчамны әтине лечить итәргә тотачакмын! Минем бик булдыклы энем бар, без шуның белән килештек инде! Ә үзем Америкага качып китәм! Радий ярдәм итәм диде!

Монда чакта егетләр ничек кенә батыр кыланырга тырышсалар да, барыбер куркыныч, алда көткән билгесезлек куркыта иде аларны!.. Варис акрынлап «аңына» килә бугай. Хәтта әтисен юксына башлады. Бәлки, ул әле исәндер дигән өмет чаткысы да керде күңеленә... Хәер, үлгән икәнлеген тәгаен белә бит инде, югыйсә! Бәлки, исәндер?.. Ул аны әүвәл үзе өчен үтергән иде бит! «Үзе үтергән» иде. Аллаһы Тәгалә аның бу гамәлен аклый торгандыр ич инде! Ул бит аның хакына, Аллаһ ризалыгы өчен шулай эшләде! Тәүхид! Бу сүз, әлеге төшенчә бар нәрсәдән дә өстен! Аллаһы Тәгаләнең кануннарын берәү дә үзгәртергә хаклы түгел! Бары тик аңа табыну тиешле!

Гарик — мулла кушкан исеме «Гариф» — башкалардан аермалы буларак, төшенкелеккә бирелми торган кешегә охшаса да, күңелендәге курку хисен басу өчен генә үзен шулай тыныч тотканлыгы барыбер сизелеп тора. Хәер, ни дисәң дә, егеттә барыннан да бигрәк үч алу хисе көчлерәк бугай. Бирәне туя белмәгән олигарх аркасында бер туган абыйсы үлем хәлендә ята, шул ук бәндә әтисе белән әнисе дә, Гариф үзе дә бик яраткан киленнәрен, аның туган апасын, алдап-йолдап, мәсхәрә итте! Авариядән соң шактый тернәкләнеп килгән абыйсы, әлеге хәбәрне ишеткәч, бөтенләй аяктан ук егылды, психикасына зыян килде бертуган абыйсының! Хәзер «сары йорт»та дәвалана! Башы авышкан булса да, үзенең кемнәр аркасында мондый хәлгә төшкәнлеген йөрәге белән сизә бугай абыйсы: җүләрләр йортында Галин дигән олигархка каршы көрәшү өчен «хәрби полк төзим» дип хыяллана!..

Галинга булган үче, нәфрәте Гарик-Гарифның бары үзенеке генә, бу хакта берәү дә белергә тиеш түгел, егетнең сизенүе буенча, алар әлеге Галин сатып алган урманда качып яталар бугай!.. Кызык, ул хәзер үзенең кан дошманына бик кирәкле төркемдә! Моның ахыры ни белән бетәчәген белмәсә дә, ул бүгенге хәлетеннән

барыбер канәгать!.. Чөнки үч алуның юлы торган саен кыскара бара кебек...

...Мәннәви Мансаровичның кунаклары урынына каенатасы ялгызы гына кайтып төште. «Җыен булмый әлегә, — дип юатты киявен Рафинад Хәләфович. — Башка мөһимрәк эшләр бар. Телефоннан сөйләшә торган нәрсәләр түгел!» — дип өстәде гаярь каената.

Рафинад Хәләфовичның төгәл уйланган планы бар иде.

— Иң беренче эш итеп Изольда белән рәсми рәвештә аерылышыгыз! — дип башлады ул сүзен. — Аңлыйсыңмы син? Төшенәсеңме, Мәннәви?

— Төшенәм бугай...

— Байлыгыңны Изага яздыр. Алайса бөтенләй ярык тагарак янында утырып калырга можете!

— Соң... Без үзебез дә шулайрак уйлап тора идек, Рафинад Хәләфович.

Тегесе, авызын ерып, киявенең җилкәсенә кулын салды:

— Нинди «Хәләфович» булыйм ди мин сиңа! Авызыңны тутырып элеккечә «эти» диген, кияү!

— Без, эти, инде загска гариза да җибәрдек. Әүвәл мин бар мөлкәтне Иза исеменә яздырдым. Тагын... бар инде... Юристлар көне-төне эшләделәр.

— Дөрес эшләгәнсез.Чиркәү вакыйгасын сиңа гафу итмәскә мөмкиннәр. Мәчет булса, бер хәл иде әле, төкереп тә бирмәсләр иде... Так... Синең монда «прослушкалар» юктыр бит?

— Юк!

— Барыбер, әйдә, аулаграк урынга чыгып сөйләшик әле. Бакчага киттек, давай. Не шутка! Бу чаклы җирләрне тегеләр тартып ала икән, эшләрегез харап булачак! Әйдә, киттек. Только вискиеңны эләктер үзең белән. Тамак кибеп тора.

Галин хезмәтчесенә ым какты да үзе каенатасы артыннан бакчага чыкты.

— Синең баш түгәрәк, кияү. Шәп уйлагансың.

— Иза белән икебезнең уртак фикер бу. Хәер, Иза миннән алданрак та эш башлаган булган. Имеш, без әйбәт тормыйбыз. Имеш, Галин гулять итә. — Үзе дә, дип өстәмәкче иде Мәннәви, ләкин каенатасы белән сөйләшүен исенә төшереп, телен тешләде.

Ә Изольда Рафинадовна белән сөйләшү болайрак булган иде һәм, әлбәттә, ул аны каенатасына җентекләп сөйләп тә бирә алмый. Сөйләүнең кирәге дә юк. «Без аерылышкан булып кыланыйк, Иза. Баш өстендә болытлар куера», — дип сүз башлаган иде Мәннәви. «Ә мин бу хакта күптән уйлыйм инде, Моня! — диде хатын. — Шуңа күрә авылның бер хәерче укытучысы белән роман да изображать иткән булып кыландым!» «Кыландың гынамы?! Әллә???» «Ты что, Моня, миңа синнән башка беркем кирәк түгел!» «Ярый, Иза, сайрама! Барыбер ышанмыйм!» «Ышанмыйсың? Ә мин сиңа докажу! — Иза иренең кулын корсагына куйды. — Менә шуның белән, малаең белән докажу!» Мәннәви өнсез калды, аннары, кинәт исенә килеп: «Иза! Ты что! Әллә?» «Әллә түгел, Моня! Точно! Синең кебек бер бөдрә малай алып кайтырга җыенам!» «Минем кебек бөдрәсе булса, ышанам! Иза, сиңа срочно чит илгә китәргә кирәк! Сохранениегә! Аннан соң Америка гражданины булып туса да әйбәт бит инде!» Сөйләшү менә шул рухта булды. Ахырда Изольда Рафинадовнадан: «Моня, теге... кем... Харакери... Хәким дигән иптәшне үзең хәл итәрсең инде. Ул үз эшен әйбәт эшләде: бөтен тирә-юньне сасыткан. Хәзер безнең аерылышуга беркем дә аптырамаячак. Иза, чынлап та малай минекеме соң?» «Борчылма, малаең бөдрә башлы булачак, Моня! Хәтерлисеңме, төрек мунчасын? Шул, төрек мунчасының сихәте яхшы булды...»

Мәннәви, уйларыннан аерылып, каенатасына карады. Тегесе балан агачына карап катып калган, йөзе агарынган, сүзен дә әйтә алмыйча үрә катып тора иде. Балан чәчәгендә бал корты утыра, каенатасының карашы шунда иде. Күптән түгел, Рафинад Хәләфовичны берьюлы ике бал корты чагып, көч-хәл белән

алып калганнар иде. Каенатанын бал кортлары угына коточкыч аллергия, тыны кысылып, жан тәслим кылырга мөмкин. Мәннәви, Рафинад Хәләфовичнын сак кына жиненнән тартты да өйгә таба әйдәде. Тегесе киявенә карусыз буйсынды.

— Мунчада жучоклар юк, эти, әйдә шунда кереп сөйләшеп бетерәбез, — диде ул сак кына.

Каената белән кияү бер үк нәрсә хакында сөйләштеләр, бертөрле үк карарга килделәр. Тик әлеге карар-гамәлгә икесе тарафыннан ике төрле мәгънә салынган, ягъни максатлары капма-каршы, бары кылыначак гамәл генә бер булып, аның нәтижәләре, әйткәнебезчә, төрле-төрле булачак иде. Рафинад Хәләфович мәсьәләгә Мәскәүдә калган дуслар күзлегеннән карады, Мәннәвинең исә үз максаты: монда тыныч түгел, эзегезне суытыгыз моннан! Югыйсә, басу чистартам дигән булып, үзегез тизәккә батып бетәчәксез! Хәер, алай гына котыла алсагыз, башыгыз белән нәжескә кереп чуммасагыз! Бездәге сектантлар, милләтчеләрне берничек тә тыеп булмый! Котырган алар! Котырган арысланнар кебек! Сак булыгыз, әфәнделәр! Үз капкагыздан борыныгызны күрсәтмәгез! Ни кызганыч, мәсьәлә Мәннән Галиев уйлаганча түгел, яна гына Үзәктән кайтып төшкән каенатасы Рафинад Хәләфович теләгәнчә, ягъни аның жан дуслары, аның арка терәкләре исәпләгәнчә дә булырга мөмкин иде. Чөнки пычрак сәясәтнең эчкерле мәнфәгатьләре бу иллә һәрвакыт жинеп килде... Парольдә килешенелде: «Изольданың кәефе яхшырды. Иртәгә төш вакытында аякка басачак, ди, табиблар!» Димәк, төш вакытында!..

Мәннәви үзе башка төрле пароль тәкъдим иткән иде: «Изольданың яшь әтәче әбәдтә күкәй салган, имеш». Каенатасы аннан көлде генә: «Шундук сизәчәкләр, син нәрсә? — диде ул. — Әтәч күкәй салмый». Ахырда Мәннәви үзе дә килеште, югыйсә, әтәч, тавык темасы һәм Иза якын төшенчәләр иде. Чөнки ул күптән түгел үзенең тавык фермасын аякка бастырып, күкәйләренә әйбәт кенә заказлар да жыярга өлгергән иде. Әтәчләре үзләре генә дә ни тора! Экологик чиста йомыркага да сорау бик зур, бәһаләре дә күркәм генә... Эшмәкәрлегә шома гына тәгәрәп китсә дә, тик вакыт-вакыт Изаның кәефе кырылып ала иде: хатын әтәч халкы хакында шактый мәгълүмат туплады һәм аның берсе хужабикәнең шактый кәефен жибәрде! Баксаң, әтәч бик масаеп, таң атуга дөнья шаулатып кычкырып гайрәтләнсә дә, койма башларына очып куныш: «Бу дөнья, бу ишегалды тулы тавыклар минеке генә!» дип канат кагынса да, баксаң, аларнын ирлек әгъзалары — жан жирләре булмый икән ләбаса! Әнә шул нәрсә күнелен төшерде Изольда Рафинадовнаның...

Ул, гитарасын кулына алып, жыру сузды. Әлеге сүзләрне ана Хәкимчигы язып биргән иде:

Ак Урда-Алтын Урда, Илаһым,  
Мин балык булганга күрәдер...  
Идел-Ярда чабаталы халык,  
Гөмбәгә дип кәржин үрәдер....

Күк Урда, Ак Урда, Алтын Урда,  
Шыгрым тулы батыр халык иде.  
Хәзер,  
көмешме син, алтын тарихлымы,  
Син бүген телсез балык инде...

Син дә — балык, мин дә, без — халык.  
Халык булсак та, без — балык!  
Ләкин бит алтын балык!!!  
Алтын балык булсак ни ди?!  
Балык балык инде...

телсез балык...
Җирсез халык.
Иле булып та,
Юктыр ханлык.
Юклык аркасында
телсез калдык.
Әтәчсез, тавыксыз калдык,
димәк, күкәйсез калдык....

«Талант бу Харакери! — дип уйлап куйды хатын, гитарасын читкә атып. — Шундый талантлы кешедән киләчәктә гений булырлык бирәр малай тапсан, ә? Чәченме?.. Чәчләрен, роддомга яшертен генә парикмахер чакыртып бөдрәләтергә дә була бит!.. Изольда яраткан җырын шыңшырга кереште:

Ялкын сүнде, очкын калды —
Күзгә керә бары тәтен.
Югалтканны табармын күк,
Сүнә күрмә, өметем!..

## Бал корты

«Фикерли белгән адәмнәр өчен бал кортларының эш-гамәлендә зур гыйбрәт вә дөреслек бардыр. Бал кортларына һичкем дәрес бирә алмас, ләкин кешеләр бал кортларыннан дәрес алсыннар...» Коръән Кәримдәге ошбу юлларны исенә төшерде дә: «Мин бүген бал кортларыннан дәрес алырга түгел, аларның балларын алырга барам», — дип пышылдады Варис үзалдына. Бал корты дигән сүз үзе генә дә егетнең күңелендә ничаклы хис, башында уй-фикерләр уятырлык. Шулай булмыйни: заманында әлеге Аллаһ ияләре ярдәмендә әнисен яман чирдән коткарып калганнар иде! Тау башы урамнары хатыннары шуларның нигъмәт-дарулары аркасында итәк тутырып балалар таба алдылар. Югыйсә аларга зур-зур табиб-профессорларның карары чыгарылган иде: «Сезнең басудагы бәрәңгене Ф. дигән агу белән агулаганнар, әлеге агу хатын-кызларның бала табу сәләтен юкка чыгара икән!..»

Хәтерли Варис: әнисенең теш казналары бозылып, канына яман бактерияләр кергәч, шул ук табиблар кул селтәгән вакытлар иде ул. Әтисе хатыны, Варисның әнисе өчен җаны-тәне белән көрәште, аны алып калырга тырышты, табиблар өмет юк дигәч, халык медицинасына мөрәҗәгать иттеләр. Файдасы күренмәде. Шуннан соң Равил атлы бер умартачы әтисенә ана бал корты сөтен эчертеп карарга тәкъдим иткән. Тирә-юньдә «Чумар» кушаматы белән билгеле нәселнең Равил атлы малайлары, чыннан да, бик күп еллар умарта тота, ул бу тирәдә «умарта профессоры» дигән ат алып, хәзер аның яныннан кеше өзелми иде. Равил һәркемгә теләп ярдәм итә. Ул инде дистә еллар бал кортлары арасында кайнашып, үзе дә шулар холкын алып бетергән: бер тиктормас, һәрвакыт нәрсәдер кайнаштыра; әгәр берәр кешегә ул тәкъдим иткән «баллы дару» килешә икән, сабыйларча ихластан сөенә торган мөхтәрәм шәхес иде ул бу якларда. «Чумар» дигән нәсел кушаматы алар гаиләсен беркайчан да каралтып билгеләрлек булмаса да, хәзер ата-бабадан калган яңгыравыклы әлеге исем-ат та онытылып, халык телендә бары «Умартачы Равил» дигән сүз генә йөри башлады. Ә, баксаң, бу кушамат гаиләдәге һәр малайга карата да аны зурлап, ихтирам йөзеннән әйтелә кебек иде. Абыйсы Рафаэль дә үзенә күрә гади генә егет түгел иде бу якларда. Гел көлеп, елмаеп торган олы җанлы, кара тутлы шул егет күз кысса, күрше Бәксәр, Усад авылларының марҗа кызлары шундук намазга

басарга әзер иде. Гомумән, әлеге гаиләгә олпатлык сыйфаты борынгыдан хас иде. Ул аларның әтиләре Исмәгыйль абыйга да, күрәсең, бабаларыннан ук килгән булгандыр. Варис мәктәптә укып йөргәндә, әтисе тимерчелектә эшли иде әле. Малай мәктәпкә барганда-кайтканда да тимерчелек алачыгы аша уза, ә юл исә Исмәгыйль абыйларының капка төбе аша иде. Варис, бу капкага килеп җитәр алдыннан, эскәмиядә тыныч кына утырган, алтын кысалы күзлек кигән Исмәгыйль карт белән исәнләшергә алдан ук әзерләнеп килә, тамагын кырып куя. Әгәр Исмәгыйль карт чынлап та шунда була икән, ерактан ук ана сәлам бирә, кайтканда очраса, тагын исәнләшә. Ул картны күрсә, малайның юлы уңа: мәктәптә «бишле» эләктерә, кайтканда очратса, берәр машина туры килеп, авылына чаклы булган өч чакрым араны шуңа утырып кайта. Варис моны әле дә яхшы хәтерли. Рафаэль белән умартачы Равил нәкъ менә шул Чумар Исмәгыйле малайлары иде. Рафаэле чынлап та маржа кызына өйләнеп, килен Наташадан Наиләгә әйләнде һәм алар ул вакытта «шәһәр тибындагы авыл!» дип дан алган Шәпшедә матур гына тормыш корып җибәрде. Равилне исә язмышы күрше авыл кызы, үзе кебек игелекле күңелле Зифа белән кушты. Зифа Казаннан укып кайтып, шәфкать туташы булып урнашкач, әби-апалар аның исемен аеруча йомшак итеп, яратып әйтергә гадәтләнеп киттеләр. Зифа кан басымын үлчи, Зифа шул даруны эчәргә кушты, Зифа болай диде, Зифа тегеләй диде. Варис боларның барысын да ишетеп, күреп үсте. Умартачылар гаиләсе белән аның әтисе аеруча дус булды. Районның бар түрәсе шулай ук Равил янына «йомыш» белән йөрде, Равил эшләгән бал ширбәте (медовуха) аеруча тәэсирле иде. Тик ялгыш аңлашылмасын, куен кесәләрендәге көмеш савытларда затлы әрмән коньягы йөрткән түрәләрнең Равил янына сәрхүшлектән килүләре түгел. Эш шунда ки: Равил умартачы ясаган ширбәттән соң әлеге түрәләр өчәр көн, кайберсе хәтта атналар буена өйләренә кайта алмыйча, сөяркәләре янында кунып калырга дучар иделәр... Әлеге ширбәтнең ир-атның көчен арттыра торган тылсымлы могҗиза булуы фән белән дә, инде җирле түрәләр тарафыннан да күптән расланды. Бу ширбәттән авыз итеп караган ирләрнең хатыннары исә аның бер граммы өчен дә зур акча чыгарып салырга әзер... Равил умартачының һәр тамчы ширбәте алтын бәһасенә тиңсез иде бу якларда!..

Борис та әүвәлрәк малаенын умартачы булуын теләде, инде дин ягына авышкач, икесе дә игелекле юл дип, каршы килмәде. Әмма Варис умарталык мәктәбен тәмамлап кайтырга өлгергән иде. Берара хәтта Равил янында ярдәмче дә булып эшләп йөрде. Менә шул Равил ана бал корты сөте биргән иде Бориска. Ике-өч атна әлеге серле даруны эчкәннән соң, әнисе аякка басты, алай гына да түгел, табибларны шаккатырып, ахыр чиктә тәмам савыгып җитте. Варис хәтерли: шуннан соң сырхау-сыктауның ни икәнлеген дә белмичә, әнисе байтак гомер тормыш тәмен тоеп, аңа сөенеп яшәде. Ананы бала кайгысы бетерде... Аяктан екты... Варис укуын тәмамлап кайтыр алдыннан, фани дөньядан китеп тә барды. Монда инде бернинди бал кортлары могҗизасы да ярдәм итә алмады.

Варисның дин юлыннан китүенә иң сөенгән кеше, мөгаен, әнисе булгандыр. Кайсы ананың үз баласын тәүфикълы итеп күрәсе килмәсен ди! Шулай бер ел узды, ике... Варис ел саен каникулга кайтып китә иде. Бер кайтуында аны ниндидер террорчылыкта гаепләп ябып куйдылар. Соңыннан ачыкланганча, гаебе булмау сәбәпле, булачак «яшь сектачыны» азат иттеләр, ул тагын укуын дәвам итәргә китте. Бу да ана йөрәгенә зур кайгы булды.

Икенче бер кайтуында аның хөрмәтенә Коръән ашы уздырырга уйладылар. Мәҗлескә хөрмәтле кунак буларак Мәхмүт хәзрәт чакырылды. Менә шул хәзрәт укып, догасын әйтеп бетерүгә, Варис ярып салмасынмы: «Сез барыгыз да наданнар! Дөрес укымыйсыз! Дөрес дога кылмыйсыз! Сез — Аллаһ

юлыннан читкә тайпылучы мескен бәндәләр!» Алай гына да түгел, Мәхмүт хәзрәткә таба караваттан мендәр алып орды. Тегесенең алдындагы кайнар чәе йөзенә чәчрәде, бите пеште. Әнисе аңын югалтып егылды, Варис өйдән чыгып китте.

Болар хакында уйлыйсы да килми. Бал кортлары хакында гына уйлыйсы килә Варисның... Андый халәт тынычландыра. Һе... алар адәм балаларына караганда мең тапкыр акыллырак һәм хаклырак та түгелме соң әле?! Аллаһ бәндәсендә бал кортындагы чаклы да акыл юк! Юк, билләһи!.. Мәгәр булса, җир йөзендә мондый сугышлар, талаш-ызгыш, үтереш-көчләүләр булыр идеме?! Бәндәләре Иллаһыдан башкага, шул ук вакытта кешегә табынырлар идеме?! Бал кортлары дөньясында юк лабаса алар! Чәнчә бармак башыннан да нәнирәк бал корты ел буена үз авырлыгыннан дистәләрчә күбрәк сихәтле ширбәт җыя. Кемнәр өчен? Адәм балалары өчен! Ә тегеләренә һаман акыл керми. Кешеләрнең баш миләре бал кортларына караганда меңнәрчә тапкыр зуррак, яхшырак уйлый белгән саен, алар кабахәтрәк, явызрак, ялкаурак, хөрәсән һәм хөсетрәкме?! Йа, Илаһым! Дөресме соң бу? Менә бүген дә синең бер бәндәң, ашарга эзләп, шул бал кортларын янына бара!..

Гарик землянка эчендә иде, ул атылып урамга чыкты да:

— Монда кемнәрдер килә? — диде куркынган тавыш белән. — Җир өстендә аяк тавышлары ишетелә!..

— Аю түгелме икән? — дип шомланды Варис. Һәм тиз генә землянка эченә чумды. Аларның монда тротилл бомбалардан тыш яхшы карабин мылтыклары да, гранаталары да бар.

Аяк тавышының иясе ялгыз бер ат булып чыкты. Бу ат, әлбәттә, аларга бернигә дә кирәк түгел, киресенчә, иясе аны эзләп монда килеп чыгу куркынычы гына бар. Гарик атны куалап җибәрмәкче булып, каршына төште. Әмма тегесе бераз читкә киткән була да янә кире әйләнеп килә. Бәлки, ул урманда ялгыз йөрүдән туйгандыр, кешеләрне сагына башлагандыр дигән карарга килде алар. Тик шуның артыннан ук аланда чит ил машинасы пәйда булды. Тавышсыз эшләгән әлеге машинаны килеп туктагач кына күрделәр һәм качаклар янә землянкаларына чумды. Тик монда качып ятудан бернинди мәгънә чыкмаганын аңлаган Варис, кулына карабин алып, өскә калыкты. Килүче кеше Савва Васильевич, аларның танышлары иде. Варис әүвәл атны да шуныкы дип уйлаган иде, тик теге, үзе атка шикләнеп карый-карый, болар янына килде һәм:

— Нинди ат бу? — диде. Тегеләр, белмибез дип, җилкәләрен сикерткәч, туп-туры муенын чыршыга ышкып торган ат янына китте, аннан соң кулы белән Варисны үз янына дәште.

— «Аргамак»тан качкан ат бу! Качкан дип, башка атлар белән каяндыр Себер ягыннан кайтты ул. Аргамаклар ярышка барганнар иде, шунда менә бу хуҗасыз ат та ияргән, — диде Савва бик белдекле кыяфәттә. — Курыкмагыз, бу атны эзләп йөрүче булмас. Хуҗасыз бит.

Савва Васильевич, кечкенә күн букчасыннан нindидер карта алып, Вариска ымлады:

— Менә яхшылап исеңдә калдыр. Бу картаны үзем белән алып китәм. Алтын Бәртәс авылы бу, күрәсеңме?

— Күрәм, — диде Варис, сүзнең ни хакында барачагын аңларга тырышып.

— Ашыкма син, Боря, — диде Савва. — Бу эш аеруча важный. Яхшылап тыңла да исеңдә калдыр! Менә Алтын Бәртәснең чиркәве. Ул күккә ашарга тиеш! Аңладыңмы! И менә бу Ябалактагы мәчет тә күккә ашарга тиеш. Менә монысы — федераль трасса. Анда да берәр «уенчык» куясыз. Урыны күрсәтелгән.

— Ә вакыты? — дип бүлдерде аны Варис.

— Көнен конкрет тагын хәбәр итәрбез. Ә вакыты... обед вакыты, яме! Онытмыйсынмы?

— Юк, Савва Васильевич, онытмыйм! — диде Варис, анын күзләренә карамаска тырышып. Чөнки анын күзләре еланныкы шикелле: каршында бака торса, ул аны шундук үз эченә суырып алырга әзер.

— Савва Васильевич, ә ашарга нәрсә алып килдегез? Безнен запас бетте бит. Куяннар да тоттырмый хәзер. Ә мылтыктан атарга куркабыз. Тавыш чыга. Егетләр ач! — диде Варис, машинага таба ымлап.

— Менә монысы минем прокол, командир, онытканмын. Ашарга иртәгә, яме. Мин көн саен монда күренеп йөри алмыйм, анлыйсын. Ха! Әнә, бу атны суегыз да ашагыз! — дип, инде тыныч кына үлән чемченә башлаган атка таба ишарәләде. Сүз шунын белән тәмамланды, Савва Вариска яна телефон сузды:

— Менә шушында задание буласы көнне сообщение килер. Бер көн алдан. Пароль: «Изольданың кәефе яхшырды. Иртәгә обедта аякка басачак, ди табиблар». Анладынмы, командир?!

— Анлавын анладым. Егетләр ач.

Савва баягы күн букчасыннан бер төргәк яшел акча чыгарды:

— Болары аванс!

— Акчаны ашап булмый бит аны, Савва Васильевич!

— Йә, ярар. Берәр жаен табарсын. Син — акыллы егет! Ә теге атны чынлап та «кых» итә аласыз. Берәү дә эзләмәячәк аны, — диде ул киткәндә.

Бу Савва иблис токымыннандыр! Бу атка куллары ничек күтәрелсен ди! Өстәвенә жөмһүрият атлары Новосибирскига ярышка баргач, шуларга ияреп кайткан ат ди бит! Өтермәннән кайткач ак аяклы кара аты турында, Байтимер абый еш сөйли иде, сагынып, яратып сөйли иде ул анын хакында. Бу дүрт аягы тиң ак булган кара айгыр шул ат түгелме икән дигән фикер дә килде Вариска. Тик мона ышануы кыен иде. Байтимер абыйга ничек күрсәтеп карарга соң бу атны? Кушаматын ничек диде әле? Хан диде бугай?.. Хан булса, шундук танып алачак бит инде ул аны? Ышан, атлар хужаларын эзләп меннәрчә чакрым юл узалар ди бит. Этләр хакында да шулай дип сөйлиләр?..

Варис атка якынрак килде. Бер кулы белән атнын ялына ябышып, ана атланды. Күрәсен, ат атландырырга өйрәтелгән иде, ул жайдагына каршылык күрсәтмәде. Шулчак Варисның башында бер фикер туды: «Атланган килеш тиз генә чаптырып умарталыкка барып килсәм? Икенче көн ачтан интегәләр бит инде?»

Жамалетдин умартачы, Галин урманны хосусыйлаштыра башлагач, тиз генә тотып Байтимер ярдәме белән умарталык жиренә — ул гажәеп матур урман аланлыгы, суга да ерак түгел, әйләнә-тирәдә гел катнаш урман булып, күпчелек агачлар исә яшь юкәләр — аренда кәгазьләре ясап өлгергән иде. Варис шул умарталыкка таба юл тотты. Ат — Варис ана нинди генә исем-кушаматлар белән дәшеп карамады, ләкин табылдык жан иясе берсенә дә игътибар итмәде — ул уйлаганга караганда да акыллырак, күндәмрәк булып чыкты, һәр таләпкә карусыз буйсынды.

Варис атны умарталыкка кадәр алып бармады, шактый ара кала, үлән йолкысын дип, бавын бушатты да шундагы бер агачка бәйләп куйды. Әлбәттә, көпә-көндез умарталыкка кереп, карак аю кебек йөреп булмаячак иде: умартачы Жамали һәрвакыт шунда, үзе булмаганда, каравылга башка кеше калдырганы да мәгълүм Вариска. Бәлкем, көндез карап, тикшереп кенә кайтырмын дип уйлаган иде ул. Тик ашыйсы килү теләге барыннан да көчлерәк, әллә, батырлыгын жыеп, шыпырт кына киртә белән әйләндереп алынган умарталыктан кырыйдагы берәр ояны ачып карасынмы? Инде балан да күптән чәчәк атты, язгы чәчәкләрдән

соң җәйге чор башланып, кортларның иң актив бал җыя торган вакытлары икәнлеген егет яхшы белә... Ә Җамали умартачының эте белән нишләргә? Аның Алабай кушаматлы эте Варисны таный, чөнки ул умартачылыкка укыганда, Җамали карт янына еш йөрде, практиканы да шунда узды. Дөрес булса, кемдер төнлә Алабайга агу биреп киткән дип ишеткән иде ул. Җамали умартачы этсез тормас, Камай аңа шәһәрдән усал бер сакчы алып кайтып бирми калмагандыр?.. Ә турыдан-туры умарта өенә барып керсә, картка мәсьәләне ачыктан-ачык аңлатса? Полициягә тотып бирерме? Чөнки алар төркеме хакында бу якларда шактый куркыныч хәбәрләр таралып өлгергәне дә мәгълүм! Аңламас, тыңламас микән Җамали умартачы? Аңлашкан очракта, ул аңа азык-төлек тә төяп җибәрәчәк бит инде канә! Хәер, алай итәрме икән? Мәхмүт хәзрәтнең бертуган энесе бит ул. Варисның теге чактагы кыланмышын искә төшермәс дип уйлыйсыңмы? Нәкъ шул вакыйгадан соң Мәхмүт хәзрәт авылдан китеп барды бит инде...

Үтереп ашыйсы килә. Варис үзе белән карабин алмаганына үкенеп тә куйды. Тик ни хәл итмәк кирәк: эш узган, буш кул белән ризык табарга тиеш ул хәзер...

Варис, озын үләннәр арасыннан шуыша-шуыша, киртә янынарак килде. Үзе дә белмичә, нәкъ эт оясы янына килеп чыккан. Соң... теге чакта аның оясы башка урында иде бит! Күчерде микәнни Җамали карт этен? Бәйдәге эт чит кеше барлыгын шундук сизеп алды һәм, бәхеткә күрә, Алабай үзе иде ул: Варисны танып, шыңшып куйды да, җиргә ятып, киртә янына ук шуышып килде, иркәләнеп, койрыгын болгый башлады. «Алабай! Алабай! Әйе, мин бу! Мин!» — диде тегесе, эткә таба кулын сузып. «Алабай, ни... миңа берәр умарта оясын ачып карарга рөхсәт бирерсең инде, яме», — дия-дия, киртә астыннан шуышып бакча эченә узды. Алабайны кочаклап яратты, сыпыра-сыпыра иркәләде. «Рәхмәт сиңа, Алабай. Син адәм баласы түгел шул, аңладың, рәхмәт!» — дип сөйләнә-сөйләнә, иң кырыйдагы умарта оясы янына килде. Беркавым колакларын торгызып, тирә-яктан килгән тавышларны тыңлап торды. Тыныч иде. Умарта оясын ачып, аннан ике рам тартып алды. Янәшәдәге икенче оядан тагын ике рам алды. Рамнар авыр, инде бал белән тулырга да өлгергән, хәтта берсен бал кортлары мөһерли дә башлаганнар, рәхмәт төшкерләре. Алабайның оясы янындагы җамаяк кырыендагы үләндә яртыга бүленгән кара ипи дә ята. Варис аны да алып капчыгына салды. «Алабай, син ачуланма инде, яме, ипиеңне дә алып торам. Мин сиңа аның урынына может куян ите алып килеп бирермен. Эләксәләр инде. Соңгы вакытта алары да бетте. Безнең тозакны сизеп, качып киттеләр бугай бу тирәләрдән. Рәхмәт, Алабай. Яме! Шәп егет син! Ярый, кеше акылллары юк әле синдә, Алабайкаем. Без, кешеләр, бер-беребезгә карата усал этләрдән дә яманрак хәзер, Алабай. Менә шулай. Ярый, мин китим инде. Алайса Җамали абыең килеп чыгарга мөмкин. Хәер, хәзер намаз вакыты. Намазлыкта әле ул. Пока, Алабай, яме! Миннән сиңа тәмле куян ите, обещаю, дустым. Пока, пока...»

Кара ипи белән хуш исле балны сыптырып куйгач, күңелләр күтәрелде, йокыга тарта башлады. Сафронны сакта калдырып, землянка эченә кереп киттеләр. Сафрон, Варис уенча, араларында иң ышанычлысы. Чөнки аның Галиннан да, Капраловтан да үч аласы юк, ул акча эшләү өчен генә иярде. Димәк, урман өстенә Галин вертолёты күренсә дә, битараф калыр, кызуланып ата башламас, гранаталар урлап, Капраловны да эзләп китмәс.

Землянка салкыны йокыларын ачты.

— Бал кортлары турында сөйләле тагын, Боря, — диде ылыслар өстендә кырын яткан Гарик.

— Мин Боря түгел, Варис!

— Ну Варис. Ярар, кәжәләнмә инде. Мин болай гына бит. Якын итеп кенә. Сөйлә инде, ә! Менә баллары белән дә сыйландык.

Тамак туйгач, чынлап та, башка әллә нинди уйлар килә, фәлсәфәгә бирелә башлыйсың. Варис, ятагын рәтләде дә, егетләр ягына борылып, кырын ятты һәм сөйли башлады:

— Бал кортларын да, адәмнәрне дә бер үк Ходай яраткан. Их, егетләр, белмисез әле сез аларның дөньясында нинди тәртип икәнен! Шаклар катарлык. Һәр кортның үз эше бар.

— Хезмәт бүленеше көчле алайса? — дип куйды Гарик.

— Көчле! Әйтәм бит: шаклар катасың!

Гарик аны тагын бүлдерде:

— Бу Маркс белән Энгельска «Капитал»ны да бал кортлары язып бирмәде микән? Алар да хезмәт бүленеше дип шашканнар бит!

— Бәлки биргәннәрдер дә. Беләсезме, егетләр, мин менә уйлыйм әле: без монда икенче атна эшсез ятабыз инде. Ә хәзер бал кортларының ин эшли торган вакытлары. Хөрәсәннәр юк алар арасында.

— Безне зур эшләр көтә бит, Варис!

— Синеке аңлашыла, Виталийның максаты да ясно... Менә мин?

— Син — безнең соратник! — диде Гарик теш арасыннан гына.

— Ярар, хет шунда теләсә кем дип атасыннар. Ә син беләсенме соң: Мөхәммәд ибне Габдел Вахаб белән гарәп әмире Мөхәммәд Согуд ил кадәр ил төзү өчен көрәшкәннәр! Ә мин!

— Син дә кемнәр беләндер, нәрсә өчендер көрәшәсең түгелме соң?

— Допустим... бездән соң нәрсә булачагы хакында уйлаганыгыз бармы сезнең?

— Галин күккә очачак!

— Аның артыннан Капралов та! — дип өстәде Виталий.

— Ә минем андый максат юк бит!

Гарик, капылт кына урыныннан сикереп торып, кулына карабинын алды да:

— Ә син! Не удавшееся создание! Әллә безне сатарга уйладыңмы?!! Балга барган жирендән берәрсен очратып, безгә каршы заговор корырга уйлыйсыңмы? Хәзер шушында ук дөмектерәм мин сине! Тынынны да чыгара алмассың!

— Да пошёл ты, Гарик! — дип кенә куйды аның жикеренүенә каршы Варис. — Мин ул турыда сөйләмим. Сарык булмасаң, башыңны включай: мин бит безнең акттан соң дип сөйләшәм! Менә шул: жөмһүрияттә тәртип ясыйбыз дип, безгә каршы пычрак ата башласалар!

Гарик тынычланган иде инде:

— Кабахәт булса да, Галинның планы акыллы бит: Питер баен өркетмәкче була!

Шулчак урман өстендә гөрелте ишетелде, Гарик, урыныннан ничек торганын да сизмичә, тышка атылды, бу юлы үзе белән карабинын да алып тормады.

— Нарат күркәсе атып кына бәреп төшермәкче булдың, ахры, Галинны? — дип көлде аннан Виталий, ул землянкага кире әйләнеп кергәч.

— Беләсезме, егетләр, шул кадәр нәфрәтем көчле минем ул бәндәгә! Ул өстән очканда, агач башына менеп утырып, күккә каравым була, хәтта нарат башларына чаклы чайкала башлый. Минем нәфрәтнең энергиясеннәндер инде?! — дип жавап бирде әлеге мыскыллы көлүгә каршы Гарик. Һәм сүзен дәвам итте: — Тәнзилә апа да, Рәнзилнең әнисе, бауга менмәкче булган. Күршеләре күреп, алып калганнар. Яшь чагында Галинны белгән булган икән Тәнзилә апа...

— Ул турыда уйлама син, Гариф туган, — дип куйды кинәт Варис һәм дәвам итте — Аллаһы Тәгалә язмаган эш булмас.

— Соң!.. Алайса, ул Аллан, күрә торып, нигә шундый гаделсезлеккә кул куеп

утыра?! Нигә жәза жибәрми ул шундый бәндәләргә? Әйт миңа шуны, аңлат алайса! Бик акыллы булсаң! Әллә Алла без мөселманнарга ачулымы? Бер-бере белән сугышып яталар! Әллә нинди мәзхәбләр уйлап чыгаралар? Син менә үзең үк әйтеп торасың: Вахаб белән әмир икесе бер булып, Согуд Гарәбстаны дигән нинди көчле дәүләт төзегәннәр дисең! Нигә берләшмисез?! Һәркем үз ягына каера булып чыга түгелме соң? Туксанынчы елларда ук бизнесмен муллалар үрчи башлады. Миңа ачуланма, Варис, мин сине дә, тоткан динеңне дә бик хөрмәт итәм! Чөнки син саф дин өчен көрәшәм дисең!.. Бүлгәләнеп беткәч, булмый бит инде ул, туганым! Башкалар ашап, ботарлап бетерәчәкләр бит! Сезне дә... шул исәптән безне дә! Нигә ислам диненең үзәге итеп Казанны алмаска! Нигә Казан тирәсенә тупланмый ислам!

Варис тамак кырып куйды да, аптырап, башын күтәрә төште:

— Карап торам да... син бик акыллы сәясәтче икәнсең, Гарик! Депутат булырга әзерләнмисеңме алай-болай?

— Әзерләнәм, — диде Гарик әле һаман да ачулы, ярсулы тавыш белән. — Өстән болгаталар барысын да. Ә гади халык интегә. Сәясәтче түгел мин, Варис туган! Шагыйрь мин!

— Шагыйрь?!

— Шагыйрь шул! Ну пока танылмаган әле. Аннан соң әдәбиятның кирәге бетте хәзерге абзыйларга. Югыйсә дин белән әдәбият бер үк яссылыкта торырга тиешле. Рухи тәрбия буенча диюем. Кол Гали дә бөек поэмасын Коръәннән файдаланып язган...

— Син ничек уйлыйсың, Виталий? — дип сорап куйды кинәт Варис. Виталий тыныч кына баядан бирле боларның сөйләшкәнен тыңлап ята иде.

— Белмим, — диде ул акрын гына. — Катлаулы мәсьәлә.

— Ничерта да катлаулы түгел! Сәясәтчеләр катлауландыралар! Махсус! Үз кесәләрен тутыру өчен! 17нче елда Рәсәйнең башын кистеләр. Хәзер без, башсызлар, ни эшләргә белмичә интегеп йөрибез. Зәңгәр канлы, особый сортлы милләт болгата дөньяны! Менә тыңла:

Иблистер ул, яисә газраилдыр,
Кайчакларда
Ленин булып күзгә күренә дә.
Ә аннары, мыегын бора-бора,
Сталиндай яши күңелләрдә!..
«Распутин» да була кай гасырда —
Ошбу аты аның асылда,
Биш хәрефкә кадәр кала да
Казаныма таба тибеп ала
Кавказларда,
Милли сугыш тынган арада.
Бер-береңә сыенып вакытта
«Тел кисүләр» кирәк, күрәсең...
«Урыс кышы» ел да булып тора...
«Урыс язы» килә күрмәсен!..

— Синең шагыйрьлегенә ышанам мин, Гарик, тик кайнар син, артык хисле, диде Варис. — Шигырең ничего! Хәер, монда әлләни кайнарлык сизелми. Бу — язучының фаразы. Галәттә, шагыйрьләр прогнозны дөрес бирә! Кисәтә, дөресрәге!.. Аңлаганнарга инде, әлбәттә... «Арабская весна» дигәннәре ничәмә ничә илне утлы себерке белән себереп узды! Дөрес әйтәсең, кирәк түгел бу безгә!..

— Шигырь түгел бу! Такмаклар! Политический...Сүгенүгә корылган шигърият шигъриятмени ул! Әүвәл коммунист булып йөреп кеше булдык.

Аннары — коммунистларны сүгә-сүгә. Хәзер дә гел сүгенеп торабыз. Бүгенге житәкче-түрәләрне сүгеп кеше булмакчы булабыз! Толк-то какой! Эт өрә тора, бүре йөри тора... Шагыйрьләргә килгәндә исә, шуны әйтергә мөмкин: аларга да адашкан наданнар иярә. Күрмисеңмени, алар ни эшләгәннәрен белмичә, тилереп, болыннар буйлап йөри?! Өстәвенә тормышка ашмаслык буш сүзләр тәкрарлыйлар, диелә Коръән Кәримнең 26нчы сүрәсендә. Кыскасы, караңгы чырай белән максатсыз вакыт әрәм итеп, чабата туздырып йөриләр. Сүгәргә лаеклы түрәләрне мактап, яхшыларны яманлап язалар. Фәраздәк исемле бер шагыйрь шигырендә бик күп кызлар белән маташып, аларның мөһерләрен ватулары хакында яза. Аны Сөләйман патша чакырып ала һәм: «Бу синең бәетеңме?» — дип сорый. «Минеке», — ди шагыйрь. «Син шәригать кануннарының чигеннән ашып киткәнсең бит!» — ди патша. «Мин үземнең гөнаһсыз икәнлегемне ошбу аять белән исбатлый алам», — дип, югарыдагы аятьне китерә шагыйрь. Һәм, әлбәттә, жәзадан котылып кала. Шагыйрь хыялындагын язган була, баксаң, ул кызларга орынып та карамаган икән!..

— Алайса сиңа ошамады?

— «Шигырь дә сүзләрдән торган жөмләләрдән хасил. Яхшысы бар, бар яманы... Бар шундый шигырьләр — хикмәтләргә тиң», диелә бер Коръән тәфсирендә. Синең бу шигырең хикмәткә тиң дисәм? Хәер, чын Коръәннең үзендә ничектер ул, мин аңлатмадан китердем мисалны...

— Син миннән көләсеңме? Акыллы булсаң, чишелеш юлын күрсәт син!

— Соң... күрсәт! Кем мишәйт итә?

— Менә мондагы мишәйт итә. — Гарик күкрәгенә сугып куйды. — Монда дүрт гасырдан артык коллыктан тапталып изелгән, тапалган эчке цензура ята. Шул ирек бирми татарга һаман! Вәт менә шуны жиңә алсаң иде ул!

— Жиңә алырсыңмы соң?

— Сезнең Баймурзин турында роман язам! Шигъри роман! Менә ул, ичмаса, шәхес! Түлке безнең бу жир кешесе түгел ул!

— Хисле син барыбер, Гарик!..

— Хисле түгел мин! Мин хаклы! Менә шулардан үч алып үземне танытам да — пусть начар яктан булсын! — аннан соң барлык усал шигырьләремне интернетка куячакмын!

— Ә үзең сәясәткә кысылмыйм, дисең? Депутат булырга да теләмисең...

— Причем монда сәясәт. Менә син, Варис мулла, кем... Варис хәзрәт, әйт әле миңа: күптән түгел сезнең авылдан, Илдар Гыймай дигән язучы Батырша хакында язып чыкты. Әйт әле, авылдашың да булгач, беләсеңдер: Батырша дин өчен көрәшкәнме, әллә жир өченме?

— Жир өчендер инде? — диде Варис, кыюсыз гына.

— Беләсең икән, пычагым! Дини изүләргә каршы көрәшкән ул һәм башбаштаклыкка каршы, димәк, гади халыкка матур тормыш теләгән. Сез, муллалар, Батыршаны маяк итеп алырга тиешсез үзегезгә! И, давай, жөмһүриятә Рәсәйдәге исламның үзәген оештырырсыз. Без болай йөрсәк, татарны да бетерәбез, Рәсәйне таркатабыз. Рәсәйне саклап калырга кирәк булган кебек, татарны да алып калырга кирәк безгә. Тарихка кара: Кузьма Минин — татар, Рәсәйне саклап калу өчен көрәшә. Алтын Урда Рәсәйне шулай ук Европа тәре йөртүчеләреннән саклап кала! Кирәк булса, моңа муеннан мисал китереп була!

— Ә син шуның өчен рәхмәтләр ишеткәнең бармы соң?

Варисның соравы бик урынлы иде, күрәсең, Гарик беркавым тын торды һәм әйтеп куйды:

— Ишетермен дип уйламыйм да!

— Ә син Галинны үтерергә йөрүеңне дөрес нәрсә дип уйлыйсыңмы?

— Анысы мине яңа идеяләргә рухландыра торган факт булачак! Мин күктә йөзеп йөргән шизо шагыйрь генә түгел! Коръәндә әйтелгән бер буш хыялый гына түгел мин! Минем ул кабахәтләрне үз кулларым белән кырып бетерәсем килә!

— Син — революционер! Безнең ислам динебез һәр түнтәрелешкә, фетнәләргә каршы!

— Революционер ди пычагым! Әгәр властьларга тиз арада илдәге вазгыятьне аңлата алмасак, чыннан да, тора-бара революциягә килеп төртелергә мөмкин бу ил! Һәр революция куркыныч нәрсә, Дәүләт өчен, халык өчен куркыныч ул, беренче чиратта! Ә мин... мин өстәгеләрнең капкасын гына шакымакчы булам! Маемлап беттегез бит инде! Акылыгызга килегез тизрәк! Алайса, урмандагы аю кузгалып, барысын да астын-өскә әйләндереп ташларга мөмкин, дип сөрән салырга телим! Мин, туган, үземнең ислам динемне синнән кимрәк хөрмәт итмим! Күбрәк булмаса әле. Чөнки ул миңа бабалардан килгән кан аша бирелгән! Канны бозып булмый аны! Мин тәңрегә дә каршы түгел, сине шаярып кына үчекләдем мин теге көнне. Ул да бабаларыбызның рухи яшәү рәвеше! Шуның аркасында халыкта гореф-гадәтләребез ныгып калган, йолаларыбыз сакланган. Шул йолаларны үти-үти, ислам динебезчә Ходайга дога кылып яшәсәк, ни булган ди?!

Шулчак җир өстендә вертолёт гөрелтесе ишетелде. Гарик атылып палатадан чыгып китте дә беркавымнан кире әйләнеп керде:

— Виталий, синең Капрал кайтты, ахрысы? — диде ул, инде йокымсырый башлаган күршесенә эндәшеп. Виталий әүвәл башын күтәрде, аннары торып утырды һәм чукынып алды да, сәке-ылыстан төшкәч, тагын бер мәртәбә чукынды.

— Фамилияң ничек әле синең, Виталий?

— Беләсең ич инде, Медведев!

— Димәк, син урыс түгел. Син — еврей! Чөнки фамилияләре кош-корт, җәнлек-хайван исеменнән ясалган кешеләр һәрвакыт еврей милләтеннән. Иванов, Петров, Сидоров, Михайлов түгел бит?

Шул нисбәттән ул бер мәзәк тә сөйләп алды:

— Урыс белән еврей поездда баралар икән. Урыс чемоданыннан кыздырган тавык ала, еврей кылчыклы бер балык чыгара. Берзаман ул:

— Балык акылны арттыра! Шуңа күрә яратам да инде мин аны! — дип куя.

Урыс, моны ишеткәч, тавыкны балыкка алыштырырга тәкъдим итә. Еврей килешә, тавыкны үзенә ала, балыкны урыска бирә. Ашаганнан соң, кылчыклы балык ашап тамагы туймаган урыс, тешен казый-казый, үзалдына сөйләнеп утыра икән:

— Нишләп бу балык дигәне яхшырак булгач, бәясе тавыкныкыннан кимрәк икән соң? — ди ул. Еврей моны эләктереп ала:

— Менә, менә, күрдеңме! Балык ашауга шундук акыл керде сиңа! — ди.

Мәзәктән берәү дә егылып көлмәде, бары көлемсерәп кенә куйдылар. Виталий, гадәтенчә:

— Да какая разница! Халыклар бергә катнашып, укмашып беткән инде хәзер! Әйтәләр бит: поскреби любого русского, найдёшь татарина!

— Менә монысы начар! — дип куйды Гарик. — Кушылып бетүләре дим. Һәр агач үзенең тамырлары белән көчле. Мәгәр аңа янәшәсендә корыган агач сөялеп тора икән, моннан аңа бернинди файда юк! Үз тамырларыңның нык булуы кирәк! Ә синең баягы фикерең әйбәт! Шәп идея! — дип дәвам итте ул. Тик Варис сүзгә катнашмады, әлбәттә, бу нисбәттән аның да фикере бар иде,

тик дәшмәвен алтын дигән әйтемне исенә төшерде бугай. Ә Гарик исә теленә килгәнне әйтмичә кала алмады:

— Ә мин сиңа шәп сәбәп уйлап табам! Дөресрәге, факт тәкъдим итәм мин сиңа, уйлап та торасы юк! Мәсәлән, ни өчен Ябалак авылындагы чиркәү өстенә менгәннәр дисең дә?!

— Ул аның гөмбәзен буярга менгән бит!

— Менгән, пычагым, буярга дип! Галин жирен тартып алган да шуңа протест йөзеннән, жиргә сикереп, үзен һәлак итмәкче булган ул!

— Ә нигә именно чиркәү өстенә менәргә кирәк иде? Шуннан ерак түгел генә мәчет тә бар бит! Аның манарасына мену жинелрәк тә әле?

— Алай димә син. Галләм абзаң бик уйлап эшләгән: чиркәү өстеннән сикереп жан тәслим кылса, тавышы бөтен илгә ишетеләчәк иде. Ә болай, мәчет манарасыннан төшсә: «Ә, бер наркоман сикергәндер шунда!» — дип кул гына селтәгән булырлар иде. Аңладыңмы?! Вопрос политический монда!

Сүзгә Варис та кушылмыйча түзә алмады:

— Язучы икәнлегең әллә кайдан күренеп тора: момент әкият уйлап чыгарасың! Ул чакта, беләсең килсә, мәчет манарасы буяуга буялган булган! Анда менсәм, артым буяуга ябышыр дип курыккан ул!

— Һе. Монысы да логично! — дип куйды Виталий.

Шулчак Гарик учы белән мангаена шапылдатты:

— Егетләр! Таптым бит! Әйдәгез, кемнеңдер канын койганчы, иң яхшысы Кирилл атакайның чиркәвен барып шартлатабыз! Вәт тавыш кубачак аннан соң,ә?!

Виталий бу сүзгә шундук каршы төште:

— Гастарбайтерларга сылтап калдырачаклар и все... Яки намаз укыган татар егетләренә!..

— Нишләп?

— Татар беркайчан чиркәүгә каршы көрәшмәгән. Тарихтан белмисеңмени: Алтын Урда заманында бер хан хәтта шундый закон чыгара: попка яки чиркәүгә кем дә кем тия икән, ул кешегә иң каты жәза бирергә тиеш булалар! Чиркәүдән хәтта налог та алмаганнар! Шулай булгач татарның чиркәүгә, бигрәк тә урыска каршы булуына кем ышаныр дип уйлыйсың?!

— Ә алайса мәчетне жимереп, аның нигезенә чиркәү салу фактлары? Көчләп чукындырулар? Әби патшага рәхмәт: ул тыйган әлеге вакханалияне! Виталий жавап кайтармады, «әйе шул» дигәндәй, башын гына какты.

Варис ятагын жайлабрак куйды да тагын сузылып ятты.

— Карап торам-торам мин сиңа, Гариф, бик гыйлемле, акыллы кеше син! Нигә кирәк иде соң сиңа бу Радий оешмасы? Тот та бастырып чыгар шигырьләреңне! Халыкны уят! Акыллы кешене, бигрәк тә талантларны бездә яраталар бит!

— Яраталар, пычагым! — дип куйды аңа каршы Гарик. — Төрки-татарның житәкчеләре гомер-гомергә акыллыбашны яратмаган. Бу болгар бабалар заманыннан ук килә. Хәтерлисеңме син, Фазланның юлъязмасын, укыган булсаң инде? Акыллы кеше пәйда була икән, мондый зирәк баш Ходайга кирәк дип, тотканнар да аягыннан каенга асып куйганнар андыйларны! Әле дә шул бара бездә!..

— Ә Камай, безнең авылның Камайны алып кара син! Конкурска дигән хезмәтен Америкага ук жибәргәннәр! Хәзер Американың бер университеты үзен эшкә чакыра, ди. Монысының барасы килми икән, ди, имеш.

— Беренчедән, Камайның шәп поддержкасы бар, ул — Баймурзин! Милләт пәйгамбәре ул сезнең Баймурзин! Дөресрәге, авыл пәйгамбәре! Космостан килеп сихерләп киткәннәрдер аны. Икенчедән, Америка Камайны юкка гына

үзенә чакыра дип уйлыйсыңмы? Шиш ди менә! Россиягә каршы эшләтмәкче була ул аны! Камай шуны аңлый һәм барырга да уйламый!

— Наивный син, Гарик.

— Үзем дә беләм, — дип куйды Гарик. — Карале, Варис, синең сүзләрдә хаклык бар бит! Әгәр син миңа теге аванс акчасын бирсәң, китәр идем мин! Шул акчага усал шигырьләрдән торган бер китап бастырып чыгарыр идем. Үз хисабыма. Русча, инглизчәгә тәрҗемә иттереп. Аннары интернетка куям!..

Варис яткан урыныннан торып утырды да, күзләрен акайтып, Гарикка карады:

— Да ты что! Поезд ушёл уже! Всё, хәзер син безнең белән! Нәрсә, хәзер качып китеп, безне сатмакчы буласыңмы?! Чиста каласың киләме?! Мин сине лучше монда ук атып үтерәм! Мин дә монда синең кебек үк акча эшләр өчен килдем, беләсең килсә!

Ул ятак кырыендагы карабинга үрелде. Гарикның моңа әлләни исе китмәде, көлемсерәп кенә куйды һәм:

— Атмыйсың син мине, Варис!

— Ике дә уйламыйм!

— Ата алмыйсың! Чөнки минем шигырьләр сиңа бик ошадылар! Кулың күтәрелмәячәк!

— Дөресен әйтимме, Гарик?

— Сон?

— Мин ишеткән шигырьләрең бомба түгел. Андый гына фикерләрне туксанынчы елдан бирле әйтеп торалар инде. Мәскәү дәрәҗәсендә дим. Президентларны да селкеп салалар! Хәзер бу яңалык түгел инде!

— Шулай дисеңме?

— Дим шул...

— Ә син хаклы бит, чёрт побери. Тик бер нәрсәдә генә хаклы түгел! Әйтимме?

— Йә?

— Безнең барыбызда да региональ уровеньда эчке цензура утыра. Әгәр мин бүтән җәмгыятьтә яшәгән булсаммы? Синең сүзләреннең хаклыгын раслап, үзем дә бер мисал китерәм. Берзаман ике айлык әдәби курсларда Мәскәүдә укып кайттым мин. Дөнья кайный инде менә! Нәрсә генә сөйләшмиләр, нинди генә грандиозный планнар төземиләр. Шуннан соң монда кайтып төштем. Нәрсә күрәм дисеңме? Пшыйк!.. И всё. Провинциаль уровень бөтенләй! Ниндидер зур түрәнең ике кияве Франциягә машина чабышына барган да призлы урыннар алган, имеш. Менә матбугатта да, болай сөйләшкәндә дә шуны обсуждать итәләр! Милли мәсьәләгә килгәндә (латинга күчәргә хыялланып йөргән вакытлар иде ул), безнең хөрмәтле профессорларыбыз, бу хәрефне алыйкмы икән, тегесен кертикме дип (кем тарафыннандыр махсус оештырылган буш бәхәсләр икәнлеге ап-ачык иде!) пыр тузып бәхәсләшеп яталар. И шуның белән вакытны да суздылар! Карап торды-торды да әлеге теманы бөтенләй ябып куйды Мәскәү! Сон... шунда, форсаттан файдаланып күчеп куйган булсак! Өлгерә идек бит! Соныннан хәрефләренне алыштыр идең шунда! Берне түгел, хет унны! Менә безнең вазгыять, дустым! Ә мин сиңа шигырьләр турында болай гына әйттем. Тавыш чыгарам да, исемемне танытам да, ул шигырьләрне бастырам, имеш. Иң беренче минем башка Галинны юкка чыгару уе килде. Сиңа әйткән бу планнар сонрак туды алар! Менә шул, Варис туган! Ә син мине барыбер ата алмыйсың!

— Нигә?

— Чөнки мин беркая да качып китмим моннан. Соныннан бергәләп таярбыз.

Тотып алып ябып куймасалар инде... Ә шигырьләргә килгәндә... Ул беркавым сүзсез торды һәм ышанычлы тавыш белән укый башлады:

Телемне кистең, үткен иске кайчың.
Каннары чыкты саркып тамчы-тамчы...
Исеңә төшәр әле татар тагын —
Аурупа сиңа янә үрә камчы!

***

Туксанынчы еллар... Азатлыкмы килде? —
Гасырның бу гадәти тулгагы иде.
Яшелләнеп шулай без дә яшәп алдык —
Татарның бу үз туксаны иде...

***

Ханлыгың гына кирәк дип басып ала.
Динең дия аннан — нәфсе тагын арта.
Моң агасы урынга хәзер кан тама,
Кисеп алам дип туган телне каната!..

***

Тынлыкмы бу? Әллә шундый озак коллык?!
Биш гасырлык инде, инде биш йөз еллык.
Җиткәндер бит нигезне торгызыр вакыт!
Нинди хак сүз: бергә булыйк, аерым торыйк!..

— Кем шигырьләре соң бу?

— Робагыйлар, — дип куйды Гарик. — Кемнеке булсын, үземнекеләр...

— Һе, теге авансны бирмичә булмас сиңа, алайса.

Каравыл торудан туеп, землянкага Сафрон керде, ул беркавым егетләрнең сүзләренә колак салып торды-торды да:

— Надоели бу политический бәхәсләрегез! Күпме чәйнәсәң дә, һаман шул бер балык башы инде ул! Олигархлар, хәерчеләр. Милләт, имеш. К чёрту всё! Без монда политический кружок оештырырга җыенган революционерлар түгел бит ахыр чиктә?! Әйдә, лучше берәр куян тотыйм да шуның шулпасыннан авыз итик әле! Виталий, безнең теге табылдык кәчтерүл исәндер бит? — дип сорады ул ишектән күренгән Виталийдан.

— Сафрон әйтә, теге вертолёт чак кына агач башына эләкмәде, ди. Шул кадәр түбәннән оча, ди, — дип, яңалык хәбәр итте ул.

— Да, малай, точно! Үз күзләрем белән күрдем! — дип җөпләде аны Сафрон.

— Кемнеке булды икән? Галинмы, Капралмы?

— Чёрт белсен! — диде Виталий, иңбашларын сикертеп. — Гарик, мин дә агач башына менеп үземнең нәфрәт энергияләрен бер бик озын наратның очына ук элеп куйдым әле. Шунда, бәлкем, һава чоңгылы хасил булмасмы!

— Тавыш кылә! — диде шулчак Варис, колагын торба — «колак аппараты» янына якынайтып. Өчесе дә бер-бер артлы өскә чыктылар.

Савва Бурзайдан яңа хәбәр алып килделәр. Бүген иртән трассада гадәттән тыш вакыйга булган: юлда бер кешене атып үтергәннәр! Шуннан соң бер сәгать тә вакыт узмаган, шул төштән ерак түгел генә зур авария булган. Кешеләр үлгән! Шуңа күрә качакларның операциясе тагын кичектерелде. Теге хәбәр китерүче ашамлыклар да алып килгән. Димәк, егетләрнең «урман тормышы» дәвам итәчәк икән.

Ә олы юлда, чынлап та, икесенең дә ахырлары үлем белән тәгалләнгән гадәттән тыш фаҗигаләр булды.

Ябалакның тарих укытучысы Хәким Нургалиев ул көнне таң белән үзенең «жиделе» «Жигули»ендә шәһәргә чыгып китте. Иртән юл буш иде, каршысына берән-сәрән шәһәр ягыннан килгән машиналар гына очрады. Ул тиз барып житте. Галин ише берәрсе юлга чыкса, ГАИ һәм сакчылары бар машинаны кырыйга сендерәләр, хәзер алар күбрәк вертолётта очканлыктан, андый хәлләргә дә тармады ул. Хәкимнең дүртенче сыйныфта укыган кызы Республика балалар хастаханәсендә ята, ул шунын хәлен белергә барды. Хәким баласы янында кунатөнә ятарга да риза иде, табиблар рөхсәт бирмәделәр, кызынның хәле начар түгел, көннән-көн алга бара, диделәр. Әйе, Аллага шөкер, Ләйләсе хәзер рәтләнеп килә, хәтта елмая да башлады, тамагына да капкалый. Ул бала Хәкимнең бу дөньядагы бердәнбер куанычы хәзер! Хатыны вафатыннан соң, алар икесе генә калдылар, карт әнисен исә үзен карарга кирәк иде. Балага соңгы өч елда ике мәртәбә зур стресс кичерергә туры килде, берсе газиз әнисенең вафаты булса, икенчесе... икенчесенең тарихы бик катлаулы иде. Бер төркем авыл баласы урманга жиләккә барган булган. Галин бурзайлары ничек күрми калганнардыр, балалар урман эченә каршылыксыз гына узганнар. Ни дисән дә, авылга ишелеп торган Ябалак урманында халык гомер буе жәен — жиләк, көзен гөмбә жыярга рәхәтләнеп йөри иде. Балалар бит: алар аның яңа хуҗасы барлыгы хакында уйлап тормаганнар инде, күрәсең. Якын булгач, жыелышканнар да киткәннәр. Инде нәни савытларын тутырып кайтып килгәндә, Галинның бер сакчысы күреп алып, өсләренә овчаркасын жибәргән! Балалар, куркышып елаша-елаша, качарга керешкәннәр. Качып котыла алмаганның өстенә бозау чаклы овчарка сикергән. Өч кыз баланың тәннәрендә әллә ни жәрәхәтләр булмаса да — хәер, Хәким әле үз кайгысы белән ишетмәгән иде бер кыз баланың корсак турысын эт умырып алырга өлгергән, икенчесенең битен бик каты тырнаган, хәзер аның аскы ирене асылынып тора ди. Балаларга көчле стресс булган, ничәмә-ничә көн кызы саташулы төшләр дөньясында яшәде, әнисен чакырды, әтисен дә хәтта күп вакыт әнисе дип кабул итә иде. Шөкер, кичә бала аңына килеп, янадан дөньяга кайтты. Бу вакыйгадан соң авыл халкы Галинга каршы сәнәк сугышына күтәрелергә әзер иде! Тик тегеләр эшне бик ансат йомдылар: имеш, урман авызына житкәч, балаларга кыргый этләр ташланган. Шулвакыт, бәхетләренә күрә, Галин сакчысы күреп алып, әлеге этләрне пистолеттан кырып салган, балалар шул сәбәпле генә исән-сау калганнар!.. Урман кырыенда көне буе берничә эт үләксәсе дә аунап ятты: күрегез, янәсе, кемнәр эше булган ул фажига! Хәкимнең кызы аңына килүгә әйтте: зур овчарка куды, диде!..

Хәким кире кайтырга чыкканда, төш вакыты якынлашып килә иде инде. Юлда машиналар күбәйгәннән-күбәя бара, шәһәр халкы, шимбә көн булудан файдаланып, урман-сулар буена агыла, кемдер — авылына, кайсыларыдыр шәһәр читендәге бакчаларына бара торганнардыр. Хәким юлда ашыгып йөрергә яратмаса да, өйлә вакыты житеп килгәнлектән, бүген ашыкмыйча да булмый: карт әнисен утыртып ашатасы бар. Шуңа күрә ул кызурак кайтырга тырышты. Тик чит ил машиналары ана бик иркенәергә ирек бирми, өстенә менә язып киләләр дә ут яндыра башлыйлар, кычкырталар, узганда исә аның иске машинасы ягына карап нindiдер ямьсез сүзләр дә мыгырданып китәләр.

Менә хәзер дә аны бер «Бэнтли» узарга маташа, югыйсә күреп тора: машиналар болай да рәт-рәт кысылып бара, инде баядан бирле «Ашыгыч ярдәм» машинасы да ташкынны узып китә алмыйча азаплана. Аның алдыннан барган «Жигули» хуҗасының да бу нахалларга ачуы килә иде, ахрысы: ул, теге күпме генә кычкыртса да, юл бирергә уйламады, югыйсә Хәким тегене уздырып жибәргән иде. «Бэнтли», сул яктан уза алмагач, уң якка таба каерып, тузанлы юлдан чаба башлады, бераздан машинасы юл кырыендагы агачларга ышкылып

сыдырылды да. Менә ул кинәт алга ыргылды һәм шып итеп тегенен алдына килеп туктады, ул рәттән барган машиналар шулай ук тормозларына басарга мәҗбүр булдылар. «Бэнтли»дан озын нечкә сыйраклы бер яшүсмер чыкты, кара күзлек кигән, уң кулын артына яшергән. Хәким алдындагы «Жигули» хуҗасы машинасыннан чыкмады, тегенен үзенә таба килгәнен көтә башлады. Менә Озын сыйрак кинәт туктады да, яшерелгән кулын алга чыгарды һәм туп-туры төбәп ата башлады. Халык бу хәлгә шаккатып торган арада, ул тиз генә машнасына утырды һәм арттагы номерга аягы белән генә төртеп алды да, машинасына чумып, зур тизлектә кузгалып та китте. Хәким чамалап калырга өлгерде: теге аяк очы белән төрткәннән соң, машина номеры кинәт икенчегә алышынды. Шуна күрә Хәким, шаһит буларак, полиция егетләренә ярдәм итәрлек бер яналык әйтә алмады: көмешсу төстәге «Бэнтли», кара күзлек кигән озын сыйраклы яшүсмер!..

Әнисе хакындагы уйлар онытылган иде инде. Вакыт та шактый узды. Адресын алып, ниһаять, Хәкимне җибәрделәр, «Ашыгыч ярдәм» мәетне дә шәһәр ягына алып киткән иде инде.

Хәким коточкыч авыр уйлар белән янә кузгалып китте. Тик озак бармады, артыннан янә бер чит ил машинасы тагылды, дөресрәге, өстенә менә язып, юл бирүен таләп итеп, фара утларын җемелдәтергә керешге. Хәким, аптырагач, юл читенә чыгып туктарга мәҗбүр булды. Беркавымнан тагын кузгалды. Алда юл капылт өч якка аерылып киткәнлектән, машиналар ташкыны үзләреннән-үзләре кими, Хәким газга баса төште, чөнки әнисен үз вакытында ашатырга гадәтләнгән иде ул. Менә кинәт, һич уйламаганда-көтмәгәндә, каршысына, юлны аркылы кисеп, «Беларусь» тракторы чыгып басты. Хәкимнен тизлеге зур иде, ул читкә алырга да, тормозга басарга да өлгерми калды: дынк итеп тимер тавына килеп бәрелде!..

...Варис, тагын умарталыкны әйләнеп кайтырга уйлап, атны арканнан алды да бу хакта Сафронга белгертте. Тегесе, белмим шул дигәндәй, инбашларын сикертте. Чөнки яна килгән хәбәрләрдән соң барысының да нерв җепселләре җәя кебек киерелгән, җинаятьчене эзләп монда да килеп чыгарга мөмкиннәр иде. Кем ышанып әйтә ала: бу җинаятьне ике дә уйламыйча аларга элеп куярга да күп сорап тормаслар. Аларның качып йөргәне билгеле бит. Һәрхәлдә, шәһәрдә дип уйласалар да. Шуна күрә бу көннәрдә төркемнән аерылып китү һәркайсында гадел шик уятырга мөмкин, Сафрон шуна күрә дә, җаваплылыкны үз өстенә аласы килмичә, җилкәләрен сикертте. Варис атны янә үлән утларга җибәрде, тик бу юлы арканлап тормады. Берәр сәгатькә булса да аерылып тору өчен, чыннан да, җитди сәбәп кирәк иде. Чынлыкта исә умарталык яныннан әйләнәсе килүенең эчке сәбәбе бар, ул да булса анда Камайны очрата алмасмы икән? Соңгы араларда Варисның күнелен төрле шик кортлары кимерә башлап, күнеле иләсләнде, ләкин берәр катгый карарга килә алмыйча азаплана иде. Камай аны сатмаячак, берәүгә дә тотып бирмәячәк. Бәлки, аның белән кинәш-табыш итеп алу файдага гына булыр шикелле. Ләкин егетләргә бу хакта турысын әйтергә ярамый, ыгы-зыгы башланачак, сатлык дип, аны атып та үтерергә бик мөмкиннәр иде. «Минем бүген туган көн ләбаса! — дип уйлады ул, үзенең туган көне икәнлеге исенә төшкәнлеккә сөенеп. — Аны бит билгеләп үтәргә кирәк! Ә Җамали умартачының Варис белгән базында берничә имән кисмәк бал ширбәте утыра!..

Варис әүвәл Гариф белән сөйләшергә булды. Егетләр каршы килсәләр дә, ничектер җаен табып, барыбер китәчәк ул, ләкин ризалык алса, тагын да яхшырак: федераль юлдагы фаҗигаләрдән соң, чынлап та, дөнья тыныч түгел.

— Гариф, минем туган көн икән бит бүген! — диде ул тез өстенә катыргы куеп

нидер язып утырган шагыйрьгә. Тегесе, әүвәл башын гына күтәреп, Вариска карап куйды да, эшеннән аерыласы килмичәдер, беркавым язуын дәвам итте, аннары гына, кәгазен читкә куеп:

— Туган көн — әйбәт нәрсә инде ул. Карале, Варис, мин монда бер шигырь, ну, бер такмак сырладым. Черновой вариантта пока. Менә тыңлап кара әле, — дип, тегенең рөхсәтен дә сорап тормыйча укырга кереште:

«Җир бит», диләр бездә оятсызга,
«Йотар» әле беркөн җир аны.
Җирен тартып алмак була һаман
Нәфесенә сыяр Җир шары.

Алдылар бит инде бер мәртәбә,
Тик рәхәтен күрә алган юк!
Җир нигә соң андыйларга дим, —
Сафсаталар сатып тамак тук!..
Билчән басуларын кара син! —
Оятыннан эт эчәгесе дә
Болай үсмәс иде чәчсәң дә!..

Гариф укып бетерде дә, фикер көтеп, Вариска карады. Тегесенең җавабы алдан ук әзер иде ахры, уйлап-нитеп тормады:

— Гениально! — дип куйды.

— Шыттырма түлке!

— Ипидер менә! Тик бераз эшләп бетерәсе бар, кайбер җирләрен, дим...

— Үзем дә беләм. Тәмамланмаган әле ул. Беләсеңме. Моны мин проза белән күз алдына китерәм. Безнең бабаларның җирен сугыш-суеш белән тартып алганнар да хәзер дус яшик, диләр. Чечняны изеп-сытып киттек тә, хәзер без — дус халыклар, дибез! Андагы һәр гаиләдә йә атасы, йә абыйсы, йә башка туганы һәлак булган бит! Әле кичә генә! Абсурд! Ярый ла безнең халыкны басып алганга дүрт гасырдан артык вакыт узды. Ул да, барыбер, онытылмый әле! Кандагы нәсел күзәнәкләре кычкыра, дулый!.. Шулай бит инде?

— Белмим, — дип куйды Варис. — Мин бу хактагы сөйләшүләрдән туйдым инде... Һаман да бер балык башы.

— Ну мин сезне аңлыйм, сезгә үз туганыгыз белән ызгышу рәхәтрәктер, бәлки! Диндәшләрегез белән!

— Беләсеңме, Гариф, әтине мин үтермәдем бит аны!

— Мин дип күкрәк кага идең бит әле?

— Юк, әлбәттә, мин түгел. Мин әтиемне бик сагынам хәзер. Их, күңел урынында түгел! Әтием исән булсын иде әле менә хәзер! Әйдә, мин туган көн унаеннан умарталыкка барып, медовуха чәлдереп кайтыйм әле. Урынын беләм. Бәлки, бераз йөрәкләргә җиңел булып китәр.

— Бар, барып кил, — диде Гариф. — Минем дә что-то күңел дөрес түгел...

Варисның онытыласы, берәр төнне булса да саташулы төшләрсез генә уздырып, аңын-җанын ял иттерәсе килә. Урмандагы озын көннәр шик-сагаю, куркулар белән узса, җәйнең кып-кыска төннәре исә төшендәге озын, күп серияле төсле фильмнар белән аралашып тора башлады. Егетләр дә төннәрен саташулы төшләр күрә икән. Бәлки, җир астында яшәү галәмәтедер дип тә уйлап карадылар. Хәер, тәгаен генә әйтү кыен: Вариска һәр төнне чиратлашып әтисе белән әнисе йә булмаса Әллүки буендагы кичке уеннар керә иде. Әти-әнисенең тавышларын ишеткәне юк, алар сөйләшмиләр, ә менә уен җырлары

аермачык хәтерендә. Бигрәк тә әнисе аны кечкенә чагында иркәләгәндә әйтә торган такмаклары...

Коенганың — Идел суы,
Йөрер юлың — атаң юлы,
Торыр җирең — бабаң җире,
Сайрар телең — анаң теле,
Карышма да тибешмә,
Яңа кердән инешкә,
Киерелгәндә — киртә буе,
Сузылганда — солы буе,
Үс-үс!

Варис атка җәһәт кенә атланды да чаптырып китеп барды, ләкин туп-туры умарталыкка түгел — яшүсмер вакытта әтисе ана Тәбәнәк тау дип аталган җирдә бер чишмә күрсәткән иде — башка тарафка юл алды. Чишмәне тапты Варис, суын да эчте, бит-кулларын да һәйбәтләп чылатты, атны да сугарды — әйтеп-аңлатып бетермәслек дәрәҗәдә рәхәт булып китте!.. Әйтерсең, янадан туды егет... Хәтта беренче мәртәбә көлеп җибәрде, анын көлүенә ат кешнәве кушылды. Юкка кешнәмәгән икән, урман эчендә арба тавышы, аның айгырына каршы биянең җавабы ишетелде. Кеше күзенә чалынырга ярамый иде, Варис атны туп-туры умарталыкка таба борды да чөнгереп куйды.

Ерак Алан ягында авыл хатыннарының кычкырып сөйләшкән тавышлары колагына керде. Варис, атын туктатып, юан чыршы артына сыенды. Авылдашларының, чынлап та, Ерак Аланга җиләккә барулары, кулларында чиләк-кәрҗин кебек савытлар да чайкала.

Умарталыкта Камайны очратасына өметләнмәде дә ул. Тиктомалдан нишләп йөрсен ди ул анда яисә аны көтеп утырсын димени?! Егет атын умарталыктан ерак түгел бер үләнле аланга бәйләп куйды да җәяүләп кенә китте. Алабай танып шыңшып алудан гайре башка тавыш бирмәде, ул, янына килгәч, аякларына сырпаланырга керешге. Бу юлы ул нигә килгәнен үзе дә белми иде. Максат юк. Бал ширбәте сылтау гына. Тәрәзәдән кеше барлыгын күреп алды, ахрысы: Жамали карт килеп чыкты. Варис әүвәл аны күрүгә куркуыннан куырылып килгән иде, картның елмаюлы йөзе аны шундук тынычландырды. Өстәвенә, ул ягымлы тавыш белән сөйләнеп тә килә иде:

— Менә бит, мина ярдәмчене Ходай үзе бирде. Бар ояны да карап чыгып өлгермим үзем генә. Менә мина ярдәмче... помощник! — диде ул һәм якын итеп Варисның җилкәсеннән какты. Жамали абзыйның аны берни булмагандай элеккечә кабул итүе, әлбәттә, баштарак бик аптыратты, качакны кем болай каршылый ди инде?!

Алар өйгә керделәр. Варис шуны аңлады: Жамали абзый анын качак икәнлеген белми иде!.. Чү! Тукта!.. Ә кем белә соң анын качак икәнлеген? Дөрес, Радий төркемендә берничә көн булды ул булуын... Тик аны эзләп йөрерлек кеше калмады да бит инде. Әтисе дә үлгәч?.. Димәк, ул бөтенләй качак түгел... Болай гына, берәр атнага үз эшләре белән авылдан чыгып киткән кеше генә?!

Вариска җиңел булып китте. Тамак кипте дип, ул Жамали абзыйдан бер тустаган бал ширбәте сорап алды, аны эчкәч, тагын да җиңелрәк хис итте егет үзен. Әйтерсең, берни булмаган да... Чү... ә нәрсә булган соң әле?.. Булмады бит! Саташып кына йөрде ул бераз. Авылдашлары анын хәленә керделәр — аңладылар. Җанына тиюче булмады. Чит илдән укып кайткан мулланың авылда дәрәҗәсе, күрәсең, бар иде әле. Кайбер сәер кыланмышларын исәпкә алмаганда... Әнисен теге чакта рәнҗетүен дә авыл яхшы хәтерли торгандыр?..

«Әти» дип саташып йөрүләре... Ләкин барыбер, ул, беренче нәүбәттә, Җамали абзыйның мөнәсәбәтеннән күренә иде, авылдашлары өчен ул элеккеге Варис булып калган, шул сурәттә яши, күрәсең... Өстәвенә, Җамали умартачы үз янына ярдәмче итеп тә чакырып тора. Аны Җәмил хәзрәтнең эзләвен дә әйтте, мәчеткә үз янына чакыра ул сине, мәчеттән бушаган арада, миңа ярдәм итәрсең, кем әйтмешли, моннан бушаган вакытта, мәчеттә булырсың...

Җамали умартачы Варисның бал кортларын яратканлыгын белә иде. Аның янында ярдәмче булып йөргәндә, шушы малай бит инде, бал кортлары тормышын кешеләрнеке белән чагыштырып, аны шаккатырырлык фикерләр әйтеп ташлый торган иде. Әлбәттә, егет хәзер үзгәргән, аның хәтта күз карашына чаклы башка, уйчан ул, беркадәр үз эченә дә йомылган кебек. Хәер, гаилә фаҗигасеннән соң айнып җитә алмый торгандыр әле дип уйлады умартачы һәм ана бу акыллы егет кызганыч булып тоела, аңа ярдәм итәсе килә иде.

— Бал кортлары да Ходайның җан ияләре, бәндәләр дә. Ләкин араларында җир белән күк аермасы, ди торган идең. Әле дә шулай уйлыйсыңмы, улым?

— Юк, — диде бал ширбәтеннән изри башлаган Варис. — Бал кортлары акыллырак! Безгә алардан үрнәк алырга кирәк. Һәй, адәм баласына бал кортына җитәргә әле! Бал кортлары Аллаһы Тәгаләнең ярдәмчеләре! Алар — Илаһы юлыннан тайпылган җүнсезләргә каршы көрәшүчеләр!..

— Безнең Камалетдин дә яшьрәк чакта умарталыктан кайтмыйча ята торган иде. Тау-тау китаплар укыды алар турында. Бераз үсә төшкәч, монда бөтенләй килмәс булды. Нәрсә булды сиңа дигәч: «Адәм заты буларак, оят миңа бал кортлары янында!» — дия торган иде. Безнең Камалетдин фәйләсуф инде ул! Гомер буе юк белән башны катырып йөрде. Әле ярый, Байтимер килеп чыгып, җүнле эшкә ярый башлады бугай.

Варис аңа җавап кайтармады, югыйсә малае хакында ул тәгаен берәр җылы сүз көткән кебек иде.

— Менә эшләремне эшләп бетерәм дә... — Варис чак кына уйланып торды. — Синең янга ярдәмче булып килəм, — диде. — Җамали абый, минем бүген туган көн икән. Аз гына медовуха кирәк иде. Мин соңыннан акчасын түләрмен! — дип тә өстәде. Җамали умартачы берсүзсез аерым савытка ширбәт агызды. Умартачының Варис белән тагын сөйләшеп утырырга исәбе бар иде әле. Тик шулчак әүвәл Алабай өргәне, шуның артыннан куркыныч тавыш белән ат кешнәгәне ишетелде. Варис урамга атылды.

Атны умарта кортлары сарып алган иде. Теге мескен, бал кортларының һөҗүменә каршы тормакчы булып, койрыгы белән шап-шоп гәүдәсенә суга, тибенеп карый, сикерә, бал кортлары, аның саен усалланып, аның тәнен, корсак астын, күз тирәләрен талыйлар — угларын төртеп торалар иде. Варис, өстендәге киемен салып, атка ярдәмгә ташланды. Аның айканулары кортларның ачуын гына китерде, хәзер һөҗүм егеткә дә башланды. Бал кортларының чагуыннан курыкмый ул, тик бу юлы тегеләр аеруча дәһшәтле һәм үчле булып чыкты: ук каламаган җирләре калмады, колак эчләренә хәтле чактылар — ул ишетмәс булды, борын тишекләренә хәтле үтеп керделәр — тын алуы авырлашты, авызын ачты — телен чактылар, иң яманы: берзаман теле шешеп, авызын ача-яба алмаслык хәлгә килде, инде ул авыз белән дә сулый алмый башлады. Тавышка килеп җиткән Җамали карт бар көченә егетне өйгә таба өстерәде, бер кулында төтен кудыргыч пышылдый иде. Берзаман кортлар тынычланды. Варисның күзләре күрми, борын тишекләре томаланган, теле авызыннан бүселеп чыккан. Җамали абзый тиз-тиз аның теленнән, борын тирәләреннән бал кортлары угларын чүпләде, ул урыннарга канәфер чәчәге мае сөртте, битләрен корвалол белән майлады. Тәнендәге агулар тизрәк таралсын дип авызына аракы коярга тырышып карады.

Варис, аз гына вакытка анына килеп: «Әти! Әтием! — диде һәм, беркавым тын алып торганнан соң: — Әти янына...» — дип өстәде. Дөресрәге, шундый мәгънә аңлашылырлык мыгырдаган авазлар гына чыкты. Жамали карт анын ни әйткәнлеген бик авырлык белән төшенде.

Жир йөзендә берьялгызы ятим калган бердәнбер сөекле һәм газиз балаларын, адашып-саташып, тилмереп йөрмәсен анда дип, Ходай ризалыгы белән үз яннарына әти-әнисе чакыртып алды бугай... Бу очракта бал кортлары бары тик арадашчылар гына иде...

...Әүвәл урман артында ук очкыч гөрелтесе ишетелде, беркавымнан агачлар өстендә вертолёт үзе күренде. Виталий, нарат очына ук менеп, үзенен нәфрәтле аурасын ботакка гына элеп төшкән минутлар иде бу. Вертолётнын кай төшедер иң озын булып үскән чыршы ботагына тиеп китеп, ул тигезлеген югалтты. Аны алда икенче агач башы көтеп тора иде, ул ана да кагылды һәм бу юлы тагын да көчлерәк чайкалып, идарәне үк югалтты һәм, юлында очраган агач башларын коя-коя, Ерак Алан дип аталган урынга юнәлде. Ачылып өлгергән парашют агач башында эленеп калды.

Гариф землянка янындагы төптә кырмыска оясын күзәтә иде. Әлеге хәлне күреп, ул бермәл телсез калып утырды, аннары, исенә килеп, теге кеше асылынып торган агачка таба йөгерде. Анын уенча, бу Капрал булырга тиеш иде. Гариф жәһәт кенә як-ягына каранды, Виталий күренмиме? Капрал булса, ике дә уйламыйча аны теге дөньяга олактырырга менә дигән жай бит ләбаса!.. Виталий бу хәлне күрмәгән иде. Гариф агачнын янына ук килде. Парашютчынын эләккән тозагыннан үзенен генә котыла алмаячагы көн кебек ачык. Гариф агач башына үрмәләде.

Парашютчыга, аягы сынуын исәпләмәгәндә, башка зыян килмәгән, беркавымнан ул телгә дә килде.

— Мин кайда? — диде ул, кипкән иреннәрен көч-хәл белән бер-берсеннән аерып.

— Жәннәттә син, туган, жәннәттә! — диде тегесе. — Син Капраловмы? — дип сорады ул, парашютчынын үзе белән татарча сөйләшүенә дә илтифат итмичә.

— Капрал, Капрал, — дип мыгырданды парашютчы һәм күзләрен йомды.

Гариф, аптырап, тирә-ягына күз ташлап алды, чит-ят күренми, Варис та киткән жиреннән аты белән бергә юкка чыкты. Качып киткәндер, дигән фикергә килде ул.

Гариф землянкага китте. Эчтә дә, тышта да беркем күренми, Сафрон белән Виталий да качып киткән, ахрысы, дип уйлады ул. Тирә-юньдә дә күренмиләр. Мөгаен, вертолёт шартлаган тавыш тирә-якнын бар игътибарын монда жәлеп итәр дип уйлап, егетләр, койрыкларын сыртка салып, сыптырткannardыр моннан!.. Югыйсә берәү дә землянканы ташлап китәргә тиеш түгел ләбаса. Хәтта коралларын да землянка эчендәге ылыс-ятак өстендә калдырганнар. Әзерләп торган бомбалары да шул килеш землянканын жир идәнендә кукраеп утыра! Тайган малайлар дип уйлады ул, инде бу юлы катгый карарга килеп. Дөрес эшләгәннәр, бәласеннән башаяк... Виталий өчен генә үкенечле: Капрал үзе кочакка килеп керде дигәндә...

Гариф, карабинын алып, янә парашютчы янына әйләнеп килде. Ул килгәндә, Капралов агачка сөялеп утыра иде. Сынган жире бик каты сызлый, күрәсен, ул йөзен чытып, бер кулы белән аягын тоткан.

— Мин төшкән жирдә дипломат күренмәдеме? Кейс? — диде ул, ынгырашып. Гариф Капралов эленеп торган нарат янына китте һәм, чыннан да, агачнын аскы ботагында гына дипломатка охшаган бер нәрсә эленеп калган иде. Ул аны ачмакчы

булды, әмма кейс ачылмады. Гариф аны хуҗасына китереп бирде дә, үзе чак кына читкә китеп, Капраловка карабинын терәде. Ышанма, дипломатында пистолет-мазар булып, билгесез качкынны атып егу берни тормый мона? Мине атып ега да, точно качып китә бу бандит!.. Хәер, бу аягы белән үзе генә ерак бара алмаячак. Вертолётның югалуын белеп — ул нәкъ Ерак Алан турысына төшеп шартлаган иде — эзли дә чыгарга мөмкиннәр бит моны! Әнчекләре күптер, алар өерләре белән бит... Һе... Һәм шулай булачак та!.. Парашютчы кейсны ачты һәм аннан, шакмаклы шешә алып, голт-голт эчәргә керешге, аннары аны Гарифка сузды. Тегесе, юк дигәнне аңлатып, башын чайкады, ә үзе шешәне алып иснәп карады, борынына затлы коньяк исе килеп бәрелде. Эчемлектән соң парашютчының күзе ачылды, авыртуны да бераз баскан иде, күрәсең, теле ачылды:

— Син кем? — дип сорады ул каршысында карабинын әзер тотып торган Гарифтан.

— Кем дигән кеше! Мәсәлән, синең коткаручың!

— Рәхмәт! — диде тегесе һәм янә коньяк шешәсенә үрелде. Гариф шешәне аның кулыннан тартып алды:

— Исереп бетсәң, сине ничек өстерим ди мин! Син кем буласың соң, вообще-то? — дип кабатлап сорады ул.

— Минме? Мин — бу урманның хуҗасы.

Гариф корт чаккандай урынында сикереп куйды һәм ышанмыйча кабатлап сорады:

— Син! Син Галинмыни?!

Галин, «әйе» дигәнне аңлатып, баш какты. Гариф, карабинын җилкәсеннән тагын шудырып төшерде дә Галинга төбәде:

— Менә бәхет! Үзең килеп каптың, сволочь!

Тегесе күзләрен зур итеп ачып аңа карады:

— Ә син үзең кем? Мине каян беләсең? Миндә нинди үчең бар? — дип сорауларын тезеп китте.

— Мин синең газраилең булам, Галин!

— Ну и что?

— Мин сине хәзер дөмектерәм, Галин! — диде Гариф, карабинның затворын шалтыратып.

— Ә мин сиңа акча бирәм! Күп акча! — диде Галин һәм кейсына таба сузылды. — Беләсеңме, энекәш, бер кейска күпме акча сыйганын? Белмисең шул, күп сыя, жиде миллионга якын. Күпме кирәк, мә, бирәм, коткарганың өчен. Сиңа тиеш. Заслужил, брат!..

— Мин! Мин! Синең аркада психбольницага эләккән кешенең бертуган абыйсы, Галин!

— Кем ул? — диде тегесе, исе китмәгәндәй генә. Күрәсең, ул әле һаман бу дөньяга кайтып житә алмый азаплана, өстәвенә аяк авыртуы да көчле иде.

— Тәнзилә апа синең аркада...

Гариф сүзен әйтеп бетерә алмады, Галин, күзләрен зур ачып, аңа текәлде һәм кычкырып диярлек:

— Тәнзилә?! Син Тәнзиләне каян беләсең? — дип сорады. Гариф җавап бирмәгәч, ул шешәне сорап алды да тагын бер-ике йотым кабып куйды һәм Гариф яхшы белгән Тәнзилә хакында сөйли башлады. Тегесе тыңламыйча булдыра алмады, чөнки Галинның сөйләгәннәре хаклыкка туры килә. Өстәвенә Галин аңа ул монарчы белмәгән тарихны сөйли иде.

— Үч итмә миңа, егет. Мин аның кызы икәнлеген белмәдем. Гашыйк булдым мин аңа. Тәнзиләгә бик охшаган бит. — Галин тагын коньяк суырды һәм буш шешәне кырыйга томырды:

— Үләр алдыннан... алайса, мина яраткан җырымны җырларга ирек бир инде, дустым.

Галин исерә башлаган иде. Гариф, карабинны чынлап та корып, бер-ике адым арткарак чикте:мангаена чәпәргә дә... таярга моннан тизрәк дип уйлады ул һәм мылтыгын Галинга төбәде.

— Не честно! — дип мыгырданды тегесе. — Соңгы сүзгә хакым бармы минем? Чёрт побери! Менә, тыңла:

Булмагач син, утлар сүнде —
Бары тотен керә күзгә...
Кышларымны җәй иттең син,
Мин яз идем сары көздә.

Гариф, гаҗәпләнеп — шаклар катып, тәмам аптырап, гаҗизләр булып дисәң дә була — Галинга карады. Галин аның җырын көйли иде. Сүзләре генә түгел, кайбер ят ноталарын исәпкә алмаганда, көе дә аныкы. Гариф кинәт әллә ничек кенә куырылып килде, аннары янә агачка сөялеп утырган дошманына бакты... Кыскасы, ул ни кылырга да, нәрсә дип әйтергә дә белми иде бу минутта...

— Төтен җибәрмә күзгә... — диде ул акрын гына.

— Мин түгел! Гарәфәгез җибәргән монда төтенне! Минем хатын — Изольданың коренной җыры бу. Үзе ул ана яңа музыка да язып караган булды. Барып чыктымы икән анысы, белмим.

Гариф йомшара башлады, хәтта борын астына хәтле юешләнде.

— Барып чыкмаган... Мин — Гарәфә! Гариф-Гарәфә!.. — дип өстәде ул, соңгы сүзләренә ачыклык кертеп.

— Минем хатынның яраткан җыры бу! Мина үч итеп җырлый, сволочь! Имеш, яшьлектә аның үлеп яраткан мәхәббәте булган! Мина да ошый бу җыр! Минем дә бар иде бит сөйгән кешем! Тәнзиләм! Карале, егет, исемең ничек әле? Тәнзилә белән кавыштыр әле миңе, ә? Мин сиңа күп итеп акча бирәм! Чү! Туктале! Син бу җырны язган шагыйрь түгелдер ич?!

— Ниһаять, барып җитте бу сиңа, Галин...

— Син шагыйрь башың белән нишләп урманда мылтык күтәреп йөрисең әле? Куян атарга чыкмаганың күренеп тора.

— Синең кебекләр мәҗбүр итә менә.

— Синең эш — язу!

— Ишетәсезме соң язганнарны?

— Нишләп алай дисең! Әнә, интернет аша хәзер целый митинглар оештыралар! Ә син шигырьләр яз! Теге җырың матур бит! Минем Изольдага ошарлык булгач... Җырлар яз. Әйдә, давай, мин сиңа Тәнзилә турында... юк, безнең бәхетсез мәхәббәт турында җыр язарга заказ бирәм, ә? Әнә, анда егетләр ниндидер чештин-пештин җыр авторларына да машина өләшеп йөриләр, ә мин сиңа бер миллион бирәм! Тәнзиләм өчен не жалко! И аннан соң яз рәхәтләнеп шигырьләреңне, роман яз! Әйдә, минем турыда роман язарга алынасыңмы?! Яз рәхәтләнеп шигырьләреңне, матур бит! Их, дөнья матур, дөнья киң! Урманда партизан кебек мылтык күтәреп йөргәнче!..

— Язып карадык инде. Беләсеңме, Галин, мин моннан ун еллап элек, әгәр әдәбият-мәдәниятне футбол тубына алыштырабыз икән, мәгәр рухи тәрбиягә игътибар итмибез икән, килер заман, ул туп тибеп үскән яшь буын мораль яктан черек булачак, мәхәббәт эшләрен чүплек артларында этләр кебек кенә башкара башлаячак, бүген балалар тәрбиясенә, әдәбиятка төкереп тә карамаган түрә агай, берзаман, таягына таянып, кибеткә сөткә барган җиреннән,

чиратта аны, йөрмәле, карт пәри дип, кабырга арасына пычак тыгып китәргә мөмкиннәр, дип язган идем. Ул чакта әйттеләр, арттырып җибәргәнсең, алай ук булмаячак, ташла бу пессимистик уйларынны, диделәр. Шулай да бастылар тагын ул мәкаләләрне. Хәзер мин ул вакыттагы фаразларның бүген тормышка ашканын күреп шаккатам! Шәһәрнең үзәк урамнарында кырыйга чыгып баскан, тәрәзәләренә кара пәрдәләр ябыштырган машиналарны күргәнең бармы синең? Минем бар! Берсендә, бу затлы иномарка нигә бала бишеге кебек тирбәлә икән дип барсам!.. Ни күрим — ике яшь нәмәрсә, икесе дә анадан тума шәп-шәрә, — мәхәббәттә аңлашалар. Ачудан тәгәрмәченә китереп типкән идем, машина эчендәге акселерат, ишекне ачып, минем якка карап та тормыйча, пистолеттан ата башламасынмы! Бәхеткә күрә, резина пулялар булып чыкты. Өч кабырга хисабына гына котылып калдым!.. Ә син яз, дисең!

Гарифның ачуы ташыр дәрәҗәдә иде. Ләкин ул үз-үзен кулга алырга тырышты. Һәм шунысы кызык: бу кешегә хәзер алай ук нәфрәтләнеп карамый иде ул. Тәнзилә апаны заманында яраткан булган икән ич... Хәзер дә яратам ди... Аннан соң... җыр сүзләрен, шигырьләрне яттан белгән олигархбандитны каян табасың хәзер?! Ул Галинны күтәреп торгызды да, җилкәсенә атландырып диярлек, урман авызына таба юнәлде. Үзе эчтән генә: «Юл кырыена чыгарып, берәр агачка сөяп калдырырга да, чыгып таярга бу тирәдән!» — дип уйлап куйган иде.

— Тукта, авырта... — дип ыңгырашты Галин. Гариф аны янә агачка сөяп утыртмыйча булдыра алмады. Сызланса да, Галин сүзгә һаман батыр. Гариф анын ачык җәрәхәтенә балы тамып торган юкә яфраклары ябып бәйләгән иде, шунлыктан кан агуы беткән, ләкин, нишләтәсең, сынган урын авыртмыйча булмас инде ул. Дөрес, утырып берчак хәл алганнан соң, авырту басыла да теле юешләнгән Галинның сөйләшәсе килә башлый. Әле дә ул, бераз тын алуга:

— Син миңа, Гарәфә, әйт әле: син баймы, хәерчеме?

— Рухи яктан ничавадыр, мөгаен, — диде Гариф. Галин белән гәпләшү анын үзенә дә кызык иде, чөнки мондый олигарх белән, шундый шартларда тагын кайчан сөйләшә аласың?! Сәлам дә бирмәячәк ул башка вакытта очратса...

— Акча ягыннан дим мин?

— Хәзер җан тәрбияләү эшенә түләү бетте бит ул.

— Ә байларны нигә шулхәтле яратмыйсыз соң?

— Бандитларны, каракларны яратмыйбыз!..

— Пафосланма! Миңа мин, мәсәлән, син яратмый дип, бар байлыгымнан баш тартырга тиешменме? Минем кесәләр бушап калгач, син мине яратсын дипме? Юк, аннан соң да яратмаячаксың син мине! Ул вакытта инде көләчәксең, мыскыл итәчәксең? Шулай бит?

— Шулай инде, бер уйлаганда.

— Әгәр миңа сиңа күп акча керергә җай килеп чыкса, баш тартыр идеңме, юкмы?

— Дуракмыни мин?!

— Миңа, алайса, син дә баеп киттең! Миңа бит... Күптән бер рус язучысының телевизордан сөйләгәнен тыңларга туры килде: безнең рус халкының холкына байлык хас түгел. Байлык безнең халыкны мораль яктан тарката, ди бу! Ярый, хуш, шулай булсын да, ди. Ә миңа татарның холкына хас сыйфат түгел бит ул хәерчелек! Адәм баласы мул яшәргә тиеш!..

— Килешәм, — диде Гариф аңа каршы.

— Алайса сез, үзегез мантый алмаган хәерчеләр, нигә байларны яратмыйсыз? Киресенчә булырга тиеш бит югыйсә?

— Син дөрес аңламадың, Галин әфәнде. Без, беренчедән, Җөмһүрият байлыгын Үзәккә олаулап озатуга каршы.

— Налогларны әйтәсенме?

— Аны да әйтәм. Бар байлыкны суырып утыра, соры корт кебек! Аннары бит... әйе, монысы да хак: аннан тыш та «кул юу» өчен күпме байлык агыла читкә! Әйе, салым турында син дөрес әйтәсең. Чыңгызхан да бары ун процент кына ясак җыйган, сиксән түгел! Димәк, рәсми булмаганнарын да, откатларны, и бездәге шома егетләр хуҗа булган җирләрне дә кертеп, бер триллион дигән сүз!!! Шуларны булгәндә, нигә безнең җөмһүрият үз сүзен әйтә алмый?! Колбиләүчелек сәясәте бит бу! Аннан соң халык сине егерме миллионлык бакыр түбә япкан, җиде миллионлык сартир ясаткан дип сөйли. Тукай әйтмешли, көнен сартир, төнен сартирдыр инде? Бар дөнья хәерче вакытта анысы ниемә кирәк иде инде? Җитмәсә әле шуның белән мактанасыз! Ачыктан-ачык!..

— Биотуалетның бәясе шулай тора шул.

— Ю-ю-юк! Син хаклы түгел, Галин. Мин байларны яратмыйм түгел, хәтта урлап баеганнарын да хөрмәт итәм. Чөнки Рәсәйдә урламыйча баеп булмый. Җөмһүриятнең байлыгы үзеннән җитеп аша, ә хәерчелек кайдан килә дип офтану гына ул! Аннары сигез йөз чакрым арадан торып, минем телемне кисеп яталар!

— Слушай, парень, — диде Галин аңа каршы. — Монда минем байлыкның ни катнашы бар соң?!

— Нәрсә, мин сине гаепләдем что ли?! Рәнзиләне мыскыл иткәнең өчен... да! Хәзер тотам да атып китәм мин сине, надоел уже! — диде Гариф һәм карабинын Галинга төрәде. — Вообще-то, гаеплим, Галин! Тегеләр талый, ә сезнең кебекләр урлый! Калганнарга ни кала?! Шымытыр! Әле өстәвенә үзегез урлап, хәерчелеккә калган халыкны күрә алмыйсыз! Җирәнәсез ул халыктан! Ә үзегез күрәләтә алдамакчы буласыз! Декларациянне күрдем мин синең, бандит! Өйдә яткан хатыныңның еллык кереме җитмеш ике миллион, синеке, имеш, бары өч миллион гына икән! Әле монысы рәсми билгеле булганы гына! Атам мин сине, сволочь!!! Кәфенлекне доллардан тексеннәр сиңа!

— Ашыкма! Әүвәл миңа дару өстәргә кирәк әле.

Гариф шаркылдап көләргә кереште:

— Ну ты даёшь! Нәкъ Берия кебек син! Атар алдыннан соң сүз әйтергә мөмкинлек биргәч, ул да: «Принесите коньяк и женщину!» — дигән түгелме соң! — Ә үзе шешәне Галинга сузды. Эчемлек йотып куйганнан соң, Гариф аны янә җилкәсенә салмакчы иде, тегесе ике кулын аның күкрәгенә төрәде:

— Чү, тукта, Гарәфә. Без бит кейсны онытып калдырганбыз!

Чыннан да, каушавыннан Гариф дипломат турында онытып җибәргән иде, югыйсә онытырлык нәрсә түгел бит инде, аның урынына, башына пуля җибәреп, агач төбендәге кырмыска оясы янында Галинны «онытып» калдыруын мең тапкыр дөресрәктер бит?

— Иренмә инде син, кем, Гарәфә, алып кил. Мин монда көтәм. Всютеки туалет кәгазе генә түгел бит!

Гариф кире китте. Галинның маңгаена берне чәпәп, кейсны алып качса гына инде каһә?! Егет икеләнә, бик икеләнә иде. Беренчедән, ул кеше үтерә ала торган җан түгел икән!.. Гомерен буе төшләренә кереп йөдәтер. Бигрәк тә акча өчен җан кыю! Юк, биш тиенлек шигырьләренә өч тиен гонорар алып, чиста күңел белән яшәвең яхшырак. Акчасы да кызыктыра, әлбәттә. Шәһәргә тыгылып, ул акчага ниндидер эшкуарлык белән шөгыльләнеп булмаслыгы көн кебек ачык. Бизнес кланнар арасында бүленеп беткән. Баймурзиннан җир алсаң гына инде. Шуннан ул җир белән нишләрсең? Ура, суга, җилгәрә, үзе тәяп җибәрәме? Юк, соң инде язмышны капылт

кына башка юлдан борып алып китү, соң хәзер... Нәшрият ачып, балалар китаплары, дини җыентыклар чыгара башласа? Белгән, кулы яткан һәм, иң әһәмиятлесе, кирәкле шөгыль бит?! Юк, монда да бизнесменнар буа буарлык хәзер... Гариф, борын төбендә әйләнеп йөри башлаган кигәвенне куып җибәрде дә, үзен мыскыл иткән шикелле, авызын чалшайтты: харам юл белән килгән мал аларның нәселенә хас нәрсә түгел. Мәрхүм әтисе гел шулай дия торган иде. Иң яхшысы моннан качып котылу?! Галинны юл кырыена чыгарып куярга да... Бирәм дисә, бу юлы акчасыннан баш тартмас иде анысы. Шәһәрдә берәр әдәби кафе ачып җибәрергә? Ә? Ул адымнарын кызулата төште. Дипломат агач төбендә иде.

Ул Галинны калдырып киткән урынга килеп җиткәч, ниндидер хәерсез хәл сизеп, туктап калды. Аны интуициясе беркайчан да алдамый торган иде. Язганда да, иҗат иткәндә дә шулай. Әйтерсең, аның баш мие галәмдәге күзгә күренмәс җепләр белән тоташкан: кайвакыт фикер агылып-агылып килә, шигырь туа. Аның беркайчан да язам дип, язасы бар дип, үзен көчләп өстәл артына утыртып, азапланып иҗат иткәне юк. Уйнап кына яза кебек иде ул. Кайвакыт, интуиция, акыл шәрифләре белән бергә кушылып, әллә нинди хикмәтләр килеп чыга. Әнә шул иҗади хикмәтләр яшәтә иде егетне! Ошбу хикмәтнең Ходай тарафыннан иңдерелгән шундый ук янә бер могҗиза икәнлеген төшенә башлаган иде ул соңгы вакытларда... Иҗат газабын, аның рәхәтлеген башка берни белән дә алыштырып булмый!..

Гарифның башы яныннан пуля сызгырып узды. Галин, мәлгунь, агачка сөялеп баскан да аның тарафына ата иде. Икенче пуля шулай ук баш өстеннән генә сызгырып узды. Ул җиргә капланды. Галин атуыннан туктамады, Гариф тирәсендә пулялар сызгырды, ату тавышларының кайтавазын урман, тагын шомлырак итеп көчәйтеп, тирә-юньгә таратып тора иде. Менә теге кабахәт атуыннан туктады да лып итеп баягы урынына утырды, кулындагы пистолеты төшеп китте, икенче кулы белән үрелеп эчемлек шешәсен алды. Гариф беркавым тын гына ятты әле. Аннары, хәрәкәтсез утырган Галиннан күзләрен алмыйча, акрын гына торып басты да чүгәләп диярлек аңа таба бара башлады. Килеп җитәм дигәндә генә, Галин, уянып китеп, янә пистолетын кулына алды һәм Гарифка төбәде:

— Син кем? Аюмы, бүреме? — диде ул исерек тавышы белән, аннары кинәт айнып киткәндәй булды. — Ха! Гарәфә! Пушкин безнең! Габдулла Тукай! Стоп, Тукай! Басып тор шунда гына!

Гариф әүвәл аны кейсны сорап алыр дип уйлап, шуны тоткан кулын алгарак сузды, тик теге акча урынына аннан урманда чыбыркы таптыра башлады:

— Чыбыркы табып кил! Тиз! — диде ул.

— Хәзер, хәзер, — диде Гариф, ашыгып. — Көтүчеләр Сай су буенда гына булырга тиеш. Хәзер чыбыркыларын сорап торам алайса, — дип дәште ул, тавышын йомшартып.

— Чыбыркы шартлатасы килә минем! Үлеп шартлатасы килә, Гарәфә! Көтүче малае бит мин! Әти белән көтү көтәсе килә! Тәгәрәп ят идең шунда болында. Ә маллар кетер-кетер, кетер-кетер... И торасың да чыбыркыны шартлатып җибәрәсең, малай! Һаваларны кисә ул чыбыркы кылы, һаваларны кисә!..

— Урманда барыбер шартлатып булмый. Агачлар бит, — дип куйды Гариф.

— Һе, син тоже хаклы. Алайса миңа шигырь укы! Укымасаң, атам. Белеп тор, малай! Түлке Тәнзиләгә багышланганын гына укы, яме. Мин сиңа акча бирермен аннан соң.

Гариф укый башлады:

Ялкын сүнде, очкын калды —
Күзгә керә бары төтен.
Югалтканны табармын күк,
Ташлап китмә, өметем!..

— Ооо-оо! Өмет — бөек нәрсә! — диде Галин һәм янә коньяк чөмереп куйды. Анын тәмам исерүе житкән иде, пистолетын жиргә ташлады да ике кулы белән дә шешәгә ябышты һәм имезлек суыргандай суыра башлады. Шуннан соң гәүдәсе бөтенләй ишелеп төште, әмма үзе һаман уяу әле, менә, кесәсендә капшанып, аннан ике бармак арасында дару савыты өстерәп чыгарды һәм бер төймәсен йотып та жибәрде. Гариф та бу вакытта ни эшләргә кирәклеген уйлап куйган, ул, жәһәт кенә барып, жирдә яткан пистолетны эләктерде. Бая агачка сөяп куйган карабинын эзләде, таба алмады. Озак мәлҗерәп утырмады Галин, янә башын күтәрде һәм бу юлы ап-аек тавыш белән:

— Бу дару — бөек нәрсә! — дип куйды, баягы тартманы жәһәт кенә кесәсенә яшерде. Дөрестән дә, әлеге дару тиз айныта һәм Галин аны бервакытта да үзеннән калдырмый, аракыга күнегеп, изләнеп беткән организмы кирәк чакларда шул дару белән бергә эчемлек тәэсиренә, бигрәк тә исерүгә каршы тора. Мәннәви Мансарович моннан биш ел элек кенә эчүнең ни икәнлеген дә белми, дуслар белән банкет-табыннарда утырганда да, үзе белән су салынган махсус шешәләр йөртергә куша, сиздермичә генә ана шуны салып бирә торганнар иде. Хәзер, әлеге чир аны йөгәнләп алганнан бирле, ул иң затлы, иң чиста француз коньяклары гына эчәргә тырыша. Ләкин күп эчкәнлектән, алар да организмны саклый алмый, киресенчә, эчү анын гадәтенә әйләнеп китте. Баштарак һәр эчемлек су кебек кенә бара иде, соңгы араларда ул тиз исерә башлады һәм, яшь бала имезлексез тора алмаган кебек, һәйбәт коньяктан аерылып тормый иде. Һәм теге тәэсирле дарудан. Тик әлеге даруны капканнан соң, ярты көн чамасы аракыны бүтән авызга да алырга ярамый, кеше ныграк исерә һәм хәтта беркавымга аңын да югалтырга мөмкин. Шуны белә торып, Галин янә коньяк йотты да бөтенләй изрәде. Гариф ничек итсә итте, аны урман ачыклыгына чаклы сөйрәп барды. Анын уянганын көтеп утырсам дип уйлады егет? Акчаны бирәм диде бит, үз кулы белән бирсә яхшырак. Ләкин тегенен айнырга исәбе күренми һәм монда озак утыру да куркыныч иде. Шулчак егетнең башына көтелмәгән уй килде: кейсны әнә теге агач куышына яшерергә дә сызарга моннан! Дөньялар тынычлангач, килеп алыр әле. Урлап китми бит?.. Аннан соң да «юлдашын» ташлап китәргә ашыкмады әле. Галин кесәсеннән баягы даруны эзләп тапты һәм бер төймәсен көчләп анын авызына тыкты. Беркавымнан Галин уянды, күзен ачты. Гариф акча турында сүз кузгатырга дип авызын ачкан гына иде, урманда мылтыктан аткан тавышлар ишетелде. Шунын артыннан ук дуңгызлар чинаган (кабан дуңгызларыдыр инде!) — тавышлар ишетелде.

Ату тавышлары Гарифтан да бигрәк, дару тәэсиреннән күзләрен ачып, янә агачка сөялеп утырган Галинны шүрләтте бугай, ул бәбәкләрен акайтып Гарифка карады:

— Нәрсә бу?!

— Аучылармы соң?

— Стоп! Минем урманда нинди аучы йөри анда?!

— Мин синең урманыңның каравылчысы түгел бит!

Галин тиктомалдан шаркылдап көләргә кереште.

— Понял! Понял! Террористлар ул, кабаннар түгел! ФСБ белән террористлар бәрелеше!..

Гариф куркуга төште һәм әле Галинга, әле кулындагы дипломатка карап тора башлады. Тик бу халәте озак бармады, ул, тиз генә качарга уйлап:

— Ууу! Киттем мин, алайса! Син теләсә нишлә!

Галин шаркылдавыннан шып туктады һәм, егеткә кулын изәп:

— Курыкма! Бернинди ФСБ юк анда! Чынлап та, кабаннар ул! Искә төште!.. — диде.

Галин кейсы турында оныткан иде, Гарифтан ул хакта сорап та карамады. Тегесе, шуннан файдаланып, як-ягына карана башлады һәм үзеннән сул ягындарак торган карт имән кәүсәсендә бер куыш күреп, аякларын шуыштырып кына шунда таба атлады. Кейсны яшерергә иң ышанычлы урын шушы иде. Ул янә Галин янына килде:

— Мин сине юл кырыена чыгарам. Шуннан үзең охранаңа шалтыратырсың. Карале, иптәш Галин, минем бер эшкә спонсор була алмыйсыңмы син? — диде ул, батыраеп. Ләкин бу минутта ул иганәче эзләүдән бигрәк, Галин дипломат турында тагын искә алырмы, юкмы икән дип көтте. Әлбәттә, тегенең хәтер чуалган вакытлар иде, коньяк белән чиратлашып эчкән дару үзенекен итте, ахрысы. «Табарсың мине, сөйләшербез!» — диде ул.

Вәгъдә иткәнчә, Гариф Галинны юл буендагы агач төбенә сөяп калдырды да үзе, бәласеннән башаяк дигәндәй, кызу-кызу урман юлыннан шәһәр ягына таба китеп барды. Киткәндә, ул, ике кулын күтәреп күрсәтеп: «Мин дипломатны тапмадым, соңыннан үзегез эзләрсез», — дигән булды. Тегесе моңа каршы: «Вертолётта шартлагандыр инде ул. Чёрт с ним!» — дип куйды һәм аннары елмайгандай итеп өстәде: «Минем фазендадагы бер туалет бәясе вак-төяк акча иде анда!» — Тик Гарифның аякларына гер асып куйган кебек иде, ул бер урында басып тора башлады. «На чёрт нужен миңа аның акчасы!» — дип уйлады ул кинәт һәм әлеге уй егетнең аякларындагы авырлыкны җиңеләйтте. «Галин, дипломатың агач куышында! Кирәк булса, үзең алырсың!» — дип кычкырды ул һәм адымнарын кызулатты. «Вертолёт белән бергә шартлаган ул!» — дип әйттем бит инде мин сиңа! «Аның бу сүзләреннән җиңел сулап куйган Гариф тизрәк китү ягын карады. Галин исә кесә телефоныннан әүвәл Саввага шалтыратты, әмма, гомердә булмаганны, тегенең телефоны сүнгән иде. Изольдага шалтыратып карады, үзе белгән тагын берничә телефон номерын җыеп бакты, тик бар тырышлыгы бушка китте, берәү дә телефонын алмады. Ул, агачка аркасы белән терәлде дә чарасызлыктан Ябалак ягына карады. Авыл өстендә шәфәкъ яктысы уйнаган кебек. Алсу-кызыл ут, болыт булып, өскә күтәрелгән. Бая җыр белән күңеле иләсләнгән Мәннәви Мансарович әлеге матурлыкка хозурланып байтак утырды. Берраттән шундый хәлләрдән соң исән калуына да сөенә иде бугай ул... Бернинди кино-картиналарда да күреп булмый мондый хозурлыкны! «Гүзәл, искиткеч гүзәл!» — дип иреннәрен кыймылдатты ул. Һәм беркавым үзенең бу кыланышына аптырап та утырды: «Таш йөрәк дип сүккән булалар! Менә бит, мин дә матурлыкны аңлый беләм! Һәй! Дөнья матур, дөнья киң шул!» — дип кычкырасы килде аның. Һәм шулай дип кычкырды да, урман аның әлеге сүзләрен үзенә йотты, аннары кайтаваз итеп, басу-кырларга, тугай-үзәннәргә таратты. Алар анда бик тиз эреп югалдылар...

Үзе күргән шәфәкънең авыл өстендәге янгын икәнлеген белсә, бәлки, ул башкача кычкырган булыр иде. Вертолёт шартлап, Ерак Аланда җиләк җыйган хатын-кызлар, кыз-балалар һәлак булганнан соң, ярсуына чыдаша алмаган халык, кулына нәрсә эләксә, шуны күтәреп барып, Галинның фазендасын астын-өскә әйләндерде, ачуы алай гына да басылмагач, гектарлап җир биләгән ихата-фазенда өстенә кызыл әтәч җибәрде!..

Гариф-Гарәфә Галиннын башланмаган тагын бер коньяк шешәсен аяк очында калдырып киткән иде. Ул, сөенеп, шешәне алды... Әйе, кейста анын коттеджындагы бер туалет бәһасе булган жиде миллион урыс акчасы иде. Бу минутларда, менә монда, хәзерге хәлендә, барыннан да бигрәк эчемлек кадерлерәк түгелме соң аңа?! Менә бу урман буенда, ялгыз башы канга батып утырганда, күнелен юатып, тәненә хәл кертү өчен, акча кирәкме, әллә эчемлекме? Әлбәттә, эчемлек кадерлерәк!.. Әлеге ачышыннан ул үзе дә көлеп куйды. Инде мона кадәрле берничә гасыр элек кешелек дөньясы өчен ачылган, дәлилләнгән хакыйкать — акчадан да мөһимрәк нәрсәләр булуы, ошбу минутларда бары Галиннын үз хакыйкате генә иде. Бары тик үзенеке генә...

Эчемлек исенә чебен-черки генә түгел, шөпшә кебек зуррак жан ияләре дә жыела башлады. Галин сөялеп утырган агач куышында умарта күче урнашкан иде. Умарталыктан оя күче аерып, монда яшәр урын эзләп тапкан, әлеге агачка килеп сыенган бал кортлары оясы иде ул. Алар да шөпшәләрдән калышмады, ят ис килгән якка очып килделәр. Тик бал кортлары бу исне яратмый, алар бу исне дошман исе буларак кабул итәләр иде. Бал кортлары бер-бер артлы дошманга һөжүм башлады. Беркавымнан Галиннын йөзен танырлык түгел иде. Нәкъ шул вакытта юл буенда анын йорт-жиренә «кызыл әтәч» жибәреп кайтып килүче ярсулы төркем күренде. Алар юл буендагы агачка сөялгән яралыны, әлбәттә, шундук күреп алдылар. Мәгәр Галинны таныган булсалар, күтәреп барып, янгынга атачаклар иде. Югыйсә күбесе Галинны кыяфәткә танып белә, күп мәртәбәләр күрешкәннәре бар иде. Бит-кыяфәте шешенеп, танымаслык дәрәжәгә килгән кешене алар танымадылар. Шуңа күрә иплап кенә күтәрделәр дә хастаханәгә озату ягын карадылар.

Бал кортлары бу вакытта да бары арадашчылар гына иде. Әлбәттә, аны чакканда, шунын белән коткарып калырбыз дип башларына да китермәде ул изге жаннар. Әллә белеп эшләделәрме моны?.. Тәмуг утында янар алдыннан, әүвәл жир өстендәге утта янса соң? Аларга ни ди? Әллә, нәфесләнеп жыйган жирләрен өчен әүвәл бу дөньяда жавап тот дип, аны юри шулай исән-сау калдырулары булдымы?

Ул көннәрдә дөнья кайнап торды. ФСБ урман эчендә террористларнын зур корал складын табып алган дигән хәбәр исә матбугатка ук чыкты. Табылган коралларына караганда, аларнын исәбе берничә йөз кешедән артып киткән булырга тиеш, ди. Экспертларнын тикшеренүләре шуны күрсәткән: һәммәсе дә мөселман өммәтеннән, ягъни ваххабитлар (мөселман булгач!) икән! Икенче бер аланлыкта канлы бәрелеш булган, тик, урман эче кан белән тулса да, мәетләре табылмаган икән!.. Ул көннәрдә Сөләйман Әл-Рәисофф кебекләр телевизор экраннарыннан төшмәделәр.

## Сиңа да җир кирәкме?

Әүвәл заманда, атабыз Адәм анабыз Хава белән тормыш итә башлагач, аны Аллаһы Тәгалә үз янына чакырта һәм агач сука, биш үгез, озын чыбыркы бирә дә: «Бар, дөнья буйлап жир сөр, нәсел-нәсәбең жирдән ризык табарга өйрәнсен!» — ди. Адәм Аллаһы Тәгаләгә өч мәртәбә баш орып, рәхмәт әйтә дә өенә кайтып китә.

Өйдә аны сөекле хатыны Хава көтеп тора. Адәм аңа мәсьәләне жайлап аңлатып бирә. Әлбәттә, Хава каршы килми, ирен юлга әзерли башлый.

Шул рәвешле чыгып китә Адәм атабыз. Әнә, йокыдан уянып килә торган агач-куакларнын башларын нурлары белән сыйпап, кояш күтәрелеп килә. Киек-жәнлекләр, сайрар кошлар, озынколак куяннар, чәчәктән чәчәккә кунып

очучы күбәләкләр, тынгы белмәс чебен-черки, әкәм-төкәмнәр — барысы да йокыдан уянып килгән вакыт була бу. Бар табигать яшәргә омтыла.

Бик ерак китә Адәм атабыз. «Күпме жир сөрим икән?» — дип уйланып тора ул башта, аннары, бисмилласын әйтеп, эшкә керешә. Үгезләр суканы өстерәп китәләр, барыр юлы ерак, сөрер жире бихисап була Адәм атабызның.

Ераккарак киткән саен, аның зиһене ачыла, киләчәк якты-матур тоела. Аның балалары да бер-бер артлы үсә һәм үрчи тора. Алар үрчегән саен, ашарга ризык тагын да күбрәк кирәк була. Адәм тагын да тырышыбрак эшли башлый. Менә берзаман ул арып туктый, үгезләрен туарып жибәрә дә ял итәргә утыра. Арыган була ул, ничек йоклап киткәнен үзе дә сизми кала. Һәм бик мәгънәле бер төш күрә. Имеш, аның нәселе байлык, муллык эчендә яши икән. Жир өсте бакчалар, сөрүле жирләр белән капланган, һәр тарафта шатлыклы авазлар яңгырый.

Адәм атабыз янә эшкә керешә. Кырыгынчы көн булды дигәндә, Аллаһы Тәгалә үзе янына Жәбраил фәрештәне чакыра һәм әйтә: «И тугрылыклы фәрештәм! Син Адәм янына бар әле. Сынап кара син аны. Әгәр ул бу жирнең хужасы үзе генә дип исәпләсә, киләчәктә жир кешеләр арасында гел ызгыш кына тудырып торыр. Тәкәбберләнмәсә, аның нәселе гомер буе байлыкта һәм муллыкта гомер кичерер, ди.

Икенче көнне таң белән уянып жир сөрә башлаган Адәм галәйһиссәлам каршысына килгән тагын бер сукачыны күреп ала. Әйе, әйе, теге нәкъ моның буразнасы янәшәсенә турылаган! Адәмнең моңа эче поша һәм ул теге сукачыга:

— Нигә минем жирем яныннан сукалыйсың, — ди. Сукачы кыяфәтендәге Жәбраил:

— Мине Аллаһы Тәгалә бар иткән. Мине ул жиргә индерде. Мин, балаларымны туйдыру өчен, менә жир сөрергә булдым, — ди.

Бу сүзләр Адәм галәйһиссәламне ярсытып жибәрә:

— Кит моннан! — ди ул. — Бу жир миңа бүләк итеп бирелде! Мин аны беркемгә дә бирергә теләмим! Аллаһы Тәгаләдән башка урыннан жир сора. Аның кодрәтеннән килә, ул синең соравыңны канәгатьләндерер! — ди.

Жәбраил фәрештә, ярты жиренне миңа бир дип, бик ялварып сорый. Адәм риза булмый.

— Барысы да минеке! — ди ул, ачуланып.

Жәбраил фәрештәнең күзләреннән хәсрәт һәм ачу чаткылары сибелә. Ул, кулларын югары күтәреп:

— И Илаһым!.. Син ничек әйттең, шулай булсын! — дигән.

Әлеге хәлләрдән соң күп сулар аккан, күп гомерләр узган, ә жир һаман талаш, ызгышка сәбәп булып кала бирә икән, ди. Халыклар, Адәмнең балалары жир өчен һаман бер-берсе белән сугышалар, туган туганга каршы бара, ата белән уллар ызгыша, һәркайда жир өчен кан ага.

Әле хәзер дә жир өстендә бер өн ишетелә сыман:

— Жир кирәк миңа, жир!..

Һәм бу Гарасат мәйданына аяк басканчыга кадәр шулай булачак, ди...

## Эпилог

Муса пәйгамбәрне бәхәстә жинеп чыкса да, Адәм галәйһиссәламнең күңеле барыбер тынычланып житмәде. Ул яшәп киткән Жирдә хәзер ниләр булып ята икән? Жирдә ниләр бар икән?! Ул, бик текәлеп, аска карады, анда сәхабәсен — үз шәжәрә агачында тамырланган бик ерак нәселдәге бер оныгын күреп

алды. Карашы ерак сәхабәсенең — Сәхаби атлы үз затының карашы белән бергә кушылып, ул хәзер жирдәниләр булганлыгын күрә дә, белә дә ала иде.

— Аллага шөкер! — диде ул пышылдап һәм жанына бермәлгә тынычлык ингән кебек булды. Сау бул, озын гомерле бул, минем жир-авылым, исән-аман булып тор!..

— Чү! Сабыр! Ашыкма, зинһар! — диде аңа кемдер. Сәхабинең үзенең дә Байтимер белән бер күрешеп аласы килә иде. — Мин Сәхаби буларак калам, Сәхабә буларак кына китәсем бар. Туйганчы сөйләшербез әле, Байтимер, — диде ул.

— Сөйләшербез, — диде Байтимер. — Тик син миңа шуны әйт: Борис Айсинны үтерүчене син бик озак эзләдең. Таба алдыңмы?

— Таптым, — диде Сәхабә, тыныч тавыш белән. — Сания күршесе белән буразна өчен талашканда, чалгысын күтәреп чыккан булган. Кызулыктан ул аны зират буендагы кычыткан арасында онытып калдырган. Жанына урын тапмаган Борис әүвәл Сания янына кергән булган, ләкин хатында ярсулыгына ялкын өстәрлек утлы су булмагач, зират коймасы аша гына хатыны янына керергә исәпләгән. Чалгы сабына абынып, тимеренә егылган...

— Нинди мәгънәсез үлем!.. Бала кайгысы, — дип куйды Сәхаби. — Иң зур кайгы... Синең дә кечкенәң туарга тора дип ишетеп беләм?

— Әйе, мин дә, Нурбикәдән соң, уйламаганда гына өйләнеп куйдым бит. Себердән яшьләрне монда китерттем. Шулар арасыннан миңа бер насыйбы табылды. Нурсия исемле. Ритага да, Нурбикәгә дә охшаган иде ул.

— Ә алар кемгә охшаган иде?

— Минем әнигә бугай?.. Бәлкем, олы апагадыр?..

— Син, Байтимер, жирдә монарчы беркем эшләмәгән эшләр эшләдең! Афәрин!

— Мин түгел, Сәхабә...

— Кем соң?

Байтимер беркавымга гына карашын күккә күчереп алды.

— Белмим, — диде ул. — Әлиф. Ләм. Мим.

— Ә мин беләм.

— Син күп нәрсәләр беләсең, Сәхабә!..

— Син дә күпне кичердең. Беләм.

— Менә тыңла әле: Аллаһы Тәгалә ул адәмнәр уйлап чыгарган иң бөек әкият дип өйрәтәләр иде безне яшь чакта... Мин яши-яши белдем. — Байтимер күкрәгенә төртеп күрсәтте. — Адәм баласының жаны икән бит ул! Тегендә, — Байтимер бу юлы күккә таба ымлады, — яхшырак аңлашыла ул! Аның өчен күп томлы китаплар да укып торасы юк. Мөхәммәдкә ингән изге Коръән сүрәләрен белү дә кирәк түгел хәтта! Нindидер бер кыска гына мизгел эчендә Бөек көчнең — Аллаһның барлыгына инанасың да куясың! Изге Коръәннең кадерен шуннан соң гына аңлый башлыйсың... Төгәлрәк аңлата алмыйм инде, син үзеннән Илаһы белән тоташкан икәнлегеңә инанасың! Авырлык кичергәннән соң гына, үз башыңа төшкәч кенә кеше Илаһыга мөрәжәгать итә, диләр. Юк, дөрес түгел. Ул туганда ук булган була инде, жан белән бергә ярала ул. Ә сынаулар каршына килеп баскач, бары әнә шул уяна, баш кына калкыта. Мин моны Аллага ышанмау яисә ышанудан чыгып әйтмим. Гомумән, бу нәрсә — Адәм баласының асылы ул. Христосмы, Мөхәммәдме — анысы Адәмнең кайсы кавем баласының нәрсәдән әвәләнүенә генә карый. Безгә, әлбәттә, галәм акылы, космический разум дигән төшенчә якынрак иде. Үзем күрмәсәм... хәер, мин нәрсә күрдем соң — анысын да белмим — мин, бәлки, һаман шулай дип кенә уйлаган булыр идем әле. Әгәр мин соңыннан үземдә, күкрәгемдә илаһи

бер көч, егәр тоймасам, мин һаман космодромда эшләп йөргән булыр идем әле. Ә мин менә бүген жир эшендә... Син миңа нәрсә булса да аңлата яки өстәп әйтә аласыңмы, Сәхабә?

— Аңлатып тору кирәкме икән соң?! — дип куйды Сәхабә.

— Адәм балаларына аңлатулар һәрвакыт кирәк булган һәм киләчәктә дә кирәк, Сәхабә!..

— Соң... алайса... Мин, мәсәлән, фанатикларча нәрсәгә булса да табынуга каршы. Һәрнәрсәнең чамасы булырга тиештер... Ләкин мәсьәләнең икенче ягы да бар: Аллаһы Тәгаләнең бөеклеген тану ул һәрдаим булырга тиеш. Шулай булмаган очракта, кайбер адәм балалары иң бөек кодрәт ноктасына үзләрен куярга мөмкиннәр! Һәм калганнар аларга табына башлаячак! Фиргавеннәргә, Патшага табыну, Ленин, Сталин кебекләргә һәм башкаларга Ходайга табынган кебек табыну халыкларны һәлакәткә китерде. Нишлисең, кешенең бер сыйфаты инде бу! Нәкъ менә шуңа күрә дә һәркем белергә тиеш: Ходайдан башка табына торган Илаһи көч юк! Һәм ул көч синең үз күңелең белән тоташкан!.. Һәрбер Адәм баласы шул элемтәне, ошбу бәйләнешне табарга гына тиеш!.. Бер караганда, бик гади югыйсә...

— Гади түгел, монысы иң катлаулысыдыр әле, Сәхаби-Сәхабә?..

Сәхаби дәшмәде, карашын читкә борды. Ләкин бу сорауга җавапсыз калырга мөмкин түгел, Байтимер атап сорый бит, әнә, аннан җавап көтә. Әмма ул, авызын ачып, нинди дә булса фикер әйтер кешегә охшамаган, әйтерсең, алар дөньяга әүвәл кукәй барлыкка килгәнме яки тавыкмы дигән инде монарчы мең кат тапталган нәрсә хакында гына сөйләшәләр. Сөйләшәләр дә, төгәл җавапның очына чыга алмыйча, икесе дә үз күңелләренә бикләнеп, эчтән генә: «Тавык, күкәй? Тавыкмы, күкәйме?» — дип үз алларында кабатлыйлар, аннан соң, ни сәбәпледер, бу сорау кызыксыз булып тоела да (бәлкем, җавабы булмаганга күрәдер?) ахыр чиктә ул хакта оныталар иде.

— Мә, алма аша, — диде Сәхаби һәм алмагач төбеннән бик тәмле булып күренгән кып-кызыл сусыл алма алып бирде. Байтимер соравына җавабы шушы булды бугай?..

— Син дә алма аша, Сәхаби.

— Син дә аша, Байтимер...

— Мин ашыйм...

— Күкләрдән сузылган нур баганасы синең йөрәгеңдә, Байтимер.

— Нинди дә булса зур эш башкару өчен, беренче чиратта, йөрәк кирәк дисеңме? Килешәм... Карале, Сәхаби, син зинһар, болай дип соравым өчен ачуланма: синең кем, кайдан икәнлегеңне һаман белмим бит әле мин?!

— Нигә бу турыда башта ук сорамадың?

— Син хаклы, әлбәттә. Элек мондый сорау бар иде минем башта. Хәтта әтине дә шелтәләдем, белмәгән кешене каравылчы итеп эшкә алгансың дип... Аннан соң... үзеннән-үзе онытылдымы, соңыннан моңа әһәмият бирелмәдеме? Сорамадым инде, кыскасы... Менә хәзер беләсем килә.

— Мин — Адәм.

— Соң... мин дә инде?.. Мин, мәсәлән, хәзер жир биләүче Адәм, фермер-Адәм, алпавыт-Адәм, кем әйтмешли, олигарх-Адәм — байларны хәзер шулай дип атыйбыз бит.

— Ә мин шагыйрь-Адәм...

— Һе!.. Син шигырь язасыңмыни?

— Мин шигырь язмыйм!

— Алайса, ничек була инде ул?

— Мин алдан хәбәр бирүчедер, бәлкем? Гомумән, элек язу хәзерге шикелле

шигъриятькә, прозага яки башкасына бүленмәгән. Шагыйрьләр генә булган. «Шагыйрьләре дә алар артыннан алашканнар барырлар». Ягъни, мәсәлән, үзләренен ялгышлыкларын (элек ялганчы кяферләргә һәм шайтаннарга ияргәннәре) аңлаган — хәзер кяферләрне яманлап язучы шагыйрьләр артыннан тәүбәгә килгән башка алашканнар иярер. Мөхәммәд пәйгамбәр юкка гына дус шагыйре Хәсәнгә: «Сина да Җәбраил фәрештә ярдәм итәр», — димәгән. Аның үзенә дә Коръән ошбу фәрештә аша ингән бит! Димәк ки, Җәбраил фәрештә белән элемтәгә аеруча талантлы булган шагыйрьләр дә керә ала диган сүз түгелме соң бу?

— Игенче иген игә, тимерче тимер чүки, укытучы сабак бирә, шагыйрь шигырь яза!

— Мин синең турыда яздым...

— Минем турыда?! Син мине белмисең бит җүнләп! Мәгәр мин сина үземнең галәмдә кичергәннәрне сөйләсәмме?

— Сөйләмә. Мин алардан да хәбәрдар...

— Ничек?!

— Җәбраил фәрештә ярдәм итте...

— Һе... Җәбраил фәрештә? Мөхәммәдкә сүрә-аятьләр дә Җәбраил фәрештә аша ингән, дип укыганым бар.

— Дөрес укыгансың, Байтимер.

— Һе... кызык һәм гаҗәп булып китте бит әле бу!..

— Әлиф. Ләм. Мим, — дисең бит.

— Әлиф. Ләм. Мим. Ра, Сәхабә!.. Йөрәк кирәк дисең инде, алайса?..

— Йөрәк кирәк дим! Башкалар кебек үк төрки кавем баласы аерым бер балчыктан ясалган. Янадан туу, күтәрелеш чоры башланды. Урыс галимнәре аны төрки-татарның пассионарлыгы, диләр!

Сәхабә карашын күккә төбәде:

— Җир шарының миллион, миллиард еллык тарихы күк катына язылган. Кавем империя оештыра икән, кавемнең үзе кебек, димәк, ул тере организм. Тере организм әүвәл барлыкка килә, туа, яши, аннан соң картая, үлә. Җирдә моның мисаллары күп. Артык маемлаган Рим империясе нәкъ шул хәлне кичерде. Хәзер бездәге империя шул хәлдә. Алтын Урданың һәлакәте дә шуның белән бәйле. Моннан биш гасыр элек нәкъ шул хәлне кичергән төрки-татар кавеме янадан бөре ярды. Ул туды, хәзер көч җыя. Ходай Тәгалә рәхмәте белән, әлбәттә! Шуны бары аңларга гына кирәк.

— Моның өчен тагын ни кирәк була дип уйлыйсың?

— Олы өйдә дә, кечесендә дә акыллы патша булудыр дип беләм...

— Аллага шөкер, алайса! — диде Байтимер. — Ходай рәхмәте белән без үз өебезне житкереп киләбез. Менә бит: агрошәһәрчекнең матур гына яшәп китәсенә башта берәү дә ышанмаган иде. Барабыз...

— Бирсен Ходай! — дип кабатлады аның артыннан Сәхабә. — Илаһы язмаган эш булмас. Кем әйтмешли, өй салуның ние бар, мүклисе дә, чутлыйсы. Хәер, башка юл юк та бит инде... Булса шул Гарасат мәйданына таба гына...

***

Сәхабинең нурлы карашы Адәм пәйгамбәргә (Җирдә бүген ниләр барлыгын бик тә белергә теләгән беренче пәйгамбәрнең инде күптән җәннәттә булган рух-җанына!..) Байтамактагы хәят хакындагы мәгълүматны да яктылык тизлеге белән илтеп житкерде. Хуш, авылым, диде тегесе. Җир тарафына багып... Сау булып тор!.. Чөнки теге заманда, алар Хава белән Җиргә төшерелгәндә, Илаһы кодрәте белән иксез-чиксез галәмдә йөзгән Җир икесе өчен дә бер авыл сыман

гына иде әле!.. Тәүфикъсыз баласының — канлы җинаять кылганнан соң, ата-ана йортыннан качып киткән тәүфикъсыз баласы Кабилнең (нинди генә булса да, барыбер үзеннеке! Бала бала инде — якын!..) — шәҗәрә агачындагы аерым ботагы да, хәзер инде тармакланып, ишәеп, Җир дигән Зур авыл буйлап таралган. Аларның кайберләренең тамырларында әлегә һаман Кабилнең дә каны ага, шул дуамал, хөсет кан кайный. Килер бер заман, кайчандыр берәр буында аның уллары Һабил, Шит пәйгамбәр һәм башка угланнары, онык-оныкчалары каны да өстенлек алып, алары да яңадан ерак бабалары иманына кире әйләнеп кайтырлар!.. Нәселдәнлек Ходай Тәгаләнең бөек сере ләбаса! Әллә ничә мең дистә еллардан соң да берәр буында ерактан-ерак бабаларның каны калкып чыгып, өстенлек итә башламас дип кем әйтә ала?! Нурлы фәрештәләр дә һаман үз гамәлләрендә бит әле!

Кинәт чыккан җил күк йөзендәге нәкъ Гарасат төтененә охшап торган болытларны Көнчыгышка таба куып алып китте. Аларның бер өлеше, Аляскалар аша үтеп, океан артындагы төньяк материкка таба юнәлде. Чөнки алар бу якка башка тарафлардан (Гыйрак, Ливия, Сүрия, Фәләстин, Әфган һ.б. илләр урнашкан кыйтгада бомбалар шартлаудан хасил булган төтен) шул ук җил канаты белән куып китерелгән болытлар иде... Коперникка чаклы йөз илле ел алдан «Җан мәхәббәт көчен таныды, Җир Кояш тирәли әйләнгәндә...» дип язган Алтын Урда шагыйре төрки-татар Сәйф Сараи мең тапкыр хаклы. Җир Кояш тирәсендә һәм үз күчәрендә өзлексез әйләнеп торганлыктан, Җил җилкәне болытларны кыйтгалар буенча әрле-бирле куып йөртә, шунлыктан Гарасат төтененнән укмашкан авыр, кара болытлар өчен күктә чикләр юк иде. Хәер, моннан соң җил кайсы яктан исәр инде... Киләчәктә җилләр кай тарафлардан исәрләр бит әле!..

Ә Байтамакта исә халык ел саен, җирләр язгы кардан ачылуга, күмәкләшеп, үзләренә тәгаенләнгән фермер җирләреннән, инкыйлабка чаклы Хәсән байның кишәрлекләре булган җир куенынннан алтын эзләү белән мәшгуль иделәр. Яз җитүгә, алар, җирне казу-сөрү эшенә керешеп, бу юлы алтын-мазар таба алмагач: «Ярый, кайгырмыйбыз! Ходай икенче елга табарга ярдәм итәр ул хәзинәне!» дигән өметләр белән, эшкәртелгән, ашланган әзер җирләргә иген йә башка нигъмәтләр чәчәләр. Көзләрен мул уңыш алып, амбарларын тутыралар! Ә хәзинәне табарлар!.. Аллаһы боерса, барыбер бер тапмый калмаслар!.. Җир астында аларга җитәрлек алтынның карасы да бар бит әле — аңа да халык хуҗа булыр бер көнне... Ул хәзинәне балаларына, оныкларының оныкларына дип тә сакларлар... Өметсез шайтан гына була ди бит! Ә алар кешеләр, алар адәм балалары, алар бөек төрки кавемнең иң асыл шәҗәрә агачындагы кодрәтле тармакны дәвам иттерүче бик гаярь һәм хезмәт сөючән, борынгы, затлы пассионар бер нәсел иде...

Сәхабә-Сәхаби атлы Адәм баласы алма бакчасында һаман каравылда тора иде әле...

Көтүче сарыкларны Байтамак астындагы Гарасат үзәненә туплады. Монда үлән мулдан иде.




*Муса Җәлил һәм очучы-шагыйрь Салих Баттал.
Мәскәү. 1935 ел.*



*Әбрар Кәримуллинның
солдат чагы.
Порт-Артур.1946 ел.*



*Татар әдәбияты һәм сәнгате вәкилләре Донбасста шахтёрлар белән бергә. Алгы рәттә, уртада — М.Фәйзуллина, Г.Минский, алар артында, икенче рәттә – Г.Ахунов, А.Арсланов. Ворошиловград (Донецк). 1972 ел.*



*Күргәзмә залында. Сулдан уңга: Бакый Урманче, Нәкый Исәнбәт, Миркасыйм Госманов, Васил Маликов. 1982 ел.*



*Республика матбугаты ышанычлы кулларда. «ТАТМЕДИА» ААҖ генераль директоры Фәрит Илдус улы Шаһиәхмәтов Татарстан район-шәһәрләренең җирле массакүләм мәгълүмат чаралары җитәкчеләре белән. 2014 ел.*

# АЯЗ ГЫЙЛӘҖЕВ ҺӘМ ЧЫҢГЫЗ АЙТМАТОВ

*Борынгылар: «Әгәр атаң акыллы зат булган булса, аны белгән кешеләр исән һәм гомерле булсын дип телә», — дип юкка әйтмәгәннәр. Очраклы әйтелгән сүзләр түгел бу. Хәтер үлгәннәрнең гомерен озайта. Истәлек-хатирәләр исәннәргә авыр югалтуларны җиңелрәк үткәреп җибәрергә мөмкинлек бирә. Хатирәләр — әрнү-сызланулар һәм үткәннәрнең чынлыгын раслау ул.*

Ч.Айтматов.

*Аерым кешенең хәтере — ялгыз агач ул, аны үтмәс балта белән дә кисеп ташлап була. Халык хәтере — мәгърур карурман шикелле, кисеп чыксаң — орлыктан шытачак, яндырып үзсаң — тамырдан калкачак. Урманның гомерен йөзәр яшьлек имәннәр ныгыткан кебек, халык хәтерен ныгыта, оештыра торган уртак хәзинәләр кирәк.*

А. Гыйләҗев.

Чыңгыз Айтматов (1928-2008) һәм Аяз Гыйләжев (1928-2002) — татар халкының чиксез горурлыгы, мактанычы, йөзек кашы. Татарстан Республикасында Чыңгыз Айтматовны ике тугандаш халыкның — кыргыз һәм татар халыкларының улы дип исәплиләр. Язучының әнисе — Нәгыймә Абдулвәлиева — татар хатыны, килеп чыгышы белән Кукмара районына нисбәтле. Мәкаләдә А.Гыйләжевнең Ч.Айтматов шәхесен һәм иҗатын кабул итү-бәяләү үзенчәлеген ачу күздә тотыла[1].

Исән вакытта ук классик саналган әлеге ике язучының тормыш юлларында уртак яклар аз түгел. Бер үк елны туган әдипләрнең иҗат биографияләре, тамырлары нәсел җепләренә барып тоташа. Килеп чыгышлары белән алар һәр икесе атаклы, билгеле татар нәселләренә мөнәсәбәтле. Ч.Айтматовның әнисе ягыннан туганнары XIX гасырдан алып Татарстанның Кукмара районында гомер сөрә. Аларның Мәчкәрә авылында ике мәчет төзүләре мәгълүм. Язучының бабасы Хәмзә Абдулвалиев беренче гильдия татар сәүдәгәре була. XIX йөзнең 70 нче еллары ахырына таба ул абыйсы Әхмәтгали һәм апасы Галия белән туган якларын ташлап чыгып китә. Аларның сәүдә юлы Урта Азия аша үтә. 1928 елның 12 декабрендә Фрунзе шәһәрендә (Таласск өлкәсенең Шөкер авылында) Хәмзә Абдулвалиевның оныгы туа, аңа Чыңгыз дип исем кушалар. Кукмара районында урнашкан зиратта бу атаклы нәселгә нисбәтле берничә кабер ташы сакланган. Мәчкәрә авылында язучының бабалары туган нигез, йорт әлегәчә исән.

А.Гыйләжевнең нәселенә Бикчура хан нигез сала. Нәселнең чишмә башы Габдеррәхман бине Туймөхәммәдкә (1691-1763) барып тоташуы хакында документлар сакланган. Р.Фәхретдиннең «Асар» хезмәтендә ул Бөгелмә өязенең беренче ахуны һәм Дала Зәе елгасы буенда урнашкан (хәзерге Татарстан Республикасының Әлмәт районы) Тайсуган авылында бу өлкәдәге беренче мәдрәсәгә нигез салучы дип искә алына. Аның улы Габделмәннән бине Габдеррахман (1756-1828) туган авылында имам һәм мөдәррис була. Улы Корбангали беренче Юрт башкорт гаскәрендә старшина, Башкорт волосте Уфа губернасы Минзәлә өязенең Нөркәй авылына (хәзерге Сарман районының Зур Нөркәй авылы) күчә. Корбангалинең улы Мөхәммәтрәхим (1805 елда туа) мөәзин була. 1837 елның 8 гыйнварында аның Гыйләжетдин исемле улы дөньяга килә, нәсел фамилиясенең килеп чыгышы шул исемгә тоташа. Шул рәвешле, А.Гыйләжевның бабалары XIX йөздән XX йөз

[1] Хезмәттә Д.Гарифуллин, Р.Фәхреддин, А.Әсфәндияров, А.Гыйләжев, Н.Вәлиев, И.Гыйләжев, Я.Юферова, М.Агишев, Д.Вәлиев, Г.Ахунов, М.Хуҗин, З.Зиннуров, Ч.Айтматов, Ф.Кутлу, Й.Каләндәр, Б.Җошкун хезмәтләре файдаланылды.

башына кадәрге аралыкта хәзерге Татарстанның көньяк-көнчыгышында имам һәм мөдәррис буларак хезмәт итәләр.

Гыйләжетдин Сарман мәчетендә имам булып тора. 1885 елда ул гаиләсе белән Төркиягә күченеп китә. Рәсәйдә аның бер генә улы кала, ул — А.Гыйләжевнең бабасы Сәхәбетдин. Сәхәбетдин алты ел дәвамында чит җирдә — Кавказда патша армиясендә полк мулласы вазифасында хезмәт итә, шул сәбәпле ул туган җирендә калуны кулайрак күрә. Нәселнең соңгы имамы 1861 елда дөньяга килгән Сәхәбетдин бине Гыйләжетдин Минзәлә өязенең Шыгай авылы мәдрәсәсендә (хәзерге Сарман районының Шыгай авылы) белем ала. Бу мәдрәсә XVIII йөзләрдән үк тирә-якта иң билгеле мәдрәсәләрнең берсе булып тора. Мәдрәсәгә Мөхәммәдшәриф бине Сөләйман (1780 елда вафат) исемле шәех нигез сала. Оренбургта руханилар җыенында имтихан тапшырып, Сәхәбетдин 1891 елда Мортыш-тамак авылында имам-хатыйп булып тору өчен указ ала (№5115 шаһәдәтнамә, 1891 елның 7 октябре). Оренбург мөселманнары журналының 1906 елгы санында Сәхәбетдинне Сарман авылының 4нче мәчете имам-хатыйбы итеп билгеләү турында кечкенә генә язма бар *(Гилязов И. «Отец был человеком ищущим» [Интервью А.Егорова] // Казанский альманах. — Казань: Татар. кн. изд-во, 2009. — С.141-143).* Шул рәвешле ул ин ярлы «Ак ыштанлылар мәхәлләсенең» имамы вазифасын башкара башлый. А.Гыйләжев мәхәллә исеменең килеп чыгышын болай аңлата: Сәхәбетдин карт Сарманда бер бәләкәй генә мәчет салдырган. Ул бик ярлы мәхәллә булган. «Ак ыштанлылар» мәхәлләсе дип йөрткәннәр аны, чөнки мәхәллә картлары, мәчеткә барганда, чалбар кимәгәннәр. Шул ак ыштаннарыннан башка киемнәре дә булмаган. 1887 елда Сәхәбетдин өйләнә. Ул биш бала үстерә: Нурлыхода, Бибиәсма, Әнвәрия, Мәхүбрахман һәм А.Гыйләжевнең әтисе Мирсәет.

1937 ел Чыңгыз Айтматов биографиясендә дә эзсез узмый. Ч.Айтматов «халык дошманы» улы булып исәпләнә. Кыргызстан ССРның күренекле дәүләт эшлеклесе Торекул Айтматов 1937 елда кулга алына, 1938 елда атып үтерелә. «Правда» газетасында милли интеллигенциянең буржуазия белән мөнәсәбәте турында сүз кузгатылгач, кызыл профессура институтының тыңлаучысы Т.Айтматов фамилиясе дә атала. Гаилә башлыгы бәла киләсен аңлап, тиз арада гаиләсен Мәскәүдән туган ягына (Сталин шымчылары күзеннән ераграк) җибәрергә карар кыла. Ч.Айтматов 1936 елның 1 сентябрендә Казан вокзалында гаиләсен озаткан вакытта әтисенең поезд артыннан йөгерүен гомерлеккә күнеленә сеңдерә. Бу вакытта ул 2 нче сыйныфка укырга барырга тиеш була. Ата кеше үзен ни көтүен ачык белә. Гаиләсен шулай саклап кала. Ч.Айтматов «Ана кыры» повестен ата-анасының якты истәлегенә багышлый, аларның рухи батырлыгына дан җырлый. 1994 елда Чыңгыз Айтматов әтисенең калдыкларын йола буенча кабергә иңдерә. Ата һәм улның каберләре бүген Бишкәк каласы янында «Ата-Бейит» каберлегендә яшәшә.

А.Гыйләжев алты ел төрмә-лагерьда газап чигә. Ни хикмәт, үз сүзләре белән әйткәндә, төрмә-лагерьлар аны язучы итә. Башыннан кичкәннәрне ул «Эзләремне эзләдем» истәлекләрендә, «Йөгез, бер дога!» романында сурәтли.

КПССның XX съезды Ч.Айтматов һәм А.Гыйләжев кебек бик күпләргә «яшел юл» ача. 1956 елда кыргыз язучысы Мәскәүгә китә. Әдәбиятчы Азиз Салиев сүзләренә караганда, Ч.Айтматов филология факультетына укырга керергә ниятли, әмма «халык дошманы» улына анда ишекләр ябык булып чыга. Укытучысы киңәше белән ул Мәскәүдә Горький исемендәге Әдәбият институтында махсус филологик белемнәре булмаган язучылар өчен оештырылган икееллык курсларда укый. Сонрак Ч.Айтматов, үзе турында сөйләгәндә, Мәскәүгә китеп, Югары әдәби курсларга укырга кермәгән булсам, язучы була алмаган булыр идем, дип еш кабатлый.

А.Гыйләжев 1956 елның 13 февралендә аклана. Ирекккә чыккач, Казанга кайтып, зур авырлыклар белән университетта укуын дәвам итү мөмкинлегенә ирешә. Бу чорда кечкенә күләмле хикәяләр яза, журналга аларны булачак хатыны Н.Гыймадиева исеме белән тәкъдим итә. Ч.Айтматов һәм А.Гыйләжев әдәбиятта беренче адымнарын авыл тормышы, җир кешесе турындагы хикәя, повесть һәм очерклардан башлыйлар. (Ч.Айтматов — «Газетчик Дзюйдо», «Ашим», «Мы идём дальше», «Лицом к лицу» (1953); «Трудная переправа» (1956); «Ночной полив» (1958); А.Гыйләжев — «Дүртәү» (1958), «Качак» (1959), «Берәү» (1958-1959)).

1961 елның сентябрендә А.Гыйләжевка Югары әдәби курсларга китәргә тәкъдим итәләр. Язучы өчен бу «күктән төшкән көтелмәгән бәхет» була. Ч.Айтматовның әсәрләрен укып рухланган А.Гыйләжев Н.Әсәнбаевка Югары әдәби курсларга язучының үзе белән танышыр өчен килгәнлеген әйтә. Алтмышынчы елларда ук А.Гыйләжев «үз иҗатында нәкъ менә халык тормышын чагылдырган юнәлешне алып баручы» (Ф.Кузнецов) яшь кыргыз язучысының әдәбият классигы булып китәчәген фаразлый.

Ч.Айтматов һәм А.Гыйләжев рус әдәбияты мәйданына А.Солженицын, А.Твардовский, Ф.Абрамов, В.Распутин, В.Астафьев кебек исемнәр килеп кергән «җепшеклек» дулкыны дәверендә бөтенсоюз күләмендә популярлык казаналар. Бу дәвер әдипләрен туган илгә, ватанга бирелгәнлек, туган халкына мәхәббәт, яшәп килүче идеология турында хакыйкатьне әйтү омтылышы берләштерә.

Әдәби текстта романтик һәм реалистик катламны матур үрә белгән, милли проблематиканы гомумкешелек яссылыгына алып чыккан нечкә психолог һәм реалист Ч.Айтматовның даны «Җәмилә» (1958) «Гүзәлем, Әсәл» (1961) повестьларыннан башлап дөньяга тарала. «Җәмилә» әсәрен Луи Арагон яратып укый, француз теленә тәрҗемә итә. А.Гыйләжевнең исеме Рәсәй халыкларына 1964 елда — «Өч аршын җир» повесте рус телендә дөнья күреп, «Дружба народов» журналының махсус бүләгенә ия булганнан соң мәгълүм була. Язучылар өчен кыргыз һәм татар авылы илһам бирүче урын булып тора башлый. Чыннан да, «Җәмилә» повестеннан соң дөнья яна талант белән генә түгел, Кыргыз Республикасы белән дә таныша, бу хакта А.Гыйләжев хатларында һәм публицистик хезмәтләрендә еш әйтә. Татар әдибе Ч.Айтматовның төп казанышы кыргыз халкын дөнья аренасына чыгаруда дип бәяли. Айтматов укучысын үзе туган җиргә гашыйк иттерә. А.Гыйләжев әдипне Шәрык фәлсәфәсен һәм Гареб мәдәниятен тоташтыручы дип тә күрә.

XX йөзнең икенче яртысы татар прозасының язмышы хакында уйланып, «Казан утлары» журналының бүлек мөхәррире М.Вәлиевкә язган хатында (1982 елның 10 марты) А.Гыйләжев XX йөз башында татар әдәбиятын Г.Тукай, Һ.Такташ, Ф.Әмирхан, М.Галәү, Ш.Камал мөмкин булганча иң югары дәрәҗәгә күтәрәләр, дип горурлануын житкерә. XX йөз башы әдипләре дөньяны татар халкы, аның мәдәнияте, тарихи язмышы белән таныштыралар, әмма XX йөзнең икенче яртысында татар әдәбияты төрки әдәбиятлар арасында әйдәп баручы булудан туктый. А.Гыйләжев татар әдәбиятында Ч.Айтматов, Н.Думбадзе, В.Быков кебек «хәзерге прозаның гулливерлары» булмавына борчылуын белдерә.

«Әдәбият-сәнгать күге айсыз йә кояшсыз була алмый. Ай яки кояш булмаса, адәм баласы күккә үрелеп карамый да дип беләм. Караса да, чуарлыктан башка берни күрми, йолдызларны исемләп аермый. Әдәбият та тоташ чуар күк ул, аны җанлы итәр өчен ана исемнәр — ай-кояшлар кирәк. Чыңгыз Айтматов дибез икән, бу исем һәркемгә мәгълүм. Ул барында кыргызның күге күк, гади укучы кыргыз әдәбияты тоташ шундый югарылыкта дип ышана, шулай дип белә. Әгәр әдәбиятта шундый югарылыктагы лидер юк икән, әдәбият гел талантлардан гына торса да, гади укучы аны бер чакта да санламый. Безгә дә шундый лидер кирәк иде. Үзебезнең әдәбиятның данын читләргә алып чыгарлык Тулы вәкаләтле әдәбият илчесе кирәк иде. Кем ул?.. Бу уй мине менә чирек гасыр инде борчый, тетрәтә»,— дип А.Гыйләжев көндәлекләрендә теркәп куя (1986 елның 21 марты).

Татар әдибе замандашын бөек рухлы кеше дип исәпли. Көндәлекләрендәге бер язмага игътибар итик: «Әйе, язучылар съезды тәмам. Делегатлар арасыннан ике кешенең чыгышы турында сүз бара: Чыңгыз Айтматов һәм Константин Симонов. Беренчесе — әдәбиятыбызның бүгенге торышы белән, икенчесе тормышның бүгенге агышы белән асла риза түгеллекләрен белдергәннәр. Хәзерге түбәнлек, күрмәсезлек, җаһиллык, комсызлык, җасуслык чорында шул сүзләрне халык алдында әйтү — егетлек. Тиле кеше чыгып акырырга мөмкин, ана колак салмаслар. Эш күрсәткән ирләр сүз әйтә ала икән, бу инде уен түгел. Менә нәрсә мөһим!»

Ф.Бәйрәмовага юллаган хатында (1983 елның 29 ноябре) А.Гыйләжев күпмилләтле Россиядә Ч.Айтматовтан рухи көч алучы халыклар күп, дип билгели: «Евтушенко шушы арада гына чыккан мәкаләсендә «Чыңгыз Айтматов чорны «геологик разрезда ала», дип язды. Тапкыр әйтелгән. Җирнең тирәнлеген җиде метр күрергә өйрәнмәгән шул без! Югыйсә манкортларның җәмгыятьтә бер катлау булып ныгуларын күрә

алган булыр идек. Ә Чыңгыз күргән. Жае килгән саен, Чыңгыз иҗатына кизәнә килгән Мөдәррис Мусин да манкортның беренче сорты ич. Тукай клубындагы мәгълүм җыелышта ул Чыңгыз Айтматовны «бары тик популяр язучы гына!» дип исбатларга бик тырышты. Янәсе, вакытлар үтүгә үк ул онытылачак, популярлык вакытлыча гына, имеш, бер көнлек! Хәзер үк чамалап була: кем калыр да кем онытылыр. Чыңгыз — илебездәге бөтен халыклар рухына көч биреп торучы кеше ул! Бигрәк тә аның соңгы әсәре «Буранлы Едегәй» безне сискәндереп уйландырды».

Кыргыз язучысы «генеологик хәтернең» бүгенге халәтен генә күрсәтү яисә бу хактагы борынгы бәянне (притчаны) искәртү белән генә чикләнми, яңадан тергезелгән легенда эчтәлеген фәлсәфи катлам белән дә баета, тулыландыра. Райфә исемле укучыга язган хатында А.Гыйләжев «Җомга көн, кич белән...» повесте героинясы Бибинурның балаларын Ч.Айтматовның «Бер көн — бер гомер» романындагы манкортлар белән чагыштыра: «Куркыныч кешеләр алар, илсез, телсез кешеләр. Ч.Айтматовның «И дольше века длится день» дип аталган атаклы романында Манкорт образы бар. Бибинурның балалары күренеп үк китмәсәләр дә, әнә шул Манкортның кан кардәшләре инде... Сүз менә нәрсә турында бара...

Ш.Рәкыйповка атап язган хатында (1980 елның 25 октябре) язучы үзенең татар әдәбиятының Ч.Айтматовы була алмавына борчылуын белдерә. А.Гыйләжев татар әдәби тәнкыйтенең торышы белән канәгать булмый, югары гыйлемле, әзерлекле тәнкыйтьчеләр, үзгә югарылыктагы әдәби-мәдәни мохит хакында хыяллана. Аның карашынча, укучы язучыны яңа иҗат үрләренә дә рухландыра, аның киләчәген дә билгели: «Әгәр «Җәмилә» повестен Луи Арогон күреп яратмаса, Чыңгыз Айтматовның әдәби язмышы ниндирәк булыр иде икән? Әлбәттә, Чыңгызның русча иҗат итүе дә аның язмышын билгеләгәндә ярдәм итмәде түгел. «Җәмилә», «Дөя күзе», «Беренче мөгаллим» кебек традицион, гадәти повестьлар авторы берзаман дөнья кинлегендә «Елга тиң сузылган көн» («Бер көн — бер гомер»—*ред.*) дигән мәшһүр романын иҗат итте. Кыюсыз гына башлаган Чыңгыз — дөнья мәйданына чыкты. Арогон биргән бәя аның рухына бәрәкәтле юл ачты».

А.Гыйләжев «Өч аршын җир» повестен язганнан соң, никадәр михнәтләр чигәргә туры килгәнлеген искә ала: «Әгәр «Өч аршын җир» повесте дә үз вакытында тиешле бәясен алып, рухымны киңәйтеп, мәсләгемне ныгытып җибәрсә, мөгаен, минем дә әдәби язмышым бүтәнчәрәк булыр иде. Ә әсәрне татар тәнкыйтьчеләре тетеп салдылар. Рух күтәрергә кирәктә бердәмләшә алмаган татарлар, сытып ыргытырга дигәндә кинәнеп, явызланып бергә тупланалар».

«Литературная газета» битләрендә Ч.Айтматовның «Бер көн — бер гомер» романыннан өзек дөнья күргәннән соң, А.Гыйләжев мифопоэтиканың үзенчәлекләре турында уйлана башлый. М.Галиевкә язган хатында әдип Ч.Айтматовның милли фольклорны тирән белүенә сокלануын җиткерә, шунда ук татар язучыларының халык авыз иҗаты җәүһәрләрен саксыз һәм урынсыз куллануына борчылуын да белдерә. А.Гыйләжев замандашларына әдәби әсәрләрдә татар халкының этник төркемнәрен — керәшеннәрне, мишәрләрне, урал татарларын тасвирлап язарга өндәп мөрәҗәгать итә. Чыннан да, «язучы тарафыннан эшкәртелгән милли образлар, элементлар (мифлар, ышанулар һәм интонацион стильләштерү) Айтматов әсәрләрендә «өстәмә бизәк», орнамент кына булып калмыйча, әдәби текстның эчке көенә ярашлы үзенчәлекле гаҗәеп бай дөнья хасил итәләр. Бу дөнья иң элек герой күңелендә барлыкка килә, геройның эчке дөньясы үз эченә буыннар хәтерен дә, бүгенге рухи кыйммәтләрне дә сыйдыра, аның уйларында киләчәккә бәйле өмет-хыяллар да, борчулар да — һәммәсе дә көзгедәге кебек чагылыш таба» *(Юферова Я. Реквием улетающей стаи // Российская газета. — 2008. — №4687. — 19 июня).*

Хат һәм көндәлекләрендә А.Гыйләжев күп тапкырлар икетеллелек проблемасы хакында уйлана: «Соңгы елларда безнең әдәбиятка килгән төркемне генә кара син: Рөстәм Кутуй, Диас Вәлиев, Әхәт Мушинский, Фәридә Рәсүлева (Атилла Расих кызы). Мин аларның русча язуларына рәнҗемим, язсыннар, бик яхшы, тик асыл максатлары — татар халкына хезмәт итәргә тиешле булуларын гына онытмасыннар! Чыңгыз да русча яза, Фазыл Искәндәр дә, Тимур Зульфикаров та, башка бик күпләр рус телендә иҗат итә. Өлкә богавыннан котылыр өчен, үзем дә русча язар идем, кулымнан гына килми! Ләкин Чыңгыз һаман к ы р г ы з язучысы, ул үз халкын дөнья мәйданына алып

чыкты», — дип яза әдип. Шул рәвешле, А.Гыйләжев әсәрнен кайсы телдә язылганлыгы әһәмияткә ия түгел, иң мөһиме — иҗат җимешенең милли рух белән өретелгәнлеге, дип тәкрарлый. Әгәр язучы бу принципка хыянәт итсә, аны манкорт язмышы көтә, дип фаразлый ул. Бу фикерен улы Мансурга язган хатында да искәртә: «Русча язуын бер дә начар түгел, русча язып та үз халыкларының улы булып кала алган бик күп гүзәл кешеләрне беләбез, шул ук Чыңгыз Айтматов русча яза, Фазыл Искәндәр, И.Друце һ.б. Русча язу — заманча, аннан бер дә читенсенергә ярамый. Тик син кайсы халыкка хезмәт итәргә телисең — монысын беренче авазданук ачыкларга иде!..»

А.Гыйләжев кыргыз язучысының һәр уңышына ихлас сөенә. Замандашлары әлеге ике әдип иҗатындагы уртак якларга һәрдаим игътибар итәләр. «Милли характер һәм халык язмышы, милли тарих барышы — менә дөнья әдәбиятының төп сюжетлары. Кулыма латинамерикалы әдип Маркес романы мисырлы Йосыф Идриси, япон язучысы Ясунари Кавабата, төньяк америкалы Фолкнер, кыргыз әдибе Чыңгыз Айтматов, татар язучысы Аяз Гыйләжев әсәрләрен алуга, мин аларда уртак бер җыр ишетәм...» — дип яза Д.Вәлиев «Мәхәббәт чүкече» исемле мәкаләсендә.

Г.Ахунов А.Гыйләжевның «Урамнар артында яшел болын» романы, «Язгы кәрваннар» повестьларының Ч.Айтматов әсәрләре белән аваздашлыгына игътибар итә. Шунда ук А.Гыйләжевнын әлеге әсәрләре танылган әдипнең әсәрләренә караганда иртәрәк язылганлыгын искәртүне тиеш таба. М.Хуҗин истәлек-хатирәләрендә тәнкыйтьчеләрнең А.Гыйләжевның «Язгы кәрваннар» повестеның Ч.Айтматовның «Иртәләгән торналар» әсәре белән охшашлыгын күрсәтүләрен яза. Ни сәбәпледер, М.Хуҗин татар повестеның өч ел алдан язылуына һәм басылуына игътибар итүне кирәк тапмый.

Г.Ахунов язмаларының берсендә болай дип билгели: «Аяз Гыйләжев иҗаты — көрәшче иҗат. Ул беркайчан да такыр юлдан бармады. Рәхмәт әйтсен, тоталитар система заманында Гарәф Шәрәфетдинов, үзенә авырлык алып булса да, аның китапларын бастырып килде. Юкса партия өлкә комитеты җитәкчеләре Аяз каләмдәшебезнең язган һәрбер әсәреннән гаеп эзләделәр. «Өч аршын җир» белән «Язгы кәрваннар» кире яктан мисалга алындылар. «Күзгә-күз» повестена карата аның каләмдәшләре газит аша погром оештырды. «Югалган бер көн» пьесасы буенча Казанның урыс Зур драма театры куйган спектакльгә өлкә комитеты секретаре ничек ярсып ташланды. Мин язучыларның рәисе идем ул чакта, әлеге спектакльне яклагач, секретарь мина да: «Хватит!» — дип кычкырган иде. Хәтеремдә әле, Каракалпакстанда Аяз, ишәкне кочаклап: «Синең дә, минем дә бер бүләгебез дә юк. Этләргә, күргәзмәдә катнашып, койрык болгаган өчен, медаль тагып җибәрәләр», — дип елаган иде. Сабыр иткән морадына җиткән, ди бабаларыбыз. Мин рәис булып эшләгәндә, ул Татарстанның Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә (1983) лаек булды. 1987 елда аңа әдәбият өлкәсендәге уңышлары өчен РСФСРның Дәүләт бүләге бирелде. «Йөгез, бер дога!» романы һәм күпьяклы җәмәгать эшчәнлеге өчен ул Гаяз Исхакый бүләген алды. 1993 елның декабрендә аңа Халык язучысы дигән дәрәҗәле исем бирелде».

Әдипнең архивында татар телендә басылган «Ч.Айтматов повестьлары» китабына рецензия саклана. А.Гыйләжев кыргыз язучысының повестьларын рус теленнән татар теленә тәрҗемә иткән биш тәрҗемәченең хезмәтен бәяли. «Анам кыры» повестеның Я.Халитов тәрҗемәсен анализлап, А.Гыйләжев тәрҗемәченең язучы сүзенә сак мөнәсәбәтенә игътибар итә, телгә бәйле аерым төгәлсезлекләрне дә күрсәтә. «Беренче мөгаллим» повестен Ә.Еники тәрҗемә кыла. А.Гыйләжев татар әдәбиятының классигы Ә.Еникине оригинал текст белән иркен эш йөртә, дип тәнкыйтьли. Тәрҗемәдә автор текстының структурасы һәм стиле үзгәрүгә канәгатьсезлеген белгертә. Х.Сарьян «Гүзәлем, Әсәл» әсәрен тәрҗемә итә. А.Гыйләжев тәрҗемәче әсәрнең исеменә салынган көйне тоймый, дип әрни, текстларны укудагы төрлелекне шуңа бәйли. Рецензент диалогларның еш кына русча яңгыравын да әйтми калдырмый. Авторның диалектизмнарны куллануын да А.Гыйләжев уңай бәяли, аларга астөшермәләр бирергә тәкъдим итә. А.Гыйләжев Х.Сарьянга кабатланган өлешләрне анализлап, текстны кыскартырга да киңәш бирә. М.Госмановның «Җәмилә» повестен тәрҗемә итүен беркадәр кыенлык белән бәяли. Шул ук вакытта А.Гыйләжев тәрҗемәченең кыргыз телендәге оригинал белән эшләвенә уңай мөнәсәбәтен белдерә. М.Госманов тәрҗемәсендә кайбер эпизодлар татар телендә русча вариантка караганда тәэсирлерәк

һәм отышлырак янгыравын искәртә. Ш.Садыйковның «Дөя күзе»н тәрҗемә кылуын А.Гыйләҗев тискәре бәяли. Уңышсызлыкның сәбәбен тексттагы этнографик материалны төшереп калдыруга бәйли, шул сәбәпле бу хезмәтне басмага тәкъдим итми.

Улы — яшь драматург Мансур Гыйләҗев белән берлектә А.Гыйләҗев Г.Камал исемендәге ТДАТта куяр өчен Ч.Айтматовның «Ахырзаман» романының сәхнә вариантын әзерли (1987, режиссёр Д.Сиражиев). «Ахырзаман» спектакле озак еллар дәвамында сәхнәдән төшми уйнала.

З.Зиннуров үзенең истәлекләр китабында замандашларыннан Ч.Айтматовның А.Гыйләҗевның «Өч аршын җир»ен укыганнан соң әйткән сүзләрен еш ишетүен белдерә: «Миңа үземнең танылу алган әсәрләрем өчен оят». А.Гыйләҗев осталыгын бәян итү өчен шул сүзләр дә җитә. 2008 елны «Мәгариф» нәшриятында «Мир татарской литературы» сериясенең А.Гыйләҗев әсәрләреннән торган беренче томы әзерләнгән вакытта, Ч.Айтматовның кереш сүз язарга алынуы һич тә очраклы түгел. Әдәбиятның чын остасы, корифее әлеге сериягә фатиха бирә (кереш сүз 2008 елның 12 мартында Брюссельдә языла).

Ф.Кутлуның хәерхаһлы тәрҗемәсендә «Өч аршын җир» повесте Төркиядә инде 4 (!) тапкыр нәшир ителә, узган елны төрек укучысы «Җомга көн, кич белән...» повесте белән таныша. Төрек әдәбиятчылары һәм тәнкыйтьчеләре татар язучысы әсәрләренә бәя биреп, монарчы төрки дөньяга мәгълүм бер генә мәгърур затны — Ч.Айтматовны гына белүләрен, А.Гыйләҗевның мирасы шундый ук дәрәҗәдә бөек икәнлеген ачуларын еш билгелиләр. Й.Каләндәр үзенең рецензиясендә болай яза: «Өч аршын җир» повестен укыган вакытта, мин, ихтыярсыздан, Ч.Айтматовның «Бер көн — бер гомер» романының кайчан язылганлыгын искә төшердем. Һәр ике әсәр күңелемне кузгатты, йөрәгемне яулап алды. Һәр ике әсәр совет режимын тәнкыйтьләүне алга куя. Ләкин, «Өч аршын җир» повесте 18 ел алдан, совет режимы чәчәк аткан дәвердә үк язылган булып чыкты, ә бу авторга карата аерым ихтирам уята, без аның кыюлыгына һәм рухи батырлыгына сокланабыз». Б.Җошкун фикеренчә, А.Гыйләҗев үзенең повестенда татар милләтенең фаҗигасен тасвирлый, дөньяга үз халкының сурәтен тәкъдир итә. Төрек укучысы XX йөздә татарларның уй-хисләрен, әрнүләрен тоя алды. Әсәрнең төп кыйммәтен әнә шул билгели.

Чыңгыз Айтматов язучы М.Ауэзов хакында болай яза: «Еллар узгач, яшәешнең алыштыргысыз кануны булуына төшенәсең — «бар да үтә, бар да үзгәрә», буыннар хәтерендә саклanучы исемнәрне дә аямый икән. Вакыт алар өчен дә уза, ләкин алар безнең аңыбызда, күңел төпкелләребездә яшәүләрен дәвам итә, димәк ки, алар өчен тарих та дәвам итә булып чыга. Вакыт гаҗәеп кызыклы, бик үк күңелле дә булмаган, ләкин беркайчан да үзгәрми торган бер сыйфатка ия: ул һәрнәрсәне үз урынына утырта, үткәннәргә, билгеле бер чордагы ышану-мавыгуларга, теге яисә бу вакыйгага карата рәсми һәм шәхси карашларга төзәтмәләр кертә. Мин шул мәгънәне күз алдында тотам. Аеруча әдәбиятта, сәнгатьтә, әдипләр һәм әсәрләр язмышында бу закончалык бик эзлекле һәм үтә дә кырыс саклана. Чөнки вакыт хөкеме үз эченә буыннар хәтеренең яна баскычын, үсеш-үзгәрешне тану-аңлау өчен кирәк булган яңа бәяләү бизмәнен ала. Вакыт көче — шул тарихи чынлыкның үзе инде ул, көндәлек тормышта без аны гаделлек дибез» *(«Ауэзов турында», 1978)*. Бу юллар, Чыңгыз Айтматов вафатыннан соң, үзе турында, үз иҗатының язмышы турында уйланулар кебек кабул ителә.

Чыннан да, иң гадел хөкем — вакыт сынавы ул. Ч.Айтматов һәм А.Гыйләҗев исемнәре милли әдәбият күгендә генә түгел, дөнья әдәбияты күгендә дә балкып яна, еллар үтү белән, алар калдырган мирасның кыйммәте тагын да арта. Ч.Айтматов һәм А.Гыйләҗев — милли һәм дөнья әдәбиятлары үсешенә зур йогынты ясаган, халыклар арасындагы дуслыкны ныгытуга үзләреннән бәһаләп бетергесез өлеш керткән әдипләр. Ничәмә-ничә буын аларның әсәрләрен укып рухлана, тәрбияләнә. Ике бөек әдипнең әсәрләре ярдәмендә бөтен дөнья халыклары кыргыз һәм татар халкының рухи дөньясы, мәдәни мирасы белән таныша.

**Миләүшә ХӘБЕТДИНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты,*
*КФУ доценты*

# «КӨТӘМ СИНЕ»


«Сүз – жырның умыртка баганасы, көй – жырның рухи җаны. Моңлы тавыш – жырны бишегеннән алып, тәпи бастырып, дөньяга таратучы илаһи көч. Шушы өч кодрәт иясе – шагыйрь, композитор, жырчы сәләте ягыннан югары кимәлдә тәңгәл килгәндә генә мөкәммәл жыр туа» *(«Сәхнә», сентябрь-октябрь, 2006)*. Жыр анын асылын тәшкил иткән «өчлек» турында Марсель Галиевтан да образлырак, төгәлрәк әйтүче булдымы икән?! Гадәттә, «мөкәммәл жыр», вакыт сынавын узып, озын гомерлеләр исемлегенә керә. Әхмәт Ерикәй сүзләренә, Сара Садыйкова ижат иткән «Көтәм сине» жыры – нәкъ шундыйларның берсе. Әлеге жыр Сара Садыйкованың композитор буларак тәүге мөстәкыйль әсәре, шул ук вакытта татар музыкасының беренче тангосы да.

Сара Садыйкова һәм Әхмәт Ерикәй – Мәскәү опера студиясен тәмамлаучы сәнгатькәрләр. Аларның танышу, якыннан аралашулары нәкъ уку чорында башлана да. Ләкин әлеге вакыт аралыгында (1934-1939) Әхмәт Ерикәй композиторлар Фәрит Яруллин, Жәүдәт Фәйзи, Мансур Мозаффаров белән тыгыз ижади элемтәдә була (бу чорда Мансур Мозаффаров белән «Галиябану» операсын да ижат итәләр). Беренче татар операсы «Сания»дә төп партия башкарган, Сәйдәшнең музыкаль драмаларында жырлап, Казан халкына танылган Сара Садыйкова исә бирелә опера жырчысы буларак белемен чарлый, «киләчәктә композитор булырмын» дигән уе да, теләге дә булмый әле. Язмыш бу ике ижат кешесен авторлар буларак соңрак очраштыра...

Казанда опера һәм балет театры ачылу, яна опералaрда төп партияләр башкару, ире Газиз Айдарскийның үлеме... Сара Садыйкованың студиядән соңгы еллары әнә шундый вакыйгалар белән билгеле. 1941 елның көзендә жырчы буларак күләгәдә кала барган Сара Садыйкова үз ирегe белән театрдан китәргә жөрьәт итә. Тормышының бу авыр чорында аны аңлаган, ярдәм кулы сузган бердәнбер кеше – театр музыканты Юлий Станиславович Крещелюнас була. Күп тә үтми, тыгыз аралашу мәхәббәткә әйләнә, алар өйләнешәләр, һәм өчәүләп (Сара Садыйкованың кызы Әлфия Айдарская белән бергә) Уфа театрына юл алалар. Ләкин Уфа ижатчыларны колач жәеп каршыламый. Биредәге театрда бик аз эш хакы вәгъдә ителү, торак мәсьәләсе белән авырлыклар килеп чыгу сәбәпле, алар кабат Казанга кайтырга мәжбүр була. Сара Садыйкова авырлык белән булса да, янәдән Казан опера театрына эшкә урнаша, Юлий Станиславовичны сугышка алалар, күп тә үтми, ул хәбәрсез югала...

«Көтәм сине» жыры нәкъ шул чорда туа. Татарстан Фәннәр академиясе Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының Язма һәм музыкаль мирас үзәгендә (укучыларга тәкъдим ителгән барлык документларның фотокүчермәләре әлеге үзәктән алынды. – *ред.*) Сара Садыйкова архивы саклана. Әлеге архивта гарәп графикасында композиторның «Көтәм сине» жыры турында үз куллары белән язган язмасы бар. Язманың ниндидер концерт өчен әзерләнгән булуы ихтимал: «Сугыш фажигасе барыбыз өчен авыр кайгы, ачы хәсрәт алып килде (...) илебезнең бәйсезлек-ирeген саклап калу өчен, ни белән булса да фронтка ярдәм итәсе килде. Без, Муса Жәлил исемендәге опера вә балет театры жырчылары, концерт бригадалары булып оешып, госпитальләрдә, хәрби гарнизоннарда, танковый мәктәпләрдә, военкоматларда, хәрби частьләрдә концертлар бирә башладык. (...) Мин үземнең сугыштагы тормыш иптәшем һәм туган энемнән (С.Садыйкованың энесе Салих турында сүз бара. – *Г.С.*) озак хәбәр булмавына озак сагышланып, моңланеп «Син кайларда йөрисең микән» дигән жыр яздым» *(121 нче ф., 2 нче тасв., 29 нчы сак.берәм.)*.

Әлеге язмада «Көтәм сине» жыры ижат ителүгә сәбәпче булган вакыйгалар бәян ителсә, Гөлшат Зәйнашева «Сара Садыйкова» *(Казан: Татар.кит.нәшр., 1996, Б.77-*



Сара Садыйкованың кульязмасы. 121 нче ф., 2 нче тасв., 17 нче сак. берәм. (аерым дәфтәрләрдә 3 нче сак. берәм.)

*78)* китабында әсәрнең конкрет тарихына игътибар итә. «Көннәрдән бер көнне Сара Садыйкова кулына Әхмәт Ерикәйнең «Көтәм сине» шигыре басылган газета килеп керә. Нәкъ Сараның күңелендә кайнаган сүзләр бу шигырьдә:

*Син кайларда йөрисең икән,*
*Алтыным, көләч йөзле иркәм,*
*Кайтырсың дип мин өмет итәм,*
*Мин сине көтәм, көтәм, көтәм...*

(...) Шигырь Сараның күңеленә керә дә утыра. Сара шул шигырь тәэсире белән әллә нинди сагышлы тойгыларга бирелә, бер мәлгә аның күңеленә нииндидер талгын моң килә, икенче мәлдә күңеле ярсулы ашкыну, җилкенү белән тула. Шушы халәт ана тынгы бирми, хисләре менә-менә түгелер шикелле мөлдерәмә булып таша. Шигырьне күңеленнән кабатлый-кабатлый эшкә китә. 1942 елның көзге салкын җилле көне. Трамвай тукталышында халык ыгы-зыгы килә. Трамвай юк та юк. Сараның ботинка гына кигән аяклары туңа башлый, ул, бер аягын икенчесенә бәрә-бәрә, авыз эченнән генә әлеге шигырьне көйгә салып кабатларга керешә. Мөлдерәмә тулган күңел моң булып түгелә, түгелә:

*Кайтырсың дип мин өмет итәм,*
*Мин сине көтәм, көтәм, көтәм...*

Түгелеп ташыган бу моңда Юлийны сагыну, аны тилмереп көтү барысы берьюлы агыла, агыла... Трамвай килеп туктый, пассажирлар утырып китәләр, Сара, әлеге моң ташкынынннан аерыла алмыйча, баскан урынында кала».

Татар җыр сәнгатендә беренче танго әнә шулай туа. Әлеге җыр Сара Садыйкова иҗатында да беренче җитди көй – Монсараның композиторлык юлы нәкъ шушы җырдан башлана. Сара Садыйкова Рәфикъ Юныс белән әңгәмәсендә тәүге иҗат җимеше турында болай ди: «Җырның нәкъ шул вакытта (тукталышта. – *Г.С.*) шытып чыгуы очраклы булса да, күңелемдә җырга әйләнергә әзер моң очраклы булмагандыр, җырны ошаттылар. «Яз әле, Сара, синең әйбәт чыга, диючеләр күп булды» *(«Татар гаме», Казан: Татар.кит.нәшр., 2013, б.16).* Алдарак искә алынган кульязмасында: «Бу җыр барлык хатын-кызларның йөрәк сагышларын, өзелеп сагынуларын әйтеп биргән җыр булып, бик тиз халыкка таралды», – дип язып үтә.

«Социалистик Татарстан» газетасының 1981 елның 3 март санында Рифкать Исмәгыйлов «Канатлы җыр» мәкаләсендә «Көтәм сине»нең тылдагылар өчен генә түгел, фронттагылар өчен дә әһәмиятле булуын ассызыклый. «Хәрби госпитальгә яраланган яшь кенә бер лейтенантны китерделәр. Ул безнең Татарстан егете булып чыкты. Фронтта якташыңны очрату – зур бәхет ул. Лейтенант беркөнне без беркайчан да ишетмәгән яна җыр җырлады. (...) Барыбыз да сихерләнгән кебек тынып калдык. Нииндидер илаһи моң, йөрәк өзгеч сагыну һәм шул ук вакытта яшәүгә ышаныч, сөйгән кешенең кайтуына өмет янгырый иде бу җырда. Җыр йөрәкләргә үтеп керә, күңелнең иң нечкә кылларын чиртә. Әйтерсең, аны яшь лейтенант җырламый, безгә турыдан-туры сөйгән кызларыбыз, яраткан хатыннарыбыз, сөекле


эти-әниләр, сенелләребез эндәшә. Жырнын сонгы куплеты безне, дошманга каршы нәфрәт утын тагын да көчәйтеп, жинү дауларга чакыра кебек. Жырны башка милләттән булган яралылар да ошатты. «Бу нинди жыр? Тәржемә итегез әле», – диләр. Аны болай тәржемә иттек:

*Где теперь ты ходишь, мой родной,*
*Золото моё, мой дорогой.*
*Я надеюсь, ты придёшь ко мне.*
*Жду тебя скучая и любя.*

Инде жырны бөтен палаталар белән, башка халык жырлары белән беррәттән жырлый башладык. Күп тә үтмәде, без, сәламәтләнеп, фронтнын алгы сызыгына киттек. Ул жыр гел безнен көнелләрдә кабатланып йөрде. Сугыш бетте. Бөек Жину көне килде. Ул канатлы жыр һаман көнелләрдә янгырый».

Шунысы кызык: Сара Садыйкова архивында әлеге жырнын әдәби тәржемәсе саклана, сезнен игътибарга анын бер өлешен тәкъдим итәбез:

*Ждёт тебя мой полный ласки сад,*
*Ждёт тебя восход и ждёт закат.*
*Два прощальных слов «жди меня»*
*Музыкой в ушах моих звучат.*



*«Көтәм сине» җырының ноталары. Төп нөсхә. 121 нче ф., 2 нче тасв., 17 нче сак. берәм. (аерым дәфтәрләрдә 3 нче сак. берәм.)*

Стиль үзенчәлегенә карагандa, бу вариантны Әхмәт Ерикәй үзе тәржемә иткән дип фаразларга мөмкин. Сара Садыйкова жыр тугач, бу турыда төркемләшенә хәбәр итми калмагандыр, әлеге тәржемәнен бераз сонрак эшләнүе дә ихтимал. Кызганыч, бу турыда төгәл фактлар китереп булмый, чөнки Әхмәт Ерикәйнен Татарстанда архивы юк, Сара Садыйкова архивында исә шагыйрьнен композиторга 50 нче елларда язган 3 хаты гына саклана. Аларда «Көтәм сине» жыры турында мәгълүматлар юк. Шуны билгеләү мөһим: әлеге жыр яна ижади тандемга юл ача – Сара Садыйкова Әхмәт Ерикәйнен тагын 22 шигыренә көй яза. Алар арасында «Сагыну вальсы», «Кайттым сина», «Айлы кич» кебек бик матур лирик жырлар бар. Ләкин алар «Көтәм сине» жыры кебек, Рабит Батулла язганча, «халкыбызнын музыка сәнгате мәйданында алтын һәйкәлләрнен берсе» дәрәжәсенә күтәрелә алмадылар.

**P.S.** «Көтәм сине» жырын профессиональ сәхнәдә Сара Садыйковадан башка Фәхри Насретдинов жырлаган була, телевидение архивында бу жыр Зилә Сөнгатуллина һәм Руслан Дәминов башкаруында саклана, 2012 елда нәкъ әлеге башкаруда Кәрим Тинчурин исемендәге Драма һәм комедия театрында Т.Миннуллин әсәре буенча куелган «Төш» спектаклендә жыр лейтмотив рәвешендә кулланыла, ул шулай ук үткән ел Татарстанда төшерелгән «Уен ахыры» кыска метражлы фильм финалында да янгырый.

**Гүзәл СӘГЫЙТОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*



*Каракалпак шагыйре Жолмурза Аймурзаев һәм татар шагыйре Сибгат Хәким. 1982 ел.*



*Төрекмән әдәбияты классигы Берды Кербабаев (сулда) Казанга килгәч. Аның янәшәсендә — Хәсән Туфан һәм Хатыйп Госман. 1958 ел.*



*Чыңгыз Айтматов (Кыргызстан) һәм Олжас Сөләйманов (Казакъстан). Уртада — Татарстанның Россиядәге тулы вәкаләтле вәкиле Назыйф Мириханов. 2000 ел.*



*Муса Җәлилнең туувына 70 ел тулуга багышланган кичәдән бер күренеш. Сулдан уңга: Сагынгали Сәитов (Казакъстан), Кайсын Кулиев (Кабарда-Балкар), Равил Фәйзуллин, Хәсән Туфан. Казан. 1976 ел.*



*Төрки халыклар әдәбиятларына багышланган симпозиумда. Уртада – азәрбайҗан әдибе Анар Рзаев. Истанбул. 2003 ел.*



*Кардәш әдәбиятлар вәкилләре бергә җыелгач. Сулдан уңга: Л.Хәмидуллин, И.Нуруллин, С.Жунусов (Алматы), Ш.Мортазаев (Алматы), З.Мирзаһитова, Ә.Мирзаһитов (Уфа), Ә.Еники, Т.Миңнуллин. 1976 ел.*

# ИҖАТЫНДА ЧОР АВАЗЫ

СӘГЫЙТЬ СҮНЧӘЛӘЙНЕҢ ТУУЫНА 125 ЕЛ

XX йөз башы татар шигърияте янарышына житди өлеш керткән, аны нечкә лиризм, публицистик аһән белән баеткан, тема-мотивлар төрлелегенә юл ачкан шәхесләрнен берсе — Сәгыйть Сүнчәләй (1889-1937).

Шигърият, драматургия, тәржемә өлкәсендә уңышлы эшләгән, җәмәгать эшлеклесе буларак танылу алган Сәгыйть Хәмидулла улы Сүнчәләев Саратов губернасындагы Хвалынск өязенә кергән Иске Мостяк авылында 1889 елның (бер шигырендә — 1890) 25 августында (аерым чыганакларда — 25 декабрь) туган. 1891 елда ачлыктан котылу максаты белән атасы гаиләне Әстерханга алып китә. Үсә төшкәч, ул «Ваһабия» мәдрәсәсендә укый, аны тәмамлаганнан соң, ике ел балалар укыта. 1905-1907 еллар инкыйлабы чорында абыйсы Шәриф белән прокламацияләр, сул фикерле рисаләләр таратып йөргәне мәгълүм.

1907 елда С.Сүнчәләй Казанга килә. Бераз вакыт Шакирҗан Хәмиди мәдрәсәсенә йөргәннән соң, ул Шәриф абыйсы янына Казан татар укытучылар мәктәбенә укырга керә. Ләкин матди як авыр булу сәбәпле, укуны тәмамлаган абыйсы белән Пермь губернасы Оса өязе Сараш авылына китәләр һәм дүрт сыйныфлы земство мәктәбендә укыта башлыйлар. Ул елларда биредә булачак язучы Риза Ишморат та укый һәм соныннан ул Сүнчәләйләр турында матур истәлекләр язып калдыра.

С.Сүнчәләйнен беренче каләм тибрәтүе Әстерхан чорына карый. «Борһане тәрәкъкый» газетасында хәбәр-мәгълүматлар бастыра, 1908 елда аның «Кавказ тоткыны», «Тунгатай» исемле тәржемәләре, «Кул — күз яше» дигән хикәясе юка китапчыклар рәвешендә дөнья күрә. Ләкин боларны С.Сүнчәләйнең иҗат биографиясе башы дип әйтеп булмый. 1909-1915 еллар — «авыл» чоры — Сүнчәләйнен иң актив иҗат еллары. Барыннан да бигрәк ул үзен лирик шагыйрь итеп таныта. Рус язучысы И.Гриневскаяга язган бер хатында: «Мин бер-икесен искә алмаганда, бөтен татар газета һәм журналларында катнашам», — дип яза. Бу еллар дәверендә С.Сүнчәләй 300гә якын шигырь, тәржемәләр һәм мәкаләләр бастыра.

1915 елда ул Уфага күчеп килә һәм шәһәр китапханәсендә эшли башлый. «Интернационал», «Марсельеза», «Матәм» кебек инкыйлаби җырлар аның тәржемәсендә халыкка тарала. 1917 елда ул өч ай чамасы эсерлар партиясендә булып ала, «Авыл халкы» газетасы мөхәррире, 1918 елда «Көрәш» газетасы редакциясендә эшли. 1918 елнын ахырында Сүнчәләй Казанга килә һәм «Кызыл Армия» газетасында языша. 1919 елның маенда ул ВКП(б) әгъзасы була һәм тиздән аны М.Солтангалиев тәкъдиме белән Кырымга агитацион (ярым легаль) эшкә җибәрәләр. Анда ул (Партанет авылында) балалар укыта, күбрәк тәржемә белән шөгыльләнә, театр белән мавыга башлый. Кырымда вазгыять кискен үзгәреп, хакимият Деникин кулыннан Врангельгә күчкәч, Сүнчәләй ашыгыч рәвештә Төркиягә кача, аннан исә Мәскәүгә кайта. Врангель гаскәре тар-мар ителгәч, ул янә Кырымга җибәрелә. Үзәк Комитетка язган докладында җирле халыкның бик авыр хәлдә яшәвен күрсәтә.

1923-1924 елларда Сүнчәләй — Башкортстан АССР Мәгариф комиссариатында коллегия әгъзасы, 1925 елда — сәнгать бүлеге мөдире. 1926 елда аны Мәскәүгә чакырталар һәм Совет генераль консуллыгы белән Төркиягә (Измир шәһәренә) тәржемәче итеп җибәрәләр. 1927 елда Сүнчәләй янә Уфада, театр-сәнгать техникумын җитәкли, 1928 елнын сентябреннән Казандагы Татар сәнгать йортының сәркатибе булып эшли.

Дәһшәтле 1920-1930 еллар Сүнчәләйне дә урап үтми. 1926 елда аны, «актив солтангалиевче» булганга, партиядән чыгаралар. «Контрреволюцион эшчәнлек» алып барган өчен, беренче тапкыр 1927 елның 2 июнендә, икенче тапкыр 1929 елның 28 февралендә кулга алалар. М.Солтангалиев эше буенча «контрреволюцион солтангалиевче» атуга хөкем ителә, иҗатына кара тамга сугыла. Төрмәдә утырганда ул Сталинга хат язып карый, тик бу эш нәтиҗә китерми. 1931 елда үлем җәзасын ун еллык сөргенгә алыштыралар һәм Соловкига җибәрәләр. Ләкин М.Солтангалиев эшен кабат тикшереп, 1937 елның 9 октябре карары нигезендә, бүтән исән калган тоткыннар белән бергә, аны да атып үтерәләр.

С.Сүнчәләй мирасын кайтару мәсьәләсен күтәрү 1958 елның 8 мартыннан соң гына («өчлек» карарын юкка чыгаргач) мөмкин була. Бу эшкә мирасны кайтару комиссиясе әгъзалары — шагыйрьнең абыйсы Шәриф Сүнчәләй, язучылар Риза Ишморат, Әмирхан Еники — күп көч куя. 1970 еллардан алып С.Сүнчәләй иҗаты Г.Халит, Х.Госман, М.Мәһдиев, З.Рәмиев, Э.Нигъмәтуллин, Р.Мостафин, Р.Мусабәкова тарафыннан тикшерелеп килә.

* * *

С.Сүнчәләйнең тормышы һәм иҗаты — XX йөз башы татар зыялыларының лирик елъязмасы, аларның омтылышлары, эзләнүләре, бәргәләнүләре тарихы. Бу уйланулар, кичерешләр шагыйрь лирикасында ачык чагылыш таба. Сүнчәләй — лирик шагыйрь. Бүтән шагыйрьләрдән аермалы буларак, аның лирик герое һәм шагыйрьнең үзе арасында аерма юк диярлек. Шигырьләрендә — шагыйрьнең үз язмышы. Аларга автобиографизм хас. Сүнчәләй лирикасының төп сыйфаты — аның хисчәнлеге. Бөтен күргән-белгәнен, уй-фикерләрен ул йөрәк аша уздыра. Һәрбер кәефе, шатлыкмы ул, кайгымы, уйлану-моңланумы, шигырь тудыруга сәбәп булып тора. Шактый катлаулы шәхси тормышы да моңа җирлек тудыра. Беренче хатыны Сәлимә баладан үлә, улы Таһир ярым ятим кала, күбрәк әбисе тәрбиясендә үсә һәм 1924 елда үлә. Икенче хатыны Фаридә белән дә тормыш барып чыкмый, ул улы Фәрит белән аерылып китә. Кырымда эшләгәндә, өченче тапкыр язмышын сынап карый, Әминә Милушева исемле артисткага өйләнә, кызлары Таһирә туа. Бу юлы да көткән бәхет урап уза Сүнчәләйне. Шуның өстенә шагыйрьнең нинди катлаулы чорда яшәгәнен дә истә тотарга кирәк. Болар барысы да лирикасында ачык чагылыш таба. Аның поэзиясе — яшәү-үлем, яхшылык-яманлык, мәхәббәт-нәфрәт, тугрылык-хыянәт кебек категорияләрне чагылдырган үзенә бер шигъри көндәлек. Автор шигырьләрендә беренче заттан сөйли. Һәрбер шигырендә үзен сиздереп тора. Сүнчәләйнең лирик герое һәрвакыт дәрт дәрьясында кайный һәм бу халәттә туган хисләрен укучыга ашыгыч рәвештә җиткерәсе килә.

Нинди тема-мотивлар шагыйрьне дулкынландырган, борчыган, игътибарын җәлеп иткән соң? Бу җәһәттән, мәсәлән, аның Тукай белән мөнәсәбәтләре аеруча кызыксыну уята. Сүнчәләйнең авылдан язган хатларына Тукай җавап бирә. Җәйләрен Сүнчәләй Казанга килә, алар еш очрашалар. Әлеге аралашу 1910 елның көзеннән башлана һәм Тукай вафатына кадәр дәвам итә. Байронның Сүнчәләй тәрҗемә иткән «Шильон тоткыны» шигырен укып, төзәтеп бастыруда Тукай булыша. Җавап хатларында Тукай яшь шагыйрьгә киңәшләрен бирә, үзенең планнары, фикерләре белән уртаклаша. Сүнчәләй, Тукай вафатыннан соң, аның турында өч истәлек-мәкалә яза, берничә шигырен багышлый. Тукай исән чакта ук Сүнчәләй, аңа мөрәҗәгать итеп, «Азан» (1912) шигырен яза. Тукай шигырен азанга тиңләп, ул аны милләтне уята алырлык көч дип саный. Шагыйрь үлгәннән соң, апрель аенда язылган «Тукай хатирәсе» (1913) шигырендә Тукайның кыска гомере турында «ятим, мохтаҗ иде», «дөнья золмына, фәнасына аның бәгъре көйде», «насыйп булды аңар рәхәт әбәдлеккә восуль», вафаты хакында «үлмәде — үтерелде ул», дип яза. Җәмгыятьнең Тукайны тиешле дәрәҗәдә бәяләмәве, зурламавы, нинди зур шагыйрьне югалтканын аңламавы Сүнчәләйне аптырашта калдыра. Ул шагыйрь фаҗигасен пәйгамбәрләр фаҗигасенә, ә җәмгыятьне көтүгә тиңли, аны битарафлыкта гаепли.

Моннан тыш Сүнчәләйнең күп кенә шигырьләре милләт мәсьәләсенә

багышланган. Анын киләчәге өчен борчылып, ул, «Агиев туенда» (1910) шигырендә халыкның киләчәгенә өмет белдереп, «сүнмәс», «төнгә әйләнмәс», «куркынмас», «аумас», «бетмәс», «аурамас», «үлмәс», «яшәр», «алга басар», дип яза. Иҗатының башлангыч чорында күпчелек замандашлары кебек халык бәхетен укыту-агарту эше белән бәйли. Милләтен сабырлыкка өнди («Тәсәллә», 1915), киләчәк үзгәрешләрне якты таң символы аша сурәтли.

Сүнчәләйнең революцион-демократик карашлары иртә формалаша. Социаль-сәяси мотивлар анын иҗатының башлангыч чорында ук үзен сиздерә. Ул, авыл тормышының социаль контрастларын, халыкның матди яктан төрле катлауларга аерылуын, гади халыкның изелеп яшәвен күреп борчыла («Ике бай», 1910). Килеп туган социаль һәм җәмгыять низагларын, Сүнчәләй фикере буенча, инкыйлаб чишәргә тиеш була. Инкыйлаб бөтен бәхетсезлекләрдән, проблемалардан чыгу юлы булып тоела башлый. Шуна күрә Октябрь инкыйлабын ул сөенеп каршылый, аннан күпне өмет итә («Ирек», 1917; «Кызыл байрак», 1919; «Батырга», 1919; «Беренче май бәйрәме», 1919; «Коммунарларга», 1920).

Әйтергә кирәк, әгәр 1910-1912 елларда 140тан артык шигырь язылган булса, 1917-1919 елларда аларның саны сизелерлек кими, бары тик 30 чамасын тәшкил итә. Дөрес, бу елларда Сүнчәләй җәмәгать эшенә чума, 1919 елда большевиклар партиясенә керә, халыкны агарту, мәдәният, сәнгать өлкәсендә эшли. Шигырьләр декларатив, лозунг төсмерен ала, аларда шигъри сурәтләү икенче планга күчә.

Сүнчәләй иҗатының буеннан-буена ватан, туган ил темасы сузылган. Шагыйрь өчен ватан — ул халык тарихы, анын үткәне, бүгенгесе, киләчәге. Мәхәббәт темасы Сүнчәләй иҗатында бик киң мәгънәдә кулланыла: милләткә, табигатькә, балаларга һәм, билгеле, хатын-кызга карата да. Лирик герой өчен мәхәббәт — яшәү көче чыганагы да, күнелсезлекләрдән котылу чарасы да. Сунчәләй шигъриятенең тагын бер мотивы — үзенә бер серле идеал юксыну, сагыну, аңа омтылу, тартылу. Һәм монын төп сәбәбе — аңа гомере буе юлдаш булган ялгызлык. Тукайдан гайре ул тормышында бүтән беркем белән дә якыная алмый. Җәмәгать эшчәнлеге белән шөгыльләнеп, кешеләр арасында яшәп тә, ул гомере буе ялгызлыктан интегә.

Дин мәсьәләсе Сүнчәләй иҗатында аерым бер урын алып тора һәм иҗат дәверендә зур үзгәреш кичерә. 1914 елга кадәр язылган шигырьләрендә шагыйрьнең лирик герое Алланы таный, Аңа өметләр баглый, ярдәм сорый. Соңрак язылганнарында ул Аллага карата канәгатьсезлеген белдерә башлый. 1922 елда язылган «Васыйят»е нык уйландыра, чөнки анда катгый шартлар куелган: анын мәетен муллалар, байлар озата бармаска, ә кабере өстендә Коръән сүзләре урынына «Бәйнәлмиләл» маршы янгырарга тиеш була.

Сүнчәләй — шагыйрь генә түгел, тәрҗемәче дә. Ияреп язган әсәрләре дә шактый. Ул тәрҗемә иткән язучылар арасында А.С.Пушкин, М.Ю.Лермонтов, И.А.Крылов, Н.А.Некрасов, И.С.Тургенев, Л.Н.Толстой, И.С.Никитин, А.П.Майков, С.Я.Надсон, А.А.Блок, К.Д.Бальмонт, Дж.Байрон, Г.Гейне, Ф.Шиллер, В.Гюголар бар. Тәрҗемәләр һәм ияреп язулар оригиналь иҗаты белән тыгыз үрелеп бара. Тәрҗемәләр шактый ирекле характерда башкарылган, еш кына алар татар тормышына якынлаштырып бирелгән. Кыска шигырьләр белән беррәттән, ул зур күләмле шигъри әсәрләрне дә татарча янгырату белән мәшгуль. Шул исәптән Байронның «Шильон мәхбүс»ен, А.С.Пушкинның «Коръәнгә тәкълид»ен, Гейненең «Әльмансур»ын, И.Гриневскаяның «Баб»ын (басылмый кала, кульязма рәвешендә саклана) атап булыр иде. Моннан тыш ул музыкага, тәнкыйтькә, әдәбиятка һ.б. багышланган ике дистәгә якын мәкалә авторы да.

**Рәйсә МУСАБӘКОВА,**
*филология фәннәре кандидаты*

# НАМУС ҺӘМ ГАДЕЛЛЕК

*(Хатирә)*

ФӘРВАЗ МИҢНУЛЛИННЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

Фәрваз абый мина әтием кебек кеше иде...

Ләкин болай дип язып, өстемә зур җаваплылык алдым да хәзер аның турындагы сүзне ничек итеп, каян алып китәргә соң әле?

Мөгаен, Фәрваз абый белән ничек танышудан башларга кирәктер.

Университетның өченче курсында укыганда (1971 ел), «Социалистик Татарстан» газетасы минем усал гына язылган мәкаләмне бастырып чыгарды да, шуннан соң дәртләнеп китеп, яшь язучылар җыентыгына рецензия язып тәмамладым, ләкин анысы күләм ягыннан зуррак килеп чыкты, шуна күрә газетаның бүлек мөдире Рәшит абый Гарипов аны «Казан утлары» журналына биреп карарга киңәш итте.

Әмма, журнал турындагы сүзгә күчкәнче, менә шушы урында бер мөһим нәрсәгә игътибарны юнәлтәсе килә. Соңрак «торгынлык» дип йөртелгән әнә шул чорда КПСС өлкә комитеты органы булган газета «чынбарлыкны шомартып, ялтыратып, өстән генә карап» иҗат итүдә гаепләүче мәкалә чыгарган бит! Әле авторы кем диген - беркемгә билгесез бер студент кисәге! Ул чагында бу редакциянең бүлек мөдире Рәшит абый Гариповның, мәдәният өчен җаваплы урынбасар Флорид абый Әгъзәмовның һәм баш мөхәррир Шәмси ага Хамматовның чын егетлеге булган инде бу! Менә сина «торгынлык» чоры...

Журналның хатлар бүлегендә калдырып кайттым мин яна язмамны. Галәттәгечә лекцияләргә йөри-йөри, китапханәдә утыра-утыра, көн артыннан көн үтә — студент кеше бит... Ә бер кичне тулай торак коридорында Марат исемле егет очрый да Матбугат йортында Фәрваз абый Миңнуллинның мин калдырган рецензияне егетләргә мактап сөйләп торганын әйтеп бирә. Үземә килергә дә кушкан икән әле...

Ул уртача буйлы, җирәнрәк чәчле, киң маңгайлы һәм калын иренле, бик тә актив мимикалы, кешенең йөзенә һәм күзенә үтә дә игътибар белән текәлеп, кыю итеп карый торган кеше иде. Минем язманы үземә артык мактамады бугай, әмма аны журналга тәкъдим итәчәген әйтте һәм «Тугрылык» дип исемләнгән ул язмам журналның 1972 елгы 4 нче санында бер дә үзгәрмәгән килеш басылып та чыкты!

Аннары ул мина тагын язарга кушты. Китапларны, әсәрләрне үзем сайлап ала идем. Ничектер, Фәрваз абыйның бу мәсьәләдә ныклы бер принцибы бар иде бугай. Шулай бервакыт Рафаэль абый Мостафин мина үзенең яна чыккан китабын Фәрваз абыйның күз алдында бүләк итте дә, бәлки рецензия дә язарсың әле, дигәндәйрәк фикерен дә белдерде. Ә Фәрваз абый ана шундук каршы төшеп болай диде: «Алай итеп яшьләрне бозмыйк әле без!»

Ә инде 1972 елның көзендә (бишенче курста укый башлагач) Фәрваз абый мине редакциягә үз бүлегенә эшкә алды. Бауман урамындагы Матбугат йортының икенче катындагы ин почмак бүлмә иде ул. Анда проза бүлеге мөдире Яхъя абый Халитов, публицистика бүлеге мөдире Малик абый Хәмитов һәм Фәрваз абый белән мин утырабыз. Һәрберебезгә аерым өстәл, телефон. Бу — җитмешенче еллар, безнен дәрәҗәле әдипләребез, классик әдипләребез исән вакыт әле... Алар, редакциягә килгәч, безнең бүлмәгә сугылмыйча китми иде. Һәм мин шул вакытта әдипләребезнең Фәрваз абыйга карата булган зур ихтирамын, хөрмәтен тоя идем. Алар аны бик зурлап сөйләшә иделәр. Ә моның төп сәбәбе исә Фәрваз абыйның әдәби тәнкыйтьтә бик тә принципиаль, бик тә намуслы шәхес булуында икән! Аның, иң беренче чиратта, әдәбият мәнфәгатьләрен кайгыртып язуында икән хикмәт!

Әлеге чор — партия хакимлек иткән вакыт һәм биредә әдәби әсәрләрдән дә һәрвакыт уңай герой гына таләп ителә, уңай персонажларның берсүзсез тантана итүе сорала. Югарыда искә алынган мәкаләдә Фатих Хөснинең мин бәйләнгән

«Мәйдан» повестендагы кебек. Татар әдәбиятының тирән-төпле, акыллы, намуслы язучылары исә мондый иҗатны кабул итә алмый. Әмирхан Еники, Салих Баттал, Нурихан Фәттах, Аяз Гыйләҗев кебекләр әдәбиятта житди юлны — тормыш һәм сәнгать дөреслегенә тугрылыкны яклыйлар, «сөттән ак, судан пакь» булган ясалма геройларга каршы чыгалар. Әдәби тәнкыйтьтә аларны бигрәк тә Ибраһим Нуруллин яклый. Ул «Совет әдәбияты» журналының 1956 елгы 7 нче санында «Иллюстрациядән — проблемага» дигән мәкаләсен бастыра. Фәрваз абый Миңнуллин да нигездә И.Нуруллин яклы, әмма ул тирәнгәрәк карый — мәсьәләне фәлсәфи һәм эстетик яктан алып тикшерә. Аның 1964 елда язылган «Әдәби геройлар диалектикасы» һәм «Конфликт тормышчан булсын!» дигән мәкаләләре нәкъ әнә шундый тирән фикерле, киң карашлы, заманча, яңача уйлый торган тәнкыйтьчене гәүдәләндерә. Менә бер өзек. «Кайбер тәнкыйтьчеләр Ә.Еникине үз геройларын иҗтимагый хезмәт торышыннан, коллективтан аерып алып тасвирлаган өчен гаепилиләр. Ләкин менә бу тышкы яктан бик шәп күренгән Майпәрвәз ханымнарның, Нәҗипләрнең, Хәмит һәм Зөфәрләрнең чын йөзләрен хезмәт аша, коллектив эчендә ачып буламы икән? Юктыр, мөгаен. Без уйлаганча, бер-ике мәртәбә җыелышта тәртипләрен тикшерүгә бик тиз генә төзәлә торган беркатлы кешеләр түгел алар. Тормыш дөреслегенә хыянәт итәргә теләмәгәндә, мондый геройларны коллектив хезмәттә, хезмәт аша ачу бик кыен эш. Чөнки алар яшеренеп яшиләр. Алар яхшы киенерләр, бик әдәпле, культуралы кыланырлар, эш нормасын һәрвакыт диярлек үтәп килерләр. Алар яшеренә белә...»

Әмирхан Еники үз вакытында әдип буларак бик дөрес тотып алган, ә Ибраһим Нуруллин белән Фәрваз Миңнуллин тәнкыйтьче буларак зур игътибар биргән әлеге тискәре типлар соңгы еллар тормышында инде тәмам өлгереп җитте! Безнең бу елларда алар бик тә кыюланды, үтә дә активлашты. Әмма барыбер да битлек салынмады — алар сүздә «ил өчен», «халык өчен» тырышса, асылда исә аларның бердәнбер һәм төп максатлары булып кесә калынайту, мал туплау калды! Шәхси мәнфәгать калды! Әнә шундыйлар бүген инде югары урыннарны били — алар хәзер дилбегә тота.

Үзләрен шәхес итеп күрсәткән Әмирхан Еники кебек әдипләр аларга нигә кирәк булсын ди! Андый бәндәләргә инде хәзер тулаем әдәбият та кирәкми, әдәбият нигезендә яткан «әдәб» һәм әхлак та кирәк түгел! «Ахырзаман» диярсең, валлаһи...

Мин редакциядә эшли башлагач, Фәрваз абый тәкъдиме белән яшь тәнкыйтьчеләр түгәрәге оештырып җибәрдек. Утырышларыбызның иң беренчесендә үк диярлек Ибраһим ага Нуруллин белән очраштык, аңа бик үткен сораулар бирдек. Фәрваз абый үзе түгәрәк эшенә катнашмый диярлек иде. Бу да аның бер принцибы иде ахры — ул безгә ышана, үзебезчә яшәргә, үзебезчә эшләргә юл куя, ирек бирә иде. Ә яшь чагында ирек һәм ышаныч бик зур нәрсә бит ул! Яшь кешегә бик тә кирәк нәрсә алар!

Безнең утырышларда булган әңгәмәләрнең байтагын Фәрваз абый «Яшь тәнкыйтьче сүз ала» дигән рубрика белән журналда бастыра иде. Ә бу исә безгә тагын да дәрт биреп җибәрә, канат куйгандай итә. Шулай ук Әмирхан ага Еники, Нурихан ага Фәттах белән очрашулар бик тә истә калган. Болар бит КПСС өлкә комитеты бер дә сөймәгән әдипләр! Әнә шул вакытта Язучылар берлеге коридорында «Тарих, әдәбият һәм Нурихан Фәттах» дигән зур белдерү, очрашуга чакыру эленеп торсын әле! Моның ише хәлләргә берлек җитәкчеләренең бик тә эче поша иде, билгеле. Шулай бервакыт Гариф абый Ахуновның, миңа таба күрсәтеп: «Фәрваз! Бу пәрине чүлмәктән син чыгардың! Менә хәзер үзең җавап бир инде!» — дигәне истә калган. Нишлисең, язучы буларак бик тә образлы итеп әйтте инде Гариф абый, берни дә эшләр хәл юк. Дөресе шулай бит... Әмма Фәрваз абый «пәрине» яңадан чүлмәккә ябарга ашыкмады. Чөнки ул үзе баш хәреф белән язардай Тәнкыйтьче һәм гаделлекне яклаучы намуслы шәхес иде!

Ул арада университетны тәмамладым һәм мине, офицер итеп, Ерак Көнчыгышка озаттылар. Аэропортка Фәрваз абый берничә дустын да ияртеп килгән иде. Ерак Көнчыгышта яшәгәндә язылган мәкаләләрне дә Фәрваз абый журналда бастыра торды, сирәк кенә булса да җылы хатлар яза иде. Ә андый хатлар ерактагы кеше өчен бик тә мөһим бит.

Аннары Фәрваз абыйны Татарстан Язучылар берлеге рәисенен урынбасары итеп куйдылар. Рәис булган кеше үзе күбрәк партиянен өлкә комитетына яисә башка оешмаларга йөри, Мәскәүдә еш була, ә бөтен эш урынбасар җилкәсендә! Иҗат остаханәләренен эшен оештыру һәм аларга контрольлек итү, идарә утырышларын әзерләү һәм үткәрү, ел саен уздырыла торган «Әдәби ел йомгаклары» җыелышларына һәр әдәби жанр буенча докладчылар табу һәм аларнын унышлы чыгышларын оештыру һ.б. Шунын өстәвенә берлектә йөздән артык язучы бар, аларнын исә төрле-төрле мәшәкатьләре-проблемалары шулай ук бик еш туып тора — барысы да ярдәм өмет итеп урынбасар Фәрваз абый янына килә. Ә ул беркемне дә кире бора алмый, һәммәсенә ярдәм итәргә тырыша. Әнә шундый эш-мәшәкать өелде Фәрваз абый өстенә. Мин инде ул чагында «Идел» альманахы редакторы булып эшлим, Фәрваз абыйга күрше бүлмәдә генә утырам, шуна күрә үтә тынгысыз, актив эшчәнлеге тулысынча диярлек күз алдында. Бу авыр йөкне җиде ел буена тартты Фәрваз абый. Ул Язучылар берлегендә чын мәгънәсендә ат кебек эшләде. Намус белән яшәде.

Шул ук вакытта берсеннән-берсе җитдирәк эчтәлекле, тирән фикерле әдәби тәнкыйть мәкаләләре язарга да мөмкинлек таба иде Фәрваз абый. Анын бигрәк тә яратып, үтә дә үз күреп язган әдипләре дә бар иде. Әмирхан Еники, Рафаил Төхфәтуллин, Әхсән Баян кебекләр... Хәтта кызына да Р.Төхфәтуллин повестендагы төп героиня исемен кушты ул — Йолдыз! Әмма үзенен яраткан әдипләре иҗатына карата да таләпчәнлекне киметмәде. Менә бер мисал. «Чыннан да, әле нефть якларына күчеп киткәнче үк, Р.Төхфәтуллин егерменче съездтан сонгы авыл, бүгенге колхоз тормышы турында «Авылдашым Нәби»ләр дәрәҗәсендә торырлык әсәр иҗат итә алмады бит. Тормыш гаять катлаулы һәм каршылыклы нәрсә, шуларнын һәммәсенә ярардай ачкыч табу, ниндидер гомуми бер караш булдыру, күрәсен, бик кыендыр. Төхфәтуллин иҗатындагы унышсызлыклар, бәлки, шунын белән анлатыладыр? Бәлки, бу — зур һөҗүмгә күчәр алдыннан бер тынып алу чоры, иҗади үсеш юлында яна сикереш ясар, сыйфат үзгәрешләренә китерердәй җитди адым ясар алдыннан бер хәл җыеп алу гынадыр? Шулай гына була күрсен иде!» *(«Якты юллар» китабы, 64 бит).*

Өлкән әдипләргә карата да тәнкыйтьче буларак таләпчән иде ул. Хәтеремдә, әдәби ел йомгакларына багышланган бер җыелышта проза буенча доклад ясады да шул чыгышында өлкән әдипләребезне иҗади пассивлыкта гаепләде Фәрваз абый. Тәнәфескә чыккач, минем күз алдында А.Расих ана: «Син дә картаерсын әле, Фәрваз!» — дип үзенен үпкәсен белдерде хәтта!

Фәрваз абыйга картаю насыйп булмады. Әмма бу мәсьәлә унаеннан шуны да әйтмичә ярамый. Урыс язучыларынын китап бастырыр урыннары — нәшриятлары күп. Шуна күрә аларнын байтагы иҗат эше белән генә, гонорар хисабына гына яши ала. Мисал өчен, ул елларда 15 басма табаклы бер китап гонорарына җинел машина сатып алырга мөмкин иде. Бәяләрне чамалау өчен язам моны. Ә бездә исә бердәнбер китап нәшрияты бар — әдип кеше роман хәтле роман тәмамласа да, анын басылып чыгуын бик озак көтәргә тиеш була. Димәк, ана тиешле гонорар да юк дигән сүз... Шуна күрә татар язучысы тагын нинди дә булса бер эштә эшләргә мәҗбүр иде. Гаиләсен туендыру өчен! Көне буена бүтән эштә тир түккәч, әлбәттә инде, иҗат эшенә дәрт-дәрман һәм көч шактый ук аз кала. Әнә шуннан килеп чыга инде «иҗади пассивлык» дигән күренеш. Әле телгә алынган Атилла ага Расих, мисал өчен, озак еллар буена ветеринария институтында укытты.

Хәер, Фәрваз абый үзе дә гомере буена «казна эшендә» булды. Сонгы елларда редакциядә һәм Татарстан Язучылар берлегендә. Әйткәнемчә, ул үзе алынган эшне бик тә бирелеп, чын мәгънәсендә җигелеп, җаны-тәне белән тырышып башкара иде. Язган яисә берәр мәкалә редакцияләгән чагында анын өстәл артында ни рәвешле мавыгып, дөньясын онытып утырганын күргән кеше бу күренешне һич тә оныта алмый инде. Әмма язучыларнын 1984 елда булган чираттагы корылтаенда аны эшеннән алдылар! Бирелә төп сәбәп — ул чагында КПСС өлкә комитетында мәдәният бүлеген җитәкләгән М.Мусиннын бәйсез һәм принципиаль шәхес Фәрваз абыйны яратмавы, аннан котылуы дип уйлыйм мин. Язучыларнын корылтайлары гадәттә май аенда була. Бусы да ямьле яз көнендә җыйналган иде. Көтмәгәндә эштән алыну Фәрваз абыйга аяз көндәге яшен

кебек тәэсир итте. Корылтай тәмамлангач, инде караңгы төшеп килгәндә, ул мине үзе белән өенә алып китте. Аның Щапов урамындагы бакча эчендә утырган зур кирпеч өйдәге иркен фатирында ул кичне башка беркем дә юк иде. Әллә инде ул телефоннан шалтыратып куйган булган... Без төн буена йокламыйча, сөйләшеп чыктык...

— Улыма мин нәрсә дип әйтермен?!

Ул кичне әледән-әле шул бер сорауны кабатлый иде Фәрваз абый. «Улыма мин хәзер нәрсә дип әйтергә тиеш? Мин бит аны һәр жирдә тырышып эшлә, һәрчак намуслы бул дип тәрбияли, шулай үстерә килдем! Ә хәзер нәрсә килеп чыга?! Хәзер нәрсә күрәчәк ул үз әтисе мисалында?!» Әйе, Фәрваз абый бик тә нык рәнжегән иде. Ул бик тә гажиз хәлдә иде.

Башта «Казан утлары»ның иң авыр бүлегендә ун ел, аннары Язучылар берлегендә жиде ел буена ат кебек жигелеп эшләгән намуслы кешене, алдан кисәтмичә-нитмичә, эшеннән алып атсыннар инде, ә! Аның жаны-тәне белән бирелеп эшләгәнен, эшеннән үзенә дәрт-дәрман алып яшәгәнен мин бик тә яхшы күреп, аңлап, тоеп тордым бит!

Менә хәзер, ул хәлләргә инде күп еллар үткәч, бу юлларны язганда, мин тукталып, уйланып утырам. Әдәби әсәрләрдәге унай геройларның тормышта нинди зур каршылыкларга очравын, шул вакытта үзләренең йөрәкләрендә, бәгырьләрендә нинди әчке гарасатлар кичерүен моңа хәтле язган мәкаләләрендә бик тә тәфсилләп тикшергән, анализлаган Фәрваз абый ул кичне шәхсән үзе әнә шундый бер зур фажигагә тарыган иде. Аның бөтен барлыгын әлеге гажизлек йоткан иде. Ул төнне аның жан газабын берниндн каты әчемлек тә баса алмый иде...

Фәрваз абый сәламәтлегенә хәлиткеч удар әнә шул чагында ясалмады микән? Алтмыш яшендә арабыздан китеп барды бит.

Бераздан югарыдагылар үзләренең гаепләрен аңладылар шикелле — Фәрваз абыйны Татарстан китап нәшриятының матур әдәбият редакциясе мөдире итеп куйдылар. Ягъни кайсы китапны дөньяга чыгарырга, ә кайсысын чыгармаска икәнлеген конкрет рәвештә хәл итә торган урын инде бу. Нәкъ менә тәнкыйтьче кеше, нәкъ менә Фәрваз абый урыны!

Фәрваз абый башкаларга карата да, үз-үзенә дә үтә дә таләпчән шәхес иде. Шуна күрә аның басылып чыккан китаплары да күп түгел. Әмма алар берәгәйле китаплар! Сез ул китапларның исемнәрен генә карагыз: «Якты юллар» (1975), «Прозаның гражданлык йөзе» (1983), «Талантлар юлы» (1984). «Затлылык» (1989), «Балта явызлар кулында» (1994).

Әйе, Фәрваз абыйның соңгы китабының исемендә күрсәтелгән явызлар байтак инде алар. Әмма Фәрваз абый аларга бирешмичә, рухи яктан сынмыйча, сыгылмыйча китте! Ул үзе турында якты истәлек — яшь көрәшчеләрдә матур киләчәккә өмет уята торган якты юллар калдырып китте!

Аның соңгы айларында һәрвакыт янында булган һәм бөтен шартын китереп мөселманча соңгы юлга озатуны оештырган хөрмәтле әдибебез Рабит ага Батуллага исә Фәрваз абыйның гаиләсе, туганнары һәм дуслары исеменнән бик тә зур рәхмәт сүзләре әйтәсе килә.

Язмамның ахырында бераз хыялга да бирелеп алыйм әле. Бик тә якын киләчәктә халкыбыз артык зур шәһәрләрдә яшәүдән туеп, яңадан авылларга яисә кечерәк шәһәрләргә, табигать кочагына — бердәнбер дөрес яшәү жирлегенә кайтсын иде дә аның туган теле һәм дине бик тә ныгысын иде. (Рәсәй мәйданында мөселманнар саны хәзер үк шактый тиз артып бара бит инде!) Шулар нәтижәсендә татар әдәбияты яңадан чәчәк ату чорын кичерсен, анда тагын Гаяз Исхакый, Әмирхан Еники кебек олуг әдипләр, Фәрваз Миңнуллин шикелле көчле әдәби тәнкыйтьчеләр пәйда булсын иде! Бирсен Ходай! Фәрваз абыйны искә төшереп уйланган саен әнә шундый хыялөметләр ныгыбрак китә кебек...

**Мансур ВӘЛИ-БАРЖЫЛЫ**

# АЛАР ОНЫТЫЛМАС. ОНЫТТЫРМАСАК...

***Җитмеш ел элек, 1944 елның 25 августында, Плётцензее төрмәсендә Муса Җәлил һәм аның ун көрәштәшенең башы чабыла. Әлеге фаҗигале вакыйга уңаеннан тарихчы Искәндәр Гыйләҗевка берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.***

**— Искәндәр әфәнде! Муса Җәлил образы күңелегездә кайчан һәм ничек туа башлады? Рафаэль Мостафин белән аның эзләнүләре хакында сөйләшергә туры килмәдеме?**

— Мин — Совет чоры баласы, совет тәрбиясен мәктәптә алдым, пионер да, комсомол да булдым. Ул вакытта, әлбәттә, Җәлил исеме төрле патриотик чаралар уздырылган вакытта еш искә алына иде. Аның шигырьләре белән танышуым да мәктәп еллары белән бәйле. Ләкин, ни гаҗәп, мин аларны башта рус телендә укыган идем, чөнки мин рус мәктәбендә белем алдым. Татарчалары белән сонрак таныштым. Җәлил шигырьләрен татарча укыганда, ихтыярсыз аларны тәрҗемәләр белән чагыштырып бардым. Әлбәттә, шигырьләрне тәрҗемә итү — гаҗәеп катлаулы эш, ләкин яшь чактан калган шундый бер күзәтүем бар: Җәлил шигырьләрен совет чорында рус теленә бик шәп тәрҗемә кылган булганнар.

Тагын Җәлил исеме белән бәйле булган яшь чакларым хатирәсе — «Моабитская тетрадь» дигән кинофильм. Яна гына Интернеттан карап алдым — ул 1968 елда төшерелгән булган, димәк, мин аны кинотеатрда ун яшемдә караганмын. Пётр Черновны Җәлил ролендә кабул итә алмасам да, гаҗәп көчле тәэсир итте бу фильм миңа... Бигрәк тә әсирлек фаҗигасе. Шундый авыр хәлдә дә кешеләрнең шәхес булып калулары мине шул вакытта ук таң калдырган иде... Шәфи Алмас ролендә — гениаль Рәфкать Бикчәнтәев, Абдулла Алиш — Әзһәр Шакиров, Илдар Идриси — яшь Илдар Хәйруллин — тетрәндергеч, хәтердән җуелмый торган образлар... Күрәсең, шул вакыттан ук бу тема күңелемә сеңеп калгандыр, сонрак, инде тарихчы булгач, мона кадәр тыелган темалар белән дә шөгыльләнергә мөмкинлек ачылгач, мин шул мәсьәләгә якын булган «Идел-Урал» легионы тарихын өйрәндем, үземчә яшьлек хатирәләремне янарттым, шул вакытта уянган кызыксынуымны канәгатьләндердем...

Инде Рафаэль Мостафинга килсәк, без, әлбәттә, аның белән аралашып тордык, мин һәрвакыт аның энергиясенә, максатчанлыгына сокландым, ул, тарихчы булмаса да, минем өчен эзләнүләр алып баруда үрнәк булып торды... Кайбер мәсьәләләрдә аның белән тулысынча килешмәсәм дә, бәхәсләшеп алсак та (ул дискуссияләр вакытлы матбугат битләрендә дә чагылыш тапты), барыбер аңа карата ихтирам хисем кимемәде...

**— Алманиядә Җәлил исемен беренче тапкыр кемнән ишеттегез? Бу сезгә ничек тәэсир итте? Анда Мусаны белүчеләр аздыр инде. Җәлил һәм җәлилчеләр Алмания хәтереннән ничәдер еллан бөтенләй җуелмасмы?**

— Алманиядә Муса Җәлил исемен бездәге кебек үк еш искә алмыйлар. Гомумән, Алманиядә сугыш вакыйгаларын артык куертырга яратмыйлар, ул җәмгыятьтә әле һаман да гаеп хисе яши. Шулай да тарихчы, әдәбиятчы галимнәр аны белә. Казанда, Опера һәм балет театрында уздырылган, Муса Җәлилнең йөз еллыгына багышланган тантанала Гиссен университетыннан килгән профессор Марк Кирхнер, саф татар телендә Җәлил турында чыгыш ясап, бөтен залны үрә торгызып, аны

алкышларга «мәжбүр иткән» иде. М.Кирхнерның Җәлилгә багышланган берничә мәкаләсе дә бар. Элекке Плётцензее төрмәсе бинасындагы Каршылык хәрәкәтенә багышланган экспозициядә Муса Җәлил батырлыгына шактый зур урын бирелгән. Алманиядә яшәүче милләттәшләребез аны аеруча яратып искә ала. ГДР чорында аны, әлбәттә, күбрәк беләләр иде, шигырьләре алман теленә дә тәрҗемә ителеп бастырылган. Ләкин бүген Муса Җәлил – күпчелек алманнар өчен экзотик персонаж. Күрәсең, шулай булып калачак та – галимнәр беләчәк, киң җәмәгатьчелек артык кызыксынмаячак...

**– Бу теманы анда махсус өйрәнмәсәгез дә, аның эченәрәк керә бару булгандыр инде. Нинди яңалыклар, үзгәлекләргә тап булдыгыз?**

– Әйткәнемчә, мин «Идел-Урал» легионы тарихы белән шөгыльләндем, аның тарихына караган монографияләрем дә, мәкаләләрем дә бар. Димәк, турыдан-туры Муса Җәлилнең тормыш юлын өйрәнмәдем. Дөрес, Алманиядә архивларда эшләгән вакытта, Җәлил һәм җәлилчеләр турында яңа, беркемгә дә мәгълүм булмаган чыганакларны табарга дигән хыялым бар иде, ләкин юк – табылмады. Асылда Муса Җәлил тормышы белән бәйле булган легион тарихын төрле яктан өйрәнеп, бу гаҗәеп тирән фаҗигане мөмкин кадәре объектив яктыртырга тырыштым. Мине бер нәрсә һаман борчыды һәм борчый бирә: без үткән заманнарга, шул вакытта яшәгән шәхесләргә үтә беркатлы карарга, нинди дер штамп тагарга яратабыз. Үткәннәр турында фикер йөрткәндә, бары тик ике төс – ак һәм караны гына кулланабыз. Менә сугышны гына алыйк. Бүгенге көн күзлегеннән ул фаҗига турында сөйләп утыру кайберәүләр өчен бик җиңел: бу кеше куркак булган, бу кеше – каһарман, монысы – сатлыкҗан, монысы – патриот. Ә ул кеше нинди шартларда яшәгән, эш иткән, заманасы нинди булган соң? Нишләп без кайвакыт андый нәрсәләрне онытып җибәрәбез? Әйдәгез, җәмәгать, тарихыбызга аек акыл белән карарга өйрәник, вакыт житте шикелле, үткәннәргә элеккечә хис-эмоцияләргә генә таянып карарга ярамый бит. «Без бөек, без бөек!» яки «без мескен, без мескен!» дип тәкрарларга кирәкми, бу – гади генә әйткәндә, ахмаклык. Мин үзем тарихка мөмкин кадәр объектив һәм тыныч карарга, чыганакларга таянып, аны булганча тасвирларга тырыштым. Ничек барып чыккандар, анысына инде укучылар бәя бирсен.

**– Бар «хыянәтче Җәлил», бар «кызыл большевик Җәлил», бар «Татар гамен дә җуймаган көрәшче Җәлил». Аның образын өйрәнүдәге эволюция ничек барды? Сез хәзер күргән Җәлил нинди ул?**

– Җәлилне шулай төрле яктан, төрлечә бәяләргә мөмкин икән, димәк, ул кызыклы, күпкырлы, катлаулы шәхес дип әйтергә ярый. Тарихчы буларак, мин бары тик тәгаен тарихи чыганакларга ышанырга өйрәнгән, лозунг-өндәүләр белән генә, тарихта күрергә теләгәннәрне генә күреп әллә ни ерак китеп булмый. Җәлил шәхесен алсак, безнең карамакта нинди чыганаклар һәм шул чыганакларда нинди тәгаен фактлар бар соң? Җәлилне күргән, аның белән бергә булган шаһит кешеләрнең истәлекләре бар – һәм алар арасында татарлар гына да түгел, онытмыйк. Җәлилне Алманиягә каршы көрәштә гаепләгән һәм аны үлем җәзасына хөкем иткән документлар бар. Ниһаять, Җәлилнең ихлас күңеленнән, үлем алдыннан язган шигырьләре бар. Һәм бу конкрет фактларны беркем дә кире кага алмый. Шуларга гына таянсак та, кистереп әйтә алабыз: Җәлил – национал-социализм дәһшәтенә һәм хыянәтләренә каршы торган каһарман шагыйрь. Бу – тарихи факт.

**– Муса Җәлил һәм Гайнан Кормаш. Бу ике каһарманның һәркайсының батырлыгы үлемсез. Җәлилчеләр арасында Алиш белән Муса иң өлкәннәре бит... Гомумән, һәр җәлилченең үз язмышы, үзләренең генә түгел, гаиләләренең, нәсел-ыруларының язмышы бар. Боларны өйрәнү һәм дөньяга чыгару галимнәр эшеме?**

– Тарихта эз калдырган, бигрәк тә якты эз калдырган шәхесләрне өйрәнү, аларның гамәлләрен оныттырмау, яңа буыннарга житкерү – бу, һичшиксез, тарихчыларның бурычы. Минемчә, аерым дәүләтнең үз тарихына карашын бәяләп, без шул дәүләтнең бүгенгесен бәяли алабыз. Кызганыч ки, бүген Русиядә

яки Татарстанда үткәннәргә караш нормаль дип әйтә алмыйм. Без бер тарихны бетереп, инде шуны янача яза башладык, тик, күпме шапырынсак та, аны үзгәртә алмыйбыз, фантазиябезне эшкә жигеп, без аны теләгәнчә «аңлата» гына алабыз. Ләкин мондый «аңлатмалар»ның гомере кыска. Заказ яки күрсәтмә генә биреп чын тарихны торгызып булмый шул ул.

Менә җәлилчеләр мисалын гына алыйк. Без һаман бары тик Җәлилнең үзен генә күтәрергә тырыштык. Ләкин ул бит берүзе генә түгел, аның белән үлем җәзасына көрәштәшләре дә хөкем ителгән. Безне бу нык уйландырырга тиеш. Бу бит уникаль хәл! Сугыш вакытында андый очраклар булган микән? Нацистларга каршы көрәш оештырган бер төркем тулаем үлемгә хөкем ителгән! Әгәр дә нацистлар каршында башкаларның «гаебе» кимрәк булган булса? Димәк, алар да тарихта шундый тирән эз калдырган! Алар да безнең чиксез ихтирамыбызга һәм игътибарыбызга лаек. Бу бер мисал гына да тарихны төрле яктан, тирәнрәк, сәяси заказларга гына таянмыйча аңларга һәм аңлатырга өйрәтә. Минемчә, ул шәхесләрнең язмышын тулы рәвештә ачыклау аларның туганнары яки аерым тарихчылар эше генә түгел, бу — дәүләт эше дә. Тарихка таянып, яңа буыннарны тәрбияләргә өйрәнмәсәк, безнең бәябез бер тиен.

**— Әтиегез Аяз Гыйләҗевнең Җәлил һәм җәлилчеләр турында күләмле әсәр язарга теләге юк идеме?**

— Юк, әтиемнән мондый нәрсәне ишеткәнем булмады. Гомумән, әтинең Муса Җәлилгә вакытлар узгач кына чын-чынлап объектив бәя бирелер дип әйткәнен хәтерлим. Интервьюларның берсендә дә шул фикерне кабатлаганы булды. Бу һич кенә дә әтинең М.Җәлил һәм җәлилчеләргә ихтирамы аз дигән сүз түгел. Киресенчә, ул аларның каһарманлыгының табигатенә төшенү, рухының кодрәте, көченең чыганакларын табуны күздә тотканнан... Чыннан да, бездә әлегә Муса Җәлилгә ниндидер үзебезгә ошаган, якын булган штампларны тагарга омтылу булды. Ә ул гади кеше түгел бит, аны бер штамп ярдәме белән генә күзаллап булмый.

**— Яшьләр арасында бу темага алынучылар бармы?**

— Әгәр дә сез Муса Җәлилнең тормыш юлын яки иҗатын өйрәнүне күз алдында тотасыз икән, әлбәттә, әдәбиятчы галимнәребез бу мәсьәләне өйрәнәләр һәм өйрәнәчәкләр. Әгәр дә инде теманы бераз киңрәк ала башласак, гомумән, татарларның чит илләрдә яшәешен, тормыш рәвешен, аларның тарихын һәм мәдәниятен күз алдында тотсак, кызганыч ки, аерым басмалардан гайре әлегә мактанырлык эш юк. Минем бер күптәнге хыялым шул: Татарстанда, Казанда татар эмиграциясе һәм диаспорасын өйрәнү үзәген булдырырга кирәк. Бу үзәк, саф фәнни эштән тыш, агарту-пропаганда эшен дә алып бара алыр иде, татар тарихына караган уникаль чыганакларны җыюны оештырып җибәрер иде, аның каршында татар эмиграциясенә багышланган музей да ачарга мөмкин булыр иде... Без, татарлар — сибелгән, чәчелгән халык, бу — гаҗәеп бер тарихи феномен. Менә шул юнәлештә, милләтне берләштерү эшендә, төрле төбәкләрдә яшәүче милләттәшләребезне өйрәнеп, аларны бер-берсе белән таныштырып, милли үзаңнарын үстереп эш башласак, бик тә яхшы, изге гамәл булыр иде. Ләкин, кызганыч ки, заманча әзерлекле кадрлар юк диярлек, чит телләрне өйрәнү дәрәҗәсе һаман да элеккечә дип әйтеп була, ә искә алынган мәсьәләләрне чит телләрне яхшылап үзләштермичә хәл итеп булмый. Матди як та оптимизм уятмый, һәм, гомумән, җәмгыятебездә андый юнәлештә тотрыклы эш алып барырга теләк тә артык күренми. Без йә йоклыйбыз, йә һаман дөнья куабыз, ә чит төбәкләрдә татарлар бетеп бара, алар бетү белән аларның тарихы да сүнә, югала. Андый мисаллар күз алдыбызда...

*Әңгәмәдәш* — **Рәфикъ ЮНЫС**

# ХӨР БУЛЫП ТУГАН ЖУРНАЛ

«Идел»нен дөньяга килүе һич тә башка гәжит-журналларныкы кебек гади генә түгел.

1940 елда татар телендә егерме өч журнал чыккан. Аларның өчесе — яшьләр журналы. Бу — «Колхоз яшьләре», «Комвуз студенты», «Яшь эшче». Сугыш башлангач, журналлар ябылып («Казан утларының чыга бирүе үзенә күрә бер могҗиза инде), сугыш беткәч аларның кайберләре тагын ачыла. Язучылар берлеге рәисләре яшьләр журналы чыгару мәсьәләсен дә кузгаткалап торалар. Ләкин ул гел КПСС Үзәк комитетына терәлеп кала бирә. Татарстан язучыларының 1968 елда үткән VII съездында исә ошбу мәсьәләне инде яшьләр үзләре күтәрә. Һәм... бик тә үзенчәлекле төстә. Съезд барган Камал театры балконыннан яшьләр журналы ачуны таләп иткән листовкалар ыргытып. Ул заман өчен шактый хәтәр булган бу эшне студентлар Разил Вәлиев, Зөлфәт Маликов һәм Мирза Мансуров башкарды. (Вакыйга «Өзелгән спектакль» исеме белән «Идел»нең 1994 елгы 4нче санында теркәлеп калды.) Бу «листовкалар яңгыры» эзсез генә үтми. Марс ага Шабаев миңа менә ниләр сөйләде:

— Ул съездда идарә рәисе итеп Ибраһим Гази сайланды. Ибраһим агай, мине чакырып алып, яшьләр журналының штат расписаниесен һәм сметасын төзергә кушты. Өч вариантта эшләдем мин моны. Сугыштан соң «Үсү юлы», аннары «Идел» альманахлары чыккан иде бит, икесе дә ябылды аларның. Менә шул «Идел»нең исемен яңадан кайтарырга булдык. Шуннан, журнал сорый торгач, альманах итеп бирделәр. Журнал өчен көрәш исә туктамады, тагын да куәтләнә генә төште...

Көрәшне аны асылда бер кеше куәтләндергән — «Идел» альманахы мөхәррире итеп билгеләнгән Мансур Вәлиев. Язучылар берлегенә алынмаган, әле бер генә китап та чыгармаган бу ярь-яшь егет татар яшьләрен журналлы итәр өчен ниләр генә эшләми. Ошбу мәсьәләдә аның төп таянычы, фикердәше Язучылар берлеге рәисенең яшь авторлар белән эшләү буенча урынбасары Илдар Юзеев була. Алар Берлектә бер бүлмәдә утыралар иде. Сибгат абый Хәким белән Илдар абый Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов янына кереп, «Идел» мәсьәләсен идарә утырышына куярга дип килешәләр. Фикер бердәм була: альманахны журнал итәргә кирәк. Ләкин ничек? Монысы ачык кала. Уйлый торгач, Мансур Вәлиев һәм аның киңәштәшләре, ачасы журнал яшьләр журналы булгачтын иң әүвәл комсомол Үзәк комитетына мөрәҗәгать итәргә, моны өлкә комсомол комитеты аша эшләргә кирәк дигән фикергә киләләр. Үзәк комитетка хатны өлкә комитетының бер бүлек мөдире язарга тиеш була. Мансур килеп туктаусыз бөлешеп торган килеш тә ярты ел буе яза ул аны һәм тәки язып бетерә алмый! Ахырдан Мансур үзе һәм ул чакта өлкә комитетында эшләгән Ринат Закиров хатны ярты сәгать эчендә язып ташлыйлар. Ләкин хат юлында тагын бер киртә пәйда була: өлкә комитетының идеология секретаре Газизуллин..... «Бик житди проблема бу. Ашыкмыйк, кичектереп торыйк. Махсус комиссия төзеп, мәсьәләне тагын бер кат тикшерик!» — ди ул. Шунда Мансурыбызның түземе бетә.

— СССР Дәүләт премиясе лауреаты Гомәр Бәширов, РСФСР Дәүләт премиясе лауреаты Сибгат Хәким, Тукай премиясе лауреаты Хәсән Туфан һәм бүтән бик күп абруйлы әдипләр фикере сезгә дәлил түгелмени! Тагын күпме сузарга уйлыйсыз! — ди ул. Хат китә, ләкин комсомол Үзәк комитетында йомылып кала.

Максатка партия өлкә комитеты аша юл яру омтылышы да башта уңышсыз тәгәлләнә. Татарстан Язучылар берлеге рәисе Гариф Ахунов, Сибгат Хәким,

Шәүкәт Галиев һәм Мансур Вәлиев катнашында идеология секретаре М. Вәлиев кабинетында ике сәгатьләп барган буш сөйләшүне баш идеолог бик оста очлый — кулына телефон трубкасын алып, кемгәдер дәшкән була да, «Леонид Ильич аша гына дисезме?» — ди ул, кабинеттагыларга күз йөртеп. Үзәк комитеттан берәү ана хәзер генә имештер шулай дип әйткән. Генераль секретарьга юлны исә Гариф Ахунов ярырга тиеш булып чыга. «Без сине ни өчен СССР Верховный Советы депутаты итеп сайладык», — ди Вәлиев.

Журнал өчен көрәшне бары өлкә комитетының беренче секретаре Фикрәт Табеев аша гына дәвам итеп булганын төшенгән Мансур, партбилеты да юк килеш, мәдәният бүлегенә дигән пропуск белән Табеевның алгы бүлмәсенә үтеп керә ала! Һәм әдәбият аксакаллары хатын (аңа Гомәр Бәширов, Хәсән Туфан, Нури Арсланов, Нәби Дәүли һ. б. әдипләр кул куя) шунда утырган егет кулына тоттыра. Һәм ошбу бюрократик аппаратка һич тә хас булмаган нәрсә: бу егет (кем икән ул?) хатны Табеевка бирә. Шуннан соң тагын бер, зуррак могҗиза була. Камал театрында теге «листовкалар буранын» күреп утырган Табеев үзе Мәскәүгә барып, Үзәк комитетның идеология секретаре М. Суслов янына керә. Һәм үтә консервативлыгы белән мәшһүр Суслов журнал чыгаруга фатихасын бирә! Ләкин... татар яшьләр журналын ачу (юкса ачу да түгел, тергезү генә инде) СССР атлы империя өчен шулкадәр дә хәтәр эш булып чыга ки, ул серле рәвештә сузыла да сузыла бирә. Шунда безнең Мансур атлы теге егетебез Мәскәүгә дә барып җитә һәм журналга юл ачарлык затларны инде Үзәк комитетның үзеннән эзли башлый! Суслов, Брежневларга ук буе җитми җитүен, әмма матбугат секторы мөдире янына кереп ярты сәгатьләп сөйләшеп утыра ул. Наил Бариевичның (мөдир татар кешесе булып чыга) вазгыятьне үзгәртергә көченнән килми, әлбәттә, ләкин туктап калуның серен ачып бирә ул. Суслов кушкач, Үзәк комитетның мәдәният бүлеге «журнал кирәк» дигән нәтиҗә чыгара һәм тиешле документларны да әзерли. Югарырак баскыч — «Кече Политбюро» утырышында исә бер дәрәҗәле зат (сектор мөдире аның исемен әчмый) «Бу мәсьәләне әлегә кичектереп торырга кирәк!» дигән фикер әйтә. Һәм күпчелек шуны хуплый.

Татар журналы СССР дигән империягә зыян сала ала дигән шикнең җинеп чыгуы була инде бу. Шуннан соң Мансур Вәлиев җиңелгәндер яки чигенгәндер дисезме? Һич юк. Тарафдарлары белән өлкә комитетының яна секретаре Рәис Беляев янына бара ул. Беляев инде Мансурның фамилиядәше түгел, уен уйнамый, ихластан сөйләшә, мәсьәләне Үзәк комитетка барып хәл итмәкче була. Ләкин өлгерми кала: үзен эштән алалар. Аның урынына куелган Наил Кадермәтов исә мәсьәләгә тиз генә кереп китми, әмма кергәч, бер генә партия җитәкчесе дә эшләмәстәйне эшли. Үзәк комитетта: «Йә безнең яшьләргә журнал бирәсез, йә мине эштән аласыз!» — дип ультиматум куя ул...

Татар яшьләренә һаман журнал бирмәүләре хакында Рәсәй язучыларының чираттагы съездында (1988 ел) Туфан Миңнуллин да тәрәзәләр зеңелдәрлек итеп ярсып сөйли.

Бусы менә «Идел»нең беренче баш мөхәррире Римзил Вәлиев сүзләре: «1988 ел ахырында өлкә партия конференциясенә КПСС ҮК секретаре В. Медведев Горбачев хакимиятенең татарларга унай мөнәсәбәтен күрсәтүче «күчтәнәч» алып килде. КПСС ҮК секретариатының Казанда яшьләр журналын ачарга рөхсәт итүе турындагы карары иде ул. Гадәттә мондый карарга яна оешманың штатлары, сметасы беркетелә. Ә мәгълүм «күчтәнәч»тә «Идел» журналын ачарга рөхсәттән башка бер нәрсә дә юк иде. Ярты ел үткәч, 1989 елның җәендә, яна газет-журналлар ачу хокукы барлык өлкә, республика хакимиятләренә дә бирелде. Шулай итеп, «Идел» журналын татар җәмәгатьчелеге, республика җитәкчеләре ачты».

Шулаен шулайдыр да ул, әмма бу иң әүвәл — «листовкачылар», Татарстан Язучылар берлеге җитәкчеләре, мәшһүр аксакалларыбыз (журнал сорап төрле инстанцияләргә бирелгән үтенеч-мөрәҗәгатьләрнең барысы да диярлек аларның имзалары белән көчәйтелә), М. Вәлиев, И. Юзеев, Ф. Табеев, Т. Миңнуллин, Н. Кадермәтов кебек затлар катнашында озак еллар дәвамында барган көрәшнең, ниһаять, җиңү белән очлануы. Аннан, мондый «күчтәнәч» килмәсә, газит-журнал чыгару хокукына ия булгач та бу эш, бәлкем, сүлпәнрәк барыр һәм озаккарак сузылыр



*Разил Вәлиев (уңда) һәм Зөлфәт. (1966 елгы фото).*

иде әле (өлкә комитетының беренче секретаре да бүтән бит инде).

«Комсомольская правда»ның Идел буендагы элекке үз хәбәрчесе Римзил Вәлиев житәкчелегендә гаять мәшәкатьле һәм катлаулы оештыру эше башкарыла. Бу җәһәттән бик тә булдыклы һәм тәвәккәл кеше ул. «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе директоры Фәрит Иделле мина шаккатып болай дип сөйләгән иде:

— ...Римзил атнасына бер мәртәбә Татарстан һәм Башкортстан турында хәбәрләр тапшыра башлады. Аннары күпмедер вакыттан мин Римзилне, ныклабрак танышу өчен дип, Мюнхенга чакырдым. Бер тапкыр трубканы алсам, ул: «Мин килдем», — ди. Мин әйтәм: «Син кая килдең? Мәскәүгәме килдең, Берлингамы килдең?» «Юк, мин Мюнхенда», — ди. Һич аптырап тормаган! Ул вакытта Көнбатыш Германия белән Көнчыгыш Германия берләшмәгән дә бит әле...

Мине бер нәрсә бик нык гаҗәпләндерде: «Идел»не ачуга шулкадәр көч салган Мансур Вәлиевнең журналдан читтә калдырылуы.

«Идел»нең беренче саны 1989 елның июлендә дөнья күрде. Римзил Вәлиев житәкчелегендә аның тагын 17 саны чыкты. 1991 елның башыннан «Идел» аңарчы баш мөхәррирнең беренче урынбасары булган Фәиз Зөлкәрнәй имзасы белән чыга башлады.

Фәизне белә идем кебек инде үзе. Мин «Татарстан яшьләре»ндә чакта ул «Ялкын»да эшләде. Аннары бергәләп Татарстан китап нәшриятында да эшләп алдык. Жиренә житкереп редакцияли торган мөхәррир, ару гына тәнкыйть мәкаләләре яза, сирәк-мирәк шигырьләре дә күренгәли, күп сөйләшми торган ипле генә егет — күрше этажда эшләп, сирәк-мирәк кул бирешеп кенә киткәләгән Фәиз турында фикерем әнә шундый иде минем. Менә шул егет мине 1991 ел азагында «Идел»гә баш мөхәррирнең беренче урынбасары итеп чакырды. Шунда мин бөтенләй башка Фәизне күрдем. Иплелеккә ипле, ләкин сүзен кистереп, үткен итеп тә әйтә ала икән бит. Татар теле, татар тарихы, татар мәгърифәте мәсьәләсендә бик тә мәгълүматлы икән... Күрче, кабинетында егетләр белән кәеф-сафа корып та утыргалый икән бит бу дип башта сәерсенгән дә идем әле, соныннан исә төшенеп алдым: монын «кәҗәсе» бер өлеш булса, «мәзәге» ун өлеш икән бит. Шул рәвешле журналга оригиналь фикерле шәп авторлар җәлеп ителәә, яңа идеяләр эшләп чыгарыла икән. Фәизнең кызгылт-сары самавыры гел гөжләп торыр иде, савыт-сабаны да үзе үк жәлт кенә юып керер иде. Үз иҗатларына ялкынны шул самавыр янында алып, тиз генә үсеп китүчеләр дә булды. Шуларның берсе күпләр ул чакта әле жырчы дип кенә белгән Зөлфәт Хәким («Идел» «ярына» аны Римзил үк дәшә дәшүен). 1994 елның 1нче санында Зөлфәтнең «Диагноз — хроник ирексезлек» дигән бик шәп мәкаләсе, 4нче санында «Кишер басуы» дигән сатирик киноповесте, 1995 елда (№5, 6) «Әүлия кабере» дигән бәяны, «Гонорар» дигән сатирик хикәясе (№ 10) һәм 1997 елда (№1) «Гөнаһ» дигән романының өзекләре басылып чыкты.

«Идел» тәүге көненнән үк хөр-мөстәкыйль журнал булып яшәде. Шактый вакыт эчтәлек ягыннан гына түгел, матди яктан да: язылу акчасы һәм беркадәр реклама акчасы журналны тулаем тәэмин итәргә житәрлек була иде. Бездә эш хакы һәм каләм хакы да башка басмаларныкыннан мулрак иде...

«Идел» беренче саннардан ук милли журнал булып чыга башлады. Юкса милли күтәрелеш көчәйгәннән-көчәя барган бу тарихи вәзгыять бөтен башка гәҗит-журналларга да шул ук кимәлдә тәэсир итәргә тиеш кебек иде. Ләкин «орган басмалар»ның канына сеңгән буйсыну инерциясеннән арыну жиңел түгел шул ул. Аннан, сугыш дип вакытлыча гына ябылган өч татар яшьләр журналы урынына бер

журнал ачуны да еллар буена тыеп килү үзе генә дә «Идел»не чын-чыннан хөрлек тансыклаучы милли басма итешкәндер.


«Идел» ике телле журнал булып ачылды. Татар телендәге әсәрләр — русчага, рус телендәгеләр татарчага тәрҗемә ителде. Милли рух, милли эчтәлек рус телендәге журналда да саклана килде. Үпкәләргә урын юк: ябылган журналлар татар телендә чыккан бит. Ләкин берәүләр үпкәләргә жай таба: «Долой гл. редактора», «Журнал «Идел — рассадник националистической чумы» дигән плакатлар тотып 1990 елны кайбер урыс телле авторлар һәм жирле шовинистлар гәжит-журнал нәшрияты ишеге төбендә пикет уздыралар. Монда баш мөхәррирнең урыс телендәге журнал буенча урынбасары Әхәт Мушинский да катышлы дип әйтүчеләр бар. Әмма булган очракта да Ирек мәйданында Фәүзия Бәйрәмова башлап жибәргән, мөстәкыйльлегебез өчен үтә мөһим ачлык акциясендә катнашып, гаебен күптән юды инде ул.

Әйе, «Идел» чын милли журнал булып дөньяга килде. Фәиз Зөлкарнәй баш мөхәррир булгач, бу җәһәттән ул тагын да көчәйде. «Без тарихта эзлебез», «Каһарман бабаларыбыз», «Мәшһүр татарлар», «Шәҗәрә», «Татарларда диссидентлык», «Казан — Мәскәү», «Миллият», «Мәдрәсә», «Татар мәктәбе» кебек сәхифәләр (рубрикалар) аша укучылар милләтебезнең катлаулы тарихына һәм хәзерге милли-сәяси вазгыятькә ялгана ала иде. Ләкин моның өчен иң әүвәл күнелендә азмы-күпме милли аң булырга тиеш бит әле. Әмма 60—70 ел буена өзлексез алып барылган «интернациональ» тәрбия нәтижәсендә бик күпләрдә моның әсәре дә калмаган иде инде. Шаккатмалы хәл: татарга аның татар булып яшәргә тиешлеген аңлатырга кирәк иде! Сыерның сыер, атның ат булырга тиешлеген аңлаткан кебек. Бу җәһәттән күренекле галим Әгъдәс Борһанов һәм күренекле язучы Миргазиян Юнысның «Идел»дә чыккан акыллы һәм нечкә мәкаләләре бик кулай булды: «Мин нигә татармын?» (1995, № 8) һәм «Мин нишләп һаман татармын?» (1996, № 2). «Идел»челәр татарга татарлык йоктыруның әдәби ысулын да уйлап таптылар: тарихи хикәяләр аша. Әсәрне йотылып укып, татар каһарманнары өчен ут йоткан кешенең баш миендә дә, күнелендә дә печтик кенә булса да милли импульс тумый кала алмый инде ул. Тарихи хикәяләр конкурсы 1993—95 елларда барды һәм мин журналдан киткәч тә терелгәләп алды әле ул. Кызганыч ки, бу хикәяләрне китап итеп чыгару кадәресе генә кулдан килмәде.

Редакция үтә мөһим темалар даирәсен билгеләп (бигрәк тә милли, ижтимагый-сәяси юнәлештә), аларны югары кимәлдә ача алырлык авторларны үзенеке итәргә омтылды. Хәер, мөхәррирләр кисәргә-сызарга түгел, автордан кыю фикер өстәтергә ажгырып торган хөр матбугат кырын мондый авторлар үзләре дә тансыклаган иде инде. Бу — Әбрар Кәримуллин, Рашат Сафин, Дамир Исхаков, Рафаил Мөхәммәтдинов, Назыйм Ханзафаров, Зәки Зәйнуллин, Раиф Мәрданов, Ирек Һадиев, Рашат һәм Равил Әмирханнар, Мөхәммәт Мәһдиев, Рәфыйк Шәрәфиев кебекләр. Татар Мәскәве дә «Идел»не бик тиз үз итте. Миргазиян Юныс документаль-публицистик жанрда, кинәт тыны ачылгандай, рәхәт итеп язып китте. Галим Әгъдәс Борһанов, сәясәтче Мөхәммәт Миначев мәкалә арты мәкалә жибәреп тордылар.

Мәрхүм Рәис ага Тузмөхәммәдне аерып әйтү кирәктер. Ул — Россия Фәннәр академиясенең Дәүләт һәм хокук институтының житәкләүче фәнни хезмәткәре, юридик фәннәр докторы, халыкара хокук профессоры, журналыбызның «Миллият академиясе»ндә (1995 елда ачылган үтә кыйммәтле сәхифәбез!) берничә бик саллы мәкалә чыгарды, һәм тагын әле «Дәүләтара хокук дәресләре»н алып барды. Бик кирәкле дәресләр, туктый гына күрмәсен — мондый фикерне безгә Мәскәү эшмәкәре дә, завод слесаре да, авыл пенсионеры да әйтте. Тик... тукталды шул. Рәис агайның сәламәтлеге кинәт нык какшагач. 1996 елның 24 июнендә исә йөрәге дә тибүдән туктады.

Бу үлем тетрәндерде мине. Кечке Казан белән хозурланып икәү жәяү йөргәннәр искә төште. Аның атлап баруына шаклар каттым. Аз гына да көч куймагандай шулай жип-жинел һәм мап-матур итеп атлап барган кешене аңарчы да, аннан соң да күргәнем булмады минем. Киләсе елда житмешен тутырачак абзый, элекке боксчы, гүяки Жирдән түгел, тарту көче алты тапкыр ким булган Айдан атлап бара иде! Әмма тавышында борчылу галәмәте дә сизелә иде. Сораштыра торгач,



*Мансур Вәлиев*

беленде: күнелендә бик тә авыр татар гаме, Татарстан гаме ята икән анын. Россия Дәүләт Думасының «Милли азчылыкларның хокукларын яклау турында»гы канун лаиһәсен (проектын) эшләүче экспертлар төркеме житәкчесе буларак, борчылырлык сәбәпләрнең без белмәгәннәрен дә белгән инде ул, әлбәттә. Әмма Рәис агайны иң гажәпләндергәне, хәтта ки нәфрәтләндергәне күп кенә татарларның, шул җөмләдән түрәләрнең дә, татарлыкларын, намус-вөждан дигән нәрсәне тәмам онытып, шәхси гамьнәрен, үз карьераларын гына кайгырта бирүләре булган икән. Хәзер уйлыйм менә: карьерасына, сәламәтлегенә зыян сала-сала татар бәхете өчен көрәшүләр Рәис аганың үзенә бик рәхәт булган мәллә? Мәкаләләренең берсен «Намусым кушканга язам моны» дип башлап жибәргән иде ул... «Идел»гә исә рәхмәте зур иде анын.

Аны, «Юристларның Азия-Тын океан регионындагы хезмәттәшлеге ассоциациясе» президентын, Берләшкән Милләтләр Оешмасының генераль секретаре Бутрос Гали да белгән. Рәис агайның татар гамен гамьләп язган хатына жавапта, аны үз итеп, «син» ди ул: «Син беләсен инде...» Ләкин жавап үзе Рәис агайны канәгатьләндермәгән шул...

«Идел»нең баш мөхәррире Фәиз Зөлкарнәй белән «Казан утлары»ның баш мөхәррире Равил Фәйзуллин аралашып яшәделәр. Фәизебез Фәйзуллин янында озак кына утырып кайткалый иде, Равил дә килгәли иде, самавыр янында аны да күргән булды. Бер килүендә (1993 елның сентябрендә була бу) Фәизнең өстәлендә Салих Баттал кульязмасын күреп ала ул. «Кайдан? Ничек? Кемнән?» кебек өзек-өзек дулкынланып әйткән сорауларыма Фәиз Зөлкарнәй тыныч кына: «1994 елның башында чыгарырга әзерлибез», — дип жавап бирде. Бу әсәрне мин моннан егерме еллар элек белгәнемне, югалту тарихына «өлеш керткән шаһит» булуымны ишеткәч, ул минем шул хакта кереш сүз итеп язып бирүемне үтенде». — бу юллар нәкъ менә шул кереш сүздән инде. Ни була соң «егерме еллар элек», ягъни 1973 елның «мартларында»? Р.Фәйзуллин яңарак кына Язучылар берлегендә жаваплы сәркатип булып эшли башлаган чак икән бу. Берлекнең рәисе Зәки Нури анын кулына кульязма тоттыра һәм болай ди: «Салих Батталныкы бу. Мәскәү редакциясеннән жибәргәннәр. Әсәрне оешмада тикшереп, авторга фикер житкерүебезне сораганнар, мондый әйберне без баса алмыйбыз, дигәннәр. «Титул биткә Салих Баттал дип түгел, Иванов Иван Иванович дип куелган, — дип яза Фәйзуллин. Исеме — «Я отрекаюсь (исповедь)...» Ай-һай хәтәр юллар, баш китәр фикерләр! Мондый уйлар күпмедер дәрәжәдә безнең һәммәбездә дә бар барын. Тик болай итеп әйткән юк та, яза алган юк...» Шул көнне Язучылар берлегенең идарә утырышы була, анда партия өлкә комитетының инструкторы И. Хәйруллин да катнаша. Соңыннан Р.Фәйзуллин янына да кереп сөйләшеп утыра ул. Өстәлдә яткан кульязманы күреп, кайбер битләренә күз салгач, «Кая, мин дә укып чыгыйм әле», дип, алып та китә. Атна-ун көннән Фәйзуллин сорап карый, «Ул папка хәзер Вәлиевтә», диләр. Тагын бер айлап вакыт үткәч, Фәйзуллин бүлмәсенә КГБ кешесе килеп керә (шагыйрь куркып тормаган, анын фамилиясен дә язган) һәм «Салих Батталның кульязмасын Язучылар Союзы КГБ карамагына тапшыра» дигән белешмәне басып, кул куеп бирегез!» — ди. Фәйзуллин баш тарта. «Андый язуны бирә алмыйм, чөнки сез эшләгән оешмага бернинди кульязма биргәнем юк», — ди. Ялга киткән З.Нури урынына калып торган иптәш исә кушканны шундук үти. Ягъни «хәтәр» авторга карата чара күрүне Язучылар берлеге таләп итә булып чыга инде! Салих аганы төрле кабинетларда ничекләр эшкәрткәннәрдер, белмим, әмма партиядән чыгарулары хак. Әсәрнең Равил Фәйзуллинның кереш сүзе белән («Талантның кодрәте чиксез...) татар телендә «Идел» дә басылып чыгуы да хак (1994, № 1, 2).

Журналда татарның милли төркемнәре турында бай мәгълүмат биреп барылды. 1994 елда, әйтик, керәшеннәр (№6) һәм Кырым татарлары турында (№12) жидешәр



*«Идел»нең беренче саны чыгу сөенеченнән төшелгән фото.*

мәкалә басылды. 1995 ел башында «Идел»нең «Акыл казанын», ягъни Аналитик үзәген оештыру бик шәп эш булды. Кураторы — Дамир Исхаков, экспертлар Рафаэль Хәким, Рәфикъ Мөхәммәтшин, Рашат Әмирхан, Рафаэль Мөхәммәтдинов, Искәндәр Измайлов кебек галимнәр һәм сәясмәннәр (политологлар). Унлап кеше бергә жыелып (кирәк булганда белгечләр читтән дә чакырыла иде), һәр утырышта бер мөһим мәсьәләне тикшерделәр, фикерләр (кайчакта — бәхәсле киселештә) журналда басыла барды. 1995 елда: «Татарстанның икътисади үсеш моделе» (№2), «Татарстанмы, татар станымы?» (Милләт һәм дәүләтчелек), (№3), «Сәяси элитабыз» (№6), 1996 да: «Жәдитчелек һәм милли идеология (№1), «Татар тарихын ничек язарга?..» (№3) һ. б. Бу «Акыл Казаны», «Миллият академиясе» һәм кайбер аерым мәкаләләр, дәүләт житәкчеләребез, милли әйдәрләребез, сәясәтчеләребез белән үткәрелгән житди, тәфсилле әңгәмәләр «Идел»не нык тирәнәйтте, аны Татарстанның хәзерге курсына, милләт үсешенә әйбәт төзәтмәләр кертү өчен хәтта күпмедер дәрәжәдә идеологик база да була алырлык кимәлгә китерде. 1997 елның 2–7, 9–12 саннарында басылган «Татарстан референдумы» дигән документаль әсәр бу олуг вакыйганы тарихка асылда аның үзенең, ягъни референдумның «авторлары» булган затлар теркәп калдыруы жәһәтеннән кыйммәт. «Прокурорлар сугышы» дигән бүлек, әйтик, тулысынча диярлек Мәскәүдән референдумны үткәртмәскә дип килгән прокурорлар бригадасына батырларча каршы чыккан дүрт Татарстан прокуроры тарафыннан бәян ителгән. (Гөлсирә Гайнанова әсәрне бөтен күнелен салып тәржемә кылды. Бик булдыклы «Идел»чебез иде бу!)

Бер тарихи казусны белүчеләр бардыр әле. 1991 елның 12 августында Казан белән Мәскәү тигез хокуклы сөйләшүләр башлап жибәреп, Мәскәү делегациясе белән озак барган үтә киеренке бәхәс-көрәштән соң Татарстан делегациясе үзе омтылган гадел Шартнамә текстын Рәсәй делегациясенең дә раславына ирешә. Делегация составында Фәндәс Сафиуллин да була. 1994 елның 15 февралендә Шартнамәгә кул куела. Әзер, расланган текстның ни рәвешле үзгәртелүен белгәч, Фәндәс абый инфаркт ала яза. Беренче текст нинди булган соң? Моны хәзер бары «Идел» журналыннан гына белә аласыз: 1995, № 2.

Мөхәммәт Мәһдиевнең «Татар провокаторлары (XX йөз башы татар зыялылары арасында патша хөкүмәте агентурасы)» дигән мәкаләсе — зур. Провокаторларыбызга бер санда гына урын житмәгән, ике санда бирелгән! Хәзер дә актуаль түгел микән бу тема?

Батулланың «Карчыга» дигән документаль әсәрен (2001, №1) шаклар катып,



*Фәиз Зөлкарнәй*

сокланып укыдым. Фатыйх Мөсәгыйтьнең, үзе белән дә озак кына сөйләшеп, чын образын тудыра алган ул. Наданрак бер тәнкыйтьче Сталин заманында бөтен әдәбият халкын дер калтыратып торган!

1992 елның сентябрь башында булды бу. Редакциягә Зәки Зәйнуллин килеп керде. Чәчәнстан-Ичкериягә барып кайткан икән, шунда башыннан кичкәннәрен сөйләде. «Яз син моны, Зәки абый, тәфсилләп яз», — дидек. Бер атна үттеме-юкмы, килеп житте. Язган. Тәфсилләгән. Шул җөмләдән Рәсәйнең элекке хәрби базасында Дудаевка ничек итеп ике атом бомбасы табып бирүен дә язган. Дудаев ул чакта Мәскәүгә дошман ук түгел әле. Аны президент итүгә Мәскәү дә көч салган. Үз генералы бит!

Базада атом яки водород бомбалары калмады микән дип генерал Дудаев үзе дә шикләнгән. Ярдәмгә полковник Зәйнуллинны дәшкән инде. Чөнки ул биш ай Семипалатинск полигонында укыган-өйрәнгән, аннары дүрт ел инженер булган, ана мондый бомбаларны жыярга-сүтәргә дә туры килгән икән... Кыскасы, 1993 елнын 1нче саны дөнья күрде, «Дудай батыр» дигән зур очеркта «Ике бомба» дигән бүлек тә бар иде. Тышлыкка ук чыгарып, татарча журналда «Дудаевка ике атом бомбасы» дип, русча журналда исә «Атомные бомбы Дудаева» дип язып куелган.

Көтәбез инде. Менә шартлый, менә шартлый дип. Бомбалар түгел, сенсацион һәм үтә мөһим хәбәребез. Көннәр, атналар, айлар үтә тора — тынлык. Югыйсә ничәдер йөз грамм «атом крәчине» — уран, плутонийише нәрсәләр югалганда да кара тавыш чыга торган иде... Һәм менә, ниһаять, өч ел тула дигәндә, «Комсомольская Правда» йодрык хәтле хәрефләр белән «У Дудаева есть атомные бомбы!» дип шәррән ярды (1995 елнын 1–8 декабрь саны). Урыс акылы да төштән сон икән, әмма, шөкер, бар икән дип уйлап куйдык инде. «Комсомолка» «Идел»дәге очерктан теге бүлекне тулысынча диярлек күчереп баскан.

— Йә, шуннан сон ни булды? — «КП»нын хәбәрчесе Б. Вишневский Зәки агайдан әнә шулай дип сораган. Жавап мондый була:

— Жаһар минем күз алдында корпусларнын номерларын, атом бомбаларынын индексларын күчереп алды, аннары президент Ельцинга хат язып жибәрде... Хатына жавап алмаган ул...

Шаккатмалы хәл: бу, күрмәскә һич мөмкин булмаган хәбәрне дә күрмәгәнгә салыштылар.

«Идел» чыга башлавынын икенче елында ук бик шәп тираж жыйды: 115 мен (татарча журналныкы — 93,7 мен, русчаныкы — 21,2 мен). «Казан утлары»ныкы ул чакта 81,3 мен иде. Шуннан сон матбугатта тираж төшү тенденциясе башланды, ләкин «Идел»некенә тагын бер нәрсә бик начар тәэсир итә: дәүләт карамагындагы журнал түгел дип аны почта аша тарату хакын, бары аныкын гына, дүрт тапкыр арттыралар. Югыйсә «Идел» 1989 елда да, 1990 елда да шундый журнал иде бит. Ана тормоз салу «артык хөр» һәм «артык популяр» булганга түгел иде микән?

Яшьләр журналы яшьләргә ни биргән сон, диярсез. Мәкаләмдә мин милләтебез өчен ин кирәкле мәлдә эшләнгән үтә мөһим эшне үзәккә куйдым. Әмма бу — яшьләргә кирәкмәгән, артык әйберме? Аларга милли гамьне кемдер индерергә тиештер бит инде. Татарнын киләчәге өчен көрәштән яшьләр өзелеп калса ни булыр? Аннан, яшьләр журналда чыккан әдәби әсәрләрне укымаска тиешме? Аларнын үзләрен ижатка тарту жәһәтеннән исә «Танышу» сәхифәсе ачылды, «Ләйлә-Мәжнүн» дигән мәхәббәт шигырьләре һәм «Йосыф-Зөләйха» дигән мәхәббәт хикәяләре конкурслары, фантастик хикәяләр конкурсы үткәрелде һәм даими рәвештә диярлек «Ша-Ярыш» (шаян ярыш) барды. Мирхәйдәр Фәйзи «Галиябану»ны берне язса,

безнең авторлар жидене язды — «Егерме беренче гасыр башы «Галиябану»ын! «Идел» ике шаян сан, ике мәхәббәт саны, ике романтик сан чыгарды. Яшьләр күңелен ачарлык ваграк сәхифә-сәхифәчекләр дә күп иде... Кыскасы, «Идел» бу җәһәттән дә алда барды. Башта, замана шаукымына бирелеп, ярымшәрә кызлар рәсемнәре дә баса башлаган иде «Идел». Әмма Фәиз баш мөхәррир булгач тукталды бу эш. Һәм... «Әхлак» дигән сәхифә ачылды.

Бөтен ягы килгән һәм тормышка да тәэсир итә алырлык көчле журнал булып «Идел» 4-5 ел эчендә калыплашты. Моны бары кушканны үтәүчеләр түгел, чын шәхесләр генә башкарып чыга ала иде. Алар өчәү иде: Фәиз Зөлкарнәй, Нәбирә Гыйматдинова, Ркаил Зәйдулла. Ркаил — әдәбиятның, юморын-сатирасын да кертеп, бөтен төрләрен-жанрларын да иярләрлек, үз фикере чәчрәп торган талантлы язучы. «Ркаил каланчасы» дигән рубрика да бирелде әле ана.

Нәбирә Гыйматдинова «Идел»гә бик тә-бик тә кирәк булып чыкты. Житди әйберләрне журналда шактый мул биргәнгә, халык ябырылып укырлык шәп проза әсәрләренә ихтыяж зур иде. Нәкъ менә шундый бәяннарны тукып кына торды Нәбирәбез. Ивановода эрләүче булырга укыган, Казанда штукатур-буяучы булып эшләгән кызый Милли китапханә ин күп укылган китапларга үткәргән конкурста бер заман китабы саен беренче урынны ала башлар дип кем уйлаган! «Елга ике повесть яз!» дип, «Кирәк булса, өенә кайтып та эшлә» дип әйтә торган идек без ана. Тырыш иде Нәбирәбез, күп сәхифәләргә кергәли иде. «Адәм белән Хәва» дигән үз сәхифәсен исә телевидение чәлдерде! (Һәм Ркаил бик яраткан «Һәйбәт гайбәт»не дә). Нәбирәгә укучы хатлары бик күп килә иде. Шуна күрә «Иделгә, Нәбирә Гыйматдиновага» дигән махсус сәхифә дә ачтык әле.

Фәизебез башкарган зур эшләрне исә санап бетерерлек кенә түгел. Әллә кем булып түш киереп йөрүчеләр күп ул, тормышны алга җибәрә торган тәгаен эшләр эшләүчеләр генә аздин аз, ләкин аларны да еш кына күрмәмешкә салышабыз, күрсәк тә бик тиз онытабыз. Фәиз Зөлкарнәйне онытмасак иде. 1997 елның 17 июлендә, машиналар бәрелешкәннән сон дөнья куйды. Яна Бистә зиратындагы кабере Тукай ягына борылган урыннан чак кына ары. Зират капкасыннан кереп туп-туры барганда исә уң якта, зур кара һәйкәл каршында Сәйфихан Нәфиев кабере кала. Мәскәү прокурорларына Татарстан референдумын өзәргә юл куймаган төп ике кешенен берсе бу. Ул чакта Казан прокуроры иде, аннары Татарстан прокуроры булды... Татарстан прокуроры Антонов Мәскәүнекеләр алдында ләббәйкә баскач, анын урынбасары Марсель Мусин законсыз эшкә Татарстан прокурорлары арасында каршылык хәрәкәтен оештырды. Марсель агай, шөкер, исән әле. Ләкин аны олылау, кадерләү бармы сон? Референдум көнендә булса да шалтыратып котлау дигәне генә дә юк кебек бит!

Фәиздән сон, шөкер, баш мөхәррир Рашат Низами белән ару гына эшләп алдык: бер әйбәт эшкә дә аяк чалганы булмады анын.

Русча «Идел»не жигелеп тарткан Роза Кожевникова (урынбасар) белән Сергей Малышевнын дөнья куйганнарына да шактый инде. Урыннары җәннәттә булсын!

«Идел»дә Туфан ага Миннуллинның безгә һәм киләчәк буыннарга васыяте кебек язмасы басылды: «Татарның әхлакый кодексы». Туфан абый аны үзе эшләгән һәм аннары Разил Вәлиев, Миркасыйм Госманов, Рәшит Ягъфәров белән дүртәүләп чарлаганнар. Кодекс 12 пункттан тора, 2004 елның һәр санында берәр пункт һәм Туфан абыйның шуна кагылышлы фикерләре бирелгән. 1нче пункт менә мондый:

**Татар кешесе! Хәтереңә ал! Синең үз мөстәкыйль дәүләтең булган. Дәүләтле милләтләрнең генә жир йөзендә кадере була. Һәр татарның күңелендә йөргән дәүләтчелек идеясе — саклансын. Шушы тарихи гаделлек өчен үзең һәм нәселең көрәшергә тиеш.**

«Идел» турында тагын бик күп язып була да ул, ләкин мәкаләне шушы урында очлап торыйк әле...

**Рәфикъ ЮНЫС**



# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

**Габдулла ТУКАЙ**

## Лөгатьләр

Чөгендер – бу бик ижтиһад белән эчүчеләрнең борыннары урынына чыга торган жимеш.

Кәбестә – гомум монафикъ муллалар башы, чөнки ул баш катлау-катлау. Һәр катлавында бер кирегә атлау.

Сарымсак – яһүдинең ашказанында үсәр бер жимештер.

Миләш – исереп, дин ачуы чыккан агай-эненең күз алмасы.

Кызыл вә кара карлыганны, бүтән исем табудан «гажиз» булганлыгымнан, ашый торган мәржән дип кенә атыйм.

***

«Ярлының углы булганчы, байның колы бул», дигәч тә, баеңның һәр төчкерегенә «ярхәмекә Алла», дип торма вә бер йөткерүенә авызына кәләпүшенне куйма.

***

Биисе килмәгәннең көе килми. Татар бае гәзит сөйми.

***

Татар шәкертен кеше ясар өчен, иң элек аның «вәкар»ен бозарга кирәк.

***

Мәсжед – муллаларның өч ишекле кибете.

***

Көтепханә – Казан татарларының фаразынча, эшсез кешеләр кереп утыра торган бер урын.

***

«Сүзең көмеш булса, тик торуың алтын», – дигән булалар; алай түгел, телсезләр һәммәсе миллионер булып беткән булырлар иде.

***

...Язам, язам – кая көлкесе; урман, урман – кая төлкесе.

**Мохтар АУЭЗОВ**

## Абай

*Казакъның язма әдәбиятына нигез салучы бөек акын, аһәңсаз Абай Кунакбаевның яшьлегендә кияү егете булып килгән мизгеле — романнан бер өзек.*

...Каршы яктан хатын-кызлар көлешкән тавышлар ишетелде. Аннары шуна чулпы чыңнары кушылды. Кияү егетен каршы алырга килүчеләр икән.

Егетләр бергә жыелышып торалар иде. Хатын-кызларның алгы рәттәгеләре:

— Абай кайсы?

— Кияү кайсы була?

— Нигә барысы да бертөрле киенгәннәр? Абай нигә кияүчә киенмәгән? — дип сөйләнә-сөйләнә килеп, исәнләшә башладылар.

Абай бу сүзләрне ишеткәч, башта жайсызланып, каушап калды. Аннан, үз-үзен кулга алып:

— Кайсыбыз күңелегезгә күбрәк ошаса, шул Абай булсын! — дип көлде.

**Фатих КУТЛУ**

## Рамазан аенда

Төрекнең шагыйрьләр солтаны Нәжип Фазыл белән Назым Хикмәт, икәү бер машинага утырып, конференциягә баралар икән. Нәжип Фазыл — уразада. Назым Хикмәт, гадәтенчә, ураза тотып мәшәкатьләнми.

Назым Хикмәт, юл кырыенда яткан арык сыерга ымлап:

— Нәжип, кара әле теге мескенне, ураза тота-тота нинди хәлгә калган, — ди.

Нәжип Фазыл югалып калмый:

— Бәй, Назым, син хайваннарның ураза тотмаганын белмисенме әллә?! — дигән.

***

Нәжип Фазыл вокзалга ашыгып килсә дә, өлгерә алмый кала, поезд аның борын төбеннән генә кузгалып китә.

Берәү, аннан көлеп:

— Нәрсә, ычкындырдыңмы поездны? — дигәч, Нәжип Фазыл:

— Юк, мин аны үзем куып жибәрдем, — дигән.

**Туфан МИҢНУЛЛИН**

## Каләмдәшләр каләменнән...

Без, татарлар, тәмле ашарга яратабыз. Шуна күрәдер инде ничек сыйланганыбызны язган әсәрләребезгә дә кертәбез. Әйтик, татар язучыларының һәм шагыйрьләренең кайберләре табынны шулайрак сурәтли.

**Аяз Гыйләжев:**

— Дошманы дип тормады алтатарлы Исмәгыйль, гармунчы Хәлилне, кунакка

чакырып, бик шәпләп сыйлады. Анын түгәрәк битле, мул күкрәкле хатыны Галиябану өстәлгә ризыкны ташып кына торды.

Алтын төсенә кергәнче хасиятләп кыздырылган кырык алты каз, махсус савытта парда гына күпертелгән егерме ике үрдәк. Әчтерханнан кайтартылган жиде кило ярым кара уылдык, башы-койрыгы кетердәп кенә торган сигезәр килолы өч чөгә балыгы, бер яшьлек елкыны ике ел симерткәннән соң суеп эшләнгән унбиш кадак казылык, кеше саен ике йөз илле исәбеннән бөгелгән кияү пилмәне, унсигез чуклы башлы ананас, Фудзияма тавын хәтерләткән чәкчәк өеме — барысы да өстәлгә куелды.

**Миргазиян Юныс:**

— Безнең пароход Испаниянең Картахена дигән портына килеп туктады. Без, буш вакыттан файдаланып, шәһәрнең иң затлы ресторанына ашарга кердек. Ресторан хуҗасы кабальеро Сервантес, йөгереп кенә йөреп, безгә хезмәт күрсәтте. Без сантандер, ла корунья, аликанже эчтек. Тозлы уэльва, үз соусында әзерләнгән альлирия капкалап утырдык. Ә инде тамакны туйдыру өчен дуэрода, сантусланган гвариана һәм хихон ашадык.

**Мөдәррис Әгъләмов:**

— Өч көн бәйрәм иттек дуслар белән,
Бәйрәмчә мул иде ашы да:
Кильки дисең, вобла кабыргасы,
Хәтта селёдканың башы да.

**Марсель ГАЛИЕВ**

## Хикмәт нәрсәдә?

Узган гасырның сиксәненче еллары. Язучылар Союзы рәисе Гариф Ахунов Мәскәүдән һәм чит илдән килгән әдипләрне кунак итә. Казан урамнарын күрсәтеп йөри. Урамнар комлы-тузанлы, әллә каян гына жил чыга да Казан ханлыгы чорыннан бирле әйләнештә йөргән тузанны биткә китереп сылый. Жилнең мондый да тәрбиясез кыланышыннан тәмам туеп, теш арасында ком бөртекләре шыкырдый башлагач, Сергей Михалков иптәш Ахуновны читкәрәк алып китә дә, дулкынлануыннан тотлыга-тотлыга:

— К-к-Казаныгызны әйтерием. Ч-ч-чит ил кунаклары алдында оят. Нинди пычраклык бу! Мәскәү белән чагыштырырлык та түгел!.. — ди.

— Ә сез чагыштырмагыз да, Сергей Владимирович, — ди Ахунов. — Мәскәүнең дворниклары татарлар бит, ә Казанның урам себерүчеләре — урыслар.

Юморны бәяли белгән Михалков шаркылдап көлә башлый. Ахуновның жилкәсеннән кага:

— Шәп әйттең. Молодец! Минем үземдә дә татар каны бар бит, ничә процент икәнен генә кистереп әйтә алмыйм...

— «Т» авазын тотлыгып әйтүегездән үк сизгән идем мин аны, — дигән Гариф Ахунов.

*Сәхифәне* **Марсель ГАЛИЕВ** *әзерләде.*

Балачак белән яшьлек арасындагы
гүзәл дөньяда яшәүчеләр, бу — безнен сәхифә!



***Илүзә Кашапова** – бик сәләтле укучы. Дәрестә бирелгән эшләрне иҗади якын килеп башкарырга ярата. Аның сочинениеләре үзенчәлекле, тирән фикерле. Башкалар игътибар итмәгән гади генә нәрсәләрне дә ул серле итеп тасвирлап яза белә. Үзе шигырьләр, хикәяләр иҗат итә.*

*Илүзә Кашапова быел Мөслим гимназиясенең VII сыйныфын тәмамлады.*

# ФАТИХАЛЫ ГОМЕР

1940 елның кышында Әмирхан белән Әминәнең тормышын тулыландырып, гаиләгә шатлык өстәп, зәңгәр күзле, сары чәчле кыз дөньяга аваз салды. Нәни иреннәре янында җиләккә охшаган кечкенә генә миңе бар. Әминәнең үзендә дә бар андый миң. Ул аңа сөйкемлелек өсти, елмаюын мәгънәле итә. Баласында нәкъ шундый миңне беренче тапкыр күргәндә, Әмирхан сөенечен яшерә алмады: «Җиләк кебек тәмле кызым», — дип сөйде.

Балага исем кушкан көннән Әминә бик каты авырый башлады. Әмирхан хатынын тәрбияли, тизрәк аякка бастыру өчен тырыша. Кызын әнисе куенына күтәреп сала да, читкәрәк китеп, сабыеның әнисе кочагында назлануын күзәтеп тора. Яшь ананың аяк-куллары сызлавына түзә алмаслык вакытлары була иде. Көчле авыртулар башланганда, Әмирхан күкрәк сөте имеп яткан сабыен тизрәк кулына ала, Әминәгә ничек ярдәм итәргә белми чарасыз кала. Кечкенә Миңсылу, әтисенә үпкәләгән кебек, нәни иреннәрен турсайтып ала да, аңлыйм хәлегезне дигән кебек, тыныч кына йокыга китә. Бик тере, хәрәкәтчән булса да, сабыр иде Миңсылу.

Әминәнең бәбидән соң өзлегеп китүе турындагы хәбәр беркемне дә битараф калдырмады. Күршедә ялгыз гомер итеп ятучы Сәрби әби һәр көн саен яңа сауган кәҗә сөте алып керә. Аллага тапшырып, борынгылардан ишетеп белгән алымнар белән яшь хатынны мунчада дегет сабыны белән сылый, төрле дәвалау чараларын сынап карый башлады. Әминә Сәрби әбинең шифалы кулларының дәвасына өметләнә иде.

***

1941 елның җәйге бер иртәсендә бөтен ил өстенә кайгылы хәбәр таралды. Август аенда хат ташучы Әмирханга повестка китерде. Әмирхан, авыру хатынын, яшь баласын калдырып, сугышка китте.

Әминә үзе генә Миңсылуны карарлык хәлдә түгел иде. Сәрби әби үзенең кирәкле әйберләрен төенчеккә төйнәде дә, ишегенә йозак салып, кәҗәсен

ияртеп, Әминәләргә яшәргә күчендe. Карчык олы яшьтә булса да, җитез хәрәкәтле, бөтерчек кебек иде. Әминәгә үлән сулары эчерде, иртәнге чыкта аунатты, кәҗә сөте кайнатып эчерде. Сәрби әбинең тырышлыгы бушка китмәде. Әминә күзгә күренеп тернәкләнде. Миңсылуны кулына алып күкрәгенә кысканда, күзенә яшь килде. Әминә өчен үз аягында йөрү зур бәхет иде. Бераз хәл кергәч, Сәрби әбигә әкренләп хуҗалыктагы вак-төяк эшләрне башкарырга булышты. Озакламый Миңсылу да «эшкә» ярый башлады. Аякка баскач, Сәрби әбигә ияреп, лапаска кәҗә саварга чыкты, ике тавык һәм әтәчкә җим салды.

***

Әминәгә Әмирхансыз бик авыр иде. Миңсылу әтисен сорап җанга тия. Фронттан җибәргән сурәтен кочаклап, Миңсылу аңа матур сүзләр әйтә. Яшь хатынның үзәкләрен өзеп, багырьләрен өтеп ала иде бу күренеш. «Сабыебыз бәхетеннән, берүк исән-сау гына кайтырга язсын инде», – дип үзалдына сөйләнеп куя Әминә.

Юк, аямады сугыш аларны...

1944 елның буранлы кышында хат ташучы, Әминәгә туры карарга кыймыйча гына, өчпочмаклы хат тоттырды. Хатны ачып укымаса да, Әминә анда яхшы хәбәр түгеллеген чамалады. Хат «Өлкән лейтенант Хәбиров Әмирхан Сабир улы сугышта батырларча һәлак булды...» дигән сүзләр белән башланган иде. Әминә, күз яшьләрен Миңсылуга күрсәтмәс өчен, чоланга чыгып, каһәр суккан сугышны каргый-каргый елады.

...Бер-бер артлы көннәр үтә торды. Миңсылуга дә биш яшь тулды. Сәрби әби авырып урын өстенә калды. Ул елларда колхозда эш бик каты иде, Әминә колхоз эшеннән кайтып кермәде. Сәрби әбине карау кечкенә Миңсылуга йөкләнде. Миңсылу әбисенә үлән чәе эчертте, урын-җирен рәтләде, аны бер минутка да ялгыз калдырмады. Көн буена Сәрби әби янында аның кәефен күтәрергә тырышып, ягымлы сүзләр сөйләп, олыларча кайгыртып йөрде. Сәрби әби үзен бу гаиләнең үз кешесенә әверелгәндәй хис итә иде. Миңсылуның шифалы кулларында ниндидер тылсым тоя, йомшак теленнән дәва таба иде карчык. Ул Миңсылуны рәхмәт фәрештәләренә тиңли, кешеләрне дәваларга сәләтле булуын күреп сөенә иде. Үз хәлен аңлап, Миңсылуга белгән дәвалау серләрен өйрәтергә ашыга. Сәрби әби озак авырмады: авыз эченнән генә догаларын укып яткан җирдән, бу йортка бәрәкәт теләп, хәер-фатыйхасын калдырып, бакыйлыкка күчте.

***

Сугыш үткән урыннарда урнашкан балалар йортларын тылга күчергән вакытта, Әминә украин кызы Оксананы тәрбиягә алды. Ап-ак йөзле, үтә ябык, гәүдәгә Миңсылудан әллә ни артык булмаган бу кызчык, аны күрүгә: «Мамочка, милая, пойдём домой!» – дип, кочагына сарылды. Әминәдә үз анасының чалымнарын тапкандыр, күрәсең. Иреннәре өстендә Оксананың да нәни генә миңе бар икән. Бөтенләй үз кызы диярсең... Авыл кешеләренең: «Башыңа тай типмәгәндер бит, үз тамагыңны көчкә асраганда, ятим бала карарга ничек йөрәгең җитә?» – дигән сүзләреннән соң шикләнеп тә калган иде югыйсә.

Әминә баланы кире кагарга үзендә көч таба алмады. Тиз арада документлар әзерләп, рәсмиләштереп тә куйды.

Миңсылу Оксананы бертуганы кебек кабул итте. Хәлсезләнгән, ачлыктан йончыган авыру кызчыкны ул бер дә үзенең игътибарыннан читтә калдырмады. Сәрби әбисенең ничек дәвалавын искә төшереп, Оксанага көн саен яңа сауган кәҗә сөте эчерттеләр. Аллага шөкер, бәрәңгесе, сөте булган кешеләргә ачлыкны җиңәргә була...

Оксана күзгә күренеп тазарып китте, кешеләр белән аралаша башлады. Элекке куркаклыгы, шикчел карашы, йомыклыгы бетеп бара. Төнлә сискәнеп уяну, куркып елаулары да сирәкләнде. Әминә кызларының татулыгын, бер-

берсе өчен өзелеп торуларын күреп сөенеп туя алмый, теге вакытта кешеләр сүзенә карамыйча, Оксананы үзенә алуына үкенми ул.

Сугыш тәмамланды. Көн артыннан көн, ел артыннан ел уза торды, сугыштан соң тормыш бераз рәтләнеп китте.

Миңсылу белән Оксанага быел җиде яшь тулды. Мәктәпкә бару өчен, әниләре иске киндердән букча тегеп бирде аларга. Миңсылу мәктәптә алдынгы укучы, әнисенең горурлыгы булды. Оксана да татарча ипле генә итеп сөйләшә башлады.

Мәктәпне «яхшы» билгеләренә генә тәмамлап, Миңсылу Казанга юл тотты, Оксана балалар бакчасына тәрбияче булып эшкә урнашты. Миңсылуның теләге табибә булу иде. Монда да сынатмады ул. Институтны «кызыл диплом»га тәмамлап, Казанда республика хастаханәсенә табибә булып эшкә урнашты. Шәһәрдә авыл кызына үзен табу җиңел булмады. Нинди генә эшкә алынса да, Миңсылуның күз алдына ак фәрештә булып Сәрби әбисе килеп баса, аңа көч бирә. Аның сынатырга хакы юк, чөнки бу юлны ул үзе сайлады. Сәрби әби фатихасын алган кыз тырыш хезмәте, авыруларга карата шәфкатьлелеге, үз өстендә туктаусыз эшләве аркасында абруйлы табибә булды. Миңсылу Әмирхановнаның үзенчәлекле дәвалау ысуллары, шифалы куллары турында сокланып сөйләделәр. Кызы турында мактау сүзләре ишетү ялгызы бала үстергән ана өчен горурлык иде. Әминә апа лаеклы ялга чыккач, Оксана белән бергәләп кызы янына күченеп килделәр. Әминә апаның шатлыгы эченә сыймады.

***

Барысы бергә чәй эчеп утырганда, ишек шакыдылар. Акрын гына торып, Әминә апа ишекне ачты. Ишек төбендә ап-ак чәчле, ябык кына бер абзый басып тора иде. Ул беренче булып эндәште:

— Исәнмесез! Мин Степан атлы булам! Оксана Бондарчук бу йортта торамы?

— Исәнмесез! Әйе. Оксана, кызым, сиңа килгәннәр!

Әминәнең күңеле нидер сизенгәндәй, йөрәге ашкынып тибәргә тотынды. Оксана үз бүлмәсеннән чыкты, таныш кешегә караган кебек, бусагада торган ир-атка текәлеп карап торды. Степан кызның ирен өстендәге миңен күреп, ишек катында басып торган Оксананың үз кызы икәнен таныды.

— Кызым!

— Әтием!

— Кызым, күпме еллар эзләдем мин сине! Менә нинди булгансың син! Сагындым сине, кызым!

Оксананың күзеннән яшь бәреп чыкты. Ата белән бала арасыннан күзгә күренми торган җылы дулкын үтте.

— Әтием, мин дә сезне бик сагындым! — диде кыз, күз яшьләрен йота-йота.

...Таң атканчы сөйләштеләр алар. Әтисе кызын Украина якларына алып китәчәген әйтте. Әминәне үз әнисе дип танып, аны кадерләп яшәгән Оксана алдагы тормышын берничек тә аннан башка күз алдына китерә алмый иде. Барысы да тып-тын калып, сагышлы уйларга чумып утырган минутларда һәркайсы алдагы көннәргә план корды. Назлы сүзләр, рәхмәтләр күп әйтелде, яшь аралаш көлүләр дә, юатулар да шактый булды бу кичтә. Аерылуны йөрәге белән аңласа да, Әминә Оксана белән хушлашырга әзер түгел иде әле.

***

Степан Казанда бер атна кунак булганнан соң, кызлары өлкәннәр өчен көтелмәгән тәкъдим ясады. Алар Степан белән Әминәне картлык көннәрендә бергә күрергә теләүләрен, барысы өчен дә шулай яхшырак булачагын әйттеләр. Балаларының фатихасы белән, Әминә апа һәм Степан бергә тормыш кордылар.

### ФЕСТИВАЛЬ

Мамадыш районы Җөри авылында XV Республика керәшен мәдәнияте фестивале булды. Аны «Питрау бәйрәме – кечке Сабантуй» дип тә йөртәләр.

Тантананы Мамадыш муниципаль районы башлыгы Анатолий Иванов ачты. Бәйрәм флагын күренекле актёр Наил Дунаев күтәрде. Кунакларны Татарстан Республикасы Премьер-министры Илдар Халиков котлады.Ул шулай ук Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миннехановның тәбрикләү хатын ирештерде.

Төнге икегә кадәр барган бу бәйрәмдә халык төрле ярышларда катнашты, күңел ачты. Көрәшчеләр Ильяс Галимов, Раил Нургалиев һәм Илдар Гыйниятуллин үз үлчәү авырлыкларында Питрау Сабан туе батыры булып танылдылар. Аларга бәйрәмнең төп бүләге – җиңел автомобильләр тапшырылды.

### ХАЛЫКАРА СИМПОЗИУМ

«Казан Кремле» музей-тыюлыгында скульптура сәнгатенә багышланган «Таш моңы» дип аталган халыкара симпозиум булды.

Аны ТӨРКСОЙ халыкара оешмасы, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, В.Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтының Казан филиалы, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлеге оештырды.

Анда Казаннан, Мәскәүдән, Кырымнан, Бакудан, Истанбулдан бер төркем сынчылар катнашты һәм үзләренең иҗат эшләрен тәкъдим итте.

Симпозиумны ачу тантанасында «Казан Кремле» музей-тыюлыгы директоры Зилә Вәлиева, Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова, Россия Рәссамнар берлегенең Татарстандагы бүлеге рәисе Виктор Аршинов, Суриков исемендәге Мәскәү сәнгать институтының Казан филиалы директоры Мәхмүт Ваһапов чыгыш ясады.

### ФӘННИ-ГАМӘЛИ КОНФЕРЕНЦИЯ

Казанда Россиянең китап нәшриятлары ассоциациясе химаясендә «Төбәкләрдә китап нәшриятының көндәшлеккә сәләтен үстерү» дигән темага фәнни-гамәли конференция булып үтте. Чарага Россиянең 23 шәһәреннән вәкилләр килде.

Конференциянең пленар утырышында Татарстан Республикасы матбугат һәм гаммәви коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесенең беренче урынбасары Нурия Беломоина, ТР мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова, «Китапчылар гильдиясе» президенты, Мәскәүдәге «Библио-глобус» сәүдә йорты холдингы директоры Борис Есенькин һ.б. чыгыш ясады. Алар китап бастыруга дәүләт ярдәме, нәфис әдәбиятны популярлаштыру, нәшриятлар арасында үзара хезмәттәшлекне үстерү мәсьәләләрен күтәрделәр.

Конференция барган көннәрдә «Татмедиа» бинасында апрель-май айларында Мәскәүдә узган «Елның иң яхшы китаплары» конкурсында җиңгән, 2013 елда төрле нәшриятларда дөнья күргән иң уңышлы китаплардан торган күргәзмә дә эшләде. Анда Татар энциклопедиясе институты әзерләгән «Татарстан. Иллюстрированная энциклопедия», Татарстан китап нәшрияты чыгарган «Татар китабы» альбомы, «Нәниләр тел өйрәнә» сүзлеге дә бар иде. Китап күргәзмәсен ачу тантанасында Татарстанның халык шагыйрьләре Ренат Харис, Разил Вәлиев, Роберт Миңнуллин, ТР Язучылар берлеге рәисе Рафис Корбан һ.б. катнашты.

### ХАЛЫКАРА ҖЫР КОНКУРСЫ

«TURKVISION» халыкара җыр конкурсы 19 ноябрьдә (ярымфинал), 21 ноябрьдә (финал) Казанда, «Татнефть-Арена» боз сараенда үтәчәк. Былтыр ул Төркиядә булды. Анда 24 илдән җырчылар катнашты.

### КҮЧМӘ УТЫРЫШ

Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитетының күчмә утырышы булды.

Татарстанда мәдәни мирас һәйкәлләрен, шул исәптән муниципаль берәмлекләргә караган, аларның биләмәләрендәге тарихи-мәдәни кыйммәткә ия корылмаларны саклау һәм янарту мәсьәләләренә багышланган бу чара Арча районы Яңа Кырлай авылында үткәрелде. Биредә катнашкан депутатлар галимнәр, эшкуарлар, язучылар,

журналистлар белән бергә әлеге төбәктәге тарихи-мәдәни һәйкәлләрне, аерым алганда Иске Казан музей-тыюлыгын, Иске Чүриле авылындагы Казан Изге ана гыйбадәтханәсен, Урта һәм Югары Курса авылларында мәчет һәм мәдрәсәне, Арчаның «Казан арты» тарих-этнография музеен, Әтнә районы Түбән Бәрәскә авылы мәчетен, сәүдәгәр Гатаулла Даутов йортын, сәүдәгәр Бакиров утарын, Хәтнә авылындагы дворян Пётр Перцов белән бәйле урыннарны, Әүлия каберен, Изгеләр чишмәсен карадылар.

## «ӘДӘБИ ИШЕГАЛДЫ»

Казанда «Әдәби ишегалды» проекты гамәлгә ашырыла. Аның максаты – классик һәм заманча шигъриятне халыкка ирештерү, яшь буынны китап укырга күнектерү, Татарстан язучыларының яңа китаплары белән таныштыру, танылган шагыйрь, язучы, актёрлар белән очрашу мөмкинлеге тудыру.

## ЕВТУШЕНКОНЫҢ КАЗАНГА КИЛҮЕ

Казанга дөньякүләм танылган шагыйрь Евгений Евтушенко килде. Башта ул «Әдәби ишегалды» проекты кысаларында әдәбият сөючеләр белән Казан федераль университеты алды мәйданында очрашты.

Кичен бу олуг шәхес М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасында чыгыш ясады. Кичәне җырчы, режиссёр, Татарстанның халык артисты Эдуард Трескин алып барды. «Соңгы 60 елда Евгений Евтушенконың шигырьләре 97 илдә яңгырады, 72 телгә тәрҗемә ителде», – дип башлады ул сүзен. Кичәдә шагыйрь «Дора франко» поэмасын укыды, аның язылу тарихын сөйләде. Сәхнәдә яңгыраган шигъри әсәрләр арасында авторның «Казан университеты» поэмасыннан атаклы математик, ректор Николай Лабочевскийга багышланган бүлек тә бар иде.

## ДЕРЖАВИН ПРЕМИЯСЕНЕҢ ЯҢА ЛАУРЕАТЛАРЫ

Күренекле шагыйрь, дәүләт эшлеклесе, якташыбыз Гавриил Державинның тууына – 271 ел. Бу уңайдан аның Казандагы Лядов бакчасындагы һәйкәле янында шигырь бәйрәме үткәрелде. «Әдәби ишегалды» Державинга багышланды. Анда шагыйрьләр Лилия Газизова, Рөстәм Сабиров, Ольга Леваднвя, Николай Алешков, Михаил Тузов, Елена Бурундуковская, Алёна Каримова чыгыш ясады. Аннары Гавриил Державин һәйкәленә чәчәкләр салу булды. Тантанада Татарстан Республикасы мәдәният министрының беренче урынбасары Ирада Әюпова, ТР Дәүләт Советының Мәдәният, фән, мәгариф һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Разил Вәлиев катнашты.

Шагыйрьнең туган көненә багышланган бәйрәм чаралары Лаеш районында дәвам итте. Монда – аның туган ягында Бөтенроссия Державин премиясенең яңа лауреатлары игълан ителде. Алар – язучылар Майя Вәлиева һәм Лев Трутнев.

## БАЛАЛАР БАКЧАСЫ – МИЛЛИОНЕР

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы кече яшьтәге балаларга ике дәүләт телен (татар һәм рус) өйрәтә торган бакчаларның хезмәтен бөрәр миллион сум акча биреп бәяли. Узган ел 20 бакча бүләкләнгән булса, быел алар – 50.

Бәйгедә җиңеп алган акчаны бакча коллективы хуҗалык кирәк-ярагына түгел, ә белем һәм тәрбия бирүдә кирәкле уку әсбапларына, китапларга, уенчыкларга, тәрбиячеләрнең белемен күтәрүгә сарыф итәргә тиеш.

## ТЕАТРЛАР САБАН ТУЕ

Чаллыда VIII республика театрлар Сабан туе булды. Анда Казан, Чаллы, Түбән Кама, Әлмәт, Минзәлә, Әтнә һәм Буадан килгән 12 театр коллективы катнашты.

Сабан туен республика җитәкчелеге исеменнән котлау һәм сәламләү сүзләре белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин ачып җибәрде. Театр әһелләрен шулай ук Татарстан Республикасы мәдәният министры Айрат Сибагатуллин һәм Чаллы хакиме урынбасары Флёра Андреева котлады.

Артистлар капчык киеп йөгерү, чүлмәк вату, көянтә белән су ташу, капчык белән сугыш, катыктан акча эзләү кебек традицион ярышларда катнашты, келәмдә бил алышты.

Сәхнәдә татар эстрадасы йолдызлары һәм театр артистлары концерт куйды.

Сабантуйның баш батыры булып Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры артисты Алмаз Гәрәев калды. Ана Татарстан Республикасы Президенты исеменнән автомобиль һәм тәкә тапшырылды.

20 июльдә галим, язучы, публицист, тәрҗемәче, Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре **Әнвәр Хәйри** (Әнвәр Нәҗип улы Хәйруллин) 67 нче яшендә вафат булды.

## В ЭТОМ НОМЕРЕ:

Интервью И.ИБРАГИМОВА с заместителем Премьер-министра РТ, министром образования и науки РТ Э.ФАТТАХОВЫМ.
«Проза и поэзия»: А.МУТАЛЛАПОВ. Роман «Испытание»; З.ХУСНИЯР. Роман «Ураган» (окон.); стихи Р.ФАЙЗУЛЛИНА, М.ГАЛИЕВА.
«Из литературы родственных народов»: Т.АБДИКУЛИ. Повесть «Разума пылающая война»; стихи А.ЖУШКУНА, С.РУСТЕМХАНЛЫ, А.СОЗАЕВА, Т.ГАНИЕВОЙ, Д.ОСМАНОВА, Н.ОРОЗАЛИНА, Ж.САЕТНАЗАРОВА, Ш.АЛИШЕВОЙ, Т.КОЖОМБЕРДИЕВА, М.КАЛМЫКАЕВА; Дастаны. «Манас», «Нургун Батыр», «Урал Батыр» (с предисловием М.ВАЛИЕВА).
«Литературная критика»: М.ХАБУТДИНОВА. «Аяз Гилязов и Чингиз Айтматов».
«Искусство»: Г.САГИТОВА. «Жду тебя».
«Наши юбиляры»: статья Р.МУСАБЕКОВОЙ, посвящённая 125-летию со дня рождения С.Сунчелея; воспоминания М.ВАЛИЕВА, посвящённые 80-летию со дня рождения Ф.Миннуллина.
«История»: интервью Р.ЮНУСА с доктором исторических наук И.ГИЛЯЗОВЫМ.
Статья, посвящённая 25-летию журнала «Идель».
«Страницы юмора»: рубрику ведёт М.ГАЛИЕВ.
«Белый парус»: рассказ И.КАШАПОВОЙ.
Из фотоархива журнала.
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Барельеф, посвящённый джалиловцам, расположенный в г.Казани. Фото Л.Губайдуллина; Дом дружбы народов в г.Казани. Фото М.Второвой.

## IN THIS ISSUE:

Interview by I.IBRAGIMOV with Deputy Prime Minister of the Republic of Tatarstan, Minister of Education and Science of the Republic of Tatarstan E.FATTAHOV.
«Prose and Poetry»: A.MUTALLAPOV. Novel «Test»; Z.HUSNIYAR. Novel «Hurricane» (ending); poems by R.FAYZULLIN, M.GALIEV.
«From related nations literature: «T.ABDIKULI. Story «War of Flaming Mind»; poems by A.ZHUSHKUN, S.RUSTEMHANLY, A.SOZAEV, T.GANIEVA, D.OSMANOV, N.OROZALIN, ZH.SAETNAZAROV, SH.ALISHEVA, T.KOZHOMBERDIEV, M.KALMYKAEV; Dastans. «Manas», «Nurgun Batyr», «Ural Batyr» (with foreword by M.VALIEVA).
«Literary Criticism»: M.HABUTDINOVA. «Ayaz Gilyazov and Chingiz Aitmatov».
«Art»: G.SAGITOVA. «Waiting for you».
«Our jubilees»: article by R.MUSABEKOVA devoted to the 125th anniversary of S.Suncheley; memories by M.VALIEVA dedicated to the 80th anniversary of F.Minnullin.
«History»: interview by R.YUNUS with Dr. of historical sciences I.GILYAZOV.
Article dedicated to the 25th anniversary of the journal «Idel».
«Pages of humor»: M.GALIEV leads the section.
«White Sail»: story by I.KASHAPOVA.
From photographic archive of the magazine.
Diary of social-cultural life.
On our covers: Bas dedicated to Dzhalilovs located in Kazan. Photo by L.Gubaydullin; House of Peoples' Friendship in Kazan. Photo by M.Vtorova.


---

*Тышлыктагы сурәтләр*

*Тышлыкның беренче битендә:* Казан шәһәрендә җәлилчеләргә куелган барельеф. *Л.Гобәйдуллин фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* Казан шәһәрендә Халыклар дуслыгы йорты. *М.Второва фотосы.*

# Яңа китаплар




**HISAMOV N. KUL ALI VE TÜRKÇE YUSUFNÂME.**
*– Ankara: «Türk Dil Kurumu» нәшр., 2014. – 182 б.*
*Тиражы – 500 данә.*

Шушы көннәрдә Төркиядән татар әдәбияты һәм әдәбият фәне өчен сөенечле яңалык килеп ирешә. Нурмөхәммәт Хисамовның «Кол Гали һәм төрки «Йосыфнамә» дигән гыйльми хезмәте, төрекчә тәрҗемәдә дөньяга чыгып, Казанга килеп житте. Китапта XIII – XV йөз төрки шигърияттендә Йосыф-Зөләйха темасы яктыртылышы анализлана һәм болгар-татар шагыйре Кол Галинең тарихтагы фундаменталь роле ачыла.
Хезмәтне төрекчәгә Паша Явызарыслан һәм Бүләнт Байрам дигән төрек мөгаллимнәре тәрҗемә иткән. Китап булып Анкарада «Төрек дил курумы» (Төрек теле җәмгыяте) нәшриятында басылган.

---




**Эльс Гадел.**
**АПРЕЛЬ КҮПЕРЕ.**
*Шигырьләр.*
*– Казан: Татар.кит.нәшр., 2014. – 158 б.*
*Тиражы – 2000 данә.*

Бу китапка Эльс Гыйният улы Гаделевның (1936-2002) үзе исән чакта туплап куйган шигырьләре, сәнгать осталары турындагы күзәтүләре кертелгән. Заманында татарның атаклы радио дикторы, аннары журналист буларак ул һәрьяктан талантлы шәхесебез иде. Мирасын саклаган хатыны Фәүзия ханым әлеге җыентыкны дөньяга чыгаруда хәерхаһ булган шәхесләр – Разил Вәлиев, Дамир Шакиров һәм Марсель Галиевка рәхмәтен белдерә.

КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

2014
МӘДӘНИЯТ ЕЛЫ




Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)